# казан утлары

11
НОЯБРЬ-1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11

НОЯБРЬ
1971

*Бу санда:*

РОМАН. ХИКӘЯ. ШИГЫРЬЛӘР

Х. ТУФАН. Кармәт эскизлары. Шигырьләр . . . 3
Ф. ХӨСНИ. Ташландык. Хикәя. . . . . . . . 13
Р. ХАРИСОВ. Яралар. Шигырьләр . . . . . . 21
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. «Мин — Сонгми!» Шигырьләр 28
С. САБИРОВ. Фирдәвес. Хикәя . . . . . . . 31
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яхшылыкның, диләр, әҗере күп. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 57
Р. ВӘЛИЕВ. Авылда туй... Шигырьләр . . . . 65
Ә. БАЯНОВ. Ут һәм Су. Роман. . . . . . . 68
Д. СИРАЙ. Төндә. Шигырьләр. . . . . . . . 111
Ш. МАННАПОВ. Бер мәкаль бар. Шигырьләр . 113
Е. УТКИН. Ат сакларга чыга. Шигырьләр . . . . 115

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Азатлык җырлаучы поэзия. . . . . . . . . . 117
ТО ХЫУ. Яшел күлмәк. Вьетнам кызына. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 118
ТЕ ХАНЬ. Ленин һәм Аппассионата. Шигырь. . 119
ХОАНГ ТХИ МИНЬ КХАНЬ. Көчсезләнеп тала бара. Шигырь. . . . . . . . . . . . . 121
ФАМХО. Тәҗрибәсез бал корты. Шигырь. . . . 121
ВАН ДАЙ. Солдат курткасы. Шигырь. . . . . . 121

ОЧЕРКЛАР

Ә. РӘШИТОВ. Өченче очрашу. . . . . . . . 122
Ф. НАСЫЙРОВ. Профессор Гыйләҗетдинова. 127
М. НАСЫЙБУЛЛИН. Эзләр кая илтә! . . . . 130
С. ХӘКИМ. Күңелдән юылмаган эзләр. . . . . 136

СӘНГАТЬ

Г. ЗӘЙНАШЕВА. Бәхетле гомер. . . . . . . 152

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ

Р. ФӘТХУЛЛИНА. Уңай герой эзләү юлында. . 158

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Хезмәт кешесенең рухи дөньясы 163

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Кеше һәм табигать . . . . . 168
Г. АХУНҖАНОВ. Үз теле, үз өлкәсе. . . . . . 170

КЫЗЫКЛЫ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Т. ХАНГИЛДИН. Татар халкының исем-фамилияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

ХАЛЫК ИҖАТЫ

С. СҮНЧӘЛӘЙ. Уеннар. . . . . . . . . . . 180

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Д. ГЫЙМРАНОВА. Гөлсем Болгарская. . . . . 187
Ш. САРЫМСАКОВ. Театрга багышланган гомер. 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . 191

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова,** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 5/VIII-1971 ел. Басарга кул куелды 27/IX-1971 ел. ПФ 09085. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 79100 экз. Заказ И-551. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

## Хәсән Туфан

# КАРМӘТ ЭСКИЗЛАРЫ

## Зәңгәр чәчәк

Яшь гомерем зәңгәр чәчәк —
Узар димәгән идем...

Халык җыры.

Малай чагым!
Кайлардан ла тагын
Килеп чыгып Казан ягына,
Әйдәлисең мине яшьлегемә,
Озатып калган кырлар янына.

Син таныйсың мине?
Мин дә сине:
Син һаман шул — уйчан, әдәпле.
Өстеңдәге киндер күлмәген дә
Таныш миңа — зәңгәр сәдәпле.

Күксел томан күмгән ерак еллар
Ятсалар да ике арада,
Таныйм сине, таныйм:
Аягыңда
Гаҗәп пөхтә җиңел чабата.

Башкаеңда — җәйге йон эшләпә,
Ак эшләпә, кара тасмалы...
Җитмешемнән төшим шунда дисәм,
Юлны күмгән кыя ташлары...

*

Дәшсәләр дә сине
Серле юллар
Бик еракка, бәхет мул якка,
Аз гына да, туган җир генә дә
Җитә иде сиңа ул чакта.

Тик бер генә кочак бәхеткә дә
Риза чагым идең син минем.
Исеңдәме?
Исеңдәдер синең
Ул — бер кочак бәхет кем иде!..

— «Мәгълүм булсын әле дөньяга, дип,
Безнең дә бит «егет» икәнлек»,—
Уң кулыңның урта бармагына
Бакыр балдак кием җибәрдең...

Сүнде ләкин, шиңде синең бу дәрт:
Бакыр балдак
Тутыга икән,
Елтыр тешле
Якты елмаюның
Тапкыр теле тотлыга икән...

...Киндер күлмәк. Көяз, шәп чабата.
Ак эшләпә — кара тасмалы!
Иөгереп кенә кайтыр идем шунда,
Кичеп булса җитмеш басманы!

*

Игелегем тиде илемә, дип
Әйтмәсәң дә үзең әйтүең,
Тик иленә имгәк булып түгел,
Илдәш булып үтте яшь көнең.

Тәрәзләргә
Пыялалар куеп,
Еллар аша үтеп киттең син,
Азмы өйгә
Айның алтын нурын,
Таң алсуын бүләк иттең син.

Заманасы туктый күрмәсен, дип,
Туган якның, туган туфракның,
Сәгатьләрнең, суга торганнарның,—
Ватыкларын төзәтеп син, энем,
Вакытларны азмы уяттың...

Ул сәгатьләр
Синнән бәхилләрдер:
Һәрберсенең талган йөрәген,
Чөй кыстырып, майлап кына түгел,
Күз нурыңны ялгап төзәттең!

Язмышның да шулай
Саф булуын
Теләсәң дә, энем, теләвен,
Кабул булмый торган дога булган
Бу теләгең синең, мөгаен.

Көн битенә
Тәрәзәләр куеп
Үтеп киттең авыллар аша.
Түрләремә якты кертте ул, дип
Кемдер бәлки сагынып лабаса.

Юктыр ла, юк,
Сагынмыймдыр сезне,
Яшьлегемнең зәңгәр еллары!
Болай гына бугай, болай гына

Искә алам сезне
Мин бары...

## Аппагым

Әссәлам, аппагым, әссәлам!
Әле дә исән-сау икәнсең.
Гел шунда — бер төштә торсаң да,
Ничәсен дәвернен кичкәнсең.

Бу якка нинди кыш килмәгән,
Бу якта кайсы җил исмәгән...
Өендә гөлләре туңса да,
Ил сине утынга кисмәгән.

Һай, син дә гамьнәрне, каенкай,
Кичергән, кичергән, кичергән,
Синең дә бәйрәмсез көннәрдә
Сәйләнең җилләрдә сибелгән...

Әле дә каравыл икәнсең,
Авылның тышында, урендә.
Сорама, аппагым, сорама,
Нәкъ шул ук миссиям минем дә.

Төн әле угрылы, бүреле.
Илдә бит
Сарык та, каз да бар,
Мәгънәви малыбыз салынган,
Дарыбыз салынган баз да бар.

Юлларда бүреләр иснәнә! —
Казлар бит
Урамда, аппагым.
Казны да, дарыбыз базын да
Саклау бит — безнең эш, сафташым!

Иң мөһим, иң җитди хезмәт ул,
Иң авыр гамәл ул — каравыл.
Маякта, фонарьда, шәмдәлдә
Йөрәккәй майларын яга ул,
Йөрәккәй майларын...

Бу якка кайсы кыш килмәгән,
Бу якка кайсы җил исмәгән.
Өендә гөлләре туңса да,
Ил сине утынга кисмәгән,
Кисмәгән, аппагым.

## Мирас

Барыйм да
Сәламнәр бирим, дип
Бабайлар ягына юнәлдем.
Кояшлар, йолдызлар төслесен
Китергән идем дә гөлләрнең...

Миндәге җан өчен, кан өчен
Рәхмәт китергән чагымда
Чардуган кайда соң, дәү әти,
Син кайсы кузгалак астында?

Яфраклар ничә кат әйткәндер:
— Киләчәк оныгың, киләчәк!..
Син кайсы канәфер төбендә,
И газиз әбкәем Гөлчәчәк?..

...Сөялдем уйлана-уйлана,
Зиратны коршаган киртәгә:
Иртәдер... иртәдер бит әле
Мең яшьлек гадәттән китәргә?..

Кемнәрдер
Кычкыра шикелле
Еракта, ир-атсыз кырлардан.
Сабанны тартырга сыерлар
Һәм кызлар җигелгән чорлардан:

— «Җуймадык! —
Яңарттык без бары
Гомерле, мәңгелек гадәтне,
Илбасар башына юнәлтеп
Бездәге күкрәүле нәфрәтне!

Әйтерсең әбиләр — мәрхүмнәр —
Әйттеләр кызларга тын гына:
Чулпымны, хәстәмне[1] бирегез
Дошманны җимерү фондына!

Бабайлар киттеләр сугышка
Нәселдә яшәгән гайрәттә,
Мең яшьлек фидаи әхлакка,
Мираска әверелгән Гадәттә!»

Кычкыра шикелле
Шулай ук
Имәннәр, каеннар, чаганнар
Еракта —
Халыкның эстетик гадәте
Ярала башлаган заманнан.

...Авылның түрендә обелиск...
Күтәргән
Ничә йөз исемне,
Халыкның тарихын раслаган
Мәңгелек таш дәлил шикелле!

## Романтиклар кайтканнар

Кайдан бу,
Әйтерсең бакырдан,
Алтыннан яралган наратлар?
Каеннар ватаны иде бит
Минем бу — легендар тарафлар...

[1] Хәстә — хәситә.

Кайтканнар «романтик» шахтерлар.
Төшкәннәр ләхетләр түренә,
Өметкә манылган кафенгә,
Ак бүзгә төренә-төренә;

Кайтканнар геркулес кебекләр,
Ахырда төп йортка кайтканнар.
«Кыямәт көнгәчә...» дип кенә
Зиратта йокларга ятканнар.

Гүрләре өстендә — наратлар...
Кем монда китергән боларны?
Әйтерсең наратка әверелгән
Ленада, Уралда бакырга,
Алтынга чыныккан рухлары...

## Кагылмагыз, карлар, истәлеккә

...Да, все это было давно
И кажется совсем недавно.

Әминә Җәлил.
25.X.70.

Истәлекләр яши әле бездә,
Исән алар, исән әлегә.
Сагынасыңдыр син дә
Аны дисең.
Сагынмаган кайда, Әминә!..

Бик еракта... Әйе, бик ерак та,
Бик якын да кебек ул мәлләр,
Шигырь генә яши ала торган
Гадидән дә гади бүлмәләр;

Мәскәүдәге Столешниковлар,
Казандагы Иске Тыкрыклар...
Ул кыйблалар ахыргача, ахры,
Һаман шулай истә торырлар.

...Карлар ява...
Карлар ера-ера
Күптәнгегә йөрәк юл сала:
Кайгылардан кая качар идек
Хәтерләрдә дотлар булмаса.

Карлар ява. Буран эчләреннән
Таныш өннәр килә колакка.
Безне эзләп, безгә дәшеп алар [1]
Аваз сала кебек бу якка...

...Хәтерләрдә — язлар, җәйләр генә,
Күзләренең дә
Алтын гынасы.
Карлар ява... ләкин шау чәчәктә
Күптәнгенең алсу кынасы.

[1] Алар — Муса һәм Луиза.

Еллар, еллар! —
Нигә болар шулай
Сагына икән һаман димәгез,
Кагылмагыз, карлар, истәлеккә,
Тимәгез сез ана, тимәгез!

Хәтер генә бераз аралый бит
Сагышлардан безне әлегә.
Сагынасындыр син дә Луны дисең,
Сагынмаган кайда, Әминә...

## Таллар әйтер

Синме бу?
Ә бу — мин, мин, канәт!
Килче, кил,
Ят кеше түгел мин.
Әбиләр, бабайлар ягыннан
Миңа бит әле дә сеңел син!

Илле биш ел гына үтсә дә,
Мин моннан киткәнгә нибары,
Уяна, терелә хәтердә
Яшьлекнең мәңгелек еллары.

Синең дә
Толымнар агарган.
Дәверләр сиңа да тигәннәр.
Сугышлар, сагышлар, матәмнәр
Сиңа да барын да биргәннәр...

Әйдәме, керикме бакчага,
Бер йөреп, әйләнеп чыгарбыз:
Сабый чак эзләрен тапмасак,
Таллардан, зиректән сорарбыз.

Жилләргә, бу якты айларга
Бернинди үзгәреш кермәгән,
Без күргән дәверләр әйтерсең
Аларны бөтенләй күрмәгән.

Шулай да
Барыбер туган жир
Күнелле, сөйкемле, сөекле!..
— Кал шунда мәңгегә, дисең син,
Инде бит, син абый, ирекле.

Ирекле булсам ла, туганым,
Илемә бирелгән ирек ул:
Әдипләр, шагыйрьләр гомере
Илдәге гомуми милек ул.

Кайдадыр,
Өермә астында
Көтәдер мине жир, гүзәлем:
Авыллар тудырган милекне
Давыллар билидер, күрәсең.

## Йолдызлар

Әнкәем хисләре шикелле
Тылсымлы, шигырьле аяз төн...
Мин шушы йолдызлар илендә
Биш яшьтә чакта ук адаштым.

Яңадан шунда мин — Карматтә.
Галәмне күзәтәм болдырда.
Алтмыш биш елдан соң эндәшәм
Җидегәнгә,
Көянтә йолдызга:

Адәм дә матдә бит, Туганнар...
Ләкин без — максатлы адәмнәр.
Ә сезнең
Төп максат нидә соң,
Әүвәлсез-ахырсыз Галәмнәр!?

Сездәге мәңгелек яшәүнең
Мәгънәсе, нияте нәрсәдә?
Дәшмиләр... Шулай да дәрт бирә,
Ямь бирә, гамь бирә фәлсәфә...

Әнә бит ымлаша төньяктан.
Төшенмиммени соң мин аны:
«Офыклар буталып бетсә дә,
Кыйбланы бутама, кыйбланы!»

Мин синең йолдызлар илендә
Бик теләп, бик рәхәт «адаштым»,
Әнкәем хисләре шикелле
Шигырьле, тылсымлы аяз төн.

## Туйралар көрсенә

Усаклар, кәкүкләр моңсуы
Әле дә хәтердә, хәтердә...
Өч-дүрт йөз яшьтәге, өлкәнем,
Син әле
Шундамы хәзер дә?

Көткәнсең, бик озак көткәнсең,
Кайтырмы, кил.ерме бәбкәм дип,
Еракта, урманда торсаң да,
Мин синең адресны беләм бит!

Исемдә:
Уралга киткәндә
— «Хәерле юга бир...» дигәнем.
Кем белгән
«Изге юл!» теләвең
«Бәхил бул...» дию дә икәнен...

Туйралар — синең яль токымнар,—
Ятимнәр шикелле
Көрсенә.
Син гөрләп яшәгән урында
Ашъяулык җәерлек төп кенә...

Уйлана, моңлана, сыкрана
Хәленне белергә килгәннәр:
Кайда сез
Баобаб [1] кебекләр,
Өчәр йөз яшьтәге имәннәр!?

## Әле дә

Әллүле, бәллүле талларым! —
Тиккә дә тибрәнгән тирәгем! —
Нәкъ сезнең шикелле әле дә,
Җилсез дә тибрәнә йөрәгем.

Атылган уклар да тишмәде,
Чабылган балта да кисмәде
Сез сыйпап, сихерләп үстергән
Чәчкәле, шигырьле хисләрне.

Йомасы идем мин, якташлар,
Күзләрне мәңгегә йомасы...
Коткарды илемнең, җиремнең,
Тирәкнең, талымның догасы.

Нигә сез әле дә төннәрдә
Сискәнеп куясыз, каеннар? —
Өйдә бит, илдә бит йөрәгем,
Кайтмаслар бугай бит кайгылар...

## Бичара

Тимерле, чуенлы табаннар
Урамның чыраен бозганнар,
Без үткән чирәмле юллардан
Әйтерсең Алыплар узганнар...

Ярсына реалист машина,
Планын үтәргә ашыга:
Туктап та тормыйча мазутын
Чәчәкләр таҗына агыза.

Сөйләнә бичара Табигать
Эстетик этика хакында...
Техника изә дә
Юнәлә
Килермен әле дип, тагын да!..

Ярсытма, янәсе, мине син,
Югыйсә,
У-у килеп, ду-у килеп,
Урманлы офыгың үрен дә
Сукалап ташлармын! — ди кебек.

Булашма, гуманист Табигать,
Ул синнән көчлерәк ләбаса:

---

[1] Африкадагы иң юан агач.

Анын бит
Бензинлы бәгырендә
Бер өер, бер көтү алаша!

Нечкәрер әле бер
Хисләрен!
Сина да ан керер, техника:
Синен дә бәгырен-йөрәген
Әверелер әле бер
Лирикка!

## Офыклар уртасында

Җидесе дә — житез, сабыр,
Җитди, тапкыр егетләр,—
Алгы хәрби сызыктагы
Лейтенантлар кебекләр.

Кояш баегач,
Кызу көрәш
Бераз тынган арада
Минем янга килде болар
Шигырь тынлап карарга...

— Күзәт әле жирне дә,— дип,—
Ял итә-итә генә! —
Алып китте мине болар
Табигать итәгенә.

*

...Ак каеннар яулап алган
Сине, ак таш аланы! —
Элгәрегә, ярлы гына,
Ташлы гына даланы.

Кармәттән дә
Куптән инде
Киткәндер дә шүрәле,
Урманымда, уйчанымда
Романтика күп әле!

Тапкыр телле жор табында
Түр башында утырам,—
Бусы инде —
Техникадан
Лирикага ихтирам.

Кармәтемнен элитасы
Ут янында ял итә...
Дәстәрханны ябыртуны
Учагыбыз хәл итә.

*

Табын тар да,
Ләкин шунда
Гәпләшкәндә узара,
Бөтен дөнья жирлегендә,
Кин куләмдә сүз бара.

Мәсьәләне киңрәк итеп,
Үзенчәрәк чишкән күк,
Халыктагы лирик җырлар
Бәреп чыга чишмә күк!

Җитди бәхәс барганда да
Челтерәп килеп чыга:
— «Моңлы кошлар булдым инде,
Сайрамыйм чыгып кына...»
Дип кинәт сузып куя.

*

Без үзебез җирдә дә бит,
Ә күңелләр — һавада.
Атмосфера мәсьәләсе
Килеп керә арага.

Күкләргә ук менеп төшә
Канатлы җырларыбыз:
— «Кайсы йолдыз астында,— дип,—
Үтәсе юлларыбыз...»

Йолдызлар да һаман шул да
Һәм шул ук та
Офыклар,
О, никадәр буйга үскән
Халыктагы колыклар!

*

Туган җирем элитасы
Уйчан гына ял итә...
Киңәшүне кыскартуны
Сандугачлар хәл итә.

Тәкъдим итә бер сандугач
Төн уртасы җитәрәк:
— Учакларны сүндерергә
Иртәрәген иртәрәк,

Ә шулай да, егетләр, ди,
Чамалагыз үзегез.
Киләчәккә күчерелсен
Киеренкерәк сүзегез;

Кайтуынча идарәгә
Керә китәсездер бит,
Таңга кадәр берәр сәгать
Черем итәсездер бит...

Көнге эшкә җыеналар
Җитез, зирәк егетләр,
Колхоз кыры штабының
Майорлары кебекләр!..

Дөнья хәле шулай инде,
Бер китә бит килгәннәр...
Сау булыгыз, каеннарым,
Сау булыгыз, имәннәр!

Иске Кармәт. 1970

**Фатих Хөсни**

# ТАШЛАНДЫК

хикәя

## I

Паровоз гудоклары, вагоннарның бер-берсенә чыркылдашып ялганулары, деподагы чүкеч, зыңгылдап төшкән рельс авазлары һәм, гомумән, тормыш ыгы-зыгысы һәр даим — көн вә төн — гөжләп торган, төп халкы инде бу тонык гөрелтегә, әчкелтем күмер исенә иялəшеп беткән тимер юл поселогында ул көннәрдә, башка көннәргә караганда, артык та, ким дә бер вакыйга да булмады... дисәк, бераз ашыкканрак яки әйтеп житкермәгән буласыбыз икән. Хәер, бер караш ташлау белән генә бу зур, инде шәһәргә әйләнә язган поселоктагы хәл-әхвәлләрне ничек белеп бетермәк кирәк. Хәлбуки, Тихая атлы арткы урамнарның берсендә, күбесе үз йортлары, үз бакчалары белән һәм берсе икенчесеннән хәбәр алышып, исәнлек-саулык сорашып, кирәк нәрсәләренә әҗәткә керешеп, кыскасы, үзара бик тә тату яшәүче гаиләләрнең берсендә ул көннәрдә көтелмәгәнрәк хәлләр килеп туды. Капка баганасына «Кадерметевлар» дигән табличка, кече капкада, гәрчә ишек алдында инде күптән эт-мазар булмаса да, «Сак бул! Ишек алдында усал эт бар» дигән калай кадаклаган бер катлы бу йортта ике генә кеше — егерме биш яшьлек токарь Кадерметев һәм аның анасы Йөзлебикә абыстай яши. «Көтелмәгән хәл» дигәнебез дә бу ике бертек кеше өчен алай көтелмәгән хәл түгел, әнисе Йөзлебикә быел май азагында улы Марсельгә егерме биш яшь тулыр алдыннан, әгәр егет туган көнен иптәшләре белән билгеләп үтәргә теләсә, үзенең каршы түгеллеген, хәзинәдә бары белән табын әзерләп бирергә авырыксынмаячагын алдан ук әйткәли йөргән иде. Эш белән мавыккан һәм карчык әнисенә андый мәшәкатьләр йөкләүне артык борчу дип тапкан тыйнак егет моңа хәтле бу сүзне колак яныннан уздыра килде. «Егерме биш яшькә тикле терәлмәгәнне егерме биштә генә терәлмәс, кеше кесәсеннән ирен чылатырга исәпләүче кешеләр икенче урамнарданрак йөри торсыннар!» белән уздырды. Кәефе күтәренке чак туры килсә, сүзне уен-көлкегә борып, шул уңайдан әнисе карчыкның бакчасына жиңел генә таш атудан да тартынып тормыйча, капкага кадакланган эт башлы калайга ишарә ясап, «Кем килсен безгә. Безнең ишек алдында усал эт бар ич» дип тә ычкындыргалый һәм андый чакларда Йөзлебикә түти, бераз күңеле кырылып:

— Каныктың шул калайга. Атаң мәрхүм кулы белән кадакланган истәлек ич ул, кемгә дә тими, тора бирсен торган жирендә,— дип авыз

эченнән сукранып та куйгалый иде. Шулай итеп, егерме биш яшь тулуны билгеләп үтү мәсьәләсе дә, капкага кадакланган «Сак бул! Ишек алдында усал эт бар!» да үз урыннарында кала бирә иде. Тик кичә кич белән, Йөзлебикә түти малаена егерме биш тулуны ничектер исеннән чыгарган бервакытта, болай искәрмәстән генә сүз кузгатуы өчен әнисеннән чак-чак кына уңайсызланган да кебек, кинәт әйтеп куйды егет:

— Әгәр син каршы килмәсәң, әни,— диде тора торгач,— иртәгә кичкә, үзем белән бергә эшләүче берничә иптәшне, аннары теге минем белән профтехшкола бетергән Володяны чакырып, егерме биш яшьне пичәтләп куярга не исәп. Табын кебек нәрсә әзерләп бирә алырсың бит? — Әллә әнисен тагын да эретә гөшү нияте белән, әллә бергә уйнап үскән Володясы өчен куанычын эчендә яшереп калдыра алмаганнан, аннары, тавышын күтәрә төшеп, өстәп тә куйды,— Володя кичә диплом яклаган, шул бер уңайдан аның дипломын юу да булыр.

— Әйттең сүз, нишләп каршы килим, ди. Үзең эшләп тапкан хәләл акча. Кибеттә алыр әйбере булмаса икән...

Шушы булды бөтен сөйләшүләре. Һәм икенче көнне Марсель эшеннән төш авышу белән үк кайтып житте.

## II

Төш авышу белән үк кайтып житте һәм кайтышлый үзенә кирәк булачак нәрсәләрнең кайберләрен ала да кайтты. Күрәсез, хәзергә, ягъни көннең бу беренче яртысында барысы да ул планлаштырганча бара, егетне иң куандырганы: шау-шусыз бара. Шундый-шундый шөгыль бар иде, дип алданрак жибәрүләрен сорады, бер сүзсез жибәрделәр, гадәттәгечә, иреннәрен ялмаштырып:

— Безне чакырмыйсыңмыни? Ничек булыр икән соң без булмагач? Кабул итәр микән ходай дигәннәре? — дип теленә салынучы булмады. Сый-хөрмәт жәлләүдән түгел, тәкәллеф һәм шау-шу яратмаганлыктан, аннан да бигрәк, карчык әнисенә күп мәшәкать йөкләүдән куркып, Марсель бу мәжлесне мөмкин хәтле ансат һәм гаеп-кыек белмәс бүлдак иптәшләре белән генә уздырып жибәрергә булган иде. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, көннең икенче яртысы ул көтмәгәнчәрәк килеп чыкты.

Иң элек, кайтып өстен алыштырырга да өлгермәде, ишекне зур ачып, местком председателе Афанасьев белән карт токарь, дөресен әйткәндә, Марсельне токарьлык һөнәренә өйрәткән кеше дядя Саша килеп керде. Ишекне болай зур ачулары да тиккә генә булмаган икән: бүләккә цех коллективы исеменнән транзистор китерә килгәннәр. Ике нәрсәдән бик тә уңайсызланып калды Марсель. Беренчедән, дядя Сашага ул бу турыда бер нәрсә дә әйтмәгән иде — карасана, түрдә утырырлык кеше онытылып калган бит, имештер, шау-шусыз узсыра. Янә килеп, ишләре белән генә утырасы — эгоист түгел диген яшьлекне! Икенчедән, кайдан уйлап тапканнар бу транзисторны? Кем көткән алардан бүләк?

Хәер, аптыратып калдырырлык өченче сәбәп тә юк түгел: бүләк китерүчеләрне шәп кенә сыйлап жибәрергә кирәк иде, ә аларның табыны да әзер түгел. Әни карчык — бу тамашадан шулай ук аптырап-таркалып калган әни карчык — куллары камырга буялган килеш, кече якта ни кыларга белмичә, бер үк вакытта бу өлкән кешеләрнең күзләренә күренергә дә кыймыйча, оядагы каз кебек таптанудан һәм тавышсызтынсыз гына малаена пышылдаудан уза алмады. Хәер, бу кыен хәлдән аларны килгән кунаклар үзләре коткарды.

— Алыш-бирешне кул куйдырып эшләүдән дә ансаты юк икән,— дигән булды местком Афанасьев, өйдәгеләрнең каушап-аптырап калуларын ачыктан-ачык сизеп. Шуңарга да карамастан, Марсельнең алар-

ны өстәлгә — әзерләнмәгән табын янына кыстап азапланунн күреп, ниһаять, тел яшермичә генә әйтеп салды:

— Нәрсә син рабочий класска килешмәгән эшне эшләп, бер дә юктан калтырап калдың, егет? Коры өйдән буш китмәсеннәр дисең икән, мондый көнне өең бөтенләй үк коры булмаска тиеш: бугазның тузанын юып төшерерлек кенә салып бир дә, безне анда машина көтә, озын-озак торырдай вакытыбыз юк.

Кыскасы, көннең бу икенче яртысындагы аптыраткыч хәлләрнең беренчесе менә шул булды: яшьләр җыям дип ниятләп торганда, Марсельнең әтисе булырга яраклы ике өлкән агай, көтелмәгән бүләк китереп, аяк өсли генә капкалау белән китеп бардылар.

Инде боларының күләгәсе күмелгәндер дип кенә торганда — яшьләрең тагын да көтебрәк торсын,— түгәрәк ак сакаллы, нечкә генә итеп кыркылган пөхтә мыеклы, олы яшьләрдә булуына карамастан, шома кызыл чырайлы, һәрхәлдә, бер дә бирешмәгән бер карт килеп керде. Бусы — бер кочак сирень чәчәкләре күтәргән һәм керә-керешкә өй эчен яңгыратып татарчалап сәлам бирде. Һәм шундук, аптырап торырга урын калдырмыйча, герләргә үк тотынды:

— Бу сиңа, Марсель энекәш. Теләсәң, түреңә утыртып куй, теләсәң, мин китүгә чүплек башына чыгарып ат, илла Фәттахи абзаңның бүләге шушы,— дип башлады ул, өй хуҗаларына авыз ачарга да бирмичә,— җәл, җиләк-җимеш өлгергән чак түгел, мин синең өстәлеңне кызарып пешкән крошавкалар белән күмеп ташлаган булыр идем.

Аннары сирень чәчәкләрен кочаклаган килеш ишләргә, нәрсә әйтергә белмичә аптырабрак калган Марсель-юбилярны бөтенләй бер читтә онытып калдырып, Иөзлебикә карчыкка борылды:

— Бу карт ычкына башлаган мәллә, дип шаккатма, Иөзлебикә килен. Ишетеп килдем, соңгарак калып булса да егетне юарга уйлагансыз икән бүген. Ә минем ул Марсель егет белән үз исәп-хисабым бар — картның болай да җәенке көләч йөзенә хәйләкәр-мут балку бәреп чыкты,— шулай бер чакны, мин әле ул чагында стрелочник булып эшли идем, сезнең шул Марсель пацан минем бакчага алма чәлдерергә кергән. И җыйган бер кепка пешәр-пешмәс алма. Коймаңы яңа гына койдырган чак, койма өстендә чәнечкеле тимер чыбык. Бот буе малай, ничек кергән диген разбойникны. Тотып алып, кай җирең кычыта, бик нык пешердем үзен. Аңыкы авырткандыр да авырткандыр, соңыннан үз кулым авыртып җәдәтте. Бер каның кыздырсаң, алны-артны уйлап тормый ул стрелочник Фәттахи. И соңыннан үземне үзем тиргәп җәдәттем: ишләп син кулыңа ирек бирдең, собачий хвост, мәйтәм. Малайның кинди малай булуы, күз алдыбыздан узган тарихы соңыннан иска төште.

Бу минутта ул чынлап та нәрсәнедер исенә төшерде булса кирәк, кинәт бүленеп, ык-мык итеп калды һәм, сүзенең җеп очын ничек тә тоттырмаска тырышып, инде янадан Марсельгә борылды:

— Әйтсәм әйтим, кем, Марсель туган, кул селтәгән чакларым булды синнән. Илла да мәгәр мин карт дуракның юраганы юш килмәде, яхшы егет булып чыктың син. Эшең-гамәлең турында гел сораша йөрим. Шулай ул безнең рабочий класс, формага үзе коя ул кешене.

Аннары анасына, малаена — икесенә берьюлы, кергәндәге кебек кычкырып, гөрләп:

— И шулай алга таба да икмәкле-тозлы, илгә-халыкка игелекле булып яшәргә язсын,— дип соңгы фатихасын әйтте дә, боларның ул фатиханы ничек кабул итүләрен тыңлап та тормастан, яшьләрчә җәһәт атлап чыгып та китте.

Карт чыгып киткәннән соң малай анисенә, анисе малаена карашып, беравык тын тордылар.

— Кайдан ишеткән бу Фәттәхи картка хәтле? Син соң бөтен поселокка сөйләп йөрмәгәнсеңдер ич? — дип, ниһаять, әнисеннән коры гына сорап куйды Марсель. Ләкин рәтле-башлы җавап ала алмады, чөнки Йөзлебикә карчыкның бу урында тамчы да гаебе юк, киресенчә, ул бу эшнең үзе уйлаганнан зуррак булып чыгарга торуын күреп, беркадәр каушабрак та калган иде. Шул ук вакытта озак аптырап торып ара да юк, кич якынлашып килә, чакырылган кунакларның озакламый килә башлау куркынычы бар, карчыкны әлегә мичкә дә кермәгән камыр ашлары арттан куа иде.

Шулай баш әйләнгән бер вакытта — бу юлы да яшьләрең бер читтәрәк торсыннар — ашъяулыкка төрелгән күчтәнәч ризыклар күтәреп бер карчык килеп керде.

— И шушы тавыгыздан күтәрелүләре,— дип башлады карчык, кулындагы төргәкләрнең әле берсен, аннары икенчесен җайлап кына өстәлгә куеп. Бер мәл сулышын ала алмыйча сүзсез утырды. Күренеп тора, бер башланып китсә аның сүзләре, әлбәттә, табылачак һәм ул озаклап чәй эчмичә мотлакан китмәячәк. Марсель моны яхшы белеп тора: беренчедән, бу ике карчык ахирәт дуслар, икенчедән, Марсель-ташбаш моннан ун-унбер ел элек Иделдә су кергәндә, артын-алдын уйлап тормастан, бу «ахирәт»нең бата башлаган оныгын коткарган булган. Бу кадерле онык инде үсеп буй җиткән, йөзәргә өйрәнгән, Марсель эшли торган цехта ук эшли, башкалар үти торган планны ук үти, башкалар эшли торган ук этлекләрне дә эшли, үзен Марсель абыйсы коткарганны инде әллә кайчан оныткан, ә менә олылары Марсельнең шул изгелеген һич оныта алмыйлар. Алай гынамы соң, картая-картая бигрәк тә ыштан тотә алмас кешегә әверелеп баралар. Марсель кайда гына очрамасын — урамдамы, кеше арасындамы — Мәхмүзә карчык аны шунда тотып алып, сырпаланырга, хәер-дога укырга, сорашырга, изге теләкләр коярга тотына иде. Тавыш-тынсыз гына уздырырга дип керешелгән туган көн уздыру вакыйгасы да — йа, хода! Бетте баш — ул күп сүзле карчыкның колагына барып кергән икән. Кыскасы, карчыкның йомшак ягын белгән Марсель өчен иң яхшысы моннан ничек тә тизрәк ычкыну ягын карау иде.

— Әни, минем барып кайтасы җирем бар икән,— дигән булды ул, тиз генә ишек ягын каерып. Ләкин эче хәер-дога белән тулган һәм, егетнең туган көнен ишетеп, махсус пешеренеп килгән Мәхмүзә карчыктан алай ансат кына котылырсың, бар.

— Тукта әле, кабаланмый тор, үскәнем,— дип, тәмле телләнеп, егетнең чыгар юлына аркылы төште Мәхмүзә карчык. Һәм һәрвакыт, һәр очраганда шулай булганы кебек, бу юлы бәйрәм унаеннан хәтта арттыра да төшеп, бала иркәләгәндәй, аның аркасыннан сыпыра-чәбәкли, егетне кире өстәл кырына алып килде.

— Бездән инде, карт кешеләрдән, әллә ни көтмәссең,— дип башлады ул башлаганда. Ләкин аның бу тыйнаклыгы ярты секундка да җитмәде һәм аннары китте тугарылып, китте тезеп: гөбәдия камырына ничә күкәй сытканын, нинди майда йөздергәнен, дөгесе берәмтекләп кул белән сайлаган саф-чиста дөге булганлыгын, бәлешнең итен «үз мөселманыбыздан» биш бәясенә сатып алганлыгын, өйдәгеләргә тагын шундый ике бәлеш пешереп калдырганын, аннары юбиляр Марсельнең фәлән төрле, тәгән төрле күркәм сыйфатларын китте тезеп, китте тезеп, бичара юбиляр бу күп сүзле карчык янында тәмам телдән язды. Кичкә җыелачак яшьләр мәҗлесе дигәннең нәкъ шулай — үзе уйлаганча барып чыгачагына өмете бөтенләй диярлек суынып барганда — рәхмәт төшкере — әнисе җолып алды үзен. Йөзлебикә карчык, нәрсәнедер җитешеп бетмәгән атлы күрсәтеп, Марсельне тиз генә кибеткә йөгертте.

Махмүзә карчык озаклап чәй эчмичә, әлбәттә, китмәде. Шулхәтле зурлап, ризыклар күтәреп килеп, бер самовар чәй дә эчмәгәч, ул ниткән татар карчыгы булсын, ди. Ниһаять, аны озатып, Марсельнең кунаклары өчен өстәл әзерләргә дип кенә торганда — поселокта күрше-тирә хәлләрен ишетеп торучы карт-коры бетәсе түгел икән — күрмәгән-белмәгән, исеме-жисеме хәтта Йөзлебикәгә дә мәгълүм булмаган янә бер түгәрәк сакал пәйда булды.

— Мине белмисез булыр, исемем мангаема язылмаган,— дип башлады бусы, ишектән керә-керешкә үк,— түлке ни... Сезнең ул Марсель улыгызның сөт әтисе кем? дип сорасагыз, ул мин булырмын. Рас шулай икән, егетне туган көне белән котламыйча калуны күңелем килештермәде. Кайда соң әле егет үзе?

Котлыйсы кешесе өйдә күренмәгәч, карт хәтта бераз иркенәя дә төшкән кебек сүзен дәвам итте:

— Әйтсәм әйтим инде алайса, кортка, мин белгәнне син дә белеп тор: ул чибәр егетне беренче булып дөнья ризыгы белән авызландыручы кеше — ул мин булырмын. Бүгенгедәй хәтеремдә, бер әкәмәт куркан ие ул чагында. Шушындый җылы җәй башында, бер кат одеял белән генә төреп, гараж чатындагы будка артына ташланган ул гөнаһсыз сабыйны табып алгач, һич онытасым юк, сезнең картыгыз, минем Әхнәф ашнә, бер мәл таркалып калды. Таркалырсың, адаштырган мәче баласы очратсаң да йөрәк сыкрый, ә бу бит мәче баласы түгел, адәм баласы. Кыймылдый, тавыш бирә, ә күзләре, мин сиңайтим, елкылдап тора: «Ник тудым?» түгел, «Яшәргә тудым!». Җылар исәбе һич кенә дә юк. Ул да булмады, Әхнәф кордашның беләгенә чылатып җибәрде. Мәйханә, бер сүз белән әйткәндә. Конечно, шундук зәңгәр фуражка — милиция килеп җитте. Китте сораштыру, протокол язу, каядыр алып китмәкчеләр сабыйны. Янәсе, закон бугазы аркылы үткәрәселәр. Ә Әхнәф кордашның бушлай кергән бу геройны кулдан ычкындырасы килми, үз малае фронтта үлеп калган чак, малай урынына малай, чат ябышкан. Законы үзе белән картның. Китте тарткалашу. Сабый шунда, барыбызга берьюлы отпор биреп, яхшы ук әче тавыш белән жылап җибәрде. Башка акыл төште шул мәл: «Тукта, мәйтәм, әвен сугып кайтмаган-кайтуын да, шулай да ашарга кирәктер моңа», дим. Безнең әлекке өй шунда, гараж буенда гына ие. Йөгердем өйгә. Киленнең шешәле сөт белән бала туйдырып торган чагы ие. «Синең сөт чишмәләрең үзең белән, үзеңнекен үзең шәт туйдырырсың, мәйтәм, анда әнә сөткә ялманып торучы яңа туган гражданин бар». Шулай дидем дә тартып алдым шешәле сөтне. И китереп каптырдым әлеге шул күзен генә ачкан адәм баласына...

Инде үзең уйлап кара, кортка: мин кеме булам ул чибәр егетнең? Котларга хакым бармы минем, юкмы?

Карт беравык тынып торды, ишеккә борылгандай итте һәм, ишеккә житкәч, янә әйләнеп килеп, бу юлы инде үтә житди рәвештә өстәп куйды:

— Үзенең өйдә туры килмәве, бәлки, хәерлерәктер дә. Өйдә туры килсә, белмәссең, сүз тота алмый торган тешсез авыздан кирәклесе-кирәксезе ычкынган булыр ие. Ә ул ташландык икәнен белмәгән килеш үсә бирсен. Бөтен поселок саклый бу серне. И шулай сакланырга тиеш тә ул.

Карт, «Мин белгәне шушы, сезнең минем турыда ничек уйлавыгыз миңа кагылмый!» дигәндәй, ничек кинәт килеп кергән булса, шундый ук кинәтлек белән чыгып та китте. Йөзлебикә карчык, ни әйтергә дә белмичә, аптырап калды. Аның колагында: «Бөтен поселок саклый бу серне. И шулай сакланырга тиеш тә!» дигән сүзләр генә байтакка хәтле әйләнеп торды.

## IV

Бөтен поселок саклаган, әле дә булса саклый, ә менә авызына теле сыймаган бер исерек баш — егетнең нәкъ шул шатлыклы көнендә — серне чишә язды. Дөрес, Марсель алай тиз ышанучылардан түгел, чынга алмады, нәрсә лыгырдамас кибет алдында «яңадан өстәргә» ялманып торучы сантый.

Ә сүз менә болай булды:

— Әй, кая чабасың, ударник? — дип, кибеттән күтәренеп чыгып килүче Марсельнең юлына аркылы төште теге. Марсель кулындагы шешәләрне күреп, кинәт йомшара калды,— ба... галстук бәйләп җибәргән кеше. Әллә кәләш куенына кабаланасыңмы, туй итмичә генә?

Марсельнең бер дә тоткарланасы килми иде — яртылаш мәлҗегән кешегә аңлатма биреп торуны бигрәк тә кирәк тапмады. Тегенең үзе кебек, тәкәллефсез генә җавап кайтарды:

— Кая чапсам да син миңа спутник түгел, юлыңны бел.

— Ишеттем, туган көненне юарга йөрисең, имеш. Иске дус бер якта кала булып чыгамыни?

— Кала инде, нишләтәсең. Бөтенләй ауганчы шул калган җирендә басып тора бирсен,— диде Марсель коры гына. Чакырмыйча ук тагылырга торган бу бәйләнчекне бер читкә этәреп, китә башлады. Җене чыкты тегенең Марсельгә.— Юк, поселокта бөтен кешеләр дә әүлия түгел икән. Башкача берничек тә ачуын баса алмагач, авызын ерып, Марсельнең артыннан урам сасытып акырып калды:

— Син бит чүплек башыннан табып алынган ташландык әрвах,— Марсель моны ишетмәде дип уйлап булса кирәк, тагын да акырыбрак өстәде,— ташландык кешенең туган көне була димени!

Марсель бу сүзләрне ишетмәмешкә салышты, ул кунаклары килгәнче тизрәк кайтып җитәргә ашыга иде. Ләкин шулай да, никадәр ишетмәмешкә салышса да, күңелендә сизелер-сизелмәс кенә төер утырып калды: «Нәрсә лыгырдады ул сантый? Кайдан теленә килде мондый сүз?»

Кунаклары җыелып, шау-гөр килеп утыра башлагач, ул, әлбәттә, кибет алдында очраган исерек башның сүзләрен онытты — барысы да яшьләр, барысы да үз ишләре, уен-көлкене, җырны-аккордеонны прокатка алмаганнар, утыра бирәләр, утырган саен җыры да, уен-көлкесе дә туа бирә иде. Шулай да бер араны, ниндидер йомыш белән кухня ягына үтеп, әнисе карчык белән йөзгә-йөз туры килгәч, кинәт йомшарып киткәндәй булды егет. Аңарга инде азмы-күпме хәмер пары да кергән иде, үзен тотып кала алмады, озак аерылышып торганнан соң беренче кабат күргәндәй, әнисенең каршысына килеп басты. Кулларын аның иңнәренә салды, туры итеп, үтәли күрергә теләгәндәй итеп, сүзсез генә карчыкка карап торды.

— Әни! — диде ул, кинәт өзеп кенә. Беравык ни әйтергә белмичә талпынып торды, аннары, шушындый ук кинәтлек белән, нәрсәнедер үзенә үзе расларга тырышкандай, кабатлап куйды,— ә мин сине барыбер яратам... барыбер яратам, әни!

Юк, поселокта бөтенесе дә әүлияләр генә түгел икән, егерме биш ел сакланган серне бер урам-авыз, уйлап-нитеп тормыйча, чишеп куйды — кара әле син, бәйрәм итәргә дип йөргәндә күңелдә фетнәле тынгысызлык кузгатты бит шул сүз. Кузгатты, ләкин озакка түгел. Үзенең эчке уйларында казынырга гадәтләнмәгән һәм, шуның өстенә тагын, яшьлеге ташып торган егет фетнәле уйны озак саклап йөртергә сәләтле түгел иде.

## V

Нәкъ шул көнне иртән Москва — Свердловск поездыннан бу станциядә кулына пөхтә юл чемоданы тоткан, гомумән, өстенә-башына пөхтә киенгән, кырык биш-кырык җиде яшьләр чамасындагы бер ханым төшеп калды. Аны берәү дә каршы алмады, хәер, ханым моңа үзе дә бик шат, ул, таныган-белгән кешеләр күзгә ташлана калган сурәттә дә, үзен танытмыйчарак үтүне хәерле саный иде булса кирәк, башындагы иске модалы кара эшләпәсе астыннан йөзенә шундый ук кара челтәрвуаль төшергән иде. Урамда очраган кешеләр йөзен челтәр белән каплаган бу ханымның поселокныкы түгел икәнлеген ачыктан-ачык чамалыйлар, караганы да ничектер ятсынып карый, күбесе күрмичә үк уза — кешеләрнең үз мәшәкатьләре. Хәер, ханымның да үз башында үз уйлары иде.

Кунак йортының регистратура бүлегендә, «килде — китте» эшләрен формалаштырганда, «Ничә көнгә? Нинди максат белән?» дигән сораулы юллар алдында аптырап калды ул. Чөнки нинди максат белән йөргәнлеген бер чама белән белсә дә, күпме булачагын белми. шуңа күрә, уйланып торганнан соң, койрыкны тоттырмастай юлын тапты: «Иртәгә киләсе «Москва — Свердловск» поездын көтеп алганчыга хәтле. Нәкъ бер тәүлеккә» дип язды.

Һәм ул көндез урамга чыгып буталып йөрүне кирәк санамады, көне буе диярлек бүлмәсендә үткәрде. Йоклады яки йоклаган атлы булып күренергә тырышты. Башына берни дә кермәсә дә, китап тотып утырган булды. Поселок белән танышу теләге көчле булса да, ул хәзергә бу теләгенә дә юл куймады. Аның каравы поселок өстенә кичке эңгер төшкәч, безнең бу серле мөсафирыбыз кинәт бик җанланып китте. Кунак йорты хезмәткәрләреннән урамнарның исемнәрен сорашырга тотынды, кичнең тынычлыгы яки тыныч булмавы белән кызыксынды. Һәм кичке эңгердә кояш сугу куркынычы һич булмаса да, йөзендәге челтәрен алмыйча, әлеге кул чемоданын тотып чыгып китте.

Болай караганда, поселокны бер дә белмәгән кеше кебек күренсә дә, үзенә кирәген белә иде, ахры, танышларыннан алдан ук сорашып, хәбәрләшеп килгән булган, туп-туры Тихая урамына таба юл тотты. Капка баганасына «Кадерметевлар» дигән табличка, кече капкада «Сак бул! Ишек алдында усал эт бар» дип өркетүче калай кадакланган бер катлы йортны да озак эзләп тормады. Максатына якыная барган саен, бу билгесез ханымның икеләнү катнаш тәвәккәлләнә баруы сизелеп тора иде. Шулай да табличкалы капкадан тиз генә кереп китәргә ашыкмады, юк, «Ишек алдында усал эт бар»дан куркып түгел, ашыкмавының сәбәбе бүтән — без уйлаганга караганда катлаулырак иде булса кирәк...

Утлы тәрәзә каршына килде, чак кына шыгая төшеп, өй эчендәге шау-шуга колак салды — ачык тәрәзәдән бөтенесе: күңелле гөрләшү, җыр-гармун, шул шау-шу арасыннан Марсельнең көр тавыш белән көлеп җибәргәләве һәм әллә нидә бер «Әни! Синең пешкән әйберләрең арта башлады, без ансыз да пешә барабыз!» кебек сүзләр белән шаяртуы аермачык ишетелеп киткәләп иде.

Шунда, утлы тәрәзәләр каршында, керергә дә, борылып китәргә дә белмичә аптырап торганда, кинәт коточыргыч бер уй үтте ханымның башыннан. Яшен тизлегендә һәм яшен суккандай көйдереп үтте: кара әле, анарга әйтергә тиеш иде бит ул егет «Әни!» дип. Ә менә әйтми, чөнки ул аны туу белән ташлап китте, әнисе була алмады, әнисе булырга теләмәде. Яшьлеге аркасында, куркаклыгы һәм җилбәзәклеге аркасында ташлап китте. Әтисез туган баланың әнисе булмый торгандыр, булмаска тиеш дип уйлады. Вакытлар узды, соңыннан яшьлек аркасында эшләп ташлаган бу җинаяте вакыт-вакыт исенә төшеп,

күңелен тырнап узгалады, ләкин ул-бу булмыйча эзе суынгач, шулай эчтән тырналу белән тынычланды. Тагын да соңыннанрак, икенче бер иргә чыгып, икенче оя корып җибәргәч, хәтта исенә дә төшермәс булды. Иртә уңмаган кич уңмас, диләр, ләкин ул яңа оя белән дә эше барып чыкмады. Күңел җилбәзәклеге ханымнан калмады, җитмәсә тагын чибәрлеге дә, чит ирләрнең күзе төшәрдәй табигый бизәкләре дә бар иде. Дөнья булгач, кашы-күзе уйнап торган андый чибәрләрдән «авыз итеп карарга» әзер торучы бәндәләр ирләр җенесеннән дә табыла торды. «законный ир» дигәне үзе кабасыны авызыннан өзеп икенче бер чит кешегә каптырырга, әлбәттә, риза булмады. Эш зурга китте, суд бу оядан туган ике баланы этисе тәрбиясенә калдырып, ирнең гаризасын канәгатьләндерде. Шулай итеп, чибәр ханым яңадан дүрт ягындагы дүрт кыйбласы белән ялгызы гына торып калды. Хәер, бу вакытта инде аның чибәрлеге чамалы калган, дөресен әйткәндә, кыйблалары-ның да ышанычы шулчаклы гына иде... Нәкъ менә шунда инде ул бу дөньяда сыеныр кеше кирәклеген исенә төшерде, бу юлы инде чын-чынлап исенә төшерде. Һәм шунда аның моннан егерме биш ел элек ташлап киткән малае исенә төште. Монда калган «чыбык очлары» аркылы малайның исәнлеген ул бер чама белә дә иде. Егетне егерме биш яше белән котлаган атлы булып, аңа бүләкләр алып, ә чын дөреслектә, бу аның, әгәр сыенырга мөмкин булса, сыенып ук калырга ниятләп кайтуы иде. Болай уйлау, мондый ният белән кайчандыр үзе ташлап киткән кеше янына әйләнеп кайту, әлбәттә, җиңел түгел. Башта да җиңел булмагандыр, хәзер дә җиңел түгел, ләкин, ничек кенә яшерергә тырышмасын, күңел түрендә, кайдадыр бик эчкәредә, шундый нияте бар иде. Хәзер инде, бу якты тәрәзәләр каршында, ләкин тышкы якта ялгызы гына басып калгач һәм, өстәвенә тагын, өй эченнән Марсельнең көр тавыш белән «Әни!» дип эндәшүләрен дә ишеткәч, эчтән ничек кенә өзгәләнгән булмасын, үзе өчен ачы хакыйкатьне, ниһаять, төшенде: бер кешенең ике әнисе булу мөмкин түгел! Һәм җан өшеткеч әрнү белән тагын шуны төшенде: бүгенгесе көндә аның ташлап киткән баласы ташландык түгел, бүгенгесе көндә ул үзе ташландык булып калды түгелме соң!

1971 ел.

**Ренат Харис**

# ЯРАЛАР

## Кереш

Яралы авыллар,
Яралы калалар,
Яралы халыклар һәм илләр!
Яралар турында сөйләргә хакым бар —
Сез минем хакыма дәлилләр.
Мин беләм,
Яраны онытып яшәргә
Тырышу — кешегә хас гадәт,
Ләкин бу шәп гадәт
Кешегә һәм илгә
Китерә аламы сәгадәт?
Күрәм дә яраны,
Хурланам мин кайчак,
Ә кайчак уяна горурлык.
Мин сизәм — аңыма, җаныма, рухыма
Иңә дәрт, иңә көч һәм зурлык.
Ил өчен, җир өчен көрәшкә әзер мин
Һәр секунд,
Һәр минут,
Һәр сәгать...
Аларны ярадан саклсам калкандай —
Сәгадәт бу!
Һәм мин канәгать!

## Вакыт ярасы

Сау-сәламәт көе килә вакыт,
Бер дә булмый аның ярасы.
«Гасырлар» дип, «Чор» дип исем алган
Вакытларга бүген кара син.
Учакларда китап, шәһәр, кеше
Белән бергә яна, яна да
Яман дан ала ул. Илләр, җирләр:
«Аһ, килмәсен,— диләр,— янадан».
Үткән вакыт кайтмый. Бусагада
Өметлесе аның, яңасы.

Безнең аша тавыш-тынсыз гына
Әйтерсең лә агып ята су.
Һәм шул суда балык кына түгел,
Шартлаталар кинәт халыкны.
Һәркайсы бер зур җәрәхәт булып
Күпме халык инде калыкты!..
Кешелекнең ярасы ни зурлык —
Вакытның да шуның зурлыгы...
Җәрәхәтле вакыт китә... Кешелеккә
Яра булып кала хурлыгы.

## Җир ярасы

Континентлар тоташ булган, диләр,
Хәзер океан алар арасы.
Шушы микән әллә Җир шарының
Иң олы һәм тирән ярасы?

Җир өстендә гүли янар таулар,
Шартлап туа һаман янасы.
Әллә шулар микән планетаның
Иң олы һәм тирән ярасы?

Сау акыллы беркем, бернәрсә дә
Яраламый үзен... Көтмәгез!
Эзләгәндә яралаучыларны,
Үзегезне читләп үтмәгез!

Яраларны кемдер, нидер сала.
Тарих шаһит моңа. Бу — канун...
Кешеләргә, җанвар, үләннәргә
Җир бетергән биреп үз канын.

Ә кешеләр кешеләргә ата,
Кешеләрдән ага Җир каны...
Без соң Җиргә «кемдер», «нидер»мени?
Ана димибезме без аны?..

«Сакланыгыз — шартлыйм!» — диеп таулар
Хәбәр итә алдан ничек тә.
Континентлар континентка якын,
«Исәнме» дип сузсаң кул җитә.

Бернәрсә дә тоташтыра алмый
Үле белән тере арасын...
Кеше кулы белән киңәйтелгән
Шундый ара — Җирнең ярасы.

## Илемнең олы ярасы

Һәрвакыт башка һәм йөрәккә
Чамалый ядрәсе катыйльнең,
Төбиме үз җирең дошманы,
Төбиме күзләре ят илнең.
Һәрвакыт башка һәм йөрәккә...

Аттылар Ленинга — йөрәккә...
Ул чакта ил әле нарасый.
Һәм илем нарасый килеш тә
Күтәрде бу олы ярасын.

Халыклар түзмәсә, ил түзми,
Ә илгә озын юл барасы.
Рухыма һаман да көч бирә,
Үч өсти илнең шул ярасы...
Халыклар түзмәсә, ил түзми!

## Төсләрдәге яралар

Һәр дәүләтнең байраклары төсен
Ихтирамлый һәркем берсүзсез.
Байрак — илне, чәчәк жирне бизи,
Бу җәһәттә алар бертигез.

Байракларны төрле төсле куллар
Күтәрәләр илләр исеменнән.
Я, әйтегез, кайсы байракларга
Төс йоккан бар куллар төсеннән?

Куллар төсе Жирнең кайсы төшен
Таплаганын әйтә аласыз!?.
Ап-ак тәнгә поскан кара җаннар,
Җавап табарга сез чарасыз.

Байракмы ул, тәнме — төсләр тигез.
Бу тигезлек кемгә ярамый?
Кемнәргәдер ярамаган өчен
Җирдә хәтта төсләр яралы...

## Гадәт ярасы

Сугыштан ул чулак булып кайтты.
Сыңар кулын ядрә йолыккан.
Дөбердәтеп эшли. Теге кулын
Әллә кайчан инде оныткан...

Тик кайвакыт көрсенгәләп куя —
Була аның шундый чаклары:
— Татарчалап, ике кулны сузып
Күрешә алмый менә татарың.

Һәм ялт итеп кулларына бага.
Көрсенмичә түзеп кара син...
Кулыннан да бигрәк гадәтендә
Аның мәңге сыкрар ярасы.

## Яралы өйләр

*(Сталинград өйләренә)*

Буйсынмаучаннарның йорт-җирләрен
Җимерәләр явыз, үчлеләр.
Карусызлар өен җимермиләр,
Үз өендә үзен көчлиләр.

Буйсынмаучаннарның йорт-җирләре
Бомбалардан ала яраны.
Карусызлар өе мәсхәрәдән,
Мыскыллардан кала каралып.

Буйсынмаучаннардан йорт-җирләрен
Сипләү өчен михнәт сорала...
Карусызлар бу газаптан азат,
Тик йөзләрен каплап торалар...

## Сугышчы ярасы

Батырның ярасы бар икән —
Күкрәктә инде ул ярасы.
Куркакның ярасы бар икән —
Яшерер яралы аркасын.

Орденга, һич югы — медальгә
Тиң була батырның ярасы.
Куркакның ярасы — хурлыкның
Вөжданга ягылган карасы.

## Коммунист ярасы

Ул яралы килеш әсир булды.
Гаепләрсез микән сез аны?
Күкрәгеннән каны саркыса да,
Сау-сәламәт иде иманы.

Кыйнадылар аның югалтканчы,
Тырнадылар күкрәк ярасын...
Иман түзәр, тик тән түзә алмас,
Коммунист та — адәм баласы!

— Мин тагы да чыдый алмыйм,— диде,—
Кыйнамагыз артык, сукмагыз,
Каләм, кәгазь, кара китерегез —
Сызам партизаннар сукмагын.
Бу күзләрем аны яхшы белә,
Кулларның да көче үзендә...
...Һәм каләмен карасына манып
Кадады ул үзенең... күзенә.

Әйтелергә тиеш хаклык сүзең
Очмый кала икән ук булып,
Үзеңнең үк намусыңа төшәр
Мәңге өтә торган ут булып.

Әйтелмәскә тиеш яла сүзең
Бер ычкына икән телеңнән,
Үз намусың синең гомер буе
Телем-телем булып теләнә.

## Яралы җыр

*(Ул — Интернационал!)*

Җирдә җыр бар — мең макталган,
Мең атылган, тапталган,
Мең тапкыр канга батып та,
Икмәк кебек саф калган.
Революционерлар Җирдә күпме —
Шулчаклы яраланган,
Йөрәге мең тишелеп тә,
Һава күк исән калган.
Патшалар киртә күтәргән,
Дәүләтләр аяк чалган,
Җир буйлап хәрәкәтендә
Җил кебек даим калган.
Аңа арттан ташланганнар
Хыянәт, яла, ялган.
Ул үзенең тумышына
Дуслык күк тугры калган.
Күпме илнең гимннары
Аңа бәрелеп ualган...
Шундый көч була торып та,
Диктатор булмый калган,
Ул тыйнак булып калган.
Җирдә җыр бар — иң күп яра,
Иң зур дан, шөһрәт алган.
Капиталларга кадалып,
Ирек булып яналган!

●

Үз батыры һәрчак иң зур батыр
Теләсә генә нинди халыкның.
Ул көчлерәк диеп чагыштырма
Муромецны яки Алыпны...

Һәр икесе халык күңеленнән
Хыял булып калкып чыкканнар.
Һәр икесе газиз иле өчен
Ат менгәннәр, кылыч тотканнар.

Илләр уртак булмаганда алар
Бер-берсенә каршы калыккан.
Көнелемдә бүген алар тигез —
Илья Муромец та, Алып та.

Чагыштырма! Чагыштырулардан
Бары рәнҗер генә батырлар.
Зур дуслыкка яра сала торган
Күтәралмас ташлар атарлар.

Үз батыры һәрчак иң зур батыр
Теләсә генә нинди халыкның...
Алар тигез, чөнки Ватан уртак
Илья Муромецның, Алыпның...

●

Нәрсә соң һәрчакта
Иркәләп, кочаклап
Үтергеч яралар салучы?

Килер дә кыямәт,
Терелер үләләр,
Әйтерләр: «Хыянәт! Хыянәт!»

Нәрсә соң һәрвакыт
Юатып-юатып
Үтергеч яралар салучы?

Килер дә кыямәт,
Терелер дәүләтләр,
Гүләрләр: «Хыянәт! Хыянәт!»

Нәрсә соң һәрьяклап
«Бай, гүзәл!» дип мактап
Үтергеч яралар салачак?

Булмас та кыямәт,
Җир әйтер, су әйтер,
Күк әйтер: «Хыянәт! Хыянәт!»

## Илләр парады

Куанасы килде, ахры, Җирнең,
Ясады ул илләр парады.
Саф-саф булып торган дәүләтләргә
Гашыйк күзләр белән карады.

Кинәт кенә кәефе кырылды...
— Барыгыз дамы?..— диеп сорады.
Аннан әйтте: — Яралылар күрәм.
Яралылар! Алга бер адым!

Һәм буйсынып Җирнең әмеренә,
Барлык илләр алга атлады.

Ә аларга бары бернчә ил
Иярергә кирәк тапмады.

Һәм аларга карап Җир эндәште:
Сез соң ничек исән калдыгыз?
Җавап бирде илләр: — Без яралы,
Хәтта адым атлый алмыйбыз...

Күз алдында булган бу эшләргә
Җир чирканып, өтеп карады.
Һәм уйлады: кайчан ясап булыр
Бәхет тулы илләр парады?..

●

Тән онытса,
Җан онытмас яраны.
Җан онытса,
Кан онытмас яраны...
Сәясәттә яки туплы фронтта
Каһарманлык билгесе ул —
Онытма!
Һәм куркаклык шаһиты да —
Онытма!
Карап безнең яраларга
Оныклар
Тарихларын бәһаләрләр,
Онытма!
Тән онытса,
Җан онытмас яраны.
Җан онытса,
Кан онытмас яраны.
Кан онытса,
Аң онытмас яраны —
Көрәш эзен
Беркайчан да
Онытырга ярамый!..

## Роберт Әхмәтҗанов

# «Мин—Сонгми!»

Руене, Лидице, Пирчюпис, Хатынь
фашистлар тарафыннан юк ителг
авыллар. Алар меңнән артык. Безн
көннәрдә бу исемлеккә тагын бер к
бан өстәлде: Сонгми... Америка солд
лары Сонгми общинасының 500 дән а
тык кешесен үтерәләр, авылны яндыр
җир белән тигезлиләр.

Инеш кенә чылтырап агып яткан
топольле һәм таллы бер авылга
төнге сәгать 12 дә,
дәшми-тынмый,
килеп керде
Сонгми.

Су сорады.
Кара шәлен япкан.
Тезләнде ул килеп
мич алдына:
Кояш мине эзли, диләр,
ә мин аны күптән
күргәнем юк.
Ә мин аннан качам,
куркам хәзер
яктылыктан...
Мин, кешеләр, сездә калам.
Йөрим нигездән нигезгә...

Без, җирдән үчкән авыллар,
йөрешәбез шулай
бер-беребезгә.

Сорашабыз хәлләрне;
карыйбыз бары тик
сүнгән учакларга,
искә төшерәбез сабыйларның
шат авазын,
икмәк исен,
тормыш төсен,
матчаларда бишек тирбәлүен...

Картларымның тамак кырган авазы
тора һаман
ишек алларымда.

Тора һаман урамнарда
агачларның яшел күләгәсе
һәм тирбәлә
юлга төшеп
гашыйкларның
ак шәүләсе...
Әтәчләрем кычкыра
таң алдыннан.
Янгыр ява!

Һәр иртәдә
кыр капкамнан
көтү чыга...
Су алалар коемнан...

Бар да миңа шулай тоела.
Үзем белән йөри күченеп
бар да...
Кайталар кешеләрем,
китәләр — төрле вакытларда,
аердылар мәңгегә
йокымнан.

Төнем — йокысыз,
Булдым Пирчюписта.
Ул савыккан,
җыйган балаларын.
Лидицеда булдым.
Ул да онытып килә бугай
Иске яраларын...

Сөйләштек утырып бер туйганчы,
таң сызылганчы...
Тик
йокыда
каядыр төш күреп еласа балалары,
үземнекеләр! дип ымсынып,
куя йөрәк
барын юксынып,
әрнеп сызлый...

Мин — Сонгми.
Мин — яну образы.
Әгәр
җир шарындагы бөтен авылларның
учаклары җыелып янса да,
яна алмас иде
минем кадәр!..

Мин — Сонгми.
калды нигезем такырланып.
Шул янудан
миллионнарга тапкырланып,
чаткыланып
үрчедем мин.

Шуннан бирле
яшь йөрәк уртасында
һәр кешегә —
берәр Сонгми.

## Бала чак кышы

Кая ул көнелнең беренче ак карлары,
Тирәкләр шыгырдаган иртә?
Кыш карларын или читән аша,
Киртәләргә куна көмеш көрпә.

Уза көнел кышкы эңгер аша,
Таңгы баскычларда буран эзе.
Чөйдә бүрек мине көтә. Төнен
Сагынгандыр инде урам безне...

Зенли капка. Тамак кыра кемдер,
Моржаларда төтен чайкала.
Төшен сөйли әни: «Әтиең кайтыр»...
Тәрәзәдә сары ут яна.

Юлда — карга, карда — «ат төшләре»,
Үрәчәләр уза чалулап...
Ап-ак таңның уйнак өермәсе
Муйнак булып каба чабудан...

## Романс

Кич,
шәүләләр озынайгач,
нәни шигем,
баганадай, юлга ята...

Икеләнү, упкын тора
йөрәгемнең яртысында.
Килер юлың — тып-тын гына
Ак каеннар яктысында.

Бүгенге кич — безнең өчен,
мәңгелектән безгә килгән.
Сагынуларым ташкынына
көймә булып кер син, иркәм.

Йолдыз булып төш син аңа,
я йөзеп йөр яфрак булып;
давылларммын — җилем тимәс,
яратырмын — саграк булып...

Ак каеннар яктысында
килер юлың тып-тын гына...

Әй, сөекле сының тора
икеләнү упкынында...

IIIIIIIIIIII

Сафа Сабиров

# ФИРДӘВЕС

хикәя

Николай белән су буенда кояшта кызынып ятабыз. Николай — боцман, мин — койрыкчы. Дөресен әйткәндә, без хәзер гади боцман, гади койрыкчы гына түгел, икебез дә су транспорты институты студентлары. Читтән торып укучылар!

Кабул ителүчеләр исемлеген бүген иртән генә элделәр. Яшерен-батырын түгел, бик куркып, борчылып көткән идек. Исемлектә үзебезне күргәч, баш күккә тигәндәй булды. Димәк, пароходка тыныч күңел белән кайтырга, озатып калган иптәшләрнең күзләренә туры карарга мөмкин. Шунлыктан күңелләр күтәренке, кәефләр шәп. Нәни малай кебек дөньяны онытып бер шаярасы, рәхәтләнеп көләсе килә.

Көне дә искиткеч матур. Яр читеннән үк башланып киткән яшел урман кошлар чыр-чуыннан, бала-чага тавышыннан гөр килеп тора. Безнең аяк очында тын елга чайкала. Ул еракка, әллә кайларга тикле җәелгән — кайда су чите, кайда күк башланганын да аерырлык түгел. Зәңгәр киңлектә, канат җәеп очкан акчарлак сыман, җилкәнле көймәләр күренә.

Безнең пароход кич белән генә килеп җитәчәк әле. Шунарчы безгә барыбер көтәргә, теләсәк-теләмәсәк тә, яр буенда кояшта кызынырга туры килә. Николай, гамьсез сабыйдай, рәхәтләнеп ята. Ул кабак чаклы зур такыр башын таза беләгенә салган да йөнтәс ботларын як-якка сузып, йөзтүбән яткан. Мин кулымдагы салам очы белән аның муенын кытыклыйм, ул аны чебен дип белеп, шап итеп муенына сугып ала. Мин рәхәтләнеп көләм.

Менә урман кырыендагы бакчадан икешәр-икешәр булып сафка тезелгән, житәкләшкән балалар килеп чыкты. Ул да түгел, ком өстендә таралышып, уйнарга да тотындылар. Тәрбияче апалары — жиңел ак халат кигән, беләкләренә йөнтәс сөлге салган урта яшьләрдәге ханым һәм киң читле салам эшләпә кигән яшь кенә кыз — безнең баш очына ук килеп туктадылар. Без аларның көн дә ятып кызына торган урыннарын алганбыз, ахрысы, кашларын җыерып ризасызлык белдереп тордылар. Әмма авыз ачып аны-моны әйтмәделәр. Бер-берсенә сүзсез генә карашып алдылар да халатларын салып безнең белән янәшә сузылып яттылар.

Өлкәнрәк яшьтәгесе базык гәүдәле, таза беләкле, аз сүзле иде. Икенчесен — минем белән янәшә ятканын — күрүгә сулышым кысылгандай булды. Чия төсле алсу иреннәре, елмайган чакта күренеп калган ап-

ак тешләре, кояш яктысына кысыла төшкән күзләре бер үк вакытта наян үчекләп тә, дустанә үз итеп тә карыйлар төсле иде.

Сары ком өстенә чалкан ятты да йомры беләкләрен ике якка җәеп салды, сул кулы минем беләккә орынып китте. Мин аның бармак буыннарын, уч төбендәге нәфис сызыкларын күрдем, кулыннан сыйпап алудан үземне көч-хәл белән генә тыеп калдым. Шундый да чибәр, шундый да сөйкемле кыз булыр икән дөньяда!

Бераздан ул зәңгәр күккә төбәлеп уйга калды. Шул хәлендә әкрен генә сүз башлады:

— Гөлҗамал апай, кичә син кайтып киткәч, тагын Әхәт килеп чыкты.

— Соң нәрсә ди?

— Һаман шул бер сүзне кабатлый: тиздән командировкага китәм, өч атнасыз кайтмыйм, шуңарчы барып гариза бирик, ди.

— Ә син ни әйттең?

— Ни әйтим... Теге чакны ничектер җиңел генә риза булган идем дә, вакыты җиткәч, икеләнеп калдым...

Гөлҗамал яткан җиреннән торып утырды да кызның чәчләреннән сыйпый-сыйпый:

— Бар, Фирдәвес җаным, ике дә уйлама, тот та бар,— диде.— Үзе чибәр, үзе уңган. Андыйлар гел очрап тормый...

Ихтыярсыздан кеше серен тыңлау уңайсыз булып китте. Алар безне татарча аңламый дип уйладылар булса кирәк, тартынмый-нитми сөйләшә бирделәр.

Шул мәлне баш очыма өч-дүрт яшьлек малай килеп утырды. Утырды да кулындагы кызыл саплы тимер соскыч белән комда бик тырышып кое казырга тотынды. Фирдәвес, яткан җиреннән генә үрелеп, аны үзенә тартып китерде:

— Марат, панамкаңны ки, башыңа кояш сукмасын.

Беркавым сүзсез яттылар. Гөлҗамал әйтте:

— Марат өчен бер дә борчылма, көзгә чаклы миндә торыр. Балам бар дип яшь гомереңне заяга үткәрмәссең бит инде! — диде.

— Анысы шулаен шулай ул, Гөлҗамал апа... уйламый булмый шул... Әхәт аны өнәп бетерми кебек. Баланы телгә алдыңмы — сүзсез кала.

Алар шулай серләшеп яткан арада, балаларның бер өлеше суга кереп киткән, калганнары яр буенда борыны белән комга килеп терәлгән моторлы көймә янында кайнаша башлаган иде. Ханымнар тиз генә торып балаларны судан куып чыгардылар һәм, тагын кереп китмәсеннәр дип, үзләре дә шунда утырып калдылар. Безнең белән калган Марат та кое казып туйды бугай, кулындагы соскычын читкә ыргытты, күзенә төшкән панамкасын күтәребрәк куйды. Минем газета өстенә куйган кителемне, алтын «кәбестәле» фуражкамны күргә ул:

— Әй, бу кем капитанкасы!? — дип бик гаҗәпләнде һәм минем фуражканы башына киеп карады.— Абый, син капитанмы? Чын капитан, әйе? Пароход кычкырта беләсең, әйе?.. Мин дә капитан булырга телим, ярыймы?..

— Нигә ярамасын, бик ярый!.. Зур үскәч, менә дигән капитан чыга синнән,— дидем.

— Капитан Марат: ту-ту-ту. Капитан Марат: ту-ту... т-т-ту-у...— дип, Марат бик гайрәтләнеп яңакларын күпертә-күпертә пароход булып кычкырта башлады.

Тәрбиячеләрнең кайтыр вакыты да җитте бугай. Су кереп чыкканнан соң, халатларын киделәр дә балаларны сафка җыя башладылар. Хәзер алар кереп китәчәкләр, бу искиткеч матур, сөйкемле яшь ханымны мин бүтән беркайчан да күрәчәк түгелмен бит...

Шунда башыма үзем дә көтмәгән бер шаян уй килде. Исеме Фирдәвес иде бугай. Тукта, бер кызык булсын әле... Куен дәфтәремнән бер бит кәгазь ертып алдым да яраткан җырымны сызгаладым:

Кашың кара, күзең күк,
Сиңа сөйләр сүзем күп,
Сөйләр идем дә сүземне,
Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Кайда күрим үзеңне?..

Язып бетергәч, кәгазьне дүрткә бөкләдем дә Марат кулына тоттырдым.

— Менә бу кәгазьне Фирдәвес апаңа бир. Югалтма, хәзер үк илтеп бир, яме...

Марат, укый белгән кеше кебек, язуны әйләндереп карады да:

— Нинди апай булсын, минем әни бит ул,— диде.— Ярар, хәзер илтеп бирермен... Абый, сез иртәгә дә монда киләсез, әйе?...

— Килербез, Марат, килербез... йөгер, сине көтәләр.

Инде безгә дә кузгалырга вакыт житкән иде. Без кергән арада, Марат язуны әнисенә илтеп тапшырды, кулы белән безгә таба күрсәтә-күрсәтә, телдән дә нидер әйтте. Ара шактый ерак иде, мин аның ни әйткәнен ишетә алмадым. Язуны тиз генә күздән кичергәч, Фирдәвеснең ак тешләрен җемелдәтеп безгә елмаеп караганын күреп калдым.

* * *

Портка барып төшсәк, безнең пароход әле һаман килмәгән. Юлда тоткарлык булган, имеш; күпкә соңгарып, кояш баер алдыннан гына килеп житәчәге билгеле булды. Димәк, тагын өч-дүрт сәгатьне бушка уткәрергә туры киләчәк.

Иртәдән бирле рәтләп ашаган юк иде, бераз тамак ялгап алырга дип ресторанга кердек. Зур зал шыгрым тулы. Иделгә караган ачык балкондагы өстәлләрнең берсе янында ике генә буш урын бар, анда көләч йөзле, юантык ханым белән купшы киенгән бер егет кәефле генә сыйланып утыралар. Алар инде күптән кергән булса кирәк, алларындагы шешәләре дә, тәлинкәләре дә бушаган, көл савыты папирос төпчекләре белән тулган. Ханым әйбәт кенә күренсә дә, егете шактый мәлҗерәгән, күзләре аларган, йөзе кайнар мунчадан чыккандай кып-кызыл булып кызарган иде. Официантка безне шулар янына утыртты да заказ ала башлады.

— Николай, бик шәп акбашлар бар икән. Институтка әләгү шатлыгын юып алыйкмы? — дидем.

Боцман аракы белән дус түгел. Пароходта эчкән кешене аеруча яратмый. Әмма бу юлы каршы килмәде:

— Әйдә, синеңчә булсын, бер савыт китертик. Гөнаһысы сиңа төшәр, сакаллы сабыйны аздыручы — син, дип язып куярбыз.

Аның сүзләреннән официантка да, безнең каршыда утыручы ханым да елмаешып куйдылар. Сәрхүш егет яңы белән ханымга таба борылды да, үчекләгәндәй авызын бөрештереп:

— Кара син бу юеш балакны, теләнә салынган булып кылана,— диде һәм официанткага коньяк китерергә кушты.

Тамак чылатып һәм капкалап алгач, Николайның чырае ачылды:

— Уйлап карасаң, гаҗәп тә инде,— диде ул безнең каршыдагы егеткә бер мәл сүзсез генә карап утырганнан соң.— Аракы кешенең аның гына агуламый, йөзен дә ахмакландыра. Күр инде син бу җан көеген, адәм карарлыгы да калмаган бит.

Ханым моны ишеттеме, әллә үзе сизендеме, уңайсызланып, як-ягына каранып алды, алдындагы рюмкасын читкәрәк этеп куйды. Әмма егете, инде күзләре калайланган булуга карамастан, әле һаман коньяк чөмерә һәм нидер мыгырдана иде. Официантка килгәч, ул менюга бармаклары белән төртә-төртә, тагын заказ бирергә азаплана, ә тегесе «сезгә җиткән инде» дип алмый иде.

Зал ягында музыка яңгырады. Яшьләр парлап биергә тотынды. Николай миңа таба иелеп:

— Бу алабай официантка белән аңлашкан арада без биеп килик әле,— диде дә ханым белән залга биергә кереп китте.

Сәрхуш егет бераздан янында ханым юклыгын төшенде, моны ничек аңларга дигәндәй, аларган күзләре белән миңа текәлде, сүз катарга теләп, рюмкага коньяк салырга сузылды. Мин рюмкамны читкәрәк алып куйдым.

— Читсенмә, мин үзем дә елгачы,— диде ул.— Чынлап әйтәм, елгачы мин... Училищеда производство бүлеге начальнигы... Иртәгә командировкага китәм. Пароходларда безнең укучыларның производство практикасын тикшерергә, инструктажга... Арылган... Ял итеп, Иделдә йөреп кайтасы килә...

Музыка туктагач, Николай белән ханым безнең янга килделәр. Икесе дә матур булып кызарынган, күз карашлары очрашкан саен, сизелер-сизелмәс кенә елмаешып куялар иде.

Тиздән моны сәрхуш егет тә сизде. Ул калайланган күзләрен акайтып Николайга ачулы карана, ачыктан-ачык әйтмәсә дә:

— Кара син юеш балакны, башы эшли икән...— дип авыз эченнән мыгырдана иде.

Эш болайга киткәч, ханым официантканы дәшеп, тиз генә расчет ясавын үтенде. Инде эшләре бетте, хәзер чыгып китәләр дип торганда, сәрхуш тагын гауга куптарды:

— Бер шешәне артык санагансың, соңгысы минем заказ түгел иде,— дип официанткага ташланды.

— Ничек инде сезнеке булмасын, алар коньяк эчмәделәр бит, сез сораттыгыз...

Күрше өстәлдән безгә таба борылып-борылып карыйлар иде. Ханым уңайсызланудан нишләргә белмичә:

— Анысы да безнеке. Кеше көлдермә, акчаңны түлә дә тизрәк китик,— диде.

Шул сүзгә колак салып, тиз генә түләсә, әйбәт кенә чыгып киткән булыр иде. Юк, үз ирке белән түләргә теләмәде бит... Ул андый кеше түгел, янәсе. Документларын чыгарып үзенең кем икәнлеген исбат итәргә, тагын да катырак этәчләнергә тотынды.

Моның белән ул бик начар эшләде. Милиция бүлеге вокзалның үзендә генә икән. Шунда алып кереп түләттеләр. Шаһит итеп безне дә алып керделәр. Соңынтын кирәк булса-нитсә дип, кайсы пароходтан икәнебезне, исем-фамилияләребезне дә язып калдылар.

* * *

Үткен борыны белән киң елганы урталай ярып һәм як-якка йөгерек дулкыннар тәгәрәтеп, күгелҗем утрау артыннан «Бурлак» килеп чыкты. Корпусыннан башлап мачтасына кадәр ап-ак. Мачта очында кызыл флаг җилферди. Салон һәм каюта тәрәзәләрендә, җиз трап тоткаларында кичке кояш нурлары уйный. Терраса тулы халык. Радиодан әйләнә-тирәгә күңелле музыка яңгырый иде.

Ай буе күрми торгангамы, пароход бик сагынылган икән, туган үскән авылга кайтып төшкәндәй, күңелләр нечкәреп китте. Гадәттә тойгыларын белдерергә яратмаган Николай да зур ачылган күзләре белән бер мәл карап торганнан соң, кемгәдер мактангандай:

— Күрәсеңме «Бурлак»ны?!. Карт булса да бирешми. Ай да молодец! — дип әйтеп куйды.

Иң өстә, рубка алдында, капитан Ислам Идрисович. Алтынчы дистәсен тутыра кеше. Ак китель белән кара чалбар аны егетләрдәй чибәр

həм нык итеп күрсәтә әле. Менә ул яр буйларын, тау битенә урнашкан шәһәр-бистәләрне яңгыратып гудок кычкыртты.

Әнә бит ничек: үз пароходыңның тавышы да тансык, көнелләрне жилкетеп жибәрде.

Команда членнары безне якты йөз белән каршыладылар. Ислам Идрисович югарыда торган жиреннән елмаеп кул болгады. Алгы палубада жиңнәрен сызганган Вәлишин, пристаньдагы халык арасыннан безне танып:

— И, кемнәрне күрәм мин!.. Студентларыбыз кайткан лабаса! Шулай да, мәгез, тотыгыз! — дип селтәнеп торып кулындагы чалкасын ыргытты һәм мин аны тартып алып причалдагы тумбага эләктереп куйгач, теләнә салынып мактап та куйды: — Молодец икәнсең әле, студент булдым дигәч тә, кулларың чалкадан бизмәгән...

Причалга трап салу белән, малай-шалай кебек түземсезләнеп, пароходка кереп киттек. Пролетта пассажирлардан читтәрәк басып торган команда членнары белән кул биреп күрешеп чыктык. Рәхәтләнеп күрештек. Күзләренә туры карап.

Ул арада Ислам Идрисович төшеп житте, туган улын каршылагандай, ачык чырай белән:

— Исән-сау кайтып життегезме?.. Юлыгыз уңдымы? — дип гөр килеп сораштыра башлады.

Үзең бәхетле булгач, дөнья ал да гөл булып күренә, эчкә сыймаган шатлыкны иң якын кешең белән уртаклашасы, үзең бәхетле булган кебек, аны да бәхетле итәсе килә бит. Чемоданымны каютага кертеп куйгач та, Гөлчирәне күрергә ашыктым. Торак каюталар буеннан үттем, коридорларны һәм палубаны йөреп чыктым, команда кешеләренең һәммәсен күреп бетердем диярлек. Әмма мин ашкынып эзләгән, имтихан тапшырган көннәрдә өзелеп сагынган кешем — Гөлчирәне генә очрата алмадым. Кеше-кара күрмәгән арада, камбуз ишегеннән караштыргалап та, каютасы янынннан да берничә мәртәбә үттем. Әмма ул юк, ул югалган.

Боегып, моңаеп, пароходта йөренә башладым. Ул мин бөтенләй көтмәгән жирдән — беренче штурман каютасыннан килеп чыкты. Чыгып кына калса бер хәл иде, мине бөтенләй дә күрмәгән сыман, ак халатын төймәли-төймәли, жиңел адымнар белән камбузга таба китеп барды. Өметсез шайтан ди. Ул мине бәлки чыннан да күрмәгәндер, күрсә дә танымагандыр? Мин аның артыннан:

— Саумы, Гөлчирә?.. Туктале, менә без кайттык ич,— дип аңык белән сөенечемне уртаклашырга теләдем.

Гөлчирә туктамады. Чак кына борылып, күз кырые белән ничектер төрпе генә карап алды да, берни дә әйтмичә, камбузга кереп китте. Мин исә, кинәт миңгерәүләнгән кешедәй, моны башыма сыйдыра алмыйча, баскан жиремдә катып калдым.

Ашханә ишеге янындагы эскәмиядә кечке аштан соң куе төтенгә күмелеп Вәлишин тәмәке тартып утыра иде. Әнә шул әрем тел минем аптырап калуыма бер мәл күзләрен чекерәйтеп карап торды да ихлас күңелдән кызганган кыяфәт белән:

— И брат, юкка күз атып йөрисең, соңга калдың бит... һи-һи-һи...— дип, борын тишекләреннән төтен чыгара-чыгара, ямьсез итеп көлеп жибәрде.

Кинәт кузгалган ачуымны тыя алмыйча:

— Ничек соңга калдым?! Шамакайланма, адәм рәтле әйт: ни булды? — дип бугазыннан буып алдым.

Вәлишин куркудан хәтта ап-ак булды, тәмәке төтененә тончыга башлады:

— Жибәр, аю! Буып үтерәсең ич...

— Кара аны, авызың сөйләгәнне колагың ишетмәсә...

— Ничек инде ишетмәсен, аны бөтен пароход күрә ич. Үзеңне-үзең кимсетеп йөрмә дип якын күреп әйтүем.

Моның шулай икәнен мин үзем дә сизеп өлгергән идем инде. Тик әле ышанырга белмичә, икеләнебрәк тора идем. Вәлишинның соңгы сүзләре, гадәтенчә ямьсез итеп көлмичә, ничектер гафу үтенгән сыман, менә кызганып әйтүе икеләнүемне юкка чыгарды, тормышымда аяныч бер нәрсә булганын аңлап алдым.

* * *

Бу ничек болай булды соң?

Безнең дуслык бик матур башланган иде бит. Гөлчирә белән без балалар йортында үстек, мәктәптә дә, училищеда да бергә укыдык.

Гөлчирә кечкенәдән үк шук телле чая кыз иде. Дөньясын онытып шаяра, усал малайлар белән ду килеп сугыша; шуның аркасында малайлардан да, тәрбиячеләрдән дә аның үзенә дә еш кына эләгә иде.

Бер тапкыр, бишенче класста укыганда бугай, мин аның үзе хәтле ике малай белән бакчада чынлап торып сугышканын күрдем. Әгәр шул чакны мин аралап калмасам, эше хөрти иде. Шуннан бирле ул миңа абыйсыдай олы итеп карый, кыерсытырга уйласалар, минем канат астына сыена иде.

Училищеда укыганда без бер-беребезгә гашыйк булдык. Җәй урталары иде бугай, бер төркем яшьләр көймәгә утырып, Идел аръягына чыктык. Көне дә бик матур туры килде. Рәхәтләнеп су кердек, комда кызындык, уеннар уйнадык, әрәмәдә карлыган, кура җиләге җыйдык. Ничектер шулай килеп чыкты: сүз куешмасак та, Гөлчирә белән мин һаман бергә булдык. Йөри торгач, без иптәшләрдән аерылып ерак киткәнебезне сизми дә калганбыз.

Кичкә таба, кайтырга борылганда, ярты күкне болыт каплады, коякшлы яңгыр ява башлады. Якында гына, түгәрәк алан уртасында, күптән түгел өеп куелган печән кибәне бар икән. Күреп алу белән кулга-кул тотынып шунда йөгердек һәм кибән астындагы куышка кереп ышыкландык.

Моңарчы безнең беркайчан да болай аулакта икәү генә калганыбыз юк иде әле. Кинәт бөркү булып китте. Тышта яңгыр яуганы да, яфраклар шаулавы да юк булды, аларның барысын басып, юеш күлмәк аша Гөлчирәнең йөрәге дөп-дөп тибә, кайнар сулышы битемне көйдерә, һәм мин, нишләгәнемне белештермәстән, аның битемә тиеп үк торган иреннәреннән үбеп алам. Гөлчирә телдән: «Юк, юк, ярамый»,— дип пышылдаса да, үзе калтыраган беләкләре белән муенымнан кочаклап, миңа сырыша һәм шашынып үбәргә тотына...

Училищены тәмамлагач, безнең икебезне дә бер судного: мине — рулевой, аны кок итеп «Бурлак» пароходына җибәрделәр. Пароход тормышына без бик тиз ияләштек. Чандыр гына гәүдәле Гөлчирә әллә ни арада буйга үсеп, көрәеп өлгерде һәм бик күпләрнең күзе төшәрлек чибәр кыз булып житеште. Камбуз тәрәзәсеннән савыт белән аш биргән чакларда матрослар, машинистлар аның зәңгәр күзләренә, кызуда эшләүдән матур булып кызарган йөзенә карана башладылар.

Соңгы вакытта аның тирәсендә беренче штурман Сәмигуллин чуала башлады. Җыелышларда урынлы-урынсыз мактап, берәр шәһәргә чыкса, вак-төяк бүләкләр ташып, төрле мәзәкләр белән шаяртып-көлдереп аның башын әйләндерергә тотынды.

Баштарак мин Сәмигуллиннан көнләшмәдем. Гөлчирә аның коры куык икәнен аңлар, бик тиз күңеле бизәр дип уйлаган идем. Бактың исә, әнә ничек килеп чыкты.

* * *

Төне буе йокы күрмәдем. Берсеннән-берсе авыр, берсеннән-берсе үкенечле уйлар күңелемә килә, тормышымның яме калмаган төсле тоела. Бик азга гына онытылып черем иткән араларда әллә ниткән төшләр күреп саташып беттем, тик таң алдыннан гына йокыга талдым.

Озак йокларга туры килмәде. Тышкы яктан каты итеп ишек шакыганга сискәнеп уяндым. Күземне ачсам — әле бик иртә, вахтага чыгарга тагын өч сәгатьтән артык вакыт бар. Димәк, авралга чакыралар.

Торып ишекне ачтым, боцман Николай килеп керде. Өстендә — эшкә кия торган иске кителе, башында — изелеп беткән фуражкасы.

— Әйдә киен, механик чакыра,— диде ул, иллюминаторны ачып.— Сул көпчәкнең бер канаты ватылган, төзәтергә кирәк.

Бүтән көннәрне мин гел көлеп уянам һәм, Николайны шаяртып, тагын одеял астына кереп ята торган идем. Бу юлы көрсенеп кенә куйдым да, ашыктырганны да көтмәстән, өстемә киенә башладым.

...Мин киенеп чыкканда, пароход инде Чабаксарга килеп туктаган, боцман Николай белән механик Сергей Петрович сул көпчәк янында маташалар иде.

— Менә бу шайтан көпчәгенең калагы сынган,— диде механик, эчкә күрсәтеп.— Пароход туктап торган арада шуны төзәтеп өлгерергә кирәк. Югыйсә расписаниедән кичегү куркынычы бар.— Гафу үтенгәндәй, икебезгә дә елмайганнан соң, ул тагын өстәп куйды.— Моны сез түгел, без, механиклар, ремонтларга тиеш идек. Ләкин анда подшипник кереләнә башлады. Кыскасы... сез, уңган егетләр, тырыша күрегез инде... Менә сезгә яңа калак, менә сезгә инструментлар.

— И дә хәйләкәр соң сез, Сергей Петрович,— диде Николай, аның кулыннан ачкычларын алып.— Болай оста юмалауга каршы торып булмый, кулдан килсә-килмәсә дә, тотынырга туры килә. Булдыра алмасак, ачуланмагыз...

— Була, сез беренче мәртәбә генә түгел лә... Мин сезгә ышанам,— дип сөйләнә-сөйләнә Сергей Петрович түбәнгә, машинистлар янына ашыкты, без тегермән тәгәрмәче хәтле иләмсез зур көпчәк ныгытмалары арасына мүкәйләп кереп киттек.

Төнге караңгыда бүрәнә бәрелгән булса кирәк, көпчәкнең бер канаты урталай сынган, аркылыга каерылып тора иде. Иң элек гайкаларны ычкындырып, шуны алып ташладык, аннары, яңа калакны алып кереп, борау белән болтларга тишекләр тишә башладык.

Көпчәк арасында ярым караңгы һәм юеш. Түбәндә аскы калакларга бәрелеп чалт-чолт су чәчри, өстән тамчы тамып тора. «Эчке якта берәрсе машинага ялгыш пар җибәрсә, көпчәк әйләнеп безне харап итәчәк». Боцманга күз салам. Николай тыныч, авыз эченнән нидер көйликөйли, калакның аргы башын гайкалар белән борып беркетә. Бер кызып киткәч мин дә тынычландым. Авыр ачкычлар белән зур-зур гайкаларны борып калакны ныгытып бетергәндә шабыр тиргә баткан һәм дөньямны оныткан идем.

Ул арада майлы кулларын коры чүпрәккә сөртә-сөртә Сергей Петрович килеп житте. Бик житди кыяфәт белән безнең эшне җентекләп тикшерде, без куйган калакның барлык винтларын карап чыкты, тик шуннан соң гына:

— Булган бу, бик әйбәт булган. Молодцы! — дип икебезнең дә иңбашларыбыздан кагып алды.— Без дә тегендә машинаны рәтләп бетердек. Хәзер кузгалабыз. Сез булышмасагыз, тагын ике сәгать чамасы казынырга туры киләчәк иде. Рәхмәт, дусларым.

* * *

Бу көннәрдә минем тормыш бик көйсезләнеп китте, өермә актарып ташлаган елга суыдай, тәмам буталып, асты-өскә әйләнде. Бәланең берсеннән арынып һушымны җыярга өлгермәдем, икенчесе килеп төште. Авырткан башка тимер тарак дигәндәй, кичәге хәсрәт өстенә бүген көндез профсоюз җыелышында яңа бәла өстәлде.

Мин барып кергәндә кызыл почмак инде шыгрым тулган, вахтадан буш булган команда членнары да, ресторан кешеләре дә — барысы да шунда җыелган; судком председателе Камардин, өстәлдәге кәгазенә иелеп карый-карый, үткән айның ярыш йомгаклары турында сөйли иде. Мин сиздерми генә керергә тырышып арткы рәттәге Николай янына кысылып утыруга, шуны гына көтеп торгандай:

— Әнә кулдашы да килеп керде,— дип, безнең якка төртеп күрсәтте.— Кичә судком утырышында беренче урынны беренче вахтага бирергә уйлаган идек. Болай бу вахтаның бөтен күрсәткечләре әйбәт кебек. График үтәлеше дә, ягулык һәм майларга экономия ясавы да, чисталык ягы да тел-теш тидерерлек түгел. Әмма бу вахтада хезмәт дисциплинасы бик нык аксый, гафу ителмәслек аксый, бөтен команданы оятлы итә...

Кешеләр карашып алдылар. Алгы рәттән кемдер берәү түземсезлек белән:

— Аңлашылмый әле бу, ачыграк итеп әйт,— дип кычкырды.

— Монда аңлашылмаслык берни юк. Бар да, аяз көн кебек, ап-ачык. Без эштән азат итеп әйбәт характеристика биреп институтка керергә җибәргән чибәр егетләребез — боцман Карпов белән рулевой Бакиров — Горькийда эчеп, сугышып йөргәннәр, милициягә эләккәннәр... Ышанмасагыз, әнә беренче штурманнан сорагыз.

Беренче штурман озак көттермәде. Бу хәлгә аптыраган кешеләр тын калгач, урыныннан торды да ачык тәрәзәдән каядыр еракка караган хәлдә:

— Үзегез беләсез, Горький вокзалында милиция бүлегендә минем энекәш эшли,— дип тыныч кына сөйләп китте.— Кичә туктап торган чакта энекәш янына кергән идем. «Сездә Карпов белән Бакиров эшлиме?» — ди. Эшли, мин әйтәм. «Эшләсә, сак булыгыз, коллективны хур итә күрмәсеннәр. Кичә ресторанда эчеп-исереп хатын-кызларга бәйләнеп йөргәннәр, милициядә эшләрен тикшердек»,— диде.

Баягы түземсез кеше, әле һаман ышанырга теләмичә, тагын кычкырып куйды:

— Бу ничек була инде, алар соң укырга кермәгәнмени?

— Кем белгән аларны...— дип, Камардин кулларын җәеп җибәрде.— Әйдә, үзләре сөйләсен.

Әлегә хәтле ышаныр-ышанмас тыңлаган кешеләр барысы берьюлы безгә каерылып карадылар, әле аннан, әле моннан:

— Әйдә үзләрен тыңлыйк... Үзләре җавап бирсеннәр,— дип кычкыра башладылар.

Мин, ни әйтергә белмичә, бер мәлгә уңайсызланып калдым. Николай, зур гәүдәсе белән ян тәрәзәне каплап, аягүрә басты да әйтер сүзләрен онытып кандай, тамак кыргалап, булган хәлне сөйләп бирде:

— Менә шул, без бераз тамак ялгап алырга гына кергән идек. Яшермим, бик аз гына тамакны да чылатып алдык. Әмма беркемгә дә бәйләнмәдек... Кем белгән аның шулай килеп чыгасын,— дип көч-хәл белән сүзен тәмамлады.

— Һи, кара син бу мескеннәрне...— дип, Камардин зәһәр көлеп куйды.— Тамак ялгарга гына кергәннәр дә эчеп-исереп җәнҗал куптарганнарын сизми калганнар, имеш...

— Юк, иптәшләр, көлкегә бора торган эш түгел бу. Хәзер монда бөтенләй бүтән ситуация килеп чыга түгелме? Шулай бит...— Сәмигуллин, сүзеннән туктап, җавап көткәндәй әйләнә-тирәсенә караш ташлады.— Транспортта эчүчелеккә каршы каты көрәш барган бервакытта, безнең укырга керергә дип киткән үрнәк егетләребез, ресторанда исереп, гауга чыгаралар, милициягә эләгәләр. Шундый кешеләргә институтка керергә фәтва бирә алабызмы без? Сез миңа шуны әйтегез: бирә алабызмы, юкмы? Шундый ышанычка лаекмы алар, юкмы?.. Минемчә, юк һәм булуы мөмкин дә түгел... Әнә шул хакта институтка хәбәр итәргә кирәк, исемлектә урын биләп тормасыннар...

— Минемчә дә шулай,— дип, Камардин тагын да катырак кызып китте.— Иптәш Сәмигуллин дөрес әйтә, Бакиров белән Карпов безнең ышанычны акламаганнар, безнең пароходка тап төшергәннәр икән, димәк, без аларга укырга рекомендация бирә алмыйбыз, шул хакта институтка хәбәр итәргә тиешлебез. Тагын кемнең нинди тәкъдиме бар?..

Бу сүзләрдән миңа эсселе-суыклы булып китте, сулышымны кысып тамак төбемә төер менеп утырды. Кешеләр бер-берсенә тагын борчулы карашып алдылар. Түр тәрәзәгә яны белән утырган механик Сергей Петрович китель якасының өске каптырмасын ычкындырды да гадәтенчә акрын тыныч тавыш белән:

— Дуслар, без төп мәсьәләдән читкә кереп киттек, чебеннән фил ясый башладык бугай,— диде.— Моңарчы без Карповны да, Бакировны да эштә тырыш, тәртипле егетләр дип белә идек. Бу күңелсез вакыйганы алар үзләре бөтенләй башкача сөйли бит. Димәк, аны башта яхшылап ачыкларга, шуннан соң гына чара күрергә кирәк.

— Дөрес! — диде Ислам Идрисович, аны хуплап.— Көн тәртибенә ярыш йомгаклары куелган икән, ярыш йомгаклары хакында сөйләшергә кирәк. Бакиров белән Карпов турындагы хәбәрне болай имеш-мимешкә таянып кына карап булмый. Горькийга менгәч тикшерербез. Чиста суны болгатырга ашыкмыйк әле.

* * *

Пароход авыл кебек: яңа хәбәр аның бер башыннан бер башына сәгате-минуты белән килеп житә. Әле генә безнең «эчеп-исереп» йөрүебез турында шау-гөр килгәннәр иде, кичкә таба яңа медичка матрослар теленә кереп китте. Ул аның чибәрлеге! Ул аның буй-сыны!

Кичке аштан соң кызыл почмакта телевизор карап утыра идек. Николай терсәге белән янтыгыма төртеп алга таба ым какты. Ул әйткән якка борылып карасам, ни күзем белән күрим: бер генә рәткә алда безгә чак кына яны белән борылып... Фирдәвес утыра. Дөресен әйтим, башта ышанмадым. Ул түгелдер, күземә генә күренәдер дип, алгарак сузылып, тагын карадым.

Әмма икеләнергә урын юк. Башын чак кына кыңгыр салып, гәүдәсен горур тотып Фирдәвес утыра. Матур итеп уеп ясагандай түгәрәк ияге дә, хәтта колагында җемелдәп торган асылташлы алкасы да — барысы да аныкы. Әмма шунысы бик сәер, безнең пароходка кайчан һәм ничек килгәнен, безнең кызыл почмакка ничек кергәнен һич кенә дә аңлап булмый. Тик бераздан, өстендә ак халат икәнлеген күргәч кенә, яңа медичка менә кем икән дип уйлап куйдым.

Теге көнне пляжда яткан вакытта Николай аны-моны күрмәгән шикелле иде. Кинодан соң, палубада икәү генә калгач, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды:

— Күрдеңме теге асыл кошны? Шул үзе ич,— дип, Фирдәвес үтеп киткән якка борылды.— Менә сиңа мә, медичка икән ләбаса. Теге чак-

ны бик хәйран калган идең. Әнә артыннан килеп тә житкән. Кара аны, тагын башыңны жуя күрмә...

Ник икәнен үзем дә абайламастан, кып-кызыл булып кызардым. Каушавымны белдермәс өчен ачулы кыяфәт белән:

— Нәрсә әйтмәкче буласың? Ташла әле шул урынсыз шаяртуларыңны! — дип аны кырт кистем дә, ялгызым гына калырга теләп, каютама кереп киттем.

Төнге вахтага чыкканчы бераз черем итеп алырга кирәк. Юкса таң алдыннан йокы килеп алҗыта. Яртылай чишенеп урыныма яттым, тизрәк йокыга китү өчен, гадәтемчә, санарга тотындым: бер, ике, өч... Бүтән вакытта егермегә житкәнче оеп киткәнемне сизми дә кала идем. Бүген мең йөздән үттем инде, күздә йокының әсәре дә юк. Борсаланып озак яттым. Кинәт ямансу булып китте. Йоклап булмаячак иде — торып утырдым. Ачык тәрәзәнең пәрдәсен төшереп, ут кабыздым да акрын гына көйли-көйли өстемне киенә башладым.

Тышкы яктан, бик якыннан гына, кемнеңдер ишетелер-ишетелмәс кенә тамак кырганы ишетелде. Аны-моны уйлап тормастан, пәрдәне ачып тышка карадым һәм нәкъ минем тәрәзәм каршындагы эскәмиядә утырган Фирдәвесне күреп таң калдым. Идел өстендә инде төн карасы куерып килгән вакыт булса да, тәрәзәдән төшкән ут яктысында мин аны шундук таныдым һәм хәтта чак кына сискәнеп куйганын да күреп калдым. Хәер, бу көтелмәгән очрашудан мин үзем дә ничектер каушап киттем һәм, тел тибрәтә алмыйча, бер мәлгә сүзсез торганнан соң гына:

— Мин сезне борчыдым бугай, гафу итегез,— дидем.

— Зыян юк, йоклар алдыннан һава алырга чыккан идем...

Бөтенләй сүзсез калмас өчен:

— Медицина кешеләре режим белән яши шул,— дигән булдым.

— Сез минем медицина кешесе икәнемне каян белдегез әле? Мин, бәлкем, бөтенләй медицина кешесе түгелмендер...

— Миңа тамаша, үзебезнең пароход медичкасын ничек белмәскә...

— Һи, сез пассажир түгелмени, шушы пароходта эшләүчемени?.. Ә нишләп соң мин көндез, пароходны йөреп чыкканда, сезне күрмәдем?

— Сез команда белән танышканда, мин вахтада булганмындыр... Ә менә кызыл почмакта мин сезне күрдем...

Фирдәвес, әле һаман ышанып бетмәгәндәй, башта миңа, аннары каюта эченә карады һәм стенада эленеп торган ак кителемне, эмблемалы фуражкамны күреп булса кирәк:

— Чынлап та пароходта эшләүче икәнсез,— диде.— Мин сезне кызыл почмакта ничек күрмәгәнмендер. Кино башланганны көтеп утырган чакта Гөлчирә миңа андагы кешеләрнең барысы турында да сөйләгән иде, никтер сезнең хакта гына берни дә әйтмәде.

— Анысын белмим инде, мин үземнең сезне күрүемне генә әйтүем. Хәер, мин сезне моңарчы да бер тапкыр күргәнем бар бит...

— Булмас, ялгышасыздыр,— диде Фирдәвес.— Әллә болай шаяртып кына әйтүегезме?

— Юк, ялгышмыйм, һич онытасым юк ул очрашуны...

Шуннан соң Фирдәвес бигрәк тә гаҗәпкә калды, балаларча түземсезлек белән:

— Кара син, шулай укмыни?..— диде.— Ничек соң мин аны үзем белмим? Я, алайса, үзегез әйтегез инде.

Сөйләп бирергә өлгермәдем, вахтага чыгарга хәбәр итеп, алгы палубада кыңгырау кага башладылар.

Ислам Идрисович белән очрашканда, мин аның күзенә туры карап, бер дә тартынмый, елмаеп-көлеп исәнләшә торган идем. Бүген аны алгы палубада күрү белән кинәт уңайсызланып калдым һәм, күзенә чалынмас өчен, тизрәк өченче класс коридорына борылдым. Әмма капитан күреп өлгергән икән.

— Бакиров, туктагыз әле,— дип үзе дәште ул.— Кая болай ашыгасыз?.. Миңа керик әле.

Ислам Идрисовичның каютасы өске катта беренче класс салоны белән янәшә урнашкан. Барып кергәч тә, иң әүвәл каютаның иркенлегенә, чиста итеп җыештырылган, һәрнәрсәнең үз урынында булуына игътибар иттем. Ишектән уң якта зур көзгеле кием шкафы. Түр тәрәзә буенда яшел постау җәелгән язу өстәле. Стенадагы киштәдә төрле китаплар, дәреслекләр, кагыйдәләр, расписаниеләр. Тәрәзә белән барометр арасындагы буш урынга Ислам Идрисовичның яшь чагында хатыны һәм бәләкәй улы белән өчәү бергә төшкән фоторәсеме элеп куелган.

Минем бу каютада моңарчы да бер мәртәбә булганым һәм карт капитанның элекке Идел, елгачылар турында күргән-белгәннәрен, үз башыннан кичкән гыйбрәтле хәлләрне сөйләгәнен онытылып тыңлап утырганым бар иде. Хәзер исә мин, аның күзенә туры карарга базмыйча, башым түбән идем. Ислам Идрисович та уңайсызланып калды булса кирәк, күрсенеп куйды, үтәли күрергә теләгәндәй, мине ашыкмый гына күздән кичерде дә:

— Рөстәм, син бер дә алай түгел идең, нишләдең соң син? — дип миңа төбәп карады.

Тизрәк акланырга кирәк иде:

— Ислам абый, зинһар, начар уйлый күрмәгез...— дидем.— Дөрес хәбәр түгел ул, ялган... Ышаныгыз.

— Ышанам мин сиңа, Рөстәм. Тик әле... олыларча киңәш итеп әйтүем: аракы, акыллының — ярты акылын, акылсызның бөтен акылын алырмын дип әйтә, ди. Моны мин үз башымнан кичердем.

Мин юләр, гаҗәпләнүемне тыя алмыйча:

— Ислам абый, ни сөйлисез?.. Сез эчкече идегезмени? — дип ычкындырганымны сизми дә калдым.

Истәлекләргә чумган капитан бу сорауга җавап бирмәде. Мине бөтенләй онытты кандай, стенадагы фоторәсемгә бер мәл сүзсез генә карап торганнан соң:

— Кичке техникумны тәмамлап чыккан көнне төшкән рәсем,— дип ашыкмый гына сөйләп китте.— Мин ул җәйне «Чаткы» дигән кечерәк кенә бер баркаста эшли идем. Капитан ярдәмчесе. Тормышымның иң бәхетле чагы шул булгандыр. Чынлап та, минем кебек ятим үскән адәмгә ни җитмәгән: кечкенәдән хыялланган һөнәрем бар, яраткан хатыным бар, алма кебек матур улым бар. Эштән бушау белән туп-туры өйгә— газизләрем янына ашыга идем.

Беләсеңме, ул елларда елгачылар арасында искедән калган бер начар гадәт яшәп килә: кайбер яшь-җилкенчәк вакытлы-вакытсыз эчкәләүне үзенә бер егетлек, гайрәтлелек дип саный иде. Көннәрдән беркөнне бу сазлыкка мин дә кереп баттым: эшкә барышлый да, кайтышлый да буфетка кереп, аяк өстеннән генә тамак чылатып алам. Әгәр шунда кереп тамак кычытканын басмасаң, нидер җитмәгән кебек, кәеф китек була торган иде.

Бөтен Иделне шомга салган фаҗига буласы кичне дә, эшкә барышлый, гадәтемчә, берне төшереп алган идем. Вахтаны кабул итеп алдым да кранчыларны, грузчикларны рудникка илтә киттем. Төнге сменага — таш төяргә. Арада Нажия дә бар: курста укыганнан соң, аның кранда яңа гына эшли башлаган көннәре иде. Көн болытлы. Яңгыр сибәли.

Кешеләрем түбәндә, кубрикны шаулатып җырлап бара. Нажия дә җырлый, тик аның гадәттәге шат тавышы ул көнне никтер сагышлы иде. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр.

Төрле-төрле суднолар белән тулы тыгыз рейдтан елгага чыктым. Төн караңгылана төште. Берни күрерлек түгел. Фарватерны маяк утларына карап кына чамалыйм.

Түбәндә җырлыйлар. Караңгыга күз күнегә төшкәч, мин дә кушылып җырлый башладым. Үзем һаман бер нәрсәне — Нажиямнең сагышлы итеп җырлавын башыма сыйдыра алмыйм. Ни булган аңар, ник алай сагышлы ул?..

Шулай уйланып баргынча, кинәт якында гына нәрсәнеңдер куәтле шарлавыктай шаулавын ишеттем. Карасам — түбән яктан өстебезгә әкәмәт зур судно ыжгырып килә. Уты юк, сигналы юк. Каушадым. Кай якка борылырга белмим. Гудок кычкыртып тавыш бирерлек тә вакыт юк. Кубриктагыларга кычкырырга да өлгермәдем. Теге судноның килеп бәрелүе булды, безнең баркас дөбердәп авып та китте. Упкын мине рубкадан бәреп чыгарды да төпкә алып төшеп китте...

Бераздан, мин өскә калкып чыкканда, безне батырган судно инде кире борылган, прожекторы белән су өстен яктыртып безгә таба килә. Су өстеннән тавышлар ишетелә. Теге судноdan төшерелгән көймәләр халыкны җыеп йөри. Прожектор уты көймәләргә юл күрсәтә. Тиздән барыбызны да коткарып бетерделәр, карасам — Нажия юк... Йөрәгем жу-у итеп китте. Кычкырып та карадык, эзләмәгән җир калмады — юк Нажия. Өч көннән соң үле гәүдәсе балыкчылар җәтмәсенә эләгеп чыкты.

Карт капитан сүзеннән туктагач, кайгылы истәлекләрдән арына алмыйча, башын түбән игән хәлдә тынып калды. Мин аны ничек тә бераз юатасым килеп:

— Ислам Идрисович, үзйөрешле баржаның сигнал утлары булмаганга сез гаепле түгел ич...— дидем.

— Анысы дөрес, турыдан-туры минем гаеп юк. Соңынтын шул беленде: ул баржаның штурманы да, койрыкчысы да салмыш булганнар, караңгы төшкәч, сигнал утларын кабызырга онытканнар. Әгәр бер дә эчмәсәм, бәлкем, мин дә игътибар белән карап барган булыр идем, үзйөрешле баржаны алданрак күреп, ничек тә котылу әмәлен тапкан булыр идем...— Ислам Идрисович боларны миңа сөйләүдән бигрәк, үзалдына уйлангандай, пышылдап кына әйтте. Аннары истәлекләреннән арынырга теләгәндәй, гәүдәсен турайтты һәм инде гадәтенчә ныклы тавыш белән өстәп куйды: — Безнең эштә, Рөстәм, менә нәрсәне анларга кирәк: Идел нык ихтыярлы кешеләрне ярата, чүп-чарны кабул итми, иртәме-соңмы ярга чыгарып ташлый.

* * *

Николай мине палубада көтеп торган икән. Капитан яныннан чыгып түбән төшүгә шул килеп чыкты:

— Я, ничек, кирәгенне бирдеме? — дип култыклап алды.— Синең кергәнне күреп калдым мин. Шуннан элек кенә анда мин дә булган идем. Чыккач сине искәртеп куярга өлгермәдем, гафу ит инде... Син ни әйткәнсеңдер, мин берсен дә яшермәдем, дөресен сөйләп бирдем.

— Мин дә дөресен әйттем. Шундый киң күңелле картка ялганларга телем тартмады...

— Анысын әйбәт иткәнсең, молодец! Әгәр дә икебез ике төрле сөйләгән булсак, картның хәтере калыр иде,— диде, Николай тәмам тынычланды.

— Шулай да эт адәм икән Сәмигуллин. Кара ничек күпертә.
— Үзенең арты чиста түгел.
— Ничек?
— Кичә кич Куйбышев вокзалында туктагач, алгы пролетта трап янында тора идем. Инде пассажирларның төшәсе төшкән, утырасылары утырып беткән, кузгалып китәргә сигнал гына көтә идек. Шунда грузчик кебек таза бер хатын килеп керде. Сигез яшьлек малай иярткән. Бер кулында чемодан, икенчесендә кәрзин. Бик ашыгып килгән, күрәсең, тирләп чыккан, уф-уф итеп көчкә сулый.
— «Гражданка, рәхим итеп билетыгызны күрсәтегез»,— дип туктаттым мин аны.
— Абау, нинди билет ул... Бу «Бурлак» пароходы түгелмени? — дип ханым аптырап калды.
— Әйе, бу «Бурлак» пароходы,— мин әйтәм,— әмма барыбер билетыгыз булырга тиеш.
— Һи,— башта ук шулай диләр аны...— ди. Күзләреннән утлар чәчә.— Бу пароходта минем законный ирем эшли, беренче штурман Сәмигуллин. Менә бу аның улы, без аңа кунакка килдек. «Әһә, мин әйтәм, бу законный хатын карт этәчнең кикриген бик тиз шиңдерер». Күп сөйләнеп торасы юк. Кулындагы чемоданын алдым да иренең каютасына озатып куйдым. Кунакны коридорда калдырып булмый, каюта ишеген дә үзем шакыдым:
— Иптәш штурман, сезгә кунаклар килгән, рәхим итеп каршылагыз!
Каютасында чагы икән. Эчке яктан аяк тавышы, кемнеңдер кабаланып пышылдаганы ишетелде. Ниһаять, ишекне яртылаш кына ачып Сәмигуллин үзе карады һәм, көтмәгәндә хәләл җефете белән улын күреп, коелды да төште, ни әйтергә белми, авызын ачкан хәлендә катып калды. Аннары, аңына килгәч, хәзер, бер генә минутка дип, ишекне ябып куймакчы иде, хатыны бик тә зәһәр нәрсә икән, ябарга ирек бирмәде. Ирен бер якка этеп җибәрде дә искиткеч житезлек белән каюта эченә атылып кереп китте.
Бу миңа бик сәер тоелды.
— Ничек инде аның хатыны булсын, берәр авантюристкадыр ул,— дип мин аның сүзен бүлдем.— Сәмигуллин ялгызак ич ул, Гөлчирәгә өйләнергә жыенып йөри иде бит.
— Мин дә шулай уйлый идем, әнә ничек килеп чыкты. Гөнаһ шомлыгы — Гөлчирә үзе дә Сәмигуллин каютасында булган икән. Мин шундук китеп бардым, ике көндәшнең ничек очрашканын да, беренче штурманның жәнжалдан ничек котылганын да күрмәдем. Актыктан бер матрос әйтте, Сәмигуллинның хатыны каютага барып керү белән коточкыч тавыш куптарган, әшәке сүзләр белән сүгә-сүгә, тегеләрнең битләрен тырнап бетергән.
— Тукта әле, тузга язмаганны сөйләмә,— дидем мин, әле һаман ышана алмыйча.
Николай ачуланып миңа карап алды. Гел шулай ул: үзем күптән жәннәттә, күршем өчен кайгырам. Эт каешы — безне батырмакчы иде.
— Гөлчирәсе жәл. Ни дисәң дә, кыз кеше бит, халык күзенә ничек күренер инде бичара,— дидем мин.

* * *

Фирдәвесне мин террасада очраттым. Каютада бик бөркү булгач, беraз жилләнергә теләп, мин дә шунда менгән идем. Койрык яктан әйләнеп күләгәгә чыксам, икенче класс салоны каршындагы эскәмиядә Фирдәвес утыра. Өстендә ак халат. Коңгырт чәчләрен артка яткырып

тараган. Уйчан күзләренең карашы каядыр еракка, киң тугайлар артындагы күгелҗем тауларга юнәлгән иде.

Безнең пароходны канатлы «Метеор» куып житте һәм, су өстендә йөгерек дулкыннар тәгәрәтеп, якыннан гына узып та китте. Аннан берәрсе сәлам биреп үттеме, әллә болай гынамы,— Фирдәвес кул болгап калды һәм, «Метеор» үткән якка бер мәл карап торганнан соң, сизелерсизелмәс кенә елмаеп куйды. Аннары ул, мине күреп, дусларча ягымлы тавыш белән:

— Хәерле көн, исәнмесез! — дип башлап үзе исәнләште һәм, үзе белән янәшә урын биреп, читкәрәк күчеп утырды.— Көнне әйтәм, бигрәк тә матур инде, сокланып туймаслык!

— Дөрес әйтәсез, Иделнең иң матур чагы.

— Карагыз әле, кичә сез башлаган сүзегезне әйтеп бетермәдегез бит,— диде ул бераз уйланып утырганнан соң.— Сез аны чынлап әйттегезме, әллә юри генәме?.. Хәер, мин үзем дә сезне кайдадыр күргән шикелле. Әмма кайчан, кайда күргәнемне никтер хәтерли алмыйм. Әгәр сез әйтсәгез, бәлкем, мин дә хәтерләрмен...

— Ник әйтмәскә... Телисез икән, әйтергә дә мөмкин...

— Туктагыз, әйтми торыгыз. Башта мин сезгә бер сорау бирим әле,— диде ул, минем сүзне бүлеп.— Сезнең быел җәй Горькийда пляжда булганыгыз юкмы?

— Булганым бар. Институтка керергә имтихан биргәннән соң, пароход килгәнне көтеп су буенда яткан идек.

— Шулаймы? Янызда бер иптәшегез дә бар идеме? Ул да елгачы иде бугай.

— Әйе, иптәшем дә бар иде. Ул да елгачы, минем белән бергә менә шушы пароходта эшли.

Фирдәвес кинәт гаҗәпләнүдән зур булып ачылган күзләре белән миңа карап торды да:

— Әһә, алайса мин дә сезне күреп беләм кебек,— дип күңелле итеп көлеп җибәрде.— Кичә кич белән каютада җырлавыгызны ишеткәч тә нидер сизенгән идем. Менә бит ничек, юкка булмаган, белеп сизенгәнмен икән.

Якында гына аяк тавышы ишетелде. Коридор ишегеннән быргы кычкырта-кычкырта бер малай атылып чыкты һәм йөгереп килеп Фирдәвескә сарылды. Ул ак бескозырка, ачык изүле, зәңгәр якалы матрос күлмәге, кыска кара чалбар кигән; кайдадыр лебедка тирәсендә чуалган булса кирәк, борын очы машина маена буялган иде. Нидер хәтерләргә тырышкандай, каш астыннан күзләрен миңа текәп карап торды да:

— И, абый, мин сине күргәнем бар ич,— диде.

Мин аны чыккач та танып алдым. Бу теге пляжда ятканда минем фуражканы киеп уйнаган малай бит, Фирдәвес улы Марат лабаса. Шулай да мин әле һаман танымагандай:

— Юк, ялгышасың, брат, син күргән ул абый түгел мин,— дип шаярта башлаган идем.

— Алдама, шул, шул,— дип, Марат хәтта бармак янап куйды.— Син ул чакны минем әнигә бер язу да биреп калдырган идең... Әни, шулай бит, калдырган иде бит...

— И Марат, болай булгач, харап иттең син. Серне шулай ачарга ярыймыни... Ул язуны кем калдырганын әниеңә әйтәсе түгел иде.

— Ничек әйтмәскә, үзе сорады ич. Шулай бит, әни, сораган идең бит...

Фирдәвес тә, мин дә ирексездән көлеп җибәрдек. Марат әнисенең алдына менеп утырды да:

— Абый, менә тыңла әле, пароход шулай кычкыртамы? — дип бар көченә өрә-өрә быргысын кычкырта башлады.

* *

Фирдәвес пароход тормышына бик тиз ияләшеп китте, аз гына вакыт эчендә бөтен команда белән танышып өлгерде. Аның кайчан ял иткәнен дә белмәссең. Әле медпунктта авыруларны кабул итә, әле ашханәдә, салоннарда санитария кагыйдәләре үтәлешен, аш-суның сыйфатын тикшерә, каюталарның чисталыгын барлап чыга.

Элекке медичка алай түгел иде, артык мәшәкатьләнми, интекми генә каютасында китап укып ятарга ярата иде. Фирдәвес килгәннән бирле медпунктка күбрәк йөри башладылар. Әле берсе, әле икенчесе, юк авыруын бар итеп, тизрәк шунда чаба, ах-ух килеп, күзен тасрайтып шунда утыра. Иркенләп бер сөйләшеп тә булмый үзе белән.

Фирдәвесне дә әйтер идем, бигрәк тә беркатлы инде. Шул оятсыз симулянтларны җилтерәтеп куып чыгарасы урында, аларның сүзенә ышанып, фамилияләрен кенәгәсенә теркәп куя, дарулар бирә, тырышыптырышып дәвалап маташа бит.

Әмма мин шуңар шат: үзе генә калган минутларда Фирдәвес авыз эченнән һаман теге җырны көйләп йөри. Медпункт яныннан үткән чакларда мин моны берничә мәртәбә ишетеп калдым. Фирдәвес аны минем өчен генә җырлыйдыр, шул җыр безне якынайтадыр кебек тоела миңа.

Кайчакларда Фирдәвес ничектер үзгәреп китүчән була. Бар дөньясын онытып, шаярып-көлеп утырганда кинәт уйга чума, күз карашы төмсәләнеп кала. Мондый вакытларда ул, эше бетүгә, Марат белән каютасына кереп бикләнә дә сәгатьләр буе палубада күренми, кичен кино карарга да төшми. Ул төшмәгәч, миңа да күңелсез була, минем дә карыйсым килми.

Бүген ул миңа бигрәк тә уйчан булып күренде. Галәттә ачык чырае хәзер никтер караңгы, күзләренең карашы сагышлы һәм борчулы иде. Коридорда минем белән очрашкач, көндәгедәй матур итеп елмаймады да, күңел күтәрерлек берәр җылы сүз дә әйтмәде, ишетелер-ишетелмәс кенә исәнләште дә ашыгып медпунктка кереп китте.

Әмма шунысы бик сәер, ул үзе, кунак каршыларга җыенган сыман, бәйрәмчә киенгән: өстендә кыска җиңле алсу күлмәк, муенына алтын чылбырлы брошка таккан, дулкынланып торган коңгырт чәчләрен артка яткырып тараган иде.

Бу хәлгә мин башта әһәмият бирмәгән идем. Әмма аның бик мөһим сәбәбе булган икән. Бераздан команда членнары арасында көтелмәгән хәбәр: пароходка медичканың кияү егете килгән диган сүз таралды. Моны беркем дә гаепкә санамый, гайбәт итеп сөйләми, әлбәттә. Фирдәвес өчен шатланып, кияве дә үзенә тиң, әйбәт кеше булуын гына теләләр иде.

Мин үзем «кияү егетне» кичкә хәтле күрә алмадым. Көндез андамонда чыгу түгел, тамак ялгап алырга да вакыт тимәде. Ислам Идрисович тагын аврал ясады: көймәләрне күтәртә-төшертә торган чыгырлар тутыгып эшкә ярамаслык хәлгә кергән икән, көне буе диярлек шуларны чистартып майладык, һәркайсын эшләтеп, сынап карадык.

Саратовта безнең пароходка агитбригада утырды. Кичен, юлга кузгалып китү белән, койрык ягы террасада халыкара хәл турында лекция һәм порт үзешчәннәренең бик күңелле концерты булды. Аннары, тамашачыларны биергә чакырып, баянчы вальс сызып җибәрде.

Фирдәвес миннән сулдарак пассажирлар арасында өстенә ак китель кигән елгачы белән сөйләшеп тора иде. Кичке Идел өстендә вальс дулкыннары агыла башлауга алар шундук түгәрәк уртасына чыктылар һәм кулга-кул тотышып, җиңел хәрәкәтләр белән биеп киттеләр.

Башта алар сизелер-сизелмәс кенә бөгелә-сыгыла аяк очларына басып мәйдан тирәли үттеләр. Аннары, көй тизли башлауга, кинәт икесе дә җилкенеп куйдылар да бер-берсен билләреннән алып, күз ирмәс

тизлек белән бер урында әйләнергә тотындылар. Егете бигрәк оста биюче икән. Өермәдәй ашкынып бөтерелгән минутларда аның аяклары палубага бөтенләй дә кагылмыйдыр, ул үзе дә менә-менә һавага бөтерелеп менеп китәр кебек иде.

Шулай сокланып карап торганда кинәт бу егет миңа ничектер таныш, күргән-белгән кешеләрдән кемнедер хәтерләтә кебек тоелды. Әһә, хәтерләдем, бу теге кем, беркөн ресторанда безнең белән бер өстәлдә утырган һәм җәнҗал кузгаткан егет бит!.. Теге чакны ул елгачылар формасында түгел, гади киемнән иде. Юкса хәзер мин аны күрү белән таныган булыр идем.

Бу биюгә бер мин генә түгел, команда членнары да, практикантлар да исләре китеп карап торалар иде. Шулар арасыннан кемдер:

— Безнең медичканың кияү егете шушы буламыни инде? — дип куйды.

— Әйе, шул,— диде икенчесе.— Җиңел сөякле булырга охшый бу, өлгер егеткә охшый.

— Нинди кияү егете булсын,— диде практикантларның берсе.— Безнең училищедан бит ул. Монда эш белән килгән кеше, пароходтан пароходка күчеп укучыларның производство практикасын тикшереп йөри.

— Булса ни, алар берсе икенчесенә комачауламый бит.

— Кара син аны, башы эшли икән, кәләше янына да командировка исәбенә килгән.

Моңарчы мин моны үзем абайламыйча ничек онытылып утырганмындыр. Бу хәбәрне көндез үк ишеткән булсам да, менә хәзер Фирдәвеснең кияү егетен үз күзем белән күрү йөрәгемә ук кебек кадалды.

Бер уйласаң — көенергә сәбәп тә юк шикелле. Фирдәвескә мин беркем дә түгел бит, аны минем белән берни дә бәйләми. Ул хакта безнең сөйләшкәнебез дә юк. Шулай да моннан соң мин аларның биегәнен тыныч кына карап тора алмыйча, халык арасыннан чыгып киттем...

Бераздан, төнге вахтага менәр алдыннан мин каютадан чыкканда, бар халык инде таралып беткән, пароход төнге тынлыкка чумган; алгы якта утлары сүнгән салон каршында караңгыда бары тик бер пар гына серләшеп утыра иде. Яннарыннан үтеп киткән чакта мин аларның берсе Фирдәвес, икенчесе аның кияү егете икәнлеген күреп алдым. Фирдәвес тә мине таныды бугай, кинәт сискәнеп чак кына читкәрәк күчеп утырды.

* * *

Волгоград портына без нәкъ расписаниедә билгеләнгән вакытта — иртән сәгать тугызда килеп туктадык.

Волгоград!..

Тиңдәшсез батырлык шәһәре...

Халыкның җиңелмәслеге, мәңгелек даны, горурлыгы...

«Бурлак» монда дүрт сәгать торачак. Пассажирлар да, вахтадан бушаган команда членнары да проспект кебек киң мәрмәр баскычтан шәһәргә менеп киттек.

Корбаннар мәйданы чәчәккә күмелгән. Кырыс сакчылар төсле каберләр тора. Обелиск янында мәңгелек ут яна. Үлеп калганнарның тынычлыгын саклап ике якта кораллы ике сакчы — пионерлар тора. Мәйдан тулы халык. Төркем-төркем килүче сәяхәтчеләр, чит ил туристлары үз илләре, үз шәһәрләре исеменнән һәйкәл итәгенә венок куялар да берничә минут тын гына басып торалар, дөнья язмышын күңелләреннән кичерәләр бугай.

Мәңгелек уттан сулдарак, яшел өянкеләр күләгәсендә кызыл мәрмәр. «Монда Советлар Союзы Герое Рубен Ибаррури, Советлар Союзы Герое В. Г. Каменщиков һәм капитан Ф. Х. Фәттахетдинов күмелгән». Шагыйрь сүзләре искә төшә: «Батырлар бар җирдә татарлар бар».

Гани Сафиуллин дивизиясе немец генералы Фон Дребберне бирелә әсир иткән. Немец гаскәрләре командующие фельдмаршал Паулюсның бөтен штабы белән әсир төшәргә әзерләнүе әнә шуннан башланган бит. Күнелдән уйлап барам: Гитлер безнең ил халыкларын дошманлаштырырга теләгән, тик явыз ниятенә ирешә алмаган. Испан егете, рус егете, татар егете бергә берләшкән икән — Гитлер дип аталасыңмы син, әллә аждаһамы — азакка көнең хурлык баганасында.

Гитлер кайчандыр Сталинградны җир йөзеннән җуеп ташларга кушкан, аның әмере белән шәһәр көл ителгән. Менә хәзер Волгоградта йөргән вакытта әнә шул хәрабәләр урынында күтәрелгән гигант заводларны, таш пулатларны, мәһабәт һәйкәл-монументларны, уннарча километрга сузылган киң проспектларны, яшел паркларны күреп хәйран каласың. Кеше кулы ниләр генә эшләми.

Әйе, кеше кулы ниләр генә эшләми... Мамай тавына барганда мин кинәт тынычлыгымны җуйдым. Алар автобуска икәү бергә кереп утырдылар. Әхәт, «кияү егете» дигәнебез, уен-көлке яратучан җор егет булса кирәк, атлаган саен диярлек нидер пышылдап Фирдәвесне көлдерә иде.

Пароходка кайтышлый тагын мәңгелек ут янышнан үттек. Мәйдан һәм аллеялар әле һаман шыгрым тулы иде. Чәчләренә чал кергән, маңгаенда дуга сыман яра эзе беленеп торган карт адмирал алгарак чыгып басты.

— Без, тын океанчылар, бирегә сугышның иң авыр көннәрендә килдек,— дип дулкынланып сөйли башлады ул.— Ут эченә кергәндә без: «Идел аръягында безгә бүтән чигенергә җир юк, менә шунда таш кыя кебек нык торырбыз!» — дип ант иттек һәм сүзебездә тордык — бөтен дөньяга шапырынган фашист ерткычның умыртка баганасын шунда сындырдык...

Адмирал сүзеннән туктап тын алган арада якында гына кемдер берәү:

— Кара син бу каһарман бабайны, исән калганына сөенми, әле һаман җикеренеп маташкан була,— диде һәм үз сүзләреннән үзе кеткелдәп көлеп куйды.

Мин ихтыярсыз шул якка карадым һәм Әхәтнең көлә-көлә Фирдәвес колагына нидер пышылдаганын күрдем. Аны башкалар да ишеттеләр һәм шундук борылып шелтәле караш ташладылар. Кайсыдыр ачу белән тамак кырып куйды. Моны Фирдәвес тә абайлап алды һәм, кинәт битләре кызарып, башын түбән иде.

* * *

Ашханәгә барып кергәч, кинәт аптырап калдым. Бүтән көннәрне беркем дә башкалар җыелып беткәнне көтеп тормый, керү белән ашарга утыра торган иде. Бүген ни булгандыр, бар халык инде җыелып беткән, табын әзерләнгән булса да, кемнедер көткән сыман, әле берсе дә ашарга керешмәгән иде.

Чынлап та ник алай, кем хөрмәтенә икән бу? Ашханәдә бар да үзебезнең халык. Арада берләнбер чит кеше Әхәт кенә. Хәер, кыска гына вакыт эчендә ул инде бөтен команда белән үз кеше кебек аралашып, бергә эшләгән кешедәй үзләшеп өлгергән. Фирдәвеснең кияү егете булганга, аңа беркем дә чит кеше итеп карамый иде.

Зур өстәл уртасында, нәкъ минем урындык турында, пыяла ваза белән чәчәкләр бәйләме һәм ике шешә шампанское куелган иде. Үз урыныма барып утыруга барысы да миңа карап елмайдылар. Хәтта комбуз тәрәзәсеннән карап торган Гөлчирә дә, мине тәбрик иткәндәй, кыюсыз гына елмаеп ым какты. Тик шунда гына мин кинәт бу тантананың сәбәбен аңлап алдым һәм моңарчы шуны абайламый торуым өчен хәтта бераз уңайсызланып куйдым.

Безнең пароходта команда члennaрының туган көннәрен бергәләп бәйрәм итү йоласы бар. Һи, бүген минем туган көнем лабаса, ул хакта бөтенләй онытып җибәргәнмен.

Барысы да тантаналы-җитди кыяфәт белән тынып калдылар. Ислам Идрисович утырган җиреннән ашыкмый гына бөтен табынны күздән кичерде дә, миннән битәр башкаларга сөйләгәндәй:

— Дуслар,— диде,— безнең белән бергә эшләүче иптәшебез Рөстәм Бакировка бүген нәкъ егерме яшь тулды. Барыбыз исеменнән Рөстәмне туган көне белән тәбрикләргә рөхсәт итегез...

Ислам Идрисович сүзеннән тукталып калды һәм, кәефе кырылгандай, җәенке кашларын җыерып бер мәл уйланып торды. Мин кинәт сискәнеп куйдым, капитан теге вакыйганы тагын искә алып бөтен команда алдында тиргәп ташламагае дип шомга төштем. Әмма юкка борчылганмын икән. Ислам Идрисович шундук ачылып китте, миңа эшемдә һәм укуда уңышлар теләп кулымны кысты.

Барысы да җиңелчә кул чабып алдылар, шау-гөр килеп мине тәбрикләргә, минем белән стаканнарын чәкештерергә тотындылар. Гөлчирә тәлинкәләргә салып әсәтер шулпасы бирде. Аны ашап бетергәч, минем алдыма табада тәмле ис бөркеп торган гаять зур бәлеш китереп куйды. Бәлешнең капкачына минем исемем һәм туган елым язылган иде.

— Менә сиңа пычак, менә сиңа кашык,— диде Гөлчирә.— Капкачын үзең ач, кунакларыңны үзең сыйла...

Башка вакытта бүтәннәрнең туган көненә Гөлчирә торт ясый торган иде. Бүген исә — моңарчы безнең пароходта әле бер дә булмаган хәл — искиткеч бәлеш пешергән. Аны күрүгә исем-акылым китте, башкалар да хәйран калдылар. Кайберләре мине тәбрикләгәндә әллә ниләр ишарәләп шаяртырга тотындылар:

— Аңлашыла, менә кайчан сер ачыла...

— Тикмәгә генә түгелдер, моның берәр сере бардыр...

Бу шаяртулардан Гөлчирә, теше сызлаган кешедәй, чыраен сытып куйды. Шул чак ашханәгә беренче штурман Сәмигуллин килеп кергәч, аның йөзе тагын да караңгыланды һәм ул, бүтән беркемгә дә карамыйча, өстәлдәге буш тәлинкәләрне подноска җыеп, камбузга чыгып китте.

Фирдәвеснең кияү егете беренче штурман белән таныш икән. Әхәт аны шатланып каршылады һәм кысыла төшеп, аны үзе белән янәшә утыртты, бәлеш салынган тәлинкәне алдына якынрак китереп куйды. Аннары ул шампанское да салып бирмәкче булган иде, әмма шешә буш булгач, як-ягына каранып алды да:

— Минем каютада бик шәп коньягым бар, тиз генә алып килимме? — диде.

— Юк, кирәкми,— диде капитан, кырт кисеп.— Без пароходта барыбыз да эш кешеләре, безгә ярамый. Ашадык, сыйландык, шул җиткән... Сез кунак кеше, безгә карамагыз... Телисез икән, әнә югарыда ресторан ачык, шунда иркенләп утыра аласыз.

Ислам Идрисович аш-су өчен рәхмәт әйтеп, миңа тагын бер мәртәбә бәхет-уңышлар теләп, ашханәдән чыгып киткәч, Әхәт бик гаҗәпләнгән кыяфәт белән күзләрен челт-челт йомгалап Сәмигуллинга карады:

— Һи, сезнең монда пионерларны өйрәткәннән ким түгел икән,— диде.— Анысы ярамый, монысы ярамый. Туган көнне бәйрәм итү түгел, көлке итү ич бу.

— Дөрес, дөрес,— диде Сәмигуллин, аны хуплап.— Безнең карт уйлап чыгарган мәзәк бу, шулай итеп бердәм коллектив тәрбияли, пароходны яраттыра, янәсе.

— Кызык, бик кызык, шундый арысланнарны бакча балалары кебек тәрбиялиләр икән...— Әхәт сүзеннән туктап Николай белән миңа күз кысып куйды.— Болай гына булмый бит... Монда ярамаса, әйдәгез, ми-

нем каютага. Минә дигән коньяк бар, закускага лимон, шоколад бар, бераз сөйләшеп утырырбыз.

Николай, сәгатенә карап, эшкә ашыгуын белдерде. Беркөн ресторанда булган теге күңелсез вакыйганы хәтерләп, миңа да бик уңайсыз булып китте.

— Гафу итегез, мөмкин түгел,— дидем.— Сезгә дә житкән бугай, юкса...

Кунакны уңайсыз хәлгә куймас өчен тел очындагы сүземне әйтеп бетермичә, шунда тукталган идем.

— Я, я, юкса ни була? — дип, Әхәт үзе кызышып китте.

Минем өчен аңар Николай җавап бирде:

— Юкса тагын Горький ресторанындагы кебек күңелсез хәлгә эләгүегез бар. Ул чакны сезнең аркада безнең авыз пешкән иде.

Әхәт безне хәзер генә таныды бугай, ул күз алдында айнып китте һәм әле Николайга, әле миңа бик гажәпләнеп карады. Әмма телдән аны-моны сиздермичә, шундук сүзне башкага борып җибәрде.

* * *

Төнге вахтага без, гадәттәгечә, нәкъ сәгать уникедә бастык. Рубкага менгәч тә башта бик караңгы тоелган иде. Әмма тиздән, күз ияләшкәч, төн карасы бераз сыегая төшкән кебек булды; сул яктан болыт күләгәседәй булып яр күренә, еракта маяк утлары җемелди башлады. Минемчә, бу — Кучмә атау борынына куелган маяк уты. Аны сул якта калдыру өчен мин аз-азлап штурвалны уңгарак бора башлыйм.

Рубканың ачык тәрәзәсеннән сүзсез генә алга карап барган Ислам Идрисович мине хуплагандай:

— Дөрес эшлисең, уңгарак тот! — дип әйтеп куя.

Ислам Идрисович моны житди-коры тавыш белән әйтсә дә, мин дөрес боруыма куанып, штурвал янында үземне ышанычлырак тотам. Бераз сүзсез баргач, мин үзалдыма сөйләнгәндәй әйтеп куям:

— Кучмә атау... Ничектер сәер исем, аны ник шулай атаганнар икән?..

— Нәрсәсе сәер аның,— ди Ислам Идрисович.— Бер урында тормыйча күчеп йөргәнгә шулай аталган. Моннан ун-унике ел элек ул елганың уртасында тора иде, хәзер әнә сул як ярга тоташып бара инде.

Кәефе әйбәт вакытта Ислам Идрисович бу атау белән бәйле булган берәр вакыйганы яки риваятьне дә сөйләп биргән булыр иде. Әмма бүген ул сүзсез генә бара. Димәк, кәефе шәп түгел.

Һавада әллә нинди авыр ис бар. Көньяк кызуы, чүл сулышы үзен нык сиздерә. Инде төн уртасы булуга карамастан, хәтта су өстендә дә әле һаман бөркү. Башка әллә нинди уйлар килә башлый.

Тормышны һич аңламассың. Җырлата да жылата дигәндәй... Укырга кереп өлгермәдем, аннан чак колак какмый калдым. Аннары Гөлчирә белән бозылышкач, кая барып сугылырга белми йөрдем, ансыз дөньяда яшь алмам кебек иде. Әмма түзәргә калган баш, авыр булса да, түзә, акрынлап барысына да күнегә икән. Шулай да йокысыз үткән төннәр, авыр кичерешләр, төзәлгән яра кебек, йөрәктә эз калдыралар.

Капитан гадәтенчә тыныч, әмма кырыс тавыш белән:

— Житте, артык борылдың... Бераз сулгарак ал, әнә теге ике утка таба тот! — дип команда бирде.

Кинәт сискәнеп киттем. Дөрестән дә, онытылып, артыграк борылып киткәнмен. Каушавымны сиздермәс өчен шундук:

— Есть, сулгарак алырга! — дип приказны кабатладым һәм капитан әйткән утларга юнәлеш тоттым.

Тиздән мин тагын уйга чумам. Әллә кайдан гына күз алдыма Фирдәвес килеп баса. Ул да бик сәер. Шундый яшь башы белән инде бер

тапкыр кияүдә булып өлгергән, баласы да бар. Менә тагын кияүгә чыгарга җыена. Белсәң иде, кияү егетен яратамы икән ул?

Күз алдыма корбаннар, һәйкәлләр килә, һәйкәлләр каршына басып, карт адмирал сөйли, Әхәт кеткелдәп көлә...

Кинәт борынга каяндыр көек исе килеп бәрелә. Тугайда көтүчеләр ут яга, шуның исе киләдер дип уйлыйм.

Күп тә үтми, борынны ярып тагын көек исе бәрелә. Бу юлы ул тончыктыргыч ачы һәм авыр. Икебез берьюлы диярлек әйләнә-тирәгә каранып алабыз. Ул да булмый, түбәндә кемдер төнге тынлыкны бозып шомлы тавыш белән:

— По-жар-р... Пожар! — дип бөтен пароходка кычкырып җибәрә.

Шундук машина бүлегеннән дә:

— Сул як топканың форсунка торбасы шартлады, аккан мазутка ут капты,— дип хәбәр иттеләр.— Үз көчебез белән сүндерә башладык, ярдәмгә матрослар төшсен...

Ислам Идрисович бөтен командага тревога игълан итте. Миңа пароходны агымга каршы борырга, боцман белән матросларга, ут сүндергечләр белән коралланып, ашыгыч рәвештә кочегаркага төшәргә кушты.

Күз алдыма кинәт коточкыч күренеш килеп басты. Пароход нәкъ шырпы тулы кап кебек бит: әгәр ут тарала калса — тоташтан буяу һәм лак белән капланган коп-коры корылма йөзләгән халкы белән күз ачып йомганчы дөрләп янып бетәчәк. Кече телем аңкавымаябышты, маңгаемнан салкын тир бәреп чыкты.

Ислам Идрисович башка пароходларны ярдәмгә чакырып гудок кычкырта башлады, шлангларны сүтеп сузарга, насосларны ходка җибәрергә команда бирде. Аның һәр хәрәкәте ышанычлы, боерыклары төгәл һәм катгый иде.

Түбәндә янгын көчәя бугай, тончыктыргыч төтен әллә кайлардан бәреп чыга, сөйләшә торган рупор торбасы буенча менеп рубкага тула, күзгә керә башлады. Ислам Идрисович рупордан механикка:

— Башка бүлекләрне саклагыз, ут тарала күрмәсен. Кочегаркага ут сүндергечләрдән сиптерегез дә бөтен ишекләрне, иллюминаторларны ябып куегыз! — диде һәм, якорь салгач, машинаны да туктатырга приказ бирде.

Команда членнары инде постка басканнар, янгынны сүндерделәр бугай, урта палубадан да, машина бүлегеннән дә эшнең барышы турында хәбәр итә башладылар. Хәзер иң мөһиме — янгынны кочегаркадан чыгармау, бөтен көч шуңар тупланган иде.

Пароход якорьга туктагач, миңа да рубкада эш калмады, Ислам Идрисович миңа түбәнгә боцман карамагына төшәргә кушты.

* * *

Рубкадан төшкәч, бөтен пароходны баскан паниканы күреп шаккаттым. Янгын турында хәбәр инде халыкка таралып өлгергән. Һәркайда күз ачкысыз төтен, юньләп күреп тә булмый. Пассажирлар уянып беткәннәр һәм, каюталарыннан чыгып, коридорларда кайнашалар, берберсенә шом салып кабаланалар. Күбесе рәтләп киенмәгән дә, кичтән ничек яткан булса, шулай атылып чыккан. Кулларында чемоданнары, кайберләре бала-чагасын җитәкләгән. Бүредән өреккән сарык көтүе кебек, әле анда, әле монда ташланалар. Бу коточкыч матавыкны тыярлык берниндн көч тә юктыр шикелле иде.

Шул мәлне репродукторлардан бөтен пароходка Ислам Идрисовичның буйсындыручан тыныч калын тавышы ишетелде:

— Тыңлагыз, тыңлагыз, пароход капитаны сөйли. Пассажир иптәшләр, тынычланыгыз... Иң мөһиме — паникага бирелмәү. Дөрес, куркы-

ныч бар иде, хәзер ул кимеде, янгын пар казаны бүлегеннән бүтән җиргә таралмады, төтене генә күтәрелә. Безгә ярдәмгә судно килә. Хәзер сезне шунда утыртып озатабыз... Тыныч кына әзерләнегез, җыеныгыз...

Кешеләр бераз тынычландылар һәм, үз урыннарына, каюталарына таралышып, ашыга-ашыга киенергә, әйберләрен чемоданнарына тутырырга тотындылар. Куркудан коты очкан халык дулкыны, чүлгә сеңеп хәлсезләнгән ташкын кебек, бер мәлгә басылды.

Түбәндә пар катнаш куе төтен эчендә безнең егетләр һәм пассажирларның яшьрәкләре, бер-берсен ашыктыра-ашыктыра, бар көчләренә ут сүндерәләр; алар арасында янган-көйгән кешеләр дә бар, каяндыр ыңгырашкан тавышы ишетелә. Николайның да кителе берничә урыннан янган, чәче яртылай өтелгән; аның утын насостан сиптереп сүндергәннәр булса кирәк, ул, суга манчып алгандай, баштанаяк юеш иде.

Безгә ярдәмгә ниндидер судно килеп тә житте. Мина сул як борттан шуны кабул итәргә команда бирделәр.

Их, килүен килгән дә, әмма бик бәләкәй судно — су трамвае гына икән. Безнең пассажирларның чиреген дә алырлык түгел. Бөтен халык берьюлы ташланса, янтаеп харап булачак. Моны трамвай капитаны шундук сизеп алды һәм килеп туктаганчы ук рупордан:

— Барысы да берьюлы ташланмасыннармы? Халыкны туктата алырсызмы? — дип кычкырып сорады.

Безнең пароход мостигыннан Ислам Идрисович аңар:

— Борчылма, әйдә сул яктан килеп тукта,— дип җавап кайтарды.— Алгы пролет аша гына үзебез санап утыртырбыз, урын бетү белән, шундук туктатырбыз.

Трамвай якыная башлагач, яңадан паника кузгалды. Болай да күзебашы тонган кешеләр, барысына да урын житмәсен ишеткәч, тагын да катырак кабаланып алгы палубага ташландылар. Чамасыз ыгы-зыгы эчендә берсе абынып егылды, кемнеңдер чемоданы ачылып китте, кайсыдыр чәрелдек тавыш белән кычкырып җибәрде. Әмма моны ишетүче дә, күрүче дә, егылган кешегә ярдәм итүче дә юк. Һәркемнең үз хәле хәл, һәркем, күршесен узып, трамвайга элегрәк эләгергә тырыша иде. Кайнаган халык арасында Фирдәвеснең кияү егете Әхәт тә күренеп китте һәм шундук күздән дә югалды.

Бөтен шау-шуны басып репродукторлардан тагын Ислам Идрисович тавышы яңгырап үтте:

— Пароход командасы!.. Мине тыңлагыз...— диде ул.— Алгы пролет аша иң элек бала-чагалы хатын-кызларны, өлкән яшьтәгеләрне утыртыгыз...

Трамвай килеп туктауга, Николай белән мин сул як пролет ишеге янына килеп бастык һәм балалы хатыннарга, картларга, егылмасыннар өчен икебез ике яктан беләкләреннән тотып, трамвайга күчеп утырырга ярдәм итә башладык. Безнең матрослардан берсе кайнаган халык арасыннан Фирдәвес белән Маратны үткәрде:

— Менә әйберләре, капитан икесен дә утыртып җибәрергә кушты,— диде.

— Юк, мин үзем китә алмыйм,— диде Фирдәвес.— Берәрсенә ышанып Маратны гына озатам. Күрмисезмени, янган-көйгән кешеләр бар, аларга ашыгыч ярдәм күрсәтергә кирәк бит...

Аның сүзен раслаган кебек, боцман Николай яртылай өтелгән чәченә кулын тидереп алды, үзеннән-үзе сораган сыман:

— Анысы шулай да, тик мондый матавыкта бу малайны кемгә ышанып җибәрергә соң? — дип әйтеп куйды.

Шул арада әллә кайдан гына бик эшлекле кыяфәт белән Фирдәвеснең кияү егете Әхәт килеп чыкты һәм беркемнән дә рөхсәт-фәлән сорап тормастан:

— Дөрес әйтә, баланы үзен генә җибәрергә ярамый, әйдә минем белән,— дип Маратны кулыннан тотып алды.
Марат пароходтан китәргә теләмичә:
— Синең белән бармыйм мин, җибәр мине,— дип бар көченә каршы башлады һәм, Әхәт кулыннан ычкынып, ялгыш ике судно арасына суга... егылып төште.
Үз күзенә ышанмагандай һәркем, нишләргә белмичә, бер мәлгә аптырап калды. Хатын-кызлардан кемдер чәрелдәп кычкырып җибәрде. Түбәндә ярым караңгыда су астыннан бөкедәй калкып Марат чыкты, нидер кычкырды да, тончыгып, тагын төпкә китте.
Бер генә секунд та кичегергә ярамый, аның кабат калыкмыйча, батып үлүе ихтимал. Мин шундук малай баткан турыга суга ташландым.
Суда дөм-караңгы, берни күрерлек түгел. Кая таба эзләп китәргә дә белгән юк. Төптә озак торып булмый бит, мин алай-болай каранган арада, сулыш кысыла башлады. Түзә алмыйча өскә күтәрелергә мәҗбүр булдым. Тиз генә күкрәгем тутырып тын алдым да тагын суга чумдым...
Чү, якында гына нидер бүлт-бүлт итә кебек. Караңгыда берни күрмәсәм дә, әле бер, әле икенче якка сузылып әйләнә-тирәмне кармалый башладым. Кулыма нииндидер чүпрәк килеп эләкте. Әһә, үзе, Маратның күлмәк итәгеннән эләктереп алганмын икән.
Ниһаять, котылдык дип сөенеп тиз генә өскә күтәрелсәм, су безне түбәнгә таба агызып киткән, пароход инде шактый еракта калган иде. Өскә калыккач, бераз тын алган арада, тагын хәтсез җир китеп өлгердек. Рәтләп кычкырып та булмый. Берничә тапкыр тавыш биреп карасам да, мине ишетүче булмады бугай. Ара ерагайган саен, мае беткән лампа кебек, пароход утлары аз-азлап тоныклана барды һәм тиздән бөтенләй юк булды.

* * *

Болай булгач, пароходтан безне күрмәячәкләр, димәк, аннан ярдәм килүгә өмет юк. Бары тик үз көчемә яки очраклы ярдәмгә генә ышанырга кала.
Бәләкәй малайга күп кирәкмени, мин су астыннан табып алганда Марат инде тончыккан һәм һушын югалтып өлгергән иде. Өскә чыгып бераз тын алгач, ул буылып-буылып коса башлады. Күкрәгемә яткырып аңа судан арынырга ярдәм иттем. Тиздән ул аңына килде һәм куркудан кычкырып җибәрде, калтыраган куллары белән бар көченә миңа ябышты.
— Марат, курыкма... Диңгезче беркайчан еламый ул. Әнә шулай ныклап миңа тотын,— дип, мин аны юатырга тырыштым.— Әйдә бергә йөзәбез. Синең белән без батыр диңгезчеләр бит... Иделне генә түгел, диңгезне дә йөзеп чыгарбыз...
Сизәм, юеш кием мине төпкә тарта, йөзәргә комачаулый. Бик кыен булса да, буш кулым белән шнурларын өзеп, ботинкаларны, аннары чалбар белән күлмәкне салып ташладым, җиңеләеп калдым. Марат та бераз тынычланды.
Хәзергә әле бер яктан да яр-фәлән күренми. Кайсы яр якынрак икәнен һич чамалап булмый, димәк, кая таба йөзәсен дә белер хәл юк. Башка чара калмагач, мин батмас өчен агым уңаена акрын гына йөзә бирдем. Ярый әле, безнең бәхеткә, су җылы, югыйсә, көзән җыерып, бик тиз төпкә китәр идек.
Белеп булмый, миңа, бәлки, су өстендә озак булырга туры килер әле. Хәзер безнең хәлдә иң мөһиме — көчне саклау. Кайсы яр якынрак икәнен ачыклап, шунда йөзәргә кирәк. Әмма төн караңгы, әйләнә-тирәгә күзләрем авыртканчы текәп карасам да, алкынып аккан караңгы судан башка берни дә күренми.

Вакыт, уч иткән кебек, бик озак үтә. Тиздән мин арый башлавымны сиздем һәм сай урын юк микән дип, әледән-әле аягымны тирәнгәрәк сузгаларга керештем.

Шулай агым кочагында бара торгач, кинәт аягым төпкә тигәнне сиздем һәм шатлыгымнан җиңел сулап куйдым. Иртәрәк сөенгәнмен, яр буе дигәнем, су төбендә бер очраклы калкулык кына булып чыкты. Куәтле агым туктарга да бирми, һаман алга җилтерәтә. Менә аяк астында ком юк булды, алкын су безне тагын агызып алып китте.

Тиздән түбән яктан, каяндыр борылыш артыннан, якты утлары белән балкып, бер судно атылып килеп чыкты. Тиз килүеннән мин аның канатлы судно — «Ракета» яки «Метеор» икәнен шәйләп алдым. Ул, атылган уктай, безне читләп ерактан бик тиз үтеп китте. Шуның белән күңелдәге өмет йолдызы да сүнде, куәтле агым кочагында без тагын үзебез генә калдык.

Минем юлдашым тәмам изрәде, кыенлык белән генә миңа ябышып бара; ул хәзер инде кычкырып елый да алмый, авызына су кергән чакта тончыгып ара-тирә ыңгырашып кына куя иде. Үзем дә аз-азлап һаман хәлсезләнә барам, күз алларым томалануын сизәм...

Байтак вакыт үткәч, ерактан, төн чаршавын ертып, тагын ниндидер утлар күренде. Болары үрдән, безнең «Бурлак» калган яктан. Башта алар бик тоныкы кына, күренер-күренмәс кенә җемелдиләр, вакыт-вакыт бөтенләй сүнгәндәй югалып торалар иде. Бераздан, ара якыная төшкәч, ачыграк елтырый башладылар. Әһә, ачык күрәм: бер як бортында — яшел, икенче якта — кызыл, мачтасы очында ак ут балкый, димәк, пассажир судносы бу. Үзе нәрсәдер эзләгәндәй әле бер, әле икенче яктан прожектор белән су өстен яктырта-яктырта килә иде.

Күңелемдә тагын өмет уты кабынды, хәлсезләнгән беләкләремә көч өстәлгәндәй булды. Үзем нәни малай кебек:

— Марат, бирешмибез, судно килә, хәзер туктатабыз аны,— дип кычкырып җибәрдем.

Хәзер инде ачык күрәм, бу зур судно түгел, су трамвае иде. Ул якынайганнан-якыная бара һәм туп-туры безнең өскә килә иде. Прожектор нурлары каядыр читкә юнәлгән. Бер яктан икенче якка борган арада ул бер мизгел генә безне дә яктыртып үтте. Әмма берсе дә күрмәде бугай, тагын бездән бөтенләй читкә яктырта башлады. Ара тагын якыная төшкәч, мин башымны бераз күтәреп бар көчемә:

— Тук-та-гыз-з!.. Безнең өскә киләсез бит...— дип кычкырырга тотындым.

Шундук ачы тавыш белән хатын-кыз кычкырганы ишетелде һәм күзне камаштырып прожектор безне яктыртты. Шул арада машинаны да туктаттылар булса кирәк, трамвай безгә яны белән якыная төште. Палубадан трап төшерделәр. Кемдер минем кулдан алып Маратны өскә сузды. Аннары мине эләктереп алдылар.

Тәмам алҗыганмын икән. Су өстендә батмыйча ничек тора алганмындыр. Палубага күтәрелгәч, коелдым да төштем, гәүдәмне тотарлык та хәлем юк. Кулларым, аякларым берсе дә үземнеке түгел. Меңләгән кырмыскалар йөргәндәй, бөтен тәнем чымырдый. Күңел болгана, су коса башлыйм... Минем өчен борчылмагыз, Маратны карагыз... Маратны, дип әйтәсем килә. Әмма телем тибрәтә алмыйм.

Тирәмдә чуалган кешеләр арасында күземә Фирдәвес чалынгандай булды. Мин аңымны җуям, саташам бугай, югыйсә, монда нинди Фирдәвес булсын инде. Аннары мине кемнәрдер эчемне авырттырып күтәрәләр, каядыр өстериләр. Ник алай итәләр икән алар? Минем кыймылдыйсым да килми бит. Юк, берни дә юк, боларны да мин төштә генә күрәм бугай...

* * *

Күпме йоклаганмындыр, белмим. Уянгач та әле, кайда ятуымны аңлый алмый аптырап яттым. Биек түшәмле, ак стеналы кечерәк кенә бүлмә. Минем аяк очындагы ачык тәрәзәдән кош-корт чырылдавы ишетелә, каяндыр күңел болгаткыч дару исе килә. Бөтен тәнемне хәлсезлек баскан.

Пароходтагы пожарны, су өстендә калуымны хәтерләү белән йөрәгем жу-у итеп китте. Сулгарак борылып карасам, тумбочка янында ак халат кигән бер ханым ниндидер кәгазьләр карап утыра. Минә ул мина таба борылды, мин аның Фирдәвес икәнен таныдым, күзләремә ышанмыйча, ирексездән:

— Фирдәвес, дөрес күрәмме? Өнме бу, төшме? — дидем.

— Борчылмагыз, тыныч кына ятыгыз,— диде ул пышылдап кына.

— Марат кайда, аның хәле ничек, ул исәнме?

— Исән, исән, хәзер әйбәт инде. Башта бик курыккан идем. Эчено су тулып тәмам тончыккан иде, көч-хәл белән һушына китердек. Хәзер үгте инде, йоклый.

Марат шушы палатада каршы як стена буендагы караватта ята икән. Трусиктан гына, аяк-кулларын як-якка ташлаган. Йөзе агарып калган. Фирдәвес, минем уйларымны сизгәндәй:

— Зыян юк, савыгыр, тазарыр. Иң мөһиме — сезнең исән калуыгыз,— диде.— Эзләп-эзләп тә таба алмагач, мин сезне исән-сау күрүдән өмет өзгән идем. Рәхмәт инде сиңа, Рөстәм, бик зур рәхмәт.

— Фирдәвес, пароход ни хәлдә? Утны сүндерделәрме?

— Сүндерделәр. Кешеләр башта бик курыккан иде, аннары тынычландылар. Ярдәмгә өч судно килде.

Палатага ак халатлы, чал чәчле врач килеп керде. Ул күптәнге танышлар кебек безнең белән ягымлы гына исәнләшкәннән соң, башта мине, аннары әле генә йокыдан уянган Маратны бик җентекләп карады, тик шуннан соң гына:

— Барысы да нормада, молодцы! — дип мыек астыннан елмаеп куйды.— Дару-мазар кирәкми. Бүген яхшылап ашасыннар, күп итеп йокласыннар. Көч-хәл җыйгач, иртәгә иртән кайтып китәрсез.

Ул безне шатландырып чыгып киткәч, Марат әнисе алдына менеп утырды, аннан күчеп минем муенга ябышты:

— Әни, төнлә без менә шулай йөздек,— дип сөйләнә-сөйләнә шаярырга тотынды.

Без уйнаганны читтән елмаеп карап торган Фирдәвеснең күзләренә мөлдерәмә яшь тулды:

— Әле һаман ышанып житә алмыйм,— диде ул, безнең янга караватт кырыена утырып.— Исемә төшсә, хәзер дә котым оча.

— Әни, без бер дә батмадык, су өстендә йөздек тә йөздек.

— Рөстәм, абыеңа рәхмәт әйт. Ул сине үлемнән коткарып калды. Юкса, безнең эшләр харап иде.

Марат балаларча беркатлылык белән:

— Әни, мин бер дә курыкмадым, Рөстәм абыйга менә болай тотындым... Я, син дә тотынып кара әле,— дип сөйләнә-сөйләнә Фирдәвеснең кулын минем иңбашыма куйды.— Рөстәм абый көчле ул, бик көчле, ныклап тотынсаң, син дә егылмас идең...

Фирдәвес ихтыярсыз көлеп жибәрде:

— Рөстәм абыеңа дә-ү итеп рәхмәт әйт, безнең өчен ул бик кадерле кеше...

Бу минутта мин ничектер Фирдәвескә туры карарга кыймыйча, каушап калдым. Әгәр карасам, ул, аңына килер дә, шундук кулын

тартып алыр кебек иде. Шунда мин үзем дә дулкынланып киттем һәм аны-моны уйлап тормастан:

— Сез үзегез дә миңа дөньяда иң кадерле кешеләр, минем сездән якын беркемем дә юк,— дип, Маратны күкрәгемә кыстым...

* * *

Безнең «Бурлак»ны янгыннан соң буксир белән тарттырып затонга кертеп куйганнар икән.

Көндезге аштан соң ял итеп алгач, безнең хәлне белергә бер-бер артлы команда членнары килә башлады, кучтәнәч һәм чәчәкләр белән тумбочканы, тәрәзә төбен тутырдылар, пароход хәлләрен сөйләп утырдылар. Иртәгә больницадан чыгасын белгәч, Марат белән миңа киемнәр китерделәр.

Кич житәрәк, иң азактан, бик ыспайланып киенгән һәм ислемайлар сөртенгән Әхәт тә килде. Клеш балаклы кара чалбары пөхтә итеп үтүкләнгән, ак кителенең жиз төймәләре чистартылган. Аның бөтен кыяфәтеннән бу очрашуга зур тырышлык белән әзерләнгәнлеге сизелә иде.

Ярым ачык ишектән Әхәт килеп кергәндә, без өчәүләшеп бик күңелле шаярып-көлеп утыра идек. Безне мондый хәлдә туры китерүдән ул бераз уңайсызланып калды булса кирәк, бер миңа, бер Фирдәвескә карап алды да рәсми тонда коры гына исәнләште:

— Алай икән...— дип чыраен сытып куйды.— Мин борчылып килгән идем, сез монда әйбәт кенә яшисез сыман...

— Әйе, зарланырлык түгел... Болай булса, иртәгә чыгарга...

Фирдәвес сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, аны канцеляриягә чакыртып алдылар. Ул чыгып киткәч, Марат йөгереп килеп минем алдыма менеп утырды. Палатада тынлык урнашты. Әхәт, хәзер генә кинәт нидер шәйләп алгандай, шаккатып безгә маңгай астыннан бер мәл сүзсез карап торды һәм чырае тагын да караңгылана төште:

— Кара син аны, жаен тапкансың икән...— диде ул, Маратка күрсәтеп.— Башта малаең үз ягына авыштырырга, аннары Фирдәвеснең күңеленә ачкыч табарга уйлыйсыңмыни?..

Кинәт ачуым кабарып китте:

— Сез культурный кешегә охшаган бит... Әдәплерәк сөйләшә белмисезмени?

— Дөрес әйтәсез, дорфа булырга ярамый, гафу итегез...— Әхәт бераз дәшмичә торганнан соң, сүзләрен йота-йота тагын кызып сөйләп китте.— Мин моны пароходта да сизгән идем, монда да шуны күрәм: нигә сез Фирдәвес тирәсендә чуаласыз, шаяру өчен генә кешенең башын әйләндерәсез. Алай эшләп сез аның жайланып барган тормышын бозасыз ич. Алай ярамый бит.

— Ничек инде мин аның тормышын бозам?

— Менә шулай,— Әхәт кипшенгән иреннәрен теле белән ялап алды һәм каядыр почмакка караган хәлдә сүзен дәвам итте: — Турысын әйтми булдыра алмыйм, Фирдәвес белән мин... ягъни без өйләнешергә йөри идек. Әмма соңгы көннәрдә ул миңа никтер... күрәм, сәбәбе сез икәнсез... Борчымагыз аны, сез аңар тиң түгел. Үзеңеке булмаса да, баласы да бар.

— Ничек үзеңеке түгел?

— Анысы кечкенә мәсьәлә... Бәла шунда, сез гади койрыкчы гына бит әле, ягъни каккан казыгыгыз да юк. Димәк, аларга рәтле тормыш күрсәтә алмаячаксыз. Шулай булгач, кеше юлына киртә салмагыз.

Мин үзем болай тыныч һәм юаш кеше, юкка-барга кыза торган гадәтем юк. Гомердә булмаган хәл, бу юлы кинәт жен ачуларым чыкты, аңа ташланудан үземне көч-хәл белән генә тыеп калдым.

— Сез бу хакта минем белән түгел, Фирдәвеснең үзе белән сөйләшегез. Ә хәзергә, сезнең миңа кирәгегез юк,— дидем, шыпырт тавыштан янауга күчеп әйттем.

Ярый әле, Фирдәвес килеп керде. Юкса, җәнҗал чыкмый калмас иде. Бу хәлне ул ишектән кергә шәйләп алды булса кирәк, безгә сүз әйтергә ирек бирмәде:

— Кирәкми, ярамый... Әхәт, әйдә коридорга чыгыйк, шунда аңлашырбыз,— дип, Әхәтне палатадан алып чыгып китте.

* * *

Алар анда ни сөйләшкәннәрдер, белмим. Әмма Фирдәвес бик озак кермәде. Без аны көтә-көтә ялыгып беттек. Марат аны эзләп коридорга чыкмакчы булган иде. Минем сүзне тыңлап кына чыкмый калды һәм уйнап яткан җиреннән, ниһаять, йокыга талды.

Миңа кинәт бик күңелсез булып китте. Монда кунарга калмасак, әйбәтрәк буласы икән. Һаман эш белән мәшгуль булып, су өстендә йөреп күнеккәнгәме, кичке эңгер-меңгергә күмелеп барган тын бакчага япаялгызым карап утыру ямансу, күңелдә сагышлы уйлар кузгата иде.

Мин тәрәзәгә төбәлеп, моңаеп утырганда, Фирдәвес килеп керде.

— Рөстәм абыйсы, ник без болай күңелсез утырабыз әле? — дип ягымлы елмаеп иңемнән кочаклады.

Алар анда ныклап сөйләшкән булсалар кирәк, Фирдәвеснең әле дә тынычланмаганлыгы сизелеп тора. Ул, йөгереп килгән кеше кебек, ешеш сулый һәм сизелер-сизелмәс кенә калтырана иде. Мин кәефем бозылуын яшерә алмыйча:

— Я, хушлаштыгызмы?.. Кияү егетегездән аерылуы кыен булды мәллә, бик озак озаттыгыз? — дидем.

Фирдәвес нидер уңайсызланып калгандай авыр сулап куйды, әмма үзе миңа кыю карап:

— Ул бүтән минем кияү егетем түгел,— диде.— Мин әле генә аның белән араны өзеп кердем. Ул хакта син дә миңа бүтән әйтмәссең дип ышанам.

Күңелсез уйларым кул белән алып ташлагандай юкка чыкты. Шатлыгымнан, нәни бала кебек, кычкырып җибәрә яздым.

— Бетте, бәгырькәем, башы-азагы шул булсын... Ул хакта бүтән берни дә әйттем юк,— дип Фирдәвесне кочаклап алдым да күкрәгемә кыстым.

Төннең үткәнен сизми дә калдык. Әле генә шәфәкъ баткан шикелле иде. Бактың исә, инде дөньяга яктылык сирпеп яңа көн туып килә.

Фирдәвес әлерәк кенә изрәп йокыга китте. Коңгырт чәчләре ак мендәр өстенә сибелгән. Алсу иреннәрендә сүнмичә онытылып калган елмаю бар иде.

Минем күз карашымны сизгәндәй, Фирдәвес елмаеп уянды, күрше караватка үрелеп, саклык белән генә Маратның өстенә ак җәймә япты.

— Фирдәвес, әйтче миңа,— дидем мин, аны башыннан сыйпап,— бу кем баласы, каян алдың син аны?

Маратны уятмас өчен Фирдәвес минем колакка пышылдап кына әйтте:

— Марат минем бертуган апамның улы иде. Алар — ирле-хатынлы ике геолог — экспедициягә киткән җирләреннән әйләнеп кайтмадылар, тайгада һәлак булдылар. Әтисез, әнисез калган Маратны мин уллыкка алдым, үз улым иттем. Хәзер ул безнең уртак улыбыз...

1971

## Равил Фәйзуллин

●

Яхшылыкның, диләр, әҗере күп.
Ә шулай да —
кайгыларга кушылып елый алмыйм.
«Бу да җәлли», диеп рәнҗер күк.

Үземне мин куймыйм яхшыга.
Ә шулай да —
кеше шатлыгына, сөенеченә
түзә алмыйм — чәчрәп яшь чыга.

●

Яздан аерып булмый Тукайны!
Язда килгән, язда ул янган.
Язы, киләчәге барлар ничек китсен,
ничек югалалсын дөньядан.

Язны җуймый кара елларда да,
халыкның ул гүзәл гамьнәрен,
хыялларын, чорлар аша, безгә,
бүгенгегә китереп бәйләде.

Уйлап баксаң, кем очына чыккан
бар кичкәнен аның, күргәнен...
Ул түгелме илгә, кешеләргә
игелекнең иң чын үрнәге?

Бу тарихта мәшһүрләрне куйсаң
ул яшәгән хәлгә, урынга,—
байтагының шаулы даны түгел,
чыкмас иде, бәлки, тыны да!

Яшәрен һәм үлемсезлеген
дәлилләүгә мохтаҗмы халык?
Шикләнүче булса, кара, тикшер,
бер бәгърен — Тукаен алып!

Апрель.
Кемнәр көтми ышанулар, гөлләр,
яшәрүләр биргән бу айны?
Яздан, гадиллектән, киләчәктән
мөмкин түгел аеру Тукайны!
Мөмкин түгел аеру Тукайны!

●



Бодай кыры уртасында
Бари ага яланбаш...
Жиргә иелә белгән баш.
Илгә иелә белгән баш.

Зәйдә ташбаш куган баш.
Иртә билен буган баш.
Дошманга ут койган баш.
Утта күзен җуйган баш,—
тик үлмәскә туган баш!
Җиңелмәскә туган баш!

Мәрхәмәтле бул, Кояш!
Мәрхәмәтле бул, Кояш!
Бари ага кырда йөри,
башын чөйгән, яланбаш...

●

Күк тулы — сер, җир тулы — сер,
Һәр үлән — сер, һәр таш — сер,
чылтырап аккан чишмәләр — сер,
йөзеңә баккан туташ — сер.
Җир-Кояш — сер, гыйшкый Яз — сер —
Дөнья — тылсым, тоташ сер...

Серле бәйрәм бит бу яшәү!
Киләчәктән һәм Вакыттан
мин — гасабый — көнләшәм.
Бу бәйрәмдә мәңге яшәр
Ай-Кояштан, йолдызлардан
күз алалмый көнләшәм.

Серле бәйрәм бит бу яшәү!
Мин яшермим, син дә көлмә!
Сердән узган күз яше...

●

Төзү, кору, кискен үзгәрүнең
мәгънәләрен эзлим күңелдә.
Борынгы ямь белән килер ямьнең
чагылышы бармы бүгендә?

Һәм Табигать җавап бирә сыман:
уең синең, сагышың, җирсүең
мәгънәле тик саклый алсаң гына
килер буыннарга Җир-суың.

•

Жирдә — аклык, жанда — шатлык!
Беренче кар, беренче кар!
Баш — бүректә, бүрек — күктә!
Беренче кар, беренче кар!
Чана-чана бала-чага —
беренче кар, беренче кар!
...Малай чакны хәтерләткән
Һәр нәрсәдә изгелек бар.
Бүрегемне салып торам,
беренче кар, беренче кар!

•

Янган еллар, янган еллар,
утларда янган еллар...

Корыч канатмыни бу мускуллар!
Бар офыклар чигенә бүгенгә!
...Ә сагынам авыру, хәлсез килеш
очкан чакны синең күгеңдә.

•

Бер оста кыз рәсемен ясады.
Ә кыз көлдә эчтән, масайды.
«Жан өрсәң дә, оста, син ташка,
таш таш инде, тере мин — башка!»

...Акты гомер. Инде оста юк.
Ә таш сын шул — көләч, яшь чырай.
Бөкре карчык шул сын алдында.
Тып-тын. Дәшми. Күздә яшь бугай.

## Болгарда төн

Хәрабәләр түбәнәя.
Биегәя Болгар күге.
Зиярәт кылып йөргәннәр
ни дисәң дә ятим-үги.

Монда вәхшәт эзе тирән,
мыскыллаулар — сүздән түбән.
Суда ухылдап чәйкалә
ярга бәйләнгән көймәм...

# Көз

Җилләр уйный — триумф!
Кышка — алкыш.
Шәрә ботакларда
кызыл балкыш!

Миләшләргә карап
гаҗәпсенмә.
— Чәчәк-ялкынмы? — дип,
син ымсынма!

Хәтерлә: чәчәге
ап-ак иде...
Тик ул чак көз түгел,
яз чак иде!

...Йөзең инде көздә.
Язда — күзең!
Бөреләнеп чәчәк
ату көзен —
хәерлеме, юкмы,
аңла үзең!

Җилләргә ни — шаша!
Кышка — алкыш!
Миләшләрдә ялкын —
Көзге балкыш!..

●

Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда...
Шундый тансык бөек тилерүләр
кануннардан торган дөньяда!

Бәрәкәтсез гомер, аһ, сүтелә!
Вакыт белән дуэль. Ни чара?!
Бу таңнарны күбрәк күргән саен,
күңелне ник моң һәм шом сара?

Янарга да, батарга да риза
эштә, өйдә, идеалларда...
Барыбер килә,
күзләр аша килә олыгаю,
күзләр аша, авыр аларга...

...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Азмыни бу фани дөньяда!

●

Язгы дәрт белән өздерә
ай яктысында тургай.
Кайтып житү шатлыгыннан
айнып беталмый бугай...

Көтмәгән төнге бәхетнең
ләззәте чиксез икән.
Хәтта чык бөртекләренең
жемелдәүләре бүтән!

Һай, яктылык! Тургай жыры
зәңгәр күк катларында!
Канат икәү генәме соң
Үз, туган якларында!

Бу күкләр, бу ялан-кырлар
шулкадәр сагындырган!
Ничек жырламыйсың! Алар
зарыгып көтеп торган...

Илереп тыңлыйм. Менә, дим,—
табигать могжизасы!
Нәни жанның туган жиргә
изге гимны, догасы!

Баш очымда — зәңгәр күк, ай,
йолдызга якын тургай.

●

Гел өр-яңа бу дөньяда
гомер-шәм бер кат яна.
Кабат янмавын искәртеп,
тик язлар кабатлана...
Күзләр яңа, күңел яңа,
йөрәк яңа, жан яңа!
Тик язлар кабатлана!
Тик язлар кабатлана...
Зәңгәр күктә, үзәк өзеп,
торналар канат кага.

## Егерме җидегә җиткәч

Заман бүтән, дисен, күзләр бүтән,
сезнен буын саурак, шатрак!
...Тукай яшен узып барам мәнә,
кылган эшкә баксәң — оятрак.
Яңа белү житми, көя белү...
Ахры, шуна
үзебездән үзебез картрак.

●

«Ни кылам?» дип, башкалардан
ник әле сорап торам!
Син бар чакта мин бит фәкать
зураям һәм яхшырам!

Ник күңел баш бирә әле
кануннар тезгененә?
Хөкемче бер — без тудырган
шул гүзәл мизгел генә!

●

Кыш башында каян килгән,
каян килгән язгы җил бу?
Үткән гомер җилләр аша
эндәшә күк: — Мин бу! Мин бу!

Әй, син, дымсу, ямансу җил!
Язлап кына килер булсаң!
Гомер үтүен тою авыр,—
килмәс идең белер булсаң!

Ләйсәннәргә ымсындырып,
күңелләрне ник кузгаттың?
Инсен күзгә зәңгәрлек, дип,
томырылып күккә бактым,—
анда кар һәм соры болыт...

Әй, син, дымсу, ямансу җил!
Язлап кына килер булсаң!..

●

Һәр тамыр, һәр бөре — һәрбере
бер шауда, бер сүздә: Яз! Яз! Яз!
Чү! Өстә — каенның тузыннан
ишетелә кызганыч бер аваз?!

Шыгырдый да сыкрый яшь юкә,
каенның иңенә ауган да...
шулайрак егыла кеше дә
җиңәм дип, житәм дип барганда.

Тантана, язгы шау урманда!
Бар да бар, бар да бар дөньяда.

●

Яңабаштан — булмый.
Мөмкин түгел. Юк. Соң.
Үткәннәргә тимим —
һич онытмыйм. Торсын.

Анда — ак бала чак —
иң газиз хатирә...
Әле дә ул көннәр
төшләремә керә!
Чирәмнәрдә аунау...
Ул беренче карлар!
Сиздермичә генә
«янып сөйгән» ярлар...

Яңабаштан — булмый.
Гомер шул, һай, кыска!
Кешеләр аерылган
дошманга һәм дуска.
Өлгерелгән. Ә бит
күп күрмәдем әле.
Ил басмаларыннан
күп йөрмәдем әле!
Хаталар да киткән...
Ул чак тоелмаган.
Ә вакыт — чос, өлгер —
шундук уеп алган,
чәчәкнең касәсен
уйган бөҗәк кебек.
Хәзерге акылдан —
үткән мәзәк кебек.

Яңабаштан — булмый.
Яшәү кабатланмас.
Бу Кояш астында
гомер-шәм гел янмас...

Син торган аулакта
бүтәннәр очраша.
Үткәнгә кайтыла
тик яңалар аша.
Түшәмгә карап ят,
кулларың — мендәрдә.
Көмеш ай нурлары
бүтән керфекләрдә...
Чиккә җитү кыен!
Чүгә башлау кыен!
Көрәеп һәм көлеп
Үлә башлау кыен!

Яңабаштан — булмый.
Мөмкин түгел. Бик соң.
Дәвамын дауларга —
алга, фәкать алга!
Бүтәнчә нишлик соң?..

●

Сары ут капкан бу кырда,
көнбагыш арасында,
мин — ничектер, ә менә син
бер зәңгәр яра сыман...

Зәңгәр яулыгын читеннән
ялварды зәңгәр күзләр!

. . . . . . . . . .

Хәтер әле кайта-кайта
бу мизгелне мең эзләр...
Үбимче сөенечтән
мөлдерәп чыккан күз яшен!
Күктә, җирдә мен-мен Кояш
уттай янсын көнләшеп!

Сары ут капкан бу кырда,
көнбагыш арасында,
безгә карап, бәхетсез, дип,
я, әйтеп карасыннар!

●

Шактый ук искергән дөнья —
Шундый үзгә!
Күк капусының ачкычы
бүген бездә!

Җирдә күпме
күрелмәгән
яңа төс, ямь!
Тәндә күпме
татылмаган
ләззәт, көч, тәм!

Яшәүне данлау — җан тулы,
күңел тулы!
Изге хисләргә һәйкәл бит —
бу онытылу!

Дөньяның газиз һәр бөртек,
һәр тамчысы!
Без тик мәңгелекнең мизгел
дәвамчысы!

Күктән йолдызлар сөенеп
безгә дәшә!
Ах! Мең гомер җитмәслек бу
сөю, яшәү!

Гашыйк җанның хис тә, уй да,
бар да яңа!
Моны тоярга гына да
Кеше булып туу ярый
бу дөньяга!

1971

≈≈≈≈≈≈

## Разил Вәлиев

### Авылда туй...

Киереп ач урыс капкаларны!
Керсен кунак безнең өйгә дә.
Авылда туй. Тракторчы егет
Сыер савучыга өйләнә.

Урамнар тар бүген егетләргә,
Җыр агыла басу ягына.
Бии бабай. «Кеше көлдермә», дип,
Еламсырап әби ялына.

Коеларның суы эчелеп беткән,
Колхоз аты баткан күбеккә,
Иске җырлар яңа булып яңрый:
Тургай кунганмыни күреккә!

Авылда туй. Гап-гади бер егет
Гап-гади бер кызга өйләнә.
Машиналар тынып калган бүген...
Атлар чаба, атлар... әл-лә-лә!

Калым да бар, бирнә дә бар туйда...
Искелек бит бу хәл! димә лә:
Егет батырлыгы калым булса,
Кызның матурлыгы — бирнәгә.

Чаба торгач тезгеннәрне өздек,
Тик һаман да җырлар өзелми!
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Кыңгыраулар илдә зеңгелди.

Урамнарны иңләп шатлык килә,
Дус сөенә, дошман көенә.
Каерып ач урыс капкаларны!
Керсен бәйрәм дуслар өенә.

### Мәҗүси

Мин корьәнсез һәм алласыз
Берүзем җир буйлап барам.
Язлар белән яшелләнәм,
Көзләр белән мин саргаям.

Оҗмахым да бу тормышым,
Тәмугым да бу тормышым...
Әкиятләргә ышанырга,
Табынырга күп тырыштым.

Барып кердем урманнарга,
Килеп чыктым киң кырларга...
Сызгырмадым урамнарда,
Ашыкмадым җыр җырларга.

Оста барда телең тый, ди...
Тургай миннән оста җырга.
Бәхет керсә төшләремә,
Куркып яттым уянырга.

Табындым мин имәннәргә,
Табындым мин усакларга...
Агачларны бергә җыеп,
Их, бер кысып кочакларга!

Мин мәҗүси бала бугай...
Диванадай шашып килдем.
Барып чыктым җир читенә...
Очрамады миңа үлем.

Очсам — күгем, йөзсәм — күлем,
Иярләнгән атым кетә...
Бер мәҗүси баладыр мин —
Табынам тик табигатькә.

●

Һәр көз саен таллар телсез калган,
Телсез калган юкә, имәннәр.
Яфракларын җилгә чәчә-чәчә,
Язга кадәр алар үлгәннәр.

Яфраклары үлгән, карлар күмгән,
Җир җылыткан ләкин тамырын.
...Көзге җилләр телем алсалар да,
Тамырымда мәңге калырмын!

## Дисбе

Әби, әби, синең истәлекне
Ничек кенә инде яңартыйм?!
Кулларымда синең серле дисбең,
Күз алдымда җылы мич артың...

Минем әткәй — синең шахтер улың,
Зур Исмәгыйл аның исеме,
Күчтәнәчкә җимеш алып кайткан,
Төшләреннән җыйган дисбеңне.

Шул дисбеңне тартып ялваргансың,
Нык булсын дип шахта тирәве.
Теләкләрең кабул булган синең...
Әле дә тибә аның йөрәге.

Сугыш килгән. Шул дисбеңне тартып
Калгансың син аны озатып...
Күз яшеннән манма сүзләреңне
Ишеткән тик яшел намазлык.

Әткәй хәзер телевизор карый,
Алланы ул күптән оныткан.
Тик шулай да сине онытмаган,
Кабереңә каен утырткан.

Күз яшьләрең сеңгән намазлыкны
Яшереп куйган сандык төбенә.
Искә төшкән саен алып карый,
...Ул кадәр үк «кәфер» түгел лә.

Аллаң, әби, миңа да ят инде,
Минем инде хәзер үз аллам...
Тик шулай да, кайгы килгән чакта
Кулга дисбең алып уйланам.

Йорт салыгыз, уллар үстерегез,
Бәхет керсен, диден өйләргә...
Насыйп булсын, диден, туган җирдә
Буразнага ятып үләргә.

Иген чәчмим, әби, ачуланма,
Бер «җилкуар» шунда, җыр язам.
Ә җыр язу шул кадәрле авыр,
Җибәрми ул, алса бугаздан.

Дисбең исән... Күрсәң иде син дә,
Дөнья хәзер ничек үзгәргән...
Ә мин һаман тугрылыклы сиңа:
Дисбе тезәм, әби, сүзләрдән.

## Самолетта

Самолетта очам, самолетта...
Аста калды Мәскәү, Касыймнар.
Монда инде мәңге болыт булмый! —
Аермачык монда гасырлар.

Җирнең генә түгел, кояшның да
Буйсынам мин тарту көченә...
Бабам хыялланган күккә мендем!
Нәрсә кирәк тагын кешегә?!

Гасырлар һәм чорлар кысылдылар,
Тарих сыйды сәгать эченә...
Сәгать нәрсә? — Аяз күктә вакыт
Чакрымнар белән үлчәнә.

Самолетта очам, самолетта —
Болытларны кичәм сөзелеп!
Ут кабызган аэропортлар кебек
Бар йолдызлар тора тезелеп.

Әхсән Баянов

# УТ ҺӘМ СУ

РОМАН [1]

Пичугин берүзе бер бүлмәдә ята — күзләре йомылган. «Кеше егылып имгәнде. Минем аркада диләр. Әллә чынлап та шулаймы? Врачлар исән калуы да ихтимал диләр. Ә үлсә?» — Фәез үзен кеше үтергән төсле тоя. Нинди эшәке, нинди бәйләнчек уй! Ул шикне башта Борис кертте. Ә теләсә нинди шик, теләсә нинди гайбәт иң якты йөзгә дә күләгә булып төшә. Нининдер гипнозы бар гайбәтнең. Менә Фәез хәтта үзеннән үзе дә шикләнә башлады. Ә бүтәннәр ни уйламас?

Пичугин егылган түшәм инде күптән төзәтелгән. Бу юлы Фәез үзе карап торды. Пичугин урынына калган кара чәчле җитез егет Алмаз җәелгән түшәм буенча шуышып кына түгел, тәгәрәп тә карады — берни юк. Димәк, сызым һәм аңа кертелгән үзгәрешнең катнашы юк. Әллә Пичугин аягүрә басканмы икән соң? Алай итсәң, калай юка, тишелүе дә озак түгел һәм... чынлап та очып төшүең бар. Мөгаен, шулай килеп чыккандыр, ләкин исбатлау хәзергә мөмкин түгел — Пичугин аңына килгәне юк. Ә килмәсә, харап булса! Фәезнең ак чыраенда нахак гаеп күләгәсе гомерлеккә калуы ихтимал — андый күләгә белән дөньяда яшәмәвең, ихтимал, артыграктыр да. Эх, Борис, Борис!..

Фәез сизә: Борис үзе дә кәефсез йөри — мөгаен, үзеннән үзе чиркана торгандыр — моннан да түбәнрәк төшү булырмы! Табигате белән усал кеше булмаса да, форсаттан файдаланып калырга артык явызланып тырышмаса да, хәзер инде әйткән сүзеннән кире кайтырга горурлык дигән нәрсә ирек бирми торгандыр. Гафу үтенәсе килсә дә, эшли алмый — чөнки аламалык эшләвеңне дөньяга фаш итүе җайсыз. Шуңа күрә, әйтелгән сүзләрен дөрескә чыгарасы килгән өчен тагын да тирәнрәк пычракка керә егет — горкомдагы ямьсез чыгыш өчен парткомга чакыртып алынгач, анда да шул ук сүзләрен кабатлаган.

Мәзәк кенә инде бу дөнья дигәнең: күпме вакытлар бергә йөргән дус кинәт кенә дошманга әверелә, ә күрмәгән-белмәгән диярлек кеше дус булып чыга. Фәез, шул рәвешле, күнегеп беткән якын кешесен югалтты. Тик аның урынына яңа дуслар күбрәк табылды. Фәезне мәгънәсез яладан яклап, баш идарәгә көн саен кешеләр килә торды. Мәсәлән, Кәрам да, хәтта рәнҗергә тиешле тоелган Рәшит тә килде.

[1] Дәвамы. Башы 9, 10 саннарда.

Беркәп иртәнге сәгать тугыз туларак Фәез партком ишеген ачса, шунда Рәшит утыра. Аны күргәч, кире борылмакчы булган иде, партком секретаре Мөбарәк Хафизович дәшеп алды:

— Фәез Сәлимович, керегез, пожалуйста.

Фәез керде, түргә узды. Беренче булып күзгә ташланган нәрсә... өстәлдә фиксатор ята! Райкомнан парткомга күчкән. Димәк, аның Шакировка керәге юк!..

Рәшит Фәез белән аягүрә торып исәнләште. Нигәдер кызара, ояла иде егет:

— Сез начар уйлый күрмәгез тагын, Фәез Сәлимович, мин... жалоба белән килмәдем.

Тотлыгып, кызарып торган егетне җайсыз хәлдән коткарыр өчен Фәез сүзне уенга борды:

— Беләм инде, нинди жалоба булсын. Минем кыйнаганым юк ич сине.

Секретарь берни төшенмичә карап тик тора, ә болар авыз ерып елмая.

— Юк инде, каян килеп кыйнарга тиеш ди син мине?

— Унбиш тәүлеккә дә утырткан дип сөйлиләр.

— Анысы дөрес,— диде Рәшит.

— Ничек дөрес? Син киткән идең бит,— диде Фәез гаҗәпләнеп.

— Яңадан килдем, курыктым. Качкан өчен өстәрләр дип...

— Менә сиңа!

— Әниләреңүпкәләгәнме миңа?

— Искә алмаган көннәре юк, синең хакка дога кылалар.

— Бергә торасызмы?

— Бергә.

Ни сөйләшергә белмичә аптырабрак торгач, Фәезнең башында яңа уй туды:

— Анысы бик әйбәт, Рәшит, мин, җае чыккач, икенче нәрсә хакында сөйләшмәкче идем.

Әңгәмә башланганда гына телефон шалтырап комачаулады. Мөбарәк Хафизовичны Лазарев кирпеч заводына чакыра икән.

— Бүгенгесе көндә удар объект — аңа аеруча игътибар кирәк,— дип куйды Мөбарәк Хафизович.

— Китәсезме?

— Бер ун минут утыра алам әле. Бик җитди сүзме?

— Бик җитди, барып чыкса.

— Чыгар, ярыйсы егет бу, чыгарга тиеш,— дип, секретарь егетнең аркасыннан какты.

Чак кына уйланып торгач, Фәез кирәкле сүзне тапты бугай:

— Менә син, Рәшит, авылда туып-үскән егет, йомшак бәгырьле, табигатьне тоя һәм ярата торган кеше булырга тиеш.

— Ә мин яратам табигатьне. Авылга җай килгән саен кайтам.

— Шәһәргә килгәч тә үзгәрмәскә булмыймы? Шул яшь урманны ни йөрәк белән изә алдың син, ә?

— Әйттем бит инде анысын — начальниклар белә торгандыр. Куштылар миңа...

— Кем нәрсә кушмас! Атарга кушсалар?

— Сугышта... атарга кушсалар, ә син шуны атмасаң? Үзең кызганган пуля үзеңә әләгер. Тәртибе шул инде аның — кушылдымы, атасың.

— Дошманга, әлбәттә. Ә ялгышып дуска атарга кушсалар?

— Мин каян белим аны.

— Теләсәң ничек бел, ләкин белмичә эшләмә. Югыйсә...

— Минем баш җитми моңа,— диде Рәшит, гаепле елмаеп.

— Алай гына да түгел, наратларның үзенә бик кирәкле дуслар икәнен белеп тордың бит син...

Рәшит җавапсыз аптырап калды. Шул форсаттан файдаланып, сүзгә Мөбарәк Хафизович катнашты:

— Бәхәсегез шактый сәер тоелса да, мин аңладым бугай сезне,— дип Фәезгә карады.— Иң яхшы тәртип — аңлы тәртип.

— Мин дә нәкъ шулай димәкче булам. Бу сезнең максатка да кирә бугай, Мөбарәк Хафизович. Аңсыз рәвештә тыңлый торган, бөтен нәрсәне шат күңел белән башкара торган тыңлаучан адәмнән, дөресрәге, җанлы машинадан теләсә нинди җинаять көтәргә мөмкин. Менә ни өчен каныктым мин бу егеткә.

— Шулай, шулай...

— Уйлый торган кешеләр белән житәкчелек итү кыенрак, әлбәттә. Үзенең башы булгач, ул, үтәүдән элек, моның кая барып чыгарын уйлый. Менә син житәкче икән, тәрбияче икән, аңлат инде максатының изгелеген. Әгәр чыннан да изге булса, аңа ышандыру һәм аңлы рәвештә үтәү ул хәтле кыен түгел. Сез шуның өчен махсус куелган кешеләр бит, иптәш секретарь.

— Без тырышабыз да инде шуның өчен.

— Һаман да бер төрле тырышасыз, Мөбарәк Хафизович, формаль тырышасыз, башлыча отчет өчен. Сезнең анда былтыргы май бәйрәменә куелган лозунгларыгыз быел да эленеп тора. Кем дә булса карый, укый дисезме шуларны? Хәзер аларны алыштырып, кирәклесен элеп куйсаң да, өйрәнелгән гадәт буенча, аларына да күз салмаячаклар. Менә нәрсә диган сүз ул күнегелгәнчә яшәү. Җиңел, ләкин бушка эшләү. Рәшитләрне уйламаска шулай өйрәтәсез сез.

— Шактый катлаулы нәрсә бу... болай гына хәл итеп булмас, ярый, сез үзегез сөйләшеп бетерегез инде. Мин киттем.

Секретарь шулай диде дә урыныннан торды һәм, нәрсәнедер исенә төшереп, кире борылды. Өстәл тартмасыннан электр бритвасы чыгарып, кырына башлады. Шуннан аның вакыты ничегрәк житү-житмәвен чамаларга мөмкин иде.

Төзелеш шул бу, төзелеш! Корбансыз, ләкин барыбер — сугыш! Сугыш! Кайчак хәтта алары да була... Һәрхәлдә, ир кешеме, хатын-кызмы — төзелештә яшәгән һәркем диярлек — батыр кеше. Төзелештә эшләгән өчен генә дә аны ихтирам итәргә кирәк.

Урамга чыккач, Рәшит үз юлы белән китмәкче иде, Фәез аны туктатты:

— Бергә барабыз ич, юл уңае.

— Мин машинага күнекмәгән бит, уңайсыз.

— Я, кыланма, киттек, киттек.

Машинада барганда бая башлаган сүзне дәвам иттерделәр.

— Мин сине ашханә янында ни өчен кыйнаганны беләсеңме?

— Ник булсын, сугышкан өчен инде.

— Аның өчен генә түгел, кирәге чыкса, кем дә сугыша.

Егет иңнәрен җыерды:

— Ни өчен соң?

— Сәбәпсез сугышкан өчен. Сиңа кемнендер танавы ошамаган өчен генә аны кыйный башласаң... Беләсеңме, бу бит садизм була!

— Мин аны уйлап тормаган шул.

— Менә шул шул, бөтен бәла дә шунда — уйламаган. Ә уйларга кирәк. Уйламаган кеше үз эшенең мәгънәсен белми.

— Бардыр инде, Фәез абый. Без укыган кеше түгел бит — сигез класс белән кая барасың хәзер.

— Эш белемдә генә түгел, эш — тәрбиядә. Менә син, саф күңелле авыл малае, төбеңдә, нигезеңдә әдәп белән баскан һәм изгән. Дөресен генә әйткәндә, син бит, шәһәрчә кыланырга тырышып, авыл малае икәнеңне сиздермәс өченрәк сугышасың.

— Бардыр инде, дөнья булгач, анысы да бардыр.

— Ә син көлмә, дустым. Көлә торган нәрсә түгел бу. Хулиганлыкта романтика күрү синдә генә түгел. Хулиганлык — егетлек, ирлек билгесе дигәнрәк ялган геройлык күп кешедә бар. Мена син шундый герой булмакчы.

— Сезгә тәрбияче буласы калган.

— Ә беләсеңме, төзү — иң яхшы тәрбияче. Без бит өйләр генә төземибез, кешеләрнең тормышын, язмышларын да иҗат итәбез. Дөньяда иң изге ике профессия бар — игенче һәм төзүче... Дөньяны җилкәләрендә шулар күтәреп бара. Белденме?

— Белдем.

— Белсәң, төштек.

— Безгә кереп чыксаң, әниләр бик сөенер иде. Вакыт таба алсаң.

— Бер керермен әле. Сәлам әйт.

Фәез үз идарәсенә, Рәшит — үзенекенә, арырак атлады.

Шулай итеп, Фәез яңа дуслар тапса, Борисны яклаучы табылмады. Аның бердәнбер козыре — Пичугин... Шәп кеше ул Пичугин. Ләкин хәзер үзенең кем кулында нинди корал ролен үтәгәнен башына да китерми торгандыр ул. Аңына килгәне юк бит әле! Бәлки, аңына килгәч тә, үзенең нинди начар эшкә катнашуын, кем кулында нинди корал булуын уйлый алмас. Ләкин, Коля дустым, беркая да китә алмыйсың, син — Филинов кулындагы хәнҗәр... Хәзер ул Фәез аркасында... Почмакта качып торып кадады аңа дус кеше... Аркадан аны алырга әллә вакыт тими, әллә кул житми... Әллә хәл юк...

Идарәгә килгәч кенә тәндәге һәм җандагы барлык авыртулар онытылып тора. Кәгазьләр, кәгазьләр, кәгазьләр. Кешеләр, кешеләр, кешеләр. Кем беләндер телдән, кайсы белән хатлар аша сөйләшәсең, бәхәсләшәсең, бозылышасың, талашасың, дуслашасың.

Телефоннан сөйләшү тагы да күбрәк... Бүген аңа райбашкармадан шалтыраттылар. Иптәш Шакиров тәкъдиме белән шәһәрне яшелләндерү буенча махсус сессия җыела икән. Шуңа әзерләнергә һәм катнашырга тәкъдим итәләр. Шакиров әйткән булырга тиеш...

— Ә ник шәһәрне генә яшелләндерү? Бөтен районны түгел? — дип сорады Фәез.

— Миңа ничек кушылган, шуны гына әйтәм,— диде башкарма комитеты секретаре.

Тагын «кушылган». Ах, бу сүзне Фәезнең никадәр яратмавын белсәләр, әйтмәсләр иде алар аны. Кайчан соң кушылганны түгел, кирәкне, үзебезгә кирәкле эшне башларбыз без?

...Хатлар, хатлар. Каян гына килми. Менә берсен кара инде — бик җитди кыяфәт белән: Кара диңгез буенда санаторий бинасы салышырга мөмкинлегегез юкмы? дип сорый.

Тагын да сәеррәк үтенеч белән Гета шалтырата:

— Фәез, кадерлем, исәнме?

— Исән, Гета. Тагын ни килеп чыкты?

— Мин Боря хакында сорашмакчы идем.

— Ә минем аның хакында бик үк сөйләшәсем килми бит әле.

— Минем беләсем килгән иде — ул ниндидер бер җыелышта синең адреска бик ямьсез сүзләр ташлаган, имеш — дөресме шул?

— Кызганычка каршы, дөрес, бик дөрес, Гета.

— Менә нахал! Иң якын кешесенә!..

— Ничек якын?

— Синнән дә якын кешесе юк бит аның, ул аны үзе генә белми.

— Якынлык шактый нык күренде.

— Нәрсәләр әйтте соң ул?

— Телгә дә аласы килми...

Телефоннан тавыш бераз ишетелми торды — Гетаның авыр сулавыннан Борис өчен һаман борчылуын сизәргә мөмкин иде.

— Бүтән сүзең юкмы, Гета?
— Бар, Фәез, синнән бер нәрсә үтенсәм...
— Белмим шул, Гета, эшли алырмынмы икән?
— Ишетмәс борын ук баш тартма инде.
— Сизенәм: Борис хакындадыр...
— Монысы минем үтенеч — сөйләшик әле тагын.
— Белмим шул, Гета.
— Бүген кызыклы кино, әйдәгез бергәләп карыйк.
— Нинди кино?
— «Королева Шантеклера». Бигрәк тә ирләр ах-ух килеп карый.
— Кинодан гына карап йөрмәсәк шул... Болай бик күренми.
— Үзең гаепле. Менә дигән кызлар йөри Чаллы урамнарын таптап.
— Берсе дә миңа дигән түгел.
— Бәлки берсе шулдыр.
— Ихтимал, мин танымый уза торганмын.
— «Шантеклер» королевасы да бәлки синең королеваңа охшагандыр, ә? Ничек уйлыйсың?
— Карамыйча әйтеп булмый бит аны.
— Алайса, шул — билетны үзем алам. Безнең егетләр ухаживать итә белми — бездән булсын әйдә. Кайсы сеанска алыйм? Кайчан эштән бушыйсың?
— Тугызларга алсаң, өлгереп булыр.
— Булды, Фәез, кичкә хәтле. Унбиш минут кала анда бул...
Кич барса, Гета белән Борис аны көтәләр иде инде. Яннарына килеп җиткәч, Фәез Бориска бөтенләй илтифат итмәгәндәй:
— Хәерле кич, Гета,— дип, мөмкин кадәр ачыграк булырга тырышып эндәште.
— Хәерле кич, Федя.
— Мин Федя түгел.
— Ну, Фәез. Барыбер түгелмени?
— Сине Галия дисәм ярыймы соң?
— Ярый.
Шуның белән сүз дә бетте. Аптырагач, Гета шаяртырга тырышып карады:
— Сез танышлар түгелме әллә? Гафу итегез, мин онытканмын. Бу — Фәез.
— Әйе, Фәез... Үзең дә әйтергә өйрәндең инде.
— Ә бу — Борис, ләкин Годунов түгел.
— Әмма ул патша булырга бик тырыша.
Борис барлык чәнчүләргә батырларча түзде һәм кинотеатрга керер вакыт җиткәнче тәки бер авыз сүз эндәшмәде. Эчкә узгач кына тукталып:
— Кая таба барырга? — дип сораган булды.
«Эшләгән эшәкелегеннән ояла белә бугай әле, бөтенләй үк пычрак кеше түгел, ахрысы, кыенсына»,— дип уйлап куйды Фәез.
Кылган гөнаһысының әз генә булса да кыенлыгын күрсен дип, Фәез аңа юри ачылмый. Гета әле Фәез белән, әле Борис белән аерым-аерым гына сөйләшә. Бәхеткә каршы, журнал башланды... Новосибирск балеты артистларының Японияга сәяхәте...
Токио шау-гөр килә... «Япония Венециясе...» — Кызык тоела бу сүз.
«Көнбатыш ул Япониядән башлана» — монысы бигрәк тә кызыклы. Япониядә ике дин — будда һәм тагын нindiдер дин, анысын ишетми калды Фәез. Халык ике дингә дә ышана икән. Шуңа күрә, табынучылар саны илдәге халык санынnan ике мәртәбә диярлек күбрәк.
Халык дингә ышана — гаҗәп, нинди культурага ирешкән халык та ышана — күк аллаларына да, җирдәгеләренә дә. Нәрсәгә яки кемгә булса да табынырга мәҗбүр итмәсән, нинди көч белән тәртип сакламак

кирәк, халыкны ничек тыеп тормак кирәк! Шулай дип уйлый торгандыр инде. Бәлки үзләренчә дөрестер дә. Изге нәрсәсе булмаган кеше өчен бернинди мораль киртәләр юк, андый кешедән хәтта җинаять тә көтәргә мөмкин. Ә җирдә тәртип булырга тиеш — шуңа күрә изге нәрсәләргә кагылмаска, шәхси яки иҗтимагый көнләшүләр һәм мәнфәгатьләр аркасында халык ышанган идеалларны фаш итәргә тырышкан кешеләрне властька якын җибәрмәскә кирәк. Кайсы халык шуңа сәләтсез — ул деспотизм юлы белән, тупас көч белән тыелып, изелеп яшәргә лаеклы. Кызганыч та түгел — өйрәнсен, изге нәрсәләрне сакларга, кагылдырмаска өйрәнсен. Әйтүе генә ансат, ә тормышта...

Журнал тагын да гыйбрәтлерәк күренешкә. Нагасаки шәһәренә көчте — үлем шәүләләре — ташка мәңгелеккә уелып калган үлем сурәтләре... Шәһәрне өр-яңадан төзегәннәр, ләкин ул шәүләләр, ул сурәтләр әле һаман да бар — таш үзе бетсә бетәр, ә үлем шәүләсе һаман калыр... Мәңгелек гыйбрәт булып...

«Без салган кирпечләргә бу шәүләләр төшмәсен, яп-якты Кама өсте мәңге шулай якты дулкыннар булып чайкалсын. Эх, Кама, Кама! Мәңгелек тынычлык, мәңгелек бәхетләр сиңа, Кама!»

Җитди күренешләрдән матурлык королевасы елмаюына һәм ягымлы җырларга күчү дә, ничектер, кыен булмады — кешенең иң беренче һәм иң соңгы хыялы шул бит инде — дөньяның матурлыгын саклау — тынычлык та шуның өчен кирәк. Җирдә муллык туар, бөтен шартлар, бөтен нәрсә житкелекле булыр, хәтта житеп артыр, ләкин матурлык, мәхәббәт беркайчан да житеп туктамас. Шуның өчен аны һәркем үзенә эләктерергә ашыга, хәтта аның белән бер кич үткәрер өчен дә күпме бәрелеш һәм гыйбрәтләр була! Аһ, түзегез генә, матурлар, сезгә яшәү кыен, сезгә тынгылык юк. Берәү яратса, икенчесе, аңа үч итеп, синең яман атыңны сата. Матурлык, түз генә, яшәү кыен сиңа — артык кыен!

Шуңа күрәдер инде, чибәр кыз Чорита Шантеклер клубыннан, үзенә табынган һәм шул ук вакытта үзенә каршы көрәшкән ләззәт корбаннарыннан бүтән тормышка качарга тырыша. Икенче бер акыллы һәм саф егет белән таныша... Шулай да үзенә гашыйк егеткә ул исемен әйтергә базмый, үзен Маргарита дип таныштыра. Маргаританы чын күңелдән ярата Санти. Аның өчен Маргарита дөнья бәһасе торырлык. Хәер, Фәез монда чак кына үз хисләрен дә өсти. Чөнки кинофильм буенча бу мәхәббәтнең чын мәгънәсендә житдилегенә ышанырлык өчен вакыт һәм вакыйгалар житеп бетми... Ярый, житмәгәнне һәркем үзеннән өсти һәм шул рәвешле ышана ала бит. Фәез шулай эшләде. Маргарита өчен егетнең үлемгә барырлык дәрәҗәгә житүенә күңел беркетте. Ләкин Маргарита күздән югала... Егеткә аның иптәшләре кызның Маргарита түгеллеген, ә «Шантеклер» королевасы икәнен, аның хәзер «Казино» театрында чыгыш ясавын әйтәләр... Егет барса, кыз, чынлап та, бозык дип даны таралган артистка булып чыга. Маргарита юк, саф мәхәббәт юк, матурлык юк, һәм ансыз дөнья да юк. Егет ярсып торган океанга таба чаба, андагы бетон мол буйлап, дулкыннары дүртәр метрга ыргылган, үкереп торган океанга — үлемгә таба атлый. Хәзер инде кирегә китәргә дә соң — артыннан Чорита кычкыруын ишетсә дә, ишетмәсә дә — ул инде кире борыла алмый — дулкын кире чигенгәндә егетне үзе белән алып төшеп китә...

Чорита исән, ләкин аны да шундый ук упкын — бозык тормыш, «Шантеклер» тормышы — гайбәтләр, интригалар, һәртөрле азгынлыклар, түбәнлекләр көтә. Алар аның талантын да, үзен дә барыбер йотачаклар.

Кино беткәч, шуның тәэсиреннәнме, баягы киеренкелек һаман узмаган идеме — урамга чыкканчы сүзсез атладылар. Бераздан гына Фәез, бүтәннәрдән бигрәк, үзе өчен әйтеп куйды:

— Мәхәббәт аркасында ирләр дә үлә ала икән. Беренче тапкыр күрәм.
— Ә Ромео? — диде Гета.
— Анда икәүләп... Ә мин аерым үлгәнне әйтәм. Гел хатын-кызлар һәлак була, гел хатын-кызлар күбрәк һәм чынрак ярата...
— Димәк, сездә чын мәхәббәткә сәләт чамалы... Менә күз алдында... Әйтик, Боря... Кем өчен суга ташланырга мөмкин ул?
— Кирәк булса, ташланырбыз да,— диде Борис төксе генә, кич буена икенче тапкыр телгә килеп.— Нәрсә, туйдыгызмы? Мин үлмичә дә сезне тынычта калдыра алам.
— Үлмә, җаным, яшә, яши генә күр. Синең шулай чын хискә бирелә алмавыңны гына әйтәбез...
Сүз тагын ялганмады. Бер караңгы юл чатына җиткәч, Гета туктап:
— Мин кайтып җиттем,— диде.
— Ярый, кино өчен рәхмәт,— диде Фәез.
— Рәхмәт, хуш,— диде Борис та.
Һәм, икесе дә кузгала башлагач, Гета кабынып китә язды:
— Нәрсә, мин сезне кино карарга чакырды дип белдегезме? Бары шуның өчен генә дипме?
Егетләр ык-мык итеп торганнан соң, кыз кискен кыяфәт алды:
— Менә нәрсә, Боря, мин бүгенге очрашуны сиңа ярдәм итмәкче булып оештырган идем.
— Миңа бернинди ярдәм кирәкми, аның өчен дисәң, ялгышкансың.
— Кирәк сиңа ярдәм, бик кирәк. Минемчә, син хәзер шундый куркыныч алдында торасың.
— Океан өстендә, бетон мол өстендә — дулкыннар мине йомычка төсле юып төшерәчәк, йотачак. Коткарыгыз зинһар, фәрештәләр!
— Син шаярган буласың, егет, ләкин эчең тулы ут.
— Мин бик тыныч — үземне бик бәхетле хис итәм.
— Бәхетле егет, менә нәрсә: хәзер син Фәездән гафу үтенергә тиеш.
Бористан бигрәк, бу тырышлык Фәезне рәнҗетте:
— Гета, син нәрсә, ник кирәк аның гафу үтенүе миңа? Мин мохтаҗмы шуңа?
— Син түгел, Боря...
— Борис мохтаҗ дисәң, тагын да катырак ялгышасың.
— Алай икән, этлек эшләде дә, хәзер шуны төзәтерлек көче юк. Нәрсә син, шундый хәлдә калмакчы буласыңмы?
— Син, Гета, үлчәбрәк сөйлә сүзеңне... Югыйсә...
— Нәрсә югыйсә? Минем белән сугышмакчы буласыңмы? Шул гына калдымы?
— Ярар, Гета, синең эш түгел бу. Ул үзе бик башлы кеше, уйласын,— диде Фәез.
— Башлы. Күренеп тора. Чак кына акылы булса, мондый әшәкелекне эшләмәгән булыр иде ул.
— Әшәке кешеләрдән ишетәм...
— Тфү!
— Ярый, хуш.
— Боря, тукта.
Гета, «ә» дигәнче, Борисның каршысына төште:
— Әгәр минем белән дус булып калырга теләсәң, хәзер үк гафу үтен.
— Ул миннән үзе гафу үтенергә тиеш.
Фәез сагая калды, шулай да ачуланмыйча сорады:
— Мин сине, Боря, рәнҗеттемме? Әйт, ничек рәнҗеттем? Гаебем булса, үзем сизмичә генә булгандыр. Чынлап та гаепле икәнмен, гафу үтенермен. Әйт, ничек рәнҗеттем мин сине?

— Үзең беләсең?
— Акча мәсьәләсендәме?
— Ну, шулай да булсын.
— Юк, аның өчен түгел, мин беләм синең ни өчен мине яратмавыңны.
— Яратмау нәрсә ул! Мин сине күралмыйм, күрә үк алмыйм, ишеттеңме? Дөньяда синнән башка кеше ярдәм итә алмый иде миңа. Ә син? Нәрсә эшләдең минем өчен? Теләсәң файда эшли ала идең. Ә киресен эшли белдең...
— Туктале, егет, тукта... Нинди файда эшли ала идем мин сиңа?
— Үзең беләсең.
— Белмим.
— Ну белмәсәң, син — дурак.
— Ничек? — Фәез Гетага таба борылды.— Ишеттеңме, Гета, ул гафу үтенде бит.
— Шулай, гаҗәп матур формасын тапты. Поздравляю, Боря. Хәзер инде мин гафу үтенәм. Гафу ит, мин ялгышканмын, мин синең күңелдә әз генә булса да затлылык бар дип йөргән идем. Мин синдә ниндидер матур хисләр, әйбәт уйлар бардыр дип өметләнгән идем, ышанган идем һәм ярата идем, чын күңелдән ярата идем. Ялгышканмын икән. Ах, никадәр каты ялгышканмын! Иң соңгы кимсетелүгә, бергә яшәмәгән килеш синең исәлегең белән яшәмәкче булып, үземне гомерлек җәзага тартмакчы идем бит! Кем өчен! Кем өчен!
— Гета, мин сиңа соңгы тапкыр әйтәм...
— Әйтмә, барыбер юньле сүз чыкмаячак синнән. Соңгы сүзне мин әйтәм — берңинди истәлек кирәкми миңа синнән. Мин иртәгә үк больницага керәм...
— Рәхмәт. Бүтән сүзем юк.
— Оятсыз! Бар, югал!
Борис китәргәме, юкмы дип бер-ике секунд кына уйланып торды да кырт борылды:
— Изге җаннар! Куркыттыгыз! — дип китеп барды.
Борис мәгънәсез сүзләре белән үзен чыннан да буш һәм беркемгә кирәксез кеше итеп күрсәтте. Фәезгә дә, Гетага да бу нык сизелде һәм шуннан соң алар аны туктатырга тырышмадылар да. Дөресрәге, Гета инде аңа бөтенләй игътибар итми, ул алдану гарьлегеннән чамадан тыш ярсыган иде. Кыз коймага куллары белән тотынып үксергә керешде. Күз яшьләре беткәнче үкседе-үкседе дә, ниһаять, башын күтәрде:
— Ярый, Фәез, гафу ит.
— Бирешмә, Гета. Кирәк булсам, мине иң якын дустың итеп исәплә.
— Рәхмәт, Фәез, яхшы кеше син.
Фәез Гетаны тынычландырып аркасыннан сыйпады да саубуллашып:
— Тыныч йокы, Гета,— диде.
— Тыныч йокы, Фәез.

* * *

Управляющий объектларны иртәнге якта карап чыга. Территориясе дистәләрчә чакрымнарга сузылганлыктан, барысын да йөреп бетерә алмый торгандыр — башлыча идарәләрдә һәм аның төп объектларында гына буладыр. Фәез идарәсендә шундый объектларның берсе — шлюз. Монда ул көн саен диярлек килә. Бүген биредә эш өзелеп тормаячак — балта осталары, бетончылар үз урыннарында, бетон килсә, кабул итәргә һәрвакыт мөмкинлек бар.
Фәез белән Лазарев тимер баскычлардан аска Кәрам бригадасы

эшләгән жиргә төштеләр. Управляющийның моңарчы биредә күренгәне юк иде әле — шуңа күрә аны көтмәгәннәр, килер дип башларына да китермәгәннәр иде. Аны күргәч Кәрам ни өчендер Керосинниковның пальто жиңеннән тартты да тегесе күз ачып йомарлык арада каядыр шылды. Кәрам исә управляющий каршында нәкъ солдатча катып калды. Ниндидер ярамаган нәрсә барлыгы әллә каян күзгә бәрелеп тора сыман. Фәез генә төшенә алмый.

Управляющий, Кәрамга болай катып торма дигәндәй, аның аркасыннан какты һәм тегесе, үзе дә сизмичә булса кирәк, Лазаревның арка ягына күчте. Башкалар аларны түгәрәкләп тезелделәр.

— Ну, егетләр, хәерле иртә.

— Хәерле иртә, Анатолий Самойлович.

— Ну, хәлләр ничек?

— Хәлләр ярыйсы...

— Ничек ярыйсы?

— Әйбәт. Тик...

— Нәрсә тик?

Участок будкасы ягыннан Борис та күренде. Егетләр аның хакында нидер әйтмәкчеләр иде бугай — үзен шәйләгәч, тындылар.

— Ярый инде,— диде Кәрам, янадан Лазарев алдына чыгып,— калсын.

Управляющийга бу сүз ошамады:

— Бу нинди куркаклык? Егет кеше, солдат! Ну, нәрсә?

— Бөтенесе бернәрсәгә тоташа инде аның, Анатолий Самойлович. Егетләр акча әз төшә дип зарланалар.

— Эшенә күрә ашы. Аз эшлисез, димәк. Кем куша?

— Беркем дә кушмый да бит.

— Материалны житкелекле жибәрмиләр.

— Жибәрсәләр дә — без юкта.

— Безнең бит семья карыйсы да бар. Ә болай үзебездән дә артмый. Нәрсә дигән сүз инде бу, Анатолий Самойлович?

— Төзелештә мондый зар барын мин беренче тапкыр ишетәм. Нишләп болай бу, Насыйбуллин?

— Шушы участокта гына ул.

— Ә ник?

Әңгәмәгә Борис та катнашты:

— Минем аркада, Анатолий Самойлович.

Борисның чырае караңгы, күңеле төшенке иде.

— Сезгә ни булды? — дип сорады управляющий, аның кыяфәтенә гажәпләнеп.

— Болай гына, әллә ни юк кебек.

— Болай гына түгел бугай шул, эшчеләрең эш азлыктан зарлана.

— Мин дә зарланам.

— Ә син ник зарланасың? Эшне булдыру өчен үзең нишлисең?

— Материал артыннан йөрү минем эш түгелдер бит? Аның махсус куелган кешеләре бар. Минем эш — бирелгән материал белән үз вакытында башкару. Эш тоткарлана икән, пожалуйста, бәйләнегез аннары.

— Ә башка участоклар? — дип сорап куйды Фәез.

— Алар остарак кылана бедә.

— Ә ник син остармыйсың?

— Изге эшкә блат катнаштырасым килми.

Лазарев ачуланмыйча гына нәтиҗә ясады:

— Ну, ярый, авыз ачып карап утырыгыз инде алайса, кош балалары кебек, атан-анан селәүчән китергәнне көтеп.

— Билгеле вакыттан соң, канатлар чыкканнан соң, кошлар да балаларын туйдырудан туктый,— дип өстәде Фәез.

— Без бала түгел, сез ата түгел, иптәш Насыйбуллин, ә материал-

ны вакытында китерт! Безнең монда бөтен хакыбыз бар. Инструкциядә эш бүлешенгән безнең.

— Ну, ярый, Филинов, бу сүзне тагын дәвам иттерербез. Сәгать кичке жиделәргә минем янга керерсең.

— Ярый, керермен.

— Ә хәзер сез миңа Керосинниковны күрсәтегез.

— Керосинниковны? — диде Кәрам гаҗәпләнеп. Әйтерсең бу фамилияне беренче тапкыр ишетә иде.

— Әйе. Кайда ул?

Егетләр елмаерга да, елмаймаска да белми аптырап участок будкасына карадылар.

— Нәрсә, шундамы? — дип сорады Лазарев.

— Мин күрмәдем — икенче яктадыр.— Ялганлый белми шул Кәрам.

— Анда түгел ул.

— Әйдәгез әле.

Барысы да управляющий артыннан иярде. Баскычтан менгәч тә — будка, шуның сул ягына, тәнәфес вакытында эшчеләр ял итә торган бүлегенә үттеләр. Тик анда беркем күренми иде.

— Керосинников!

Тавыш-тын юк.

— Качыргансыз. Исерекме әллә?

— Юк, тамчы да капмаган иде.

— Ә монда керосин исе килә...

Лазарев, түргә узып, мич тирәсен әйләнгәндә, ишек ачып ябылуын шәйләде һәм моржа артыннан бу якка ашыкты.

— Качырдыгыз! Шутлар! Качырдыгыз! — диде ул үзенең күкрәүле тавышы белән. Ләкин бу тавышта һич тә усаллык юк иде.— Ну, сез аңа әйтеп куегыз: икенче тапкыр горисполком председателе хатыны янына куна кермәсен, үз тиңен карасын. Булдымы?

— Ничек булдымы? Ул ниткән хатын тагы? — диешкән булдылар. Янәсе, беркем берни ишетмәгән.

Ә Фәез чынлап та гаҗәпләнә калды:

— Нишләгән соң ул, Анатолий Самойлович?

— Кыланмагыз, яме.

— Чынлап, бернәрсә дә ишеткәнем юк минем.

Лазарев хәйләле кыяфәт белән елмайды гына — сөйләмәде. Нәрсә булды дигәндә, хәл, имеш, менә болай булган.

Теге чакта: я өеңә кайта башлыйсың, я эштән китәсең дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйгач, Керосинников өенә көн саен кайта башлый, сәрхушланган чаклары да сирәгәя. Әмма соңгы получканы алгач тагын бик каты салмыш, имеш. Салмышы бер хәл, тагы өен бутамыш.

Төнге сәгать уникедә өенә дип кайта Ваня.

Бәрелә-сугыла өченче катка менә. Звонокка баса. Эчке яктан уяулы-йокылы хатын-кыз тавышы ишетелә:

— Синме бу?

Ишекнең бу ягыннан аңгыл-миңгел җавап:

— Мин.

Хатын ишекне ача да йокы бүлмәсенә кереп, җылы урынына ята — ут та яндырмый. Ваняның ут кабызырлык аңы да, хәле дә юк. Аннан-моннан чишенә дә йокы бүлмәсенә керә, караватка ята һәм йоклап та китә.

Күпмедер вакыт үткәч, тагын звонок чылтырый. Хатын уяна да Ваняны селкеткәләп:

— Женя, Женя, кемдер килде. Тор, торып ач әле,— ди.

Ә «Женя» авыз эченнән мыгырданып кына куя — кая ул уяну. Хатын аптырагач үзе торып чыга:

— Кем ул?
— Аня, мин бу.
Ишек бикләнмәгән дә икән — хатын аны ача да коелып та төшә:
— Атакай гынам, Женя, син кайткан идең бит инде.
— Нишләп кайтыйм? Утырыш әле бетте генә бит.
— Алайса... Женя... Анда кемдер бар... Женя! — дип, хатын хәлдән таеп залдагы диванга утыра.
— Кем бар? Кайда?
— Караватта, Женя, бар, карале, мин куркам.
— Ничек? Син ни сөйлисең?
Евгений Степановичның күзләре шар була.
Ышанырга да, ышанмаска да белмәстән, ире тәки йокы булмәсенә кереп анда ут яндыра һәм анда рәхәтләнеп йоклап яткан Иванны өстерәп төшерә. Лап иткән тавыштан куркып хатын да шул якка чыга һәм берничә минут кына элек кем янында ятканын абайлап, һушсыз кала.
Евгений Степанович исә чакырылмаган кунакны йокы булмәсеннән өстерәп чыгара да милициягә шалтырата...
Милиция Ваняны алып киткәч, ир белән хатын ничек сөйләшкәннәр һәм ничек көлешкәннәрдер, анысы безгә караңгы. Гомумән, бу хәлнең чынмы, әллә анекдот кынамы икәнен хәзер беркем дә ныклап раслый алмый инде. Сорасаң, Иван үзе дә «юк» дигән була һәм кинаяле итеп мыегын бора. Тик шунысы бәхәссез: бу мәзәкне хәзер бөтен шәһәр буйлап сөйлиләр. Моны иң элек ишетүчеләрнең берсе — Лазаревтыр. Хәзер шул очрак белән ул Керосинниковны «котларга» килгән иде. Әмма герой качып котылган, көне буе эштә күренмәде. Икенче көнне исә Ваня, караңгы белән эшкә килеп, гауганы үзе куптарды. Әлбәттә, башкалар аңа бәйләнгәнче, алданрак кузгалуы иде бу аның, һөҗүм итү — иң яхшы саклану чарасы, диләр бит. Килде дә еларга кереште:
— Урлаганнар! Урлаганнар!
— Кем урлаган? Нәрсәне? — диеште егетләр тыныч кына.
— Балтамны, болтларымны, инструментларны... Әрҗәсе белән урлаганнар! — Иван күз яше белән елый — кем аңа, ничек ачулана алсын!
— Ваня абзый, борчылма ул хәтле, кемгә кирәк синең балтаң, кемгә кирәк синең тимерләрең?!
— Миңа кирәк, миңа. Харап булдым мин, урлаганнар, бетте минем баш.
— Бергәләп эзлик, кая куйган идең соң? — ди Кәрам көлеп.
— Менә шушында,— дип, Ваня будканың барлык почмакларын әйләнеп чыкты.
Егетләр дә өйнең астын өскә китереп эзләделәр — юк. Эш урынында калмаганмы дип, аннан карадылар — анда да юк.
— Шушында калдырган идеңме соң? — диде Кәрам.
— Әйе, шушында инде, бүтән кайда булсын.
— Әле будкада, әле шушында... Ничек инде ул?
— Шушында, шушында.
— Исерек булгансың син, мөртәт, пары әле бүген дә бераз калган. Бар, яхшы чакта сыпырт, медпунктка кереп, нашатырь иснә.
— Урлаганнар, урлаганнар!..
— Җиттеме сиңа, юкмы?!.
— Нишлим соң? Урлаганнар!
— Урлатам мин сине, шүрәле, әнә кара, тагын килә Лазарев.
Бу сүзләрне ишеткәч, Ваня тиз тынды һәм медпунктка китте. Икеөч сәгатьтә инструментлары да табылды тагы. Күз тимәсен, соңгы көннәрдә майлаган кебек йөри.

* * *

Ваняны куркытканда, Фәез белән Анатолий Самойлович чынлап та якын тирәдә йөриләр иде. Ләкин алар шлюзның икенче ягына киттеләр.

Лазарев:

— Сезнең Филинов белән хәлләр ничек? — дип сорады.

— Начар, Анатолий Самойлович. Теге жыелыштан соң эндәшеккән юк.

— Участок белән элемтән беткән алайса?

— Бетмәде бетүен. Прораблар белән турыдан-туры сөйләшәм. Ә беләсезме, эш болай хәтта яхшырак та бара башлады.

— Димәк, Филинов артык анда.

— Артык булган һәм хәзер дә шулай.

— Да, сезгә кыендыр — борын төбендә, көн саен очраша торган жирдә... Кәефне көн саен кырып тора торгандыр ул.

— Сезнең белән Лебедев кебек без хәзер.

— Аккош очты.

— Ә ябалак жыенмый да.

— Нишләргә соң инде сезнең белән, ә?

Лазаревның үзе уйлаганчарак карарга килүен сизеп, Фәез тәкъдим әйтте:

— Минемчә, монда Филиновның үзенә дә кыен. Аңа үз карашларына, принципларына ярашлы эш табарга кирәк, минемчә, сәгать тугыздан алтыга хәтле эшли торган канцелярия эше.

— Бухгалтериядәме? — дип көлде Лазарев.

Фәез көлмәде:

— План бүлегенә. Яки ГЭС директоры белән сөйләшеп, аның карамагына күчерергә мөмкин. Мәсәлән, инженер-куратор сыйфатында.

— Монысын инде ул үзе кайгыртырга тиеш.

— Ярдәм итәргә мөмкин, аның хәле авыр хәзер.

— Ярый, бүген мин аның белән сөйләшермен...

Сөйләшүнең нәтижәсе икенче көнне үк күренде. Борис Фәез кабинетына килеп керде:

— Сәлам, Фәез.

— Исәнме, Борис. Нишләп йөрү?

— Менә, китәм инде синнән, котыласың.

Фәез, «дөрес» дигәндәй, Борисның күзләренә караган иде, тегесе тиз генә читкә борылды.

— Сиңа да шулай уңайлырак булачак.

— Әлбәттә, шулай,— дип, Борис гаризаны бирде.

Гаризада: «Трест администрациясенең тәкъдиме буенча бүтән идарәгә күчүем сәбәпле, дүртенче идарәнең беренче участок начальнигы вазифасыннан азат итүегезне үтенәм»,— дип язылган иде.

Фәез ручкасын алып, кәгазьгә виза салырга жыенгач, тыелып калды:

— Трестка түгелмени? Идарәгәмени?

— Идарәгә. Үзем сорадым. Плановойга китереп тыкмакчы. Мин нишлим анда? Нәрсә уйлап чыгара алам?

— Шулай шул, син иҗат кешесе — урыныңжайлы эштә булырга тиеш. Ләкин характерың... Шулай, син бит, икенче яклап караганда, идарәдәге көндәлек агымнан читтә, ирә алмыйсың син аңа.

— Теләмим. Гауралашып яши торган гадәтем юк. Ләкин идарәдә фәнни режим һәм тәртип урнашса...

— Ярый, Борис. Мин кул куям.

Фәез «каршы килмим» дип тиз генә виза салды. Борис исә гаризаны үзе күтәреп керсә дә, Фәез кулыннан аны һич тә аласы килми генә

алды — гарьлек һәм кимсенүдән күзләре сагышлы бер кыяфәттә мөлдерәп тора... Тагын чак кына бераР сүз әйтсәң, күз яшьләре түгелеп китәр сыман.

«Гаҗәп бит кеше табигате: аңа тормышның, тарихи хәрәкәтнең иң кайнаган урынында, төп агымында булырга кирәк. Ләкин ул аның төп эчтәлеге белән үзе килешми, агымның бүтән тизлектә баруын һәм үзе теләгән төсләр белән бизәлүен күрергә тели. Тик алай булмый шул, тормыш аерым шәхесләр теләгәнә түгел, ә табигать, вакыт тудырган шартлар һәм мөмкинлекләр дип аталган җыпкы буйлата һәм аерым җәмгыять ихтыярына буйсынып ага бирә. Аның агышын үзгәртү мөмкин түгел, бигрәк тә Борис кебек сайрак кешеләргә».

Шулай дип уйлады Фәез — дустын сай дип ул, ихтимал, субъектив бәя биргәндер, әмма төбендә бу фикердә дөреслек бар бугай шул.

Шулай итеп, ничә еллар буе бергә эшләгән ике дус сәхнәнең ике ягыннан чыгып киттеләр. Туры сызыклар буенча киттеләр... Ә кояш тирәсендәге пространствода туры сызыклар очрашмый дигән бит Лобачевский абзаң...

Тик Фәезнең прогнозы ялгыш булып чыкты. Сызыклар беренчедән туры түгел иде, икенчедән, алар артык тиз очраштылар, очрашу ноктасы Пичугин булды...

Ниһаять, Пичугин аңына килде һәм Фәез аның янына берничә тапкыр барды. Ике тапкыр Фәез белән Борис та шунда очраштылар.

Килгән саен: «Я, Коля, хәлләр ничек?» — дигән сорауны кабатлыйлар.

Ә Коля һаман әле гипста. Күзләре генә ялтырап ята. Сөяк авыртуы, җәрәхәтләр сызлавы узса да, хәле җиңел түгел, хәзер инде гипс эчендә озак яту аркасында тәне әчетеп интектерә. Шулай да ул, кеше килгәч, күзләрен ача, күзләрен тутырып-тутырып карый.

— Я, хәлләр ничек?

— Әйбәтләнә.

Күпме вакытлардан соң ишетелмәгән тавыш, ниһаять, дөньяга чыкты, димәк, Коляга ничәмә көннәр борчып, интектереп торган сорауны бирергә мөмкин... Ләкин иртәрәктер әле. Хатыны белән, врачлар белән киңәшкәч һәм алар да, житди сүзне хәзергә катнаштырмау яхшырак, дигәч, сөйләшмиләр. Нишлисең бит, көтәргә, түзәргә туры килә.

Борис белән шушында очрашкан бер көннә һич оныта алмас Фәез. Авыруның күзләренә, бөтен торышына озак-озак карап, сүзсез утырган Борис саубуллашып чыгып киткәч, Коля үзе сорап куйды:

— Бу кеше ник килә икән минем янга?

— Синең хәлеңне белергә.

— Ул бит миңа бөтенләй дус түгел иде диярлек.

— Авыргач, кызгангандыр инде.

Коляның чырае караңгыланып китте:

— Кызганыптыр дисеңме? Юктыр. Мин аның күзләреннән күреп торам — кызганмый ул мине, хәлемнең җиңеләйгәнен белгән саен чырае карала төшә. Ник икәнен генә әйтә алмыйм — ул бит миңа бөтенләй таныш түгел диярлек. Бер зыяным да тигәне юк.

Фәез Коляны аңлый, әлбәттә, аның хаклы икәнен дә тоя, тик бөтен уйлаганны әйтеп бирү мәҗбүри түгел ләбаса — бигрәк тә авыру кешегә. Дөресен әйтсәң, аның кәефе китәчәк һәм чынлыкта бу Бориска ярдәм булып чыгачак, шуңа күрә Коляны ул тынычландырырга тиеш.

— Кеше турында алай начар уйламыйк, Коля. Без бит берни дә белмибез.

— Ә минем күңелгә шулай килә.

— Күңелгә нәрсә килмәс...

Авыру борчылып күзләрен йомгалады да беразга тагын тынды. Тик Фәез моны әйбәт билге, Коляның сүз жебен ычкындыруы дип уйлап өлгергәнче, авыру тагын баягыны кабатлады:

— Беләсеңме нәрсә... Күңелгә килә бит...

— Борчылма, Коля. ярый, сөйләшмик.

— Син теге киноны караган идеңме?

— Кайсы киноны?

— «В снегах Килиманджаро» бугай.

— Ә... караган идем. Ник?

— Шунда, гангренадан үләргә яткан кеше исен сизеп, ике кош килә...

— Ул кошларның берсе мин түгел, Коля, берүк алай уйлый күрмә,— диде Фәез, сүзне шаянга борырга тырышып.

— Сиңе әйтмим. Минем исне сизеп бирәү генә килә. Карап торатора да, үлмәгәч тагын китә. Тик өметен өзми әле һаман — иртәгә тагын киләчәк.

— Сиңа андый сүз сөйләшергә ярамый. Тынычлан. Ярый, мин дә китим инде, Коля.

— Син китмә, синең белән әйбәт.

— Шулаймы? Алайса бераз утырам, тик Борис хакында сөйләшмик.

— Күземә гел яман кош кебек күренә шул. Кайчак козгын төсле... тавышларын ишетәм хәтта.

Фәез Коляның башыннан сыйпады, күзләрен йомдырды. Озакламый, авыру йоклап киткәч, Фәез больницадан чыкты.

Икенче тапкыр килгәндә, Коля үзенең ничек егылып төшүен сөйләде. Кызганыч, ул көнне Борис килмәде.

Пичугин хәлнең ничек булганын хәтерләргә тырыша. Аның күзләре каядыр еракка карый һәм, нәрсәнедер бик үк ачык күрә алмаганлыктан, бөтен көчен җыеп, текәлеп тора, күзләрен әле тутырып карый, әле кыскалап куя. Ә хәтерләгән бер нәрсәсен Фәезгә сөйли бара.

— Әһә... шул көнне бит бу...

Фәез, Коляга комачау итмәс өчен, сорау бирми, фикерләрен нәкъ үзе уйлаганча, үзе күргәнчә әйтсен өчен, ашыктырмый да, чөнки бу вакыйга Фәезгә нәкъ булган хәлендә, бернинди үзгәрешсез кирәк бит.

Иреннәрендә, битендә берни булмаса да, Коля тыны белән чебен куган төсле өргәләде дә тагын тынычланды.

— Нәкъ шул көнне шул — хәтерлим. Үзеңнең дә исеңдәдер әле, калай түшәмдә тишек калган өчен синнән әләккән иде миңа.

— Бер тишек калай аркасында тимерчелек цехын бөтенләй кабул итмәгәннәр иде.— Пичугинның дөрес аңлавы һәм үпкәләве фарыз булганга, Фәез шундый аңлатма бирергә тиеш тапты.

— Дөрес әләкте, гаеп бездә инде, синдә түгел.— Иреннәрен бөреп сулышын тагын өргәч, Коля сүзен дәвам иттерде: — Сиңа үпкәләргә хакыбыз юк инде безнең. Үзебезнең аркада килеп чыккан тоткарлык бит, бигрәк тә ай азаклары иде — аңлашыла инде ул. Шуңа күрә дә беркемгә дә кушмадым, начальник эше булмаса да, үзем мендем. Мин ул түшәмнең мәгънәсен белмәгән кеше түгел — шуышып бардым. Тишек калган җиргә барып җиткәнем хәтердә юк. Әммә бензорезның зәңгәр ялкыны һаман күз алдында. Астан да, өстән дә сәдәпләрне тоташтырган тимерләрне шул ут кисә бит — күңелле эш бу, утның тимер кисүе кызыклы. Син уйлама тагы, кызык булганга күрә мавыгып киткән дип. Хәер, әйтүе кыен инде аны, бәлки чынлап та мавыккандыр. Булгандыр инде. Шулай кистерә торгач, шул тирәдәге бөтен фиксаторларның да бик үк шәп беркетелмәгәне күренде дә — миннән соң кем дә булса менсә, бәлагә очравы бар дип уйладым. Кайсыдыр юньсезе, әллә салмыш баш белән язапланган, әллә болай, кулыннан килмәгән. Кеше егылгач, аның нинди хәлдә эшләве кызык түгел бит.

Шулай инде, Фәез туган, шулай, күрәсең булса, бәлане үзең эзләп табасың икән аны. Әйттем бугай инде — мин тишек калайны гына түгел, шул тирәдәге кайбер бүтән калайларны да куптарып алдым. Куптарып ала тордым, бозылганнарын түбәнгә ыргыта бардым. Яңадан беркетеләсе урыннар ачык калды, мин, астан калай табаклар алып менеп, ачык урыннарга калайны яңа фиксаторлар белән каптыра-беркетә бардым. Инде эш бетте дип, бензорезны тоткан килеш төшәр җиргә китим дисәм... инде очып барам — каядыр түбәнгә мәтәлдем. Хикмәт, нинди дер секундлар эчендә генә булган шул очуны әйтәм, ах...

Коля, башы әйләнгәндәй, күзләрен йомды — караса, ул тагын каядыр оча...

— Ай-й!..

Фәез авыруның башыннан сыйпый, күзләрен ачтырырга тырыша:

— Коля, курыкма, берни юк. Булган инде, беткән, бернинди куркыныч юк, син караватта ятасың.

Коля еш-еш сулыш ала башлаганга, Фәез тиз генә сестраны чакыра китте. Кабат икәүләп аһ-уһ килеп керсәләр, Коля күзләрен ачкан, тынычланган иде. Фәезнең күзләрен тутырып, кызганып караганын сизде, ахры:

— Куркыттыммы? — дип сорады ул.

— Әйе, Коля.

— Искә төшкән саен егылам... Кайчан үтәр инде бу курку.

— Үтәр, үтәр. Әле синең хәлсез нервларга көч килә дигән сүз, авырту бетмәгәндер.

— Авыртуы түгел, хәзер кычыта — үрсәләндерә прямо. Шул үзәккә үтә.

— Теңкәгә тия инде ул.

— Әйе.

Сестра салкын су эчереп чыгып киткәч, Коля тагын үзе:

— Сөйләп бетердемме соң? — дип сорады.

— Бетердең, Коля, бетердең, уйланма.

Боларның үзен тынычландырыр өчен генә әйтелгән сүзләр икәнен сизеп, ниһаять, Коля, егылуыннан соң беренче тапкыр көлемсерәп куйды.

— Нәрсә аркасында егылганны ник сорамыйсың?

Фәез дә көлеп кенә куйды. Шулай да Коля әйтте:

— Мин, куптаргач, бер калайны алып идәнгә атарга онытканмын. Беркетелгән дип, шуның өстенә таянганмын да...

— Коля, җитте, бүтән сөйләмә, барысы да аңлашылды. Исән калгансың — бик әйбәт, ничек исән калдың диген әле, җиде метрдан бетон идәнгә егылгансың бит!

— Мине бер нәрсә коткарды.

— Нәрсә?

— Очып барганда кинәт аңыма килеп, аяклар һәм куллар белән төшәргә тырышканым хәтердә. Чынлап та, тырышканмын бугай — күрәсең бит — баш исән.

— Аллага шөкер — исән. Калганы рәтләнер, Коля. Шулай бит? Врачлар инде шикләнми.

Коля күзләрен йомгалады, тагын көлемсерәде. Аның шушы карашы, ап-ак башы һәм гәүдәсе — бигрәк тә акыллы соры күзләре мәңге онытылмас сурәт булып Фәезнең хәтерендә калыр, ташка уелган шәүлә һәм сурәтләр шикелле, тыныч көннәрдә дә куркыныч хәлләр булуны, төзелешнең җиңел нәрсә түгеллеген сөйләп торыр... Җиңел түгел, тормыш шул — көрәш, бәрелеш Кама күкрәгендә балкыячак муенсага, күктәге йолдызлар санынча җемелдәгән җем-җем бизәкләргә, өр-яңа урамнар һәм бакчаларга, шул урамнарда йөрүчеләрнең көләч һәм кайгысыз чырайларына, көләч йөзле кешеләр кебек үк елмайган йорт-

лар һәм сарайларга — шул бәхетле дөньяга бер акыллы кеше карар да бу дөнья аңа зәңгәр һавадан төзелгән күк сарае шикелле җиңел тоелыр һәм аны бар иткән кешеләр дә шулай гел елмаеп, көлеп кенә эшләгәннәрдер дип уйлар һәм ялгышыр, бик нык ялгышыр. Пичугин шаһит — аның өчен бу көннәр тыныч түгел, аның өчен барыбер сугыш бу. Ихтимал, бер аның өчен генә дә түгелдер. Борис яшәгән кебек, ул уйлаган кебек кенә — тән ләззәте өчен генә яшәп кара син бу төштә һәм бу көннәрдә!

Пичугин, Фәезгә дә, язмышына да үпкәләмичә, туганнан алып ахыргача мәшәкатьле булган шушы әйбәт һәм алама дөньяга да бернинди шелтәле сүз әйтмичә, ята бирә. Күзләрендә ачу, өметсезлек тә күренми — анда тик сызлану... һәм үлемне җиңү шатлыгы гына бар. Исән калу мәгънәсендә түгел, ә үз куллары белән салган йортларның киләчәк елларда яшәячәген тоюдан — тел белән әйтелми торган шатлык ул.

— Ярый, исән булып тор, Коля.

— Тагын кил.

— Килермен.

— Бориска әйт, бүтән монда күренмәсен.

— Ник?

— Үзең дә беләсең бит... Миңа хатын әйтте.

— Нәрсә?

— Мине ул синең гаеп белән егылды дип сөйләгән. Әгәр үлгән булсам, сиңа зыян китерәсе дә булган икән.

— Белмим шул, Коля... Ярый, терел әле, шуннан соң сөйләшербез.

— Әгәр үлгән булсам, мине ул иң якын дусты дип атар иде. Каршы килүче булмас иде — мин тегеннән кайтып әйтә алмыйм бит инде ул дуска... Кара син аны, ә?! Мине корал итеп, сиңа каршы күтәргән, ә!..— дип, Пичугин тозлап-борычлап сүгенеп алды.

— Аныңча барып чыкмады, Коля, борчылма. Мин тагын килермен.

— Хуш.

Бориска Пичугин гозерен җиткерергә бик теләсә, җай да, вакыт та табылган булыр иде, әлбәттә. Ләкин, бердән, Фәезнең аны һич тә күрәсе килмәсә, икенчедән, андый авыр сүз йөртә алырлык усаллык юк иде аңарда. Фәезнең күңеленә беркетеп куйган бер кагыйдәсе бар: ачу килгәч, үзе югында кем хакында кем нәрсә әйтмәс? Шул начарлыкны җиткерү дуслык, я булмаса, гаделлек билгесеме? Юк, һич тә гаделлек тә, дуслык билгесе дә түгел бу. Сүзне әйткән кешедән бигрәк, аны җиткерүче яман, чонки ул үз сүзе итеп әйтәсе килгәнне, тәвәккәллеге җитмәү аркасында гына әйтә алмаганны куркакларча бүтән кешегә җиткерә. Юк, Фәез Коля йомышын хәтта үзенә этлек эшләгән Бориска да әйтә алмады һәм шуның аркасында кӧтелмәгән кыенлык килеп чыкты.

Тагын бер килүендә, Коля янында аның хатыны һәм Борис утыра иде. Фәез кереп исәнләшкәч, Коля аңа да кырыс кына итеп җавап бирде.

— Нәрсә, хәле тагын авырмы? — дип сорады Фәез Коляның хатыныннан.

— Юк, авыр түгел диделәр.

— Кәефе юк.

— Ятып туйды... Ике ай бит инде... Ятып кара әле шул гомер.

— Әйе шул.

Коляның начар кәефе, башкаларга да күчеп, аларны да сөйләшми утырырга мәҗбүр итте...

Шулай озак кына утыргач, Фәез Коля белән Борисның сүзсез дуэлен сизә башлады. Коля тегеңә әллә нинди кызганыч бер ачу белән — үзенең тора алмавын, көчсезлеген тоюдандыр бәлки — әледән-әле усал караш ташлый. Бориска уңайсыз, ул башын аска ия, читкә борыла яки

ара-тирә Коляның үтергеч карашын күреп, аңа көйрәп торган күзләре белән текәлә... Фәез белә: бу — рәхимсез дуэль, карашлар, күзләр сугышы. Кылычлар чыңлаган тавышлар ишетелгәндәй тоела... Әйтерсең Борис чигенә һәм, кысрыклана башлагач, тагын алга ыргыла... Кайчанга чаклы дәвам итәр бу сүзсез һәм утсыз сугыш?

Юк, авыру нервлар тиз биреште, менә ул, әллә нинди тавыш белән кычкырып, барысын да сискәндереп җибәрде:

— Шакал, козгын! Шакал! Барыбер үлмим! Үлмим!..

Фәез дә, Борис та шаккатып калдылар. Хатын тиз генә караватка иелде:

— Коля, нишлисең, нәрсә бар? Тынычлан, җаным, кычкырма, кешеләрне куркытасың.

Ләкин ире һаман ярсый бирде:

— Барыбер үлмим, шакал, юкка көтәсең. Сиңа ризык юк монда, сиңа азык булмаячак, бар, бүтән җирдән эзлә! Бар, кит!

Борис нәрсә булса да сизендеме, юкмы, әйтү кыен, ләкин куркуы хак, битләре ап-ак иде. Шулай да тотлыга төшеп, елмаерга тырышып, ишетелер-ишетелмәс кенә әйтә алды ул:

— Саташа!

— Саташа! — диде Коля, аны үчекләп.— Саташмый ни!

— Коля, җүләрләнмә, җитәр.

— Әйт әле син аңа: килсен әле яныма.

— Кемгә? Кем килсен?

— Шул, Борис дигән егет, килсен якынрак, иелсен.

Хатын турайды һәм аптырап, нишләргә икән, дигәнрәк кыяфәт белән Фәезгә һәм Бориска карады:

— Ул чакыра...

— Ник?

— Сүзем бар! — диде авыру чак кына тынычланган кебек.

Икеләнә-икеләнә генә Борис аның янына килгәч, Пичугин тагын боерды:

— Иел!

Һәм... секунд эчендә лач иттереп Борисның битенә төкерде! Тегесе башта битен ике кулы белән каплады, аннары исенә килгәч, кесәсеннән кулъяулык чыгарып сөртергә мәҗбүр булды. Югарыдан Коляга зәһәр ачу белән сөзгән кебек карап торды-торды да, ниһаять, кып-кызыл булып, аннары көл төсле күгәреп кычкырды:

— Котырган эт!..

— Ә син шакал, шакал! Бар, күземә күренмә, югал! Югал моннан яхшы чакта! — дип Коля үксергә тотынды.

Эшнең кая барып җиткәнен, тагы да ямангарак китәчәген төшенгән Фәез шулай ук җикерергә мәҗбүр булды:

— Кит, диләр бит сиңа, кит, кит яхшы чакта.

Борис монысын ук көтмәгән иде, ахрысы — коелды да төште — каршы сүз әйтергә батырчылык итә алмыйча, елардай булып, күзләрен йомгалады. Тагын бер сүз әйтсәң, ул да үксеп җибәрер кебек иде.

— Бар, җитте, кит,— диде Фәез, тавышын әкренәйтә төшеп,— ул сине күралмый.

— Барыгыз, алла хакы өчен! — дип ялварды хатын.— Аның да күзләреннән яшь тәгәри иде.— Барыгыз, тизрәк.

Коля исә:

— Барыбер үлмим, барыбер ашатмыйм, шакал! — дип һаман үксүендә булды.

Борис, моның үзенә әйтелгән сүзләр булуына һаман ышана алмыйча, тагын текәлеп Коляга озак кына карап торды да кырт борылып чыгып китте.

Авыру исә ул киткәч тә тиз генә тынычлана алмады — үкси-үкси һаман сөйләнә бирде:

— Көтә дә утыра бит, килә дә көтеп утыра — кайчан үләр икән дип көтә, авызларын ялмап-ялмап куя, шакал!

Сестра белән бергәләп, салкын су һәм дарулар эчерә-эчерә Коляны тынычландырдылар. Үксүеннән һәм сулкылдавыннан туктагач, Пичугин, күзләрен бер ноктага текәп, уйланып ятты. Нәрсә хакында уйлады икән ул бу минутта? Дөньядагы начарлык һәм яхшылык, яшәү һәм үлем кебек мәңгелек төшенчәләр һәм хәлләр турындамы? Әллә терелеп аякка баскач үзен нинди кыяфәттә күрәчәген уйлап борчылдымы? Әллә терeләчәген сизеп, планнар кордымы, яки исән калырына һаман ышанмыйча, бүгенгедән дә ямьсез һәм куркынычрак хәлләрне күз алдына китердеме икән?

Ни генә уйламасын, ниләр генә күз алдына китермәсен, аңа хәзер комачау итәргә ярамый, үзе уйласын, үзе хәл итсен һәм ял итсен.

Фәез ана җавап бирергә урын калдырмас өчен аның хатыны белән генә сөйләште һәм озакламый терeләчәгенә ышануын әйтте дә саубуллашып чыгып китте.

Ул көнне булган хәлне, билгеле, беркемгә дә сөйләп йөрмәсә дә, сүз үз законнары буенча, барыбер, гыйбрәт буларак, бөтен шәһәргә таралды. Баш идарә җитәкчеләренә дә ишетелми калмагандыр. Моны шуннан сизәргә мөмкин: кайбер идарәләрдә моңарчы Пичугинның егылуында Фәезне гаепләгән төслерәк сөйләшкән, һич булмаса, шулай серлерәк итеп караган, хәтта сорашкан кешеләр очраштырса, хәзер Фәезгә ул хакта әйтү түгел, хәтта шикле күз карашы да чалынмый башлады. Фәез йөзендәге күләгә бөтенләй юкка чыкты һәм ул элеккечә үк бирелеп үз эшенә чумды.

Бөтен нәрсә үз җае белән бара тора, кирпечкә кирпеч берегеп, стеналар, йортлар күтәрелә. Шлюз блоклары да, авырлык символы төсле, әкрен-әкрен өскә калка. Төзелеш турында газеталарда көн саен диярлек мәкаләләр басыла, радио тапшыруларында таныш исемнәр яңгырый. Фәез исеме дә еш кабатлана. Ләкин күп кенә әйберләр, күңел серләре, сводкалар һәм информацияләргә эләкмичә, шул серле көенчә кала бирә. Алар вакыт төшенчәсенә кагылмыйлармы әллә? Мәңге булган һәм булачак, бер-берсенә охшаган чиксез күп вакыйгаларның вариантлары гынамы болар?

Борис хәзер Фәез күзенә (бәлки аныкына гына да түгелдер) чалынмаска тырыша. Үзе эшләп киткән һәм хәзер эшли торган идарәсендә аңа караш бөтенләй үзгәрде: ул үзе белән ачылып сөйләшкән кеше туры килсә, хәтта гаҗәпләнеп карый. Андый кеше Пичугин вакыйгасын белмәгән булып чыга...

Шәһәр һәм аның тирәсендәге юллар буйлата таныш машина — карасу-зәңгәр «Волга» уза... Көн саен диярлек күрергә мөмкин аны. Ләкин машинада Гетаны да, хәтта кибетче кызны да күрермен димә хәзер, Борис янында шактый таушалган кыяфәтле кызлар күренеп калыр...

Бер карасаң, егет үз машинасы булган, бөтен шартын китереп, тулы тормыш белән яшәгән бәхетле кеше кебек. Ә икенче карасаң, ул шундый кызганыч, бөтен халыктан аерылган, ихтирамга мохтаҗ мескен бер кеше... Ах, Боря, Боря, үз теләгең, үз мәнфәгатьләрең белән генә йөри торгач, бу машинада кая барып чыктың син?

Ярый, Фәезне югалтуың зур фаҗига түгел ул. Ә син бит үзеңне чын күңелдән яраткан һәм киләчәктә дә шулай ук яратуы мөмкин булган иң якын кешеләреңнән дә үз теләгең белән аерылдың, кадерләрен белмәдең. Хатыныңны, балаңны ташладың, Гетаны, сатучы кызны... Һәр ике идарәдәге иптәшләреңнең җылы карашын югалттың. Баш идарә җитәкчеләре хакында әйтәсе дә юк инде. Выжлап узган машинаң

артыннан: «Борис, тукта, борыл, кирәк якка борыл!» — дип кычкырасы килә дә бит, нишлисең, булмый — һаман чаба бирә карасу зәңгәр машина. Кая таба чаба? Еракка мы?

Беркөнне кинога чират торганда Фәез Гетаны очратты. Ничектер, чистарынган, тагын да матурланган. Моның мәгънәсен чамалады Фәез...

Гета үзе дә аска карап елмайды.

— Борисны күргәнең юкмы, Фәез?

— Юк, күрәсем дә килми.

— Минемчә, аның хәле шәп түгел.

— Кайчак кызганам да, ачу да килә. Җанны өшетте тик...

— Мин дә кызганам хәтта.

Тагын кино карадылар. Саубуллашканда, беркөнге таныш коймага кулын куеп, Гета авыр сулап әйтте:

— Яхшы кеше син, Фәез. Синең кебек булсын иде...

— Кем?

— Әйтмим, үзең беләсең.

Шулай диде дә кыз тиз-тиз атлап өенә кереп китте.

Фәез аны аңлады, билгеле. Ләкин аңлап нишлисең? Күңелдә бүтән кеше бит...

* * *

Ялга каршы көнне Фәезнең кәефе әйбәт түгел иде. Уйлап-уйлап торды да бер нәрсәне ачыклады: аңа эштән дә мавыктыргычрак бүтән шөгыль юк икән. Уку бу исәпкә керми. «Хоббиегыз нинди?» дип сорасалар, ул «Сунарчылык», дияр иде. Ләкин хәзер яз — ауга йөрү тыела һәм кешелексезлек тә була (җәнлекләргә яки кошларга карата). Яна кинофильм юк, спектакль турында әйтеп тә торасы түгел. Кая барырга? Барыр җир юк. Чак кына элегрәк булса, ул бернинди икеләнүсез Борис янына китәр иде. Ә хәзер — арада бетон тау... Шулай итеп, кемгә барырга? Соңгы вакыттагы күнел әрнешләреннән соң бераз ял итү кирәк иде. Аның яшендәгеләр һәр кич диярлек танцыга йөриләр. Фәез ничектер моны кешелек дәрәҗәсен кимсетә торган кимчелек дип исәпли... Әле кичә генә берүзе калды дип, Борисны кызганса, бүген үзенен дә аннан артык җире юк икәне ачылды. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында курыкмый ишек кагарлык кеме бар соң аның? Гетамы? Тфү, нинди мәзәк уй керә күңелгә. Лазарев? Аңа барырга мөмкин дә булыр иде, ләкин беркөнге җайсыз хәлдән соң, хәзер беркайчан да аның бусагасына аяк басмаячак Фәез.

Шулай, Фәез эштә генә коллектив члены, эштә генә көчле, ә шәхси тормышында Борис кебек үк ялгыз, Борис кебек үк кызганыч бугай...

Тукта!

Фәезнең исенә кылт итеп Гөлнисаттәйләр төште. Алар бит аны күптәннән бирле чакыралар. Теләсә кайчан күрешсәң, теләсә кайчан керсәң дә кыенсынырлык кешеләр түгел — даһи гадилек. Бөтенләй үк ялгыз түгеллегенә сөенеп, Фәез Гөлнисаттәйләргә китте.

Ишекне Рабига әби ачты һәм ачкач шикләнә калды:

— Исәнме, әби.

— Исән әле, балам. Кем дип әйтим соң сине? Әйдә, түргә уз. Моннан килешмәс.

Ишектән узгач та Фәез тукталып калды:

— Гөлнисаттәй өйдә юкмы әллә?

— Юк шул. Күргәндәй дә булам үзеңне, кем буласың соң син?

— Мин Фәез дигән кеше булам.

— Фәез? Безнең Фәезме?

— Белмим шул, кайсы Фәезне әйтәсез икән?

— Мин инде шул Иске Чурайда безгә кереп йөргән Фәезне әйтәм. Безгә монда фатир биргән Фәезне.

— Фатирны мин бирмәдем, әби, дәүләт бирде, шәһәр Советы һәм баш идарә. Мин алардан үтендем генә, алар бирергә кирәк таптылар.

— Шул инде, син әйткәнгә күрә бирделәр. Шул Фәезмени әле син, балакаем. Үсеп беткәнсең.— Шулай дип әби аның аркасыннан какты.

— Анысы булгандыр инде.

— Син шул Фәезме инде, балам?

— Шул.

— Әй, рәхмәт төшкере. Мин, ачык авыз, түргә дә чакыра белмим тагы. Баш юк шул, гүпчи бетте баш. Әйдә, балам, кунак булырсың.— Үзе Фәезнең пальтосын салдырмакчы.— Сырманны сал, балам, өй җылы, аллага шөкер. Миче булмаса да, җылысы килә, хикмәт. Мәзәк кенә инде бу шәһәр өе.

Фәез түргә узды. Өй эчендәге җиһазларның житкелекле түгеллеге кергәч үк күзгә ташлана икән. Гади тактадан ясалган өстәл, аның янында бер урындык һәм артсыз ике утыргыч. Ләкин барыбер ямьсез түгел, хәтта келәмнәр белән капланган бик күп квартирлардан монда күңеллерәк сыман — чөнки әби чын күңелдән яратып сөйләшә, бернинди гаеп итәр дигән уй килерлек түгел.

Рабига әби йокы бүлмәсенә кереп кем беләндер пышы-пышы сөйләште дә кире чыкты:

— Рәшит... Кай арада күнекте, шәһәр ялкавына әйләнде. Шушы көнгә хәтле йоклый, бичара.

Ул сүзен әйтеп бетергәнче, тегесе елмаеп килеп тә чыкты:

— Син, дәү әни, куй әле. Сәгать өчтә генә кайттым бит — йокы туямы шул арада!

— Акыллы булсаң, кич иртәрәк ят,— дип тиргәгән булды әбисе.

— Соңрак тор...— дип сүз кыстырды оныгы.

— Иртән иртүк тор — менә булырсың кеше. Минем әти әйтә торган иде: бәхетне, бәләкәчем, иртән өләшәләр аны, чыпчыкларны кара, чык түгел, бәхет эчәләр алар, кояш күтәрелгәнче көтсәң, бер тамчысы да калмый аның, ди торган иде, мәрхүм. Дөресе дә шул — йокы яратсаң, бәхетсез каласың.

— Авылда гына шулай ул, әби. Шәһәрдә аларга эчәрлек чык юк, чык төшәрлек агач та юк. Мин тиз генә юыныйм инде, гафу итегез,— дип, Рәшит ванна бүлмәсенә кереп китте.

— Бик начар, балам, дөрес әйтә ул — мең өйгә ун агач юк, ачуым да бер килмәгәе. Менә безнең авылда ул... менә агач, менә үлән — иртән чыгасың да атлап китәсең — чыклы үләндә эзләрең аермачык кала. Әй, авыл яшеллеге... Әй, авылымның матурлыгы!

Рабига әби утыргычка утырды да яулык очы белән күзләрен сөртте. Фәез аны тынычландырырга кирәклеген сизеп:

— Рабига әби, авыл үзенә матур, шәһәр үзенә матур инде ул,— диде.

— И балакаем, үзенчә дә матур түгел икән монда, бүтәнчә дә түгел икән.

— Ник алай дисең, әби? Нинди матур яшисез менә... Яп-якты иркен өй...

— Яктылыгы да ул түгел аның. Бөтенләй бүтән ул.

— Ягарга кирәк дип хәстәрлисе юк, суга барасы юк.

— Әйе шул, суы да өйгә керә — көянтә-чиләк асып барыйм дисәң, коесы гына да юк. Көянтә-чиләк белән суга көлешә-көлешә йөргән кызларны бер күрергә тилмереп саргаям.

— Су үзе өйгә кергәч, көянтәнең ни хаҗәте бар?

— Менә бар шул, миңа кое кирәк, көянтә кирәк, чылтырап торган чишмә кирәк. Шуннан узганда җәйге челләдә битләреңне-кулларың-

ны юсаң — дөнья рәхәте. Монда ул акча биреп алыйм дисәң дә табылмый. Юк инде, юк, балам, шәһәрне макта да авылда тор икән аны. Ялгыш булды күчү, гүпчи ялгыш булды, балам, күңелеңә авыр алма.

— Бая гына квартир биргән кешеләргә рәхмәт укыдың, әби.

— Хәзер дә укыйм, балам, шушы хәтле өйне бушка, бер тиенсез биргән кешеләргә ничек рәхмәт укымассың инде. Бирүегезгә рәхмәт инде. Әмма да миңа кирәкми бу фатир — миңа авылдагы җимерек өем кирәк. Миңа хәзер яз җитә — ничек итеп түзеп ятмак кирәк монда — исемә төшкәч тә йөрәгем жу итә.

— Үзеңә берәр шөгыль тапсаң, әби, искә дә төшмәс ул.

— Шөгыль тапсаң да төшәр, балам. Аннан ары, минем кебек кешегә шөгыле дә юк инде аның. Булса да, миңа ятышлы булмас ул. Минем хәзер каз утырта торган, бәбкәләр чыгарта торган чагым. Шулар белән пайпылдаша-пайпылдаша яшәүне нәрсә белән алыштырмак кирәк инде. Юк инде, юк. Яз көне кулга каз күкәйләре тотмыйча ничек түзәрмен инде, искә төшсә, исләрем китеп, йөрәкләрем сыза.

Әбине үгетләүдән файда юк икәнен, аның авылын чын күңелдән сагынуын Фәез тәмам төшенде, хәтта шул сагыш аның үзенә дә күчкән һәм йөрәген сызлаткандай тоелды.

— Бигрәк җирсим шул, балам, бигрәкләр дә жирсим. Рәшиткә әйткән идем дә — әни кайтсын әле, ди, ул кайткач сөйләшербез, ди.

Юынган һәм күңеле тагын да күтәрелгән Рәшит ванна бүлмәсеннән балкып чыкты:

— Ух, әби, салкын душ... Искиткеч... әллә син дә коенасыңмы?

— Ходай язмаганны... әллә котырдыңмы? Мин нишләп салкын суга керим ди.— Әби монысына да бик ихлас ачуланды — аның өчен шаяру дигән нәрсә гомумән юк, ахрысы.— Үзебезнең чишмә суын сагындым. Килен генә кайтсын... Миллек белән чабынуга ни җитә эссе мунчада!

— Гөлнисаттәйне әйтәсезме, әби? Ул кайда соң?

— Санатурий диләрме соң, сантаяләт диләрме... Ерак моннан, бик ерак, Каф таулары ягында, ди. Элек заманда җеннәр генә яши торган җирдә... Әкият.

— Пансионатта ял итә әни.

— Әйе, бик дөрес әйтәсең, сантиянәт.

Рәшит өстәлгә бер тәлинкә киселгән ипи чыгарды:

— Яна торган путевка булган ди... Барырга ашкынып торучы бүтән кеше булмагач, әнигә биргәннәр.

— Кәгазен күрсәтте — алдаганнар икән, янган дип, чип-чиста матур кәгазь.

— Отпуск алырга вакыты житкәнмени әле Гөлнисаттәйнең?

— Авылда каравыл торганнары белән житкән шул.

— Ә! Мин оныткайммын анысын. Ну, ничек соң? Хат язамы?

— Яза, ике хаты килде инде,— диде Рәшит һәм тагы кухняга чыкты.

Әби исә йокы бүлмәсенә кереп, олы бер китап алып чыкты:

— Корьәнме, әби?

— Корьән, балам. Менә мин авылга алып китсәм, нишләрләр инде, корьәнсез өйгә җен иялашә бит ул.— Әби китап арасыннан хат табып чыгарды.— Укы әле, улым.

— Рәшит укымадымыни?

— Аның эше... Ашык-пошык.— Хатны конвертыннан алып укбирде.

Латин хәрефләре белән язылган... Бу хәрефләр белән яза торган бер буын бар шул... Утызынчы еллар яшьлеге — бер карасаң, илнең иң якты, кояшлы — тагын да ямьлерәк киләчәк вәгъдә иткән еллар, ә бер карасаң, тарихта буталчык аянычлары белән йөрәкләрне һаман

да тетрәндерә торган ялгышлыклар, адашулар... Шундый бер чор, яхшысын да, яманын да сызып ташлау мөмкин түгел. Һәм кирәкми, сызып карасаң, менә шушы латин хәрефе белән яза торган буын яшьлеген юкка чыгару булыр иде ул... Ә кеше алдагы гомереңең бер өлешен бирсә бирер, ләкин күңелендә мәңгелеккә калган хатирәләрне, иң матур елларны — яшьлеген, мәхәббәтен һәм кабатланмас хыялларын барыбер бирмәс.

Фәезгә хат шундый изге хисләр белән бизәлгән төсле тоелды. Бизәкләр — хәрефләр үзләре... латин хәрефләре.

Укырга керешим дигәндә, Рәшит өстәлгә үзе кирәк тапкан барлык ризыкларны чыгарган иде инде.

— Кичәгедән калган аш... Мин яратам, сез ничек? — дип Фәезгә карады ул.

— Мин дә.

— Ашыйбыз алайса.— Кухнядан башта Фәезгә, аннан соңрак үзенә бер тәлинкә аш чыгарды да тагын кереп китте. Кулында — ярты литрлы.— Безнең өйдә сез беренче тапкыр, төшереп алмый ярамас.

Фәез дә елмайды:

— Что син, Рәшит, әби алдында.

— Әби андый түгел безнең, дөнья күргән. Ник чакырмыйсың дип үзе теңкәгә тиде инде.

— Юк, балам, җаныгыз теләгәнчә эшләгез, миннән куркып утырырга, теге. Дөньясында ни булса, сезгә дә шул инде. Күз тимәсен, безнең Рәшитебез ул хәтле артыгын кыланмый — исерек чагын күргәнем юк, әйтмәгәнем булсын.

Әби Фәез кулындагы хатны алды: — Башта ашап-эчегез, соңыннан укырсыз инде.

Ә ашап-эчкәч, әби шундук кухня ягыннан конвертны яңадан тотып чыкты.

— Мә, Фәез балам, хәзер укы инде иркенләп Гөлнисаттәңнән килгән хатны.

— Җитәр инде, дәү әни, егерме кабат укыдым бит инде,— диде Рәшит һәм әбисенә кул селтәде.— Синең шул булыр инде...

— Бәй, укысаң соң... Менә тагы, бар икән... Кеше белән бер кат сөйләштем инде дип, икенче кабат сөйләшмәскә дигән сүз бармыни?! Бүген сөйләшсәң иртәгә тагын сөйләшергә сүз кала ул. Укы, балам, син дә укып күрсәт.

Чын күңелдән әйтелгән үтенечне ничек үтәми була инде. Фәез, бая ук укып бирмәгәнгә үкенеп, урыныннан торды да, әбигә иркенләп тыңларга җайлырак булсын дип, тәрәзәгә табарак барды һәм, тегесе шундагы урындыкка утыргач, хатның конвертына күз салды. Конвертның тышындагы ямь-яшел күренеш монда кышкы салкында күңелне әллә ничек җылыта торган төс икән шул! Беренче планда «Орленок» пионер лагере. Өч яшел тау. Алдагысы зур, уртадагысы (ераграгы) кечкенә булып күренә, сул яктагысы башланып кына кала, конвертта анысына урын җитмәгән. Тоташ тәрәзәле йортлар каршында ук шикелле төп-төз кипарислар күккә кадалган. Алар янында кызыл күлмәкле кыз балалар... Рәсемнең кырыена «Туапсе» дип язылган.

— Туапсега ук киттемени Гөлнисаттәй? — диде Фәез, рәсемнән күз алмыйча.

— Әйе, шундый шәһәр ди, Каф тавы артында ди ул.

— Артында ук түгел дә... Ну, шул тирәдә.

— Ыы-ы...— Әби шул ерак тауларны күрергә тырышкандай күзләрен тәрәзәгә, офыкка төбәде дә иреннәрен очлайтыбрак тынып калды. Фәез исә нәкъ язылганча, хаталарын төзәтми-нитми, укырга кереште.

«Исәнме сез!.. Дөньяларда ин кадерле әнкәм белән улыма шулай ук Краснодарский райдан сагынып кайнар сәлам. Язучы Гөлниса

Кадерле әнкәм и улым, мин бик яхшы гына ял итеп ятам, бик күңелле монда, 18 градус җылы, плащ белән йөрибез. Ә көндез эссе була, моннан кайтасы да килми, әнкәй. Шундый табигать үзенә тарта, гел үзенә карата, күземне аласы килми, әнкәй. Мин әле 5 кенә көн ял итәм. Халатым ярамый, сыймыйм, әнкәй. Чаллыга кайткач, син мине танымассың, танысаң да, бәлки, киемемнән танырсың. 5 көн эчендә ике килога арттым. Монда без торган җирдә зур кибетләр юк. Бернәрсә алганым юк. Мена Сочига экскурсиягә барасы диләр, шунда карармын. Көн саен экскурсиягә алып йөриләр и акча да сораган кеше юк. Күп вакыт Кара диңгезгә төшәбез үзебез, 380 баскыч төшәбез, диңгезгә, әнкәй. Диңгезнең суы бик күп, әмма тозлы, эчеп карагач, шуны белдем, әнкәй. Менә төнге сәгать 12, маржа йоклый, ә мин сезгә хат язам. Кара диңгез дә йокламый, шаулый, мин дә йокламыйм, сезгә хат язам, мин, әнкәй, шунсыз йоклый алмыйм, ну үземне бик яхшы хис итәм, әнкәй, минем өчен борчылма, ничек килгәнмен әле, торган кумытны күрсәң, исең китәр. Көн саен кино була, билет 20 тиен тора, карточкаларга төшерделәр. Син, әнкәй, ышан, бик яхшы монда, мин үзем шуннан куркам — бик юанланам дип кенә. Монда хәзер дә әфлисун бар, алып ашыйм. Менә, әнкәй, үзегездә нихәл, авырмыйсызмы? Әнкәй җаным, хатка язып кына бетереп булмый, исән-сау кайткач сөйләрмен барын да и сөйләп тә бетерә торган түгел. Кайтканда самолет белән кайтырмын дип торам. Менә шулай, әнкәй җаным, хуш хәзергә, сагынып хат язучы киленегез Гөлниса».

Хатны конвертка салгач, Фәез әбинең кыяфәтенә карап куркып калды — шундый җитдилек, шундый уйчанлык! Күңеле белән әби ниндидер бүтән дөньяларда гизә... Әллә ул да ерак Кара диңгез ярларына барып чыкканмы? Әбинең уйларын куркытырга, урыннан кузгалырга базмыйча, Фәез шундый ук җитди кыяфәт белән Рәшиткә күз салды. Анысы шахматта нindидер мәсьәлә чишеп утыра иде. Карашлары очрашкач, әбигә күз ташлады да тагын шахмат тактасына иелде. Ниһаять, әби тирән итеп көрсенгәч:

— Каф тавында кыш көне дә яшел микәнни? — дип сорады.

— Шулай дигән шул. Сез әйткән оҗмах шул була торгандыр инде ул, әби. Әфлисуннар ашыйбыз дигән бит.

— Булса да... безнең Иске Чурайга җитәме соң инде! Кая җитсен, юк, безнең анда бөтенләй икенче чут бит. Бер дә Каф тау артларына йөрисе юк. Андагы яшеллек, андагы иркенлек... Безнекенә җитәме соң инде, исәр... Гөлниса киленне әйтәм. Әллә нинди чит-ят җирләргә исе китеп йөри икән, үз җиреннән бизеп, адәм тәганәсе... Алла каргамасын тагы. Кайтып күрергә насыйп итсен. И авылдагы яшеллек, андагы иркенлек...

— Анда кыш көне яшел түгел бит, ә Каф тавы артында кыш бөтенләй диярлек булмый.

— Сөйләмә, балам, көферлек йокмасын үзеңә — бездәге яшеллек, бездәге иркенлек бүтән бер җирдә дә юк ул. Эзләмәгез дә, нитмәгез дә — сез аны барыбер табалмассыз. Андагы чишмәне — тау астыннан үзе тишеп чыккан изге чишмәне күрсәң — диңгез ишемени! Шул чишмәне рәнҗетеп бит, әллә нинди тозлы суны мактамаса... Әбәү!

Әбинең үрталүе төсенә үк чыкты. Ул, кул селтәп, урыныннан кузгалды. Шуннан соң гына Фәез Рәшит янына, диванга утырды:

— Әбинең хәтере нык калган хатларга...

— Үзе тагын укыта ул аларны, егерме икенче кат. Аныкын белмәссең.

Кухня ягына кереп киткән әби бу якка тиз генә чыкмады. Егетләр ким дигәндә ике сәгать шахмат уйнадылар. Фәез китәргә кузгалгач (каян сизгән-ишеткән диген), әби ялт итеп бу якка башын сузды:

— Чәй кайнаттым, балам, чәй эчеп китәрсең.

— Эчтек бит инде, әби, рәхмәт.

— Тагын эчәрбез, рәхмәте шуннан соң булыр.

— Рәхмәт, әби, рәхмәт,— шулай дип, Фәез ишеккә таба юнәлде.— Тагын да эчәрбез әле, ходай насыйп итсә.

— Менә монысын әйбәт әйттең, балакаем, тәүфыйклы бала икәнсең. Алла сине ташламас, бәхетле бала булырсың.

— Ярый, әби.— Фәез перчаткаларын кесәсеннән чыгарды да кулын Рәшиткә сузды. Елмаешып кул кысыштылар. Ишек ачам дигәндә, әби туктатты:

— Карале, балам, бу арада безнең Чурайга барганың юкмы?

— Баргаладым, әби.

— Безгә кермәдеңме?

— Анда бит беркем дә юк хәзер.

— Булмаса соң... Барыбер... Безнең җаннарыбыз шунда. Габделисламның җаны шунда...— Фәез ни әйтергә белмичә уңайсызланып, тагын ишек бавына тотынгач, әби әйтеп калырга ашыкты: — Икенче юлың төшсә, керми калма, яме, керә йөр. Исән генә тора микән инде? Сүтеп якмасыннар тагы.

— Юк, сүтмиләр, сүтмиләр. Капкалар бикле, тәрәзәләр тактлы, әби.

— Алаһемә саллигале... Рәнҗетәбез бит ходайны, рәнҗетәбез туган нигезне. Әллә ниләр күрербез әле, алла сакласын. Ярый, исән йөр, балакаем, барсаң, бүрек салып, сәлам биреп булса да кит, яме.

— Ярый, әби. Хуш булып тор.

Ник икәнен дә аңлап бетермәстән, Фәезгә әллә ничек ямансу булып китте. Тәрәзәләре кадакланган өй кышкы салкында иясен җуйган маэмай төсле шыңшып, зар елап торадыр сыман тоелды. Ә әби монда. Үзе монда яшәсә дә, күңеле барыбер анда, салкын өйдә туңа... Эх, бу дөньялар!

Фәезнең күз алдында ике шәүлә барлыкка килде — каядыр еракка, үткән заманнарга күзләрен текәп тын калган әби һәм... яшьлек кыяфәтле, Кама кыяфәтле кыз. Үткән заман һәм киләчәк заман... Аларның икесен дә рәнҗетмәскә, икесе хакында да уйларга кирәк. Әби өчен син узган көннәрне, узган хатирәләрне коткар, ә кызга киләчәкне сакла... син әби белән кызны берләштер...

Әби һәм кыз...

Уйлап чыгарылган төшенчәләр, фантастик көчләр генә түгелме болар? Күзеңне кинрәк ачып, кул селтәп кенә котылып булмый алардан? Юк, булмый, алар бар, икесе дә — җирдә. Котылырга, күрмәскә мөмкин дә булыр иде, ләкин андый теләк үзе юк — алар белән дөнья тулырак, алар белән күңел тынычрак, бөтенрәк, ямьлерәк. Әби күңелен күрим дисәң, тәрәзәсенә такта кагылган өйгә яңадан тормыш кертергә кирәк. Ә моның өчен Рәшит анда кайтырга тиеш. Ул кайтса, аның кебек меңнәрчә егетләр өйләренә инде китеп таралса, каланы кем салыр? Каланы салмасаң, бәлки Кама да шатланыр — аның яшеллеге (әлеге дә баягы яшеллек — нинди сихерле төс ул?!) кимемәячәк.

Әби белән кыз...

Яшеллек һәм тимер.

Синең тәндә һәм җаныңда шулар очрашты — син аларны бергә кушарга һәм түзәргә, аларны да, үзеңне дә имгәтмәскә, бөтен килеш сакларга тиеш.

«Изге һәм ямансу әби!

Син яраткан чишмәләр мәңге корымас, син яраткан кошлар чык эчә торган яфраклар мәңге саргаймас, тирәкләрең мәңге шаулар —

без аларга кагылмабыз. Яшел дөньяң, яшел тынычлыгың, изге хатирәләрең гүзәллеге һәлак булмас, кайгырма, әби, тыныч бул!»

«...Гүзәл әкиятем минем, Кама, утлардан тезелгән муенса... Болай да матур күкрәгеңә төшеп торган энҗеләр җемелдәве... Синең сулышың белән күтәрелеп-күтәрелеп куйган балкышлар — синең сөенечләр, минем шатлыклар — безнең мәңгелеккә кабынган мәхәббәтебез... Алар да булачак, ул көнне син күрәчәксең, Кама, мин сине яраткан кебек үк, син дә мине ярачакчаксың. Шул җавабыңа рәхмәт рәвешендә, мин сиңа шундый ук асыл балкышлы йөзек — өр-яңа кала бүләк итәчәкмен. Ил сүзен ни өчен мин әйтәмме? Чөнки яңа завод, ул яңа шәһәрне безгә йөкләделәр бит. Менә шулай, Кама дустым, муенсаны да, алмаз кашлы йөзекне дә без бүләк итәчәкбез сиңа! Димәк, мин дә, әйе, мин дә!

Ярый, син миңа һаман эндәшмисең әле. Ачуың — салкын кыш, ап-ак кар шул әле. Ләкин синең аклыгыңда — февраль яктылыгы. Февраль төсе сине дә балкыткан, шәһәр салыначак дигән яңа хәбәр, мөгаен, сине дә шатландырган! Тик син аны миңа әйтергә иртәрәк дисеңдер, ышанып житмисеңдер. Ә яз житкәч, аңларсың әле. Мин моңа язның киләчәгенә ышанган кебек ышанам. Менә без шунда сөйләшербез — язгы шау-шулар, язгы ташкыннар телендә! Безнең аңлашу, безнең әйтелгән мәхәббәт шулай башланыр. Кама, мәхәббәтем минем, Кама!

Минем хәзер бернинди шигем, икеләнүем калмады, чөнки аңлашылмаган нәрсәләр юк бугай инде, хәзер үземне борчып торган барлык сорауларыма җавап таптым бугай. Ничек, кайчан дисеңме? Тыңла...»

* * *

Җыелышлар безне куркытып бетергән. Көн туса — кирәкле җыелыш, көн туды исә — кирәксез җыелыш. Адәм туйган ул җыелышлардан. Ләкин мин аларның сиңа кирәклесе хакында әйтмәкче булам, бу хакта бүтән сөйләшмәскә сүз бирәм, ә бу юлы соңгы тапкыр буларак әйтми калырга ярамый торган җыелыш хакында (ике-өч сүз белән генә) сөйләмәкче булам.

Бу көн — 1970 елның 21 феврале — Чаллы шәһәренең яңа елъязмасында истәлекле сәхифә булып калыр. Газеталарда шулай дип яздылар. Мин бу юлы ышанам аларга — чөнки үз күзем белән күрәм бит — күпме гасырлар буе бер чамадарак торган шактый буталчык каланың өр-яңа биографиясе башлана! Аның киләчәге хакында мондый да җаваплы һәм әһәмиятле (әйдә, монысы да газетадагыча булсын!) җыелышның беренчеседер әле бу. Мондый да зур игътибарның һәм ихтирамның беренчеседер. Көн тәртибендә — Чаллы... Җыелыш Казанның иң күркәм урынында, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында бара.

Театрда — яңа Кама, яңа Чаллының беренче таш нигезләрен, диварларын куйган, беренче стеналарын күтәргән алдынгы әһелләр.

Театрда — проектчы галимнәр, конструкторлар, инженерлар, энергетиклар, планлаштыручылар (ләкин хыялыйлар түгел), төзү материаллары табучылар (юкны бар итүче, кирәксә, кош сөте табуны да үз өсләренә алудан курыкмый торган тәэминатчылар һәм сәүдә кешеләре (ләкин сәүдәгәрләр түгел), колхоз председательләре, совхоз директорлары (алардан җир сорыйлар бит — алардан да дәрәҗәле кеше юк бүген), архитекторлар, художниклар, язучылар һәм башкалар, һәм башкалар.

Театрда — сәхнәдә, партерда, ярусларда һәм барлык-барлык галеркаларда — халык тулы. Халык тулы, ләкин тамашачы юк.

театрда әр-яна вакыйгалар төенләнә, ләкин чишелеш тиз генә күренмәячәк: сулар агышы туктамаган кебек, әр-яна «КамАЗ» маркалы автомобильләр күтәргән конвейерлар агышы тукталмаган кебек, су өсләрендә, шлюз һәм плотина тирәләреннән ургылып яктылыкка әверелгән дулкыннарның чиге кителмәгән кебек, монда башланган вакыйгалар да ерак гасырларга тоташачак.

Сәхнәдә — СССР Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары, КПСС Үзәк Комитетының җаваплы кешесе, СССР автомобиль промышленносте министры, шулай ук СССР һәм РСФСРның бүтән министрлык һәм ведомство вәкилләре.

Барысы да, барысы да безнең Чаллы турында сөйлиләр.

Трибунада — Партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре... Чаллы хакында сөйли.

Трибунада — партиянең Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Кама хакында сөйли.

Калган барлык кешеләр — тыңлаучылар, ләкин тамашачылар түгел.

Безнең төзелешне комсомол яшьләр төзелеше дип юкка гына әйтмиләр икән — уртача алганда, безгә егерме биш яшь!

Егерме биш яшь!

Шәһәрне яшьлек төзи, шәһәрне егерме биш яшьтәгеләр сала!

Яшьлек — романтика дигән сүз, гүзәллек дигән сүз... ләкин шул ук вакытта тиле яшьлек дип тә йөртәләр аны, онытмыйк, онытмыйк... соңыннан үкенергә калмасын.

Яшьлек — җидешәр тонналы, теләсә нинди юлсызлыклардан да курыкмый торган машиналар тудырачак...

Аларга без хәзер ясый торган бәллүләр һавада, биеклектә чайкалачаклар!

Бу бәллүләрдә тирбәлгән автомобильләр дөньяда иң гайрәтле баһадирлар булачак.

— Колхозчылардан төзүчеләргә ялкынлы кайнар сәлам. Ләкин җирнең кадерен белегез, ул — без алтын үстерә торган җир... Небоскреблар салыгыз! — Колакларда шундый сүзләр дә яңгырап калды.

Әгәр Фәез трибунада булса, ул да нәкъ шулай дияр иде. Җирнең генә түгел, суның да кадерен белегез, дип өстәр иде, Кама йөзен каралтмагыз, рәнҗетмәгез, үзегезнең вөҗданыгыз аның суы төсле булыр, дип өстәр иде. Ләкин аның сүзләрен бүтәннәр әйтә. Әйтсеннәр соң — кем әйтсә дә барыбер түгелмени?! Әнә, яңгырап тора аның сүзләре... Әнә аның сүзләрен Лазарев сөйли.

— Уен эш түгел. Без завод һәм ГЭС кына салмыйбыз. Портлар, урамнар гына, шәһәр генә төземибез, без кешеләрнең тормышларын, язмышларын да яңартып корабыз. Без язмышлар турында кайгыртабыз, яңа кешеләр, яңа бәхетләр хакында. Кем әйтә әле безне кирпеч кенә тезә белә дип? Яңа тип житәкчеләр, үзләре кул астында эшләүчеләрнең, бер генә кешенең генә рухын имгәтсә, җимерсә, нинди житәкче инде? Әгәр кеше күңелен таптый икән, нигә кирәк ул автомобиль?!

Кама буена көннән-көн күбрәк кеше килә. Шундый зур коллективны иске методлар белән җитәкләү мөмкин түгел. Кешеләрнең һәм эшчеләрнең күплеге инженерлар хезмәтен оештыруда принципиаль яңа схемалар таләп итәчәк. Зурлыгы ягыннан бөтен тарихны шаккатырырлык төзелеш мәйданында һәр тармакның кайчан, нәрсә эшләп житкерәчәген һәм башка тармакларга моның ничек кагылуын хезмәтне фәнни оештырусыз белү мөмкин булмаячак. Бер тармакның үз эшен кирәгенчә башкармавы аркасында бүтән тармак интекмәслек

булсын өчен барлык звеноларда заданиеләрнең төгәл үтәлүен, барлык тармакларның үзара төзек механизм булып берләшүен шунсыз күз алдына китерү мөмкин түгел. Шулай ук безгә материаллар, механизмнар җибәрергә тиешле бүтән шәһәрләр һәм ведомстволардагы предприятиеләрнең дә безгә өзелмәслек шкифлар, ныклы график белән бәйләнүен алдан ук хәл иткән булырга тиеш без. Төзелешне бүген шактый каты бизгәк тота икән, бу әнә шул механизмны без әле барлыкка китерә алмаганбыз дигән сүз. Безнең заманның чын геройлары — иҗат кешеләре! Фәнни җитәкчелекне без иҗат итәргә тиеш!

Тукта, Борис әйткән фәнни төгәллек хакында сөйли түгелме соң бу? Шундый механизм хакында? Борис моны күптәннән әйтеп килә, димәк, ул ерактанрак күргән, күбрәк күргән һәм белгән... Ә без кайчандыр аңа каршы килеп, аның эш формасын һәм производствога мөнәсәбәтен яраксыз дип, ялкаулык һәм мещанлык дип каһәрләп, кешене чыгырыннан чыгарып ташладык та — хәзер аның сүзләрен сөйләп, дөньяга үзебезне акыллы итеп күрсәтәбез түгелме соң? Гаделлекме бу? Юктыр, гаделлек бездән еragrак качкандыр бу вакытта. Әле соң түгел, Лазарев белән икәүләп үз хатабызны танырга һәм Бористан гафу үтенергә кирәк икән безгә — шунсыз ярамый, шунсыз үзебезне ихтирам итәргә хакыбыз калмас безнең. Ә үзеңне үзең ихтирам итә алмагач, дөньяда яшәүнең нинди мәгънәсе кала?

Әйе, фикерләр туры килә. Ләкин Борис үзе проблеманы ник менә шушылай итеп кантары белән күтәреп чыкмады соң? Уйлау — бер нәрсә, ә эш — икенче... Шактый зур аерма... Көрәшсез принцип — тормыштан читләшү. Шундый көрәшсез принцибы Борисны әшәкелеккә китерде. Үзе аңлыймы икән шуны? Сизә башладымы икән?

— Якындагы иң зур бурычларның берсе — йортлар төзү комбинаты салу. Чаллыдагы иң төп индустриаль үзәк шул булыр...

Ә бусы — Лебедев идеясе... Кара син, барыбыз да бер үк нәрсә өчен көрәшкәнбез — ә нинди каршылыклар килеп чыкты!

Ник?

Чөнки Лебедевта да, эштән бигрәк, бүтән максат иде...

Әгәр бу комбинат берсеннән икенчесен аерып булмаслык бишәр катлы игезәкләр түгел, ә Чаллыга гына хас стиль сакланган хәлдә, берсенә икенчесе һич охшамаган архитектура истәлеге булып калырлык өйләр корса, ә вәкилләре бүген театрда утырган барлык оешмалар туристлар карап йөрерлек бөтен бер ансамбль тудыра алса, Фәез теләге дә үтәлгән булыр иде.

Ләкин Лазарев Фәезнең бу фикерен әйтмәде, онытты, ахрысы. Бәлки, Фәез шикелле үк, берәрсен ачуландырырмын дип курыккандыр?..

Ачыкланмаган, күптәннән бирле тынгысызлап торган соравыма җавап ишетә алмаммы дип утырган Фәез тагын борчыла башлады. Әгәр ул чын шәһәр түгел, өйләр өеме генә икән, ни мәгънәсе кала шәһәр салам дип трибуналардан, газета битләреннән акыруның? Килер буын син салган каланы кадерләр булмагач, ник шушы хәтле ду кубарырга? Әнә бүтән буыннар төзегәннәр бит... тарих белә... без дә беләбез һәм үлемсез сәнгать әсәре итеп карыйбыз — салганнар бит әнә бабаларыбыз Сөембикә манарасын! Салганнар бит әнә Болгар пулатларын! Заманында Лондоннан да өстенрәк булган шәһәр төзегәннәр. Шундыйларны хәзер сала алмыйбызмы? Алабыз. Ерак барма, Түбән Кама каласын гына кара. Чаллы һич югында аннан ким булмаска тиеш...

Лазаревның күкрәп торган тавышы белән бөтен театрны, аны гына да түгел — бөтен дөньяны яңгыратырга тырышып, төзелеш үзе аваз бирә:

— СССР «Госстрой»ына, «Госгражданпроект»ка, проектчы фәнни-тикшеренү институтына яңа шәһәр проектлау тапшырылды. Чаллы

бүтән шәһәрләрдән бары тик үзенә генә хас планировка, үзенә генә хас сыйфатлар белән аерылып торачак. Анда өч йөз мең кеше яшәячәк. Урыны — яңа Кама дингезе һәм салыначак автомобиль заводы арасында. Бу — бөтен бер шәһәр, юллар һәм урамнар белән бәйләнгән бердәм система дигәнне аңлата. Йортлар төрле кыяфәтле һәм төрле катлы йортлар төрлечә бизәләчәк. Нигездә шәһәр биш катлы (әлеге дә баягы!) өйләрдән, кырык проценты тугыз катлы, кайбер өлеше уникешәр катлы йортлардан торачак. Квартираларда ярдәмче мәйдан дигәннәре — кухня, санитар бүлем, коридорлар зуррак итеп ясалачак, төрләндереләчәк. Вильнюс, Навои, Шевченко кебек шәһәрләр үрнәгендә Чаллы да шундый ук үзенчәлеккә ирешергә тиеш. Әлбәттә, без кемнән ким?!

Менә кайда икән ул сүз!

Генплан бар! Димәк, шәһәр булачак, ә поселоклар көтүе түгел! Ниһаять, бу сүзләрне дә ишетер көн бар икән! Автозавод коткарды... Менә нәрсә кирәк булган, менә нәрсә көткән икән Фәез. Димәк, аны аңлаганнар — аның кебек борчылучы берәү генә булмаган!

Күз алдында максат калыккач, Фәезгә дөнья да бөтенләй башка төрле яктылык белән ачылып китте, бөтенләй башка төсләр белән бизәлде, сулышлар киңәйде. Булачак Кама дингезенең япь-яшь дулкыннарның ни сөйләп, нәрсә өчен шаулап, кая таба йөгерәчәге дә, Кама киңлегеннән ким булмаган яктылык диңгезенең кая таба агылачагы да ачыкланды, мәгънә алды хәзер.

Шулай уйланып утырган җирдән Фәез кинәт сискәнеп китте. Бөтен тәне, судагы кислород төсле, чемерди, яңа башлады. Ник? Ничек?

Өченче идарә инженеры Камилә Сафарова...

Шулай диделәрме? Әйе, Кама сөйли, су кызы бүгенгесе көндә, кем әйткәндәй, авызыннан ут чәчә.

— Без — җитмешенче еллар яшьлеге, яңалыкка беренче булып юл салучылар исемлегенә үз исемнәребезне язган яшьләр — без бүгенге көн тәкъдим иткән имтиханны, авыр имтиханны үтәргә әзерме? Бүген бездән шушы сорауга җавап көтәләр. Аңа җавапны без эш белән бирергә тиеш. Шул имтиханны уңышлы тапшырачагыбызга шик бармы? Әзерме без аңа? Сезнең каршыда тантаналы рәвештә әйтергә рөхсәт итегез. Әйе, без аңа әзербез!

Шул вакыт театрдагы бөтен халыкның дары шикелле кабынуын, шау-гөр килеп кул чабуын ничек аңларга инде? Яшьләр вәгъдәсен олыларча ихтирам белән каршылыйбыз дигән сүзме бу? Ихтимал, шулайдыр. Алай дисәң, андагыларның яртысы — яшьләр. Әллә «Камилә Сафарова сүзе безнең уртак сүзебез» дигәнне аңлату өченме? Ихтимал, шулайдыр. Дөресрәге — икесе дә бергәдер. Әллә кызның сәнгать дәреслеге төсле яңгыраган ышанычына, чын күңелдән әйтә алуына кул чабаларммы? Ихтимал, шулайдыр... Әллә аның ерактан күренгән, Кама зәңгәрлеге төсле күксел зур күзләренә, Кама болыннарында өлгергән җиләкләр төсле йөз алсулыгына һәм иреннәре тылсымына соклануданмы бу алкышлар? Гафу итегез... Бу матурлык нәкъ менә табигатьнең үзеннән һәм аны бары тик шул чын җимешләр белән генә чагыштырырга мөмкин бит! Сәнгатькә күчә торган гүзәллек булганга һәм хәзер аны табигый хәлендә күрү мең мәртәбә ләззәтлерәк булганга күрәме бу алкышлар? Шулайдыр, әлбәттә, шулайдыр. Дөресрәге — бөтенесе бергәдер.

Башкалар белән бергә Фәез дә кул чапты һәм теге чакта кыз белән ачыграк сөйләшмәгән, якынрак танышмаган өчен ныклап үкенә башлады. Матурлык ерактан яхшырак күренә бугай шул. Синең үзеңә дә шулай карыйлардыр, дустым. Чит якларга киткәч, анда мәшһүр артист яки шагыйрь булып танылсаң да, үз җирең, үз авылың өчен барыбер ертык ыштанлы малай син...

Тукта әле, Фәез дус, игътибарны тагын читкә җибәрәсең — тагын үкенерсең. Хәзер ул сөйли бит, бүтән беркайчан да кабатламас өчен, Кама сөйли, тыңлап кал, егет.

— Әйе, шигебез юк! Комфорт дип атала торган җайлылыктан хәзергә мәхрүм булган поход тормышына чумып караган һәр кеше, ачык далалардагы көйдергеч җилләр әчелегән күнегелгән дүрт стена җылысыннан өстенрәк күргән, татлырак итеп тойган һәркем кабатлый ала бу сүзләрне. Андый кешеләребез, андый иптәшләребез күп безнең. Аларның исемнәре бөтен республикага танылды хәзер. Яңа диңгез тудырып, гаҗәеп плотина салып, дөньяга тагын да күбрәк яктылык өстәргә һәм яңа шәһәр, гигант завод төзеп, илебез байлыгын, үзебезнең горурлыкны тагын да арттыра төшәргә кушылды безгә. Тапшырылганны үтәү өчен монтажчыларның, бетончыларның, ташчыларның ныклы куллары һәм дәртле йөрәкләре кирәк, тагын да күбрәк кирәк. Хәзергә безнең арага килеп өлгермәгән шундый егетләр һәм кызлар ярдәме белән без үзебезгә тапшырылган яңа шәһәрне, әлбәттә, төзербез. Иптәшләрем исеменнән республикабыз яшьләренә чакыру белән мөрәҗәгать итәм: «Ир йөрәкле кыю яшьләр, килегез безнең янга, көтәбез сезне!»

Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл» балетыннан яңгырап калган җылы һәм якты моңнар, чәчәкләр биюенә мәйдан булган Кама болыннары, героиняга әйләнгән сөекле кыз Кама... тын калган музыка — художник ташка әйләндергән гаҗәеп сызыклар һәм бизәкләр, булган һәм булачак архитектура сурәтләре һәм сыннар, соңыннан да колакларда чыңлап, күңелне җәйге күренешләрдәй җылытып торыр. Шушындый ук гүзәллекне Чаллы якларында күрә һәм таба белергә, шуңа башкаларны да өйрәтергә, шундый гүзәллекне чын яктылыкка әверелдереп, еракларга, ерак елларга сәфәр җибәрергә кирәк бит инде! Төзүче һәм композитор, төзүче һәм художник — никадәр мәгънәдәш бу сүзләр!

Самолетлар гөрелтесе дә шул тавыш, шул мәгънәләргә кушыла шикелле. Тыңлый белсәң, бүгенге шатлык ул кичәге аккордларның, кичәге пассажларның дәвамы лабаса. Шулай димәсәң, әнә аэропорт кырына чыккан Чаллы кешеләре йөзендәге яктылыкны бүтән ничек аңлатасың?! Бер Фәез генә кичергән хисләр түгел болар,— әллә кайдан күренеп тора. Бигрәк тә кичә барысын да таң калдырган Камилә балетның үзеннән килеп чыккан да карашларны ымсындырып йөри. Якташлары аңа сәбәп белән дә, сәбәпсез дә (күбесенчә — сәбәпсез) сүз кушарга тырышалар, самолет соңлады инде, сине җибәрмәс өчен юри шулай эшлиләр, диген булып, юк-бар сүзләр белән тегенең игътибарын җәлеп итәргә тырышкан булалар. Ә Фәез аның белән шаяра алмый, аның уйлары җитди, шуңа күрә чират җитми. Ә аннары соң булса? Шуңа күрә Фәез дә кыз каршына килгәли:

— Әйдә, җаяу генә китик булмаса,— янәсе.

Тик шаярту барып чыкмый. Шаяруы бүтәннәрнекенә кушыла алмый, гаять тә җитди һәм килешсез чыга Фәезнең кыланышы — башкалар янында хәтта кызганычрак та кебек. Нигә дисәң, каушый егет.

Ә кызның:

— Сезгә ышанып юлга чыксаң...— дип кырт кисүен һәм читкә борылуын кара син! Килешмәгәнне!

— Шулай, шулай,— дип сүзгә кушыла Лазарев,— егетләрнең ышанычлысы булмый аның. Без, ирләр, үзебез алып кайтабыз, самолет килмәсә дә.

— Барыгызга да канатлар чыкты тагы,— дип, кыз тагын чын күңелдән көлгән була. Кыланчык!

— Мәхәббәт канатландыра кешене!

үен-көлке дәвам итә. Кыз Фәезгә керфек тә сирпеми, Фәезнең күңел кителә, ул тыныч кына тора, сүзгә анда-санда гына катнаша башлый.

Самолетка таба барганда, Камилә белән булачак очрашулар хакында башына уй төшкәч, егетебез бөтенләй каушады. Аптырагач, тырышып-тырышып фикерләрен Бориска күчерде һәм дөньяның якты-лыгы тагын чак кына кимегәндәй тоелды. Эх, Борис, Борис, син хәзер бу эшләргә бөтенләй катнашмас булдың, моннан ары ничек яшәрсең? Моңарчы ничек яшәсәм, шул рәвешле дисеңме? Ә ул рәвешле озак яшәп буламы? Яңа эшәкелекләргә бармассыңмы? Әйтик, минә бу киңәшмәгә ник килмәскә иде сиңа? Тыңлый торгач, фикерләрең үзгәрер, һәм тора-бара үзең дә үзгәрер идең...

Бетон кыр буйлап атлаганда башыннан шуларны кичереп, Фәез Лазарев янына килде дә тыныч кына сорау бирде:

— Борис нишләп килмәде икән бу киңәшмәгә?

— Кайсы Борис?

— Филинов.

— Ә... Филинов чакырылмады.

— Нишләп?

— Производство алдынгылары гына чакырылды.

Шуның белән сүз дә бетте — Лазарев трапка менеп китте. Ә эчкә кергәч, алар бер урынга туры килмәделәр. Гөнаһны яшермик, Фәез Камилә белән туры килеп булмасмы диебрәк өметләнсә дә,— алдарак икенче идарә башлыгы өлгергән: кыз белән көлешә-көлешә сөйләшеп утыралар иде. Бергә эшләп туймаганнар, имеш!

Ләкин хәзер инде Фәездән Каманы тартып алу мөмкин түгел, ул аның йөрәгендә, ышанычлы йозаклар белән бикләнгән. Ә ачкычлары югалган, ачып чыгарасы килсә, егет үзе дә таба алмас иде.

Фәез Кама хакында, чиксез киңлекләр, хәзергә карлы кырлар, якын яз турында, мәхәббәте һәм булачак көрешүләр хакында хыяллана. Хуш инде, Казан, син югалдың күздән. Самолет болытлар өстенә алып менеп китте. Болытлар, болытлар — баштарак алар шулкадәр күп итеп сибеп ташланган сарык йоны төсле күренсә, күп тә үтми, карлы киңлекләр кыяфәтенә керделәр. Рокуэл Кент картиналарындагы шикелле — таулар, узып чыга алмаслык чокырлар... Барасың-барасың да шаккатасың — мәңге җимерелмәс тоелган таулар ишелеп кенә тора — хыял кебек, иллюзия кебек. Җирне, андагы тереклекне син шулай мәңгелек дип йөрисең дә — бер көнне бөтен нәрсәнең газга әйләнәчәген күз алдыңа китерәсең... Дөньяда бернәрсә дә мәңгелек түгел, диләр шул. Тормыш — үзе әкият. Ә бөтен нәрсә вакытлы, бөтен нәрсә — иллюзия дип уйласаң, бу кеше дигәнең ник шушы хәтле кайгырта һәм мәшәкать чигә? Дөнья шул тырышлык бәясе торамы соң? Әллә юкмы? Юк дисәк, без бүгенге хисләрдән, кичәге сүзләр һәм кичерешләрдән, кулга моңарчы тоткан һәм киләчәктә тотарга җыенган кирпечләрдән баш тартырга, аларны әнә шул бушлыкка, төпсез чокырга атарга тиеш булабыз түгелме соң? Тик адәм баласы бушлык белән килешми, юк, дөньяның хыялый сурәт булуы белән ул ризалашмый һәм беркайчан да ризалашмаячак. Фәез дә шулай.

Менә ул вакытлы дигән төшенчә турында уйлана-уйлана Кама буена китте. Адәм баласы шушы җирдә ак болытлардан ясалган калалар шикелле шәһәрләр бастырып куярга җыена һәм ул сүзендә торачак та. Болыт сарайлар һәм заводлар да юкка чыкмаячак, ә без тозегәннәре дә мәңгелеккә калачак. Вакыт дигән нәрсә, кем белә, торабара бәлки чыннан да көчен җуяр әле. Бу киңлекләр, бу ак шәһәрләрне — тиздән җиргә төшәчәк сурәтләрне күрү өчен хәзергә менә шушы мең метрлы биеклеккә, күккә күтәрелергә кирәк... Чак кына биегрәк мендеңме, дөнья гел якты, гел киң — күлә, елмая дөнья. Фәезнең бүгенгесе кебек, Каманың киләчәге төсле...

Әллә нинди кеше булып чыкты бу Фәез — бер карасаң, үзенең якын иптәшләреннән берни белән дә аерылмый кебек. Әйтик, әлеге дә баягы, Бористан. Белемнәре белән бертигез, икесе дә бер типтагы институт бетергәннәр. Төс, бит, кыяфәт дисәң, шулай ук бер тирә бугай. Һәрхәлдә, Борис ярыйсы ук пөхтә егет. Сүзгә осталык ягыннан шулай ук үз уйларын әйтә алмый интегә торганнардан түгел. Аның ким җире юк, ә бәлки артык ягы бардыр. Мәсәлән, ул Фәездән ундүрт яшькә зур — аңа инде кырык тулып килә — тәҗрибә күбрәк, төрле кешеләрне күргән, күбрәк аңлый. Ә иң мөһиме — Борис иҗади яктан Фәез белән чагыштырганда бәхәссез өстен. Шундый аз гына арада күпме яңалык кертеп өлгерде һәм әлеге чатаклык килеп чыкмаса, тагын ниләр уйлап тапмас иде. Соң? Ә Фәез дә төшеп калганнарданмы? Көнләшүгә охшашлы теге кортның баш калкытуын һәм үрмәләп тышка чыгарга маташканын сизгәч, ул аны бик тиз йолкып ыргытты бит... Озын сүзнең кыскасы: Фәезнең Бористан бернинди өстенлеге юк. Әмма Фәез фартлы егет — бәхетлерәк. Ике ел эчендә гади инженердан идарә башлыгы булып китте!.. Колагыннан тартып дигәндәй, Фәезне үстерделәр, Борис исә һаман күләгәдә кала бирә һәм аның шуңа күрә күзләре көннән-көн уйчанлана, моңсулана бара. Күз алдында үзгәрә егет...

Әйе, ни сәбәптән шушы хәтле фартлы егет булуына Фәез җавап таба алмый. Мөгаен, бу сорау Борисны аптырата торгандыр, ул да, мөгаен, үзенең Фәездән һич ким ягын таба алмыйча интегә торгандыр. Үзенә шушы хәтле җай килмәүнең сәбәбен төшенә алмыйча җәфа чигәдер. Чынлап, Ә сер нәрсәдә икән соң?

Нindидер бер китаптан укыганы хәтерендә бугай.

Билгеле күләмдә, җитәкчелек итү — табигатьнең үзенә дә — җәнлекләргә дә хас. Әмма яшәү һәм үрчү шартлары тигез булганда, кыргый җәмгыять тигез дәрәҗәле члennардан, яисә күренекле җитәкче һәм аның ихтыярый юлдашларыннан тора. Ихтыярый «буйсынучылар» еш кына очракларда җитәкчегә үзләренең тугрылыкларын күрсәтәләр, ләкин, өстенлек итүче тарафыннан рәнҗетелсәләр, аларга үзләре теләгән җиргә китәргә, җитәкчене ташлап качарга мөмкинлек бар — аларны койма белән уратып алмаганнар бит! Шул рәвешле, кыргый дөньяда властька түзү кыен түгел. Алай гына да түгел, күп очракта чын җитәкче үзенә буйсынучыларга файда китерә торган да була — гадәттә, ул бүтәннәрдән өлгер һәм сизгеррәк — якынлашып килгән дошманны ул тизрәк күреп ала. Азыклы, сулы җирләрне дә бүтәннәргә караганда тизрәк һәм күбрәк таба. Кайбер хайваннарда, мәсәлән, пошиларда шулай: алдынгылык итүне, җитәкчелек ролен ана поши башкара торган була. Ихтимал, бу аның җаваплылык хисе, тирә-якны яхшырак күзәтә белүе һәм балалар тәрбияләүдә зуррак тәҗрибә туплаган булуыннан киләдер.

Ә менә береңнең икенчеңнән өстенлек итүе нинди эчке теләкләр — ниятләр белән бәйле икән? Бер җан иясенең икенчесен кимсетергә тырышуы каян килә? Табигатьтән үкме икән анысы да? Моны әле фән кешеләре үзләре дә рәтләп әйтә алмыйлар бугай. Властьлык итәргә тырышу нәселдән бирелә торган хәлме, әллә соңыннан тәрбияләнә торганмы?

Канада илендә 1934 елда туган биш игезәк кыз белән булган тәҗрибә хакында укыган иде Фәез. Бер үк орлык-күзәнәктән яралганга күрә, бу игезәкләргә нәселдән бертөрле үзенчәлекләр бирелгән һәм алар арасында нинди булса да аерма килеп чыкса, бу инде тугач барлыкка килә торган сыйфат булачак. Тәрбия шартлары бишесе өчен дә бер үк төрле булуга карамастан, туганнарның берсе башта ук бүтәннәрдән үзенең өстенлеген күрсәтергә тырыша башлый. Галимнәр көткәнчә, бу кыз бүтәннәренә караганда зиһенлерәк, физик көчлерәк

һәм үскәнрәк булып чыгарга тиеш була. Ләкин андый фаразларның берсе дә акланмый: акыл үсеше ягыннан ул беренче урынны ала алмый, авырлык ягыннан да аерылмый. Бүтәннәрдәгедән иртә уянган «өстенлек итү» омтылышы ни белән аңлатыла соң? Галимнәр моңа тәки җавап таба алмаганнар.

Аларның тикшеренүләрендә хәтта шундый мисаллар да бар: житәкчегә буйсынучылар арасында гәүдә ягыннан караганда «хуҗалардан» зуррак, көчлерәк, акыл һәм хис культурасы ягыннан караганда югарырак торганнары да күп икән. Ә шул хәлдә дә буйсыналар. Ник буйсыналар? Җитәкче нинди сыйфат аркасында өстенлек итә? Ихтимал, бердәнбер сыйфат — үз көченә ышанганлык аркасындадыр. Белми Фәез: табигать аңа өстенлек итү омтылышы бирмәгән. Фәез, киресенчә, оялчанлык дәрәҗәсендә тыйнак. Ник аны начальник итеп куйганнардыр һәм хәзер, чак кына теләк сиздерсәң, тагын да югарырак күтәрергә ник әзер тора торганнардыр?! Хәер, аллага шөкер, андый тәкъдимнәрдән Фәез баш тарта килә. Бориска андый тәкъдим юк. Ә нигә юк?

Кинәт Фәезнең башына шундый уй килде: тукта әле, нишләп Фәез Борис өчен бу чаклы ут йота әле? Борис үзе шушылай интегә, дустын (кайчандыр дус иде бит) рәнжеткән өчен газап чигә, аның хәлен җинеләйтер өчен борчыла дисеңме? Һай, шулай булса, алар ачуланышмаган ук булырлар, Борис үз этлеген эшли алмаган ук булыр иде. Гәрчә шундый юньсезлеген күрә торып, Фәез борчыла менә. Димәк ки, димәк... Кара син, ә, аңардан олырак җанлы булып чыга түгелме соң? Шулай итеп, шулай, башны кисмәгә биреп бәхәсләшергә мөмкин: Фәез белән бүген берәр бәхетсезлек килеп чыгып, иртәгә аны эшеннән алсалар, түбәнгәрәк күчерсәләр, Борис шатланачак кына.

Олы җанлылык — күп чакта ялкаулар өстенлеге, диләр. Фәез аңардан ялкаурак түгел, ләкин артык тыйнакланмаганда, өстенлеге бар: аның күңеле киңрәк, җаны зуррак. Кеше олырак җанлы булуы белән көчлерәк, димәк ки. Ә Бориска нәрсә комачау итә? Димәк ки, димәк... Юк, нәтиҗә ясарлык ук нигез юк, шулай да фараз өчен җитеп арткан. Әйе. Бәлки олырак җанлы булу аны көчлерәк итәдер. Җитәкченең хәзергә галимнәр таба алмаган төп сыйфаты да, мөгаен, шундадыр. Кем моңа «түгел» дип кистереп әйтә ала? Әйтәсегез килсә, тагын бер тәҗрибә ясарга тиеш сез: бер орлык-күзәнәктән яралган биш игезәк тәртибен күзәтегез... Бәлки шунда нәкъ Фәез теориясен расларсыз. Фаразан, төрлечә булуы да ихтимал, әлбәттә. Фәез дә бит бары тик фараз гына итә. Тормышта да төрлечә булуы ихтимал. Карьера ясау ягыннан алсаң, нәкъ менә булдыксызрак, ялагайрак, принципсызрак кешенең (менә бит нинди өстенлекләр бар дөньяда!) югарырак үрләве ихтимал. Әлбәттә, билгеле бер очракларда. Күпчелек хәлдә, бигрәк тә чын эш, чын нәтиҗәләр кирәк булганда — иген үстерү, йорт салу, сәнгать әсәре язу кебек эшләрне ялагайлык белән генә башкару кыендыр — эшләүчеләр чын булган кебек, җитәкчеләр дә чын буладыр. Сүз белән, бугаз белән монда берәр нәрсә кырам димә. Сүз белән кирпечберекми... Сүз сөйләп торганнан иген үсми, аңа кояш яктылыгы кирәк, яңгыр кирәк, игенченең изге куллары һәм күңеле кирәк.

Элек ничегрәк булгандыр, әмма хәзерге хәлендә үзен бик кечерәйтте Борис, кечкенә адәмчек булып калды һәм бөтен шәһәргә бик ачык күрсәтте. Хәзер аны өр-яңадан тәрбияләү — иң әһәмиятлесе, шулай кирәгенә үзен ышандырырга, күзләрен ачарга кирәк. Моны Фәез эшли алыр. Ул булдыра алмаса, бүтән, усалрак кеше булдырыр. Ләкин кайчан да булса шундыйрак, рәхимсезрәк кеше кулына кабачак әле ул. Без артык кешелекле булдык (гафу итсен!), фикерләренә, башына, күңеленә дезинфекция ясый алмадык.

Самолетта Камилә килгән тавыш ишетелде: хихылдау түгел, тыйнак кына көлгән тавыш, шулай да Фәез ишетми калмады. Бусы инде бик үк яхшы галәмәт түгел — егет бөтенләй тынычлыгын җуйды дигән сүз бу. Хәерлегә юрыйк, хәерлегә.

Чаллыга кайтып житкәч тә ул кызга якын килә алмады. Траптан төшкәч, шәһәр комитеты секретаре янынарак тайпылды һәм, ахрысы, дөрес эшләде — Шакиров аңа үзе игътибар итте.

— Ә, синме бу? Я, кәефләр ничек?

— Кәефләр шәп.

— Дөрес, инде дә кәеф начар булса, ул нормаль хәл булмый бит. Начар кәеф белән яхшы эйбер эшләү гомумән кыен. Бигрәк тә сезнең урында.

— Сезнең урында бигрәк.

Монысы сүз юктан үзара макташугарак кайтып калды бугай, бер ара тынып бардылар. Машиналар янына житәрәк, секретарь тагы сүз кушты:

— Сез машина чакырткан идегезме?

— Юк. Җәяү генә кайтмакчы идем.

— Әйдә, алайса, минем белән.

Фәез карышмады, зәңгәр «Волга»ның арткы креслосына берүзе утырды. Алардан алданрак Лазарев гөжләп узды.

Юлда секретарь тагы телгә килде:

— Ну, ничек соң? Тынычландыңмы инде бераз?

— Ник алай дисез?

— Генплан булды ич! — Секретарь тавышында нindидер зур эш башкаргандагы тәслерәк канәгатьләнү, шатлану, хәтта горурлык аермачык ишетелде. «Дипломатлар да сөенә белә икән!» — дип уйлап алды Фәез. Гадәттә, Шакировның барлык хәрәкәтләре, сүзләре бертигез — ачуланамы, сөенәме ул — белмәссең. Мондый кешеләрне Фәез бик кызгана — яшәүнең иң нечкә борылышларыннан читтә калалардыр сымак алар. Житәкче буларак шәп, ә кеше буларак алай дип әйтү кыен, билгеле. Әмма Фәез өчен шунысы күңелле яңалык: булачак шәһәрнең кыяфәте хакында Шакиров әллегрәк тә уйланган һәм борчылган икән, аның да башында нindидер планнар булган. Хәзер, шулар тормышка ашкач, аның да шатлыгы тышка чайпалды. Бу чайпалуда Фәезнең хезмәте бар...

— Әйе, генплан булды! — дип кабатлады Фәез дә секретарь тавышы белән.— Шәһәр дә булачак!

— Чын шәһәр, поселоклар җыелмасы түгел.— Елмаюын кара — ә үзе Фәез сүзен кабатлый!

— Бик зур яңалык булды бу.

— Автозавод ярдәм итте.

— Фарт килде.

— Анысы да бардыр инде. Ләкин көтеп кенә ятсаң, сезгә автозавод дип, икенче блюдо төсендә өстәлгә кем дә китереп куймас иде. Йөзгә якын өлкә һәм республика тырышты шуны үзенә алырга.

— Ә сез җиңдегез.

— Өлкә комитеты секретаре... Ул да ишеткән иде бит халык ничек уйлаганны. Хәтерендәме?

Фәез нәрсә әйтсен инде? Үзенең теге чакта ник кайнарлануын гына аңлатырга тырышты:

— Кама буенда начар шәһәр төзү оят иде бит.

— Шулай шул, география дә ярдәм итте — Кама, ГЭС. Хәзер инде китсәм дә, үзе төзеткән начар шәһәрне ташлап качты дия алмассыз.

Фәез ирексездән, чын күңелдән көлеп җибәрде. Аннары:

— Төзетеп бетергәч, китсәгез дә ярый. Карарсыз,— дип куйды.

— Рөхсәт итәсезме?

— Китә алсагыз. Шундый шәп кала килеп чыкса... Китә дә алмассыз әле.
— Китә алмас идем... Ләкин җибәрәләр инде... Ну, хәерле. Мин монда төшәм. Ә сез барыгыз.
— Ә ник җибәрәләр, Мөнир Афзалович?
— Бүтән эшкә күчү сәбәпле. Хуш, энекәш.
— Хушыгыз.
Аның торган җире Иске Чаллыда икән (менә бит, яңасы әле папкаларда, ә «Иске Чаллы» инде телгә дә килде!), секретарь агач өйләрнең берсенә таба атлады. Ә Фәез — машина белән яңа шәһәрнең беренче өйләре җыелмасына — секретарьга зыян китергән гидрострой поселогына китте. Беренче тәҗрибә, беренче коймак...
Беренче коймак төерле булды шул!..

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

Яңа шәһәр әле уй, идея хәлендә. Ул әле күңелләрдә, хыялларда, проектчылар бүлмәләрендә һәм кара савытларында. Шуңа күрә Чаллының үзендә беренче елны тыштан караганда әллә ни зур үзгәрешләр күзгә ташланмады. Яралу чоры бу...
Күзгә күренми, шауламый яралгы, ләкин ананың бөтен әгъзаларын, аның холкын, гадәтләрен һәм хәрәкәтләрен үзгәртә дә куя ул. Яралу — табигатьнең иң бөек һәм гүзәл сере. Күзгә күренми торган бәхет. Ә күренә торган булса, үзенең сәнгатьчә нәфисләгән генә түгел, мәгънәви гүзәллеген дә җуяр иде ул... Табигать зирәк, аны шуңа күрә яшерен нәрсә иткән дә бит инде. Башта күңелдә ярала: хис ярала, кичереш ярала, мәхәббәт ярала, бала ярала, шигырь ярала, көй ярала, музыка... архитектура ярала, шәһәр ярала.
Күңелләрдә Яңа Чаллы ярала — өр-яңа шәһәр тиздән кыймылдый, яши башлар, биографиясе башланыр, елъязмасы языла башлар, чынында — ул инде башланды... Шуларның кайбер галәмәтләре, газета битләренә күчә, эфирга чыга, юллар, урамнар буйлап шаулый, күкләргә күтәрелә.
Аэропортка самолетларның көннән-көн күбрәк килүен, гостиницаларның һәрвакыт шыгрым тулы торуын, «Камгэсэнергострой» баш идарәсенең кадрлар бүлегенә тезелгән озын-озын чиратларны, аннары идарәләргә килгән, бер-берсен белмәгән-күрмәгән кешеләрнең сөйләшә-гәпләшә каядыр баруын, яңа бригадалар, хәтта бөтен-бөтен идарәләр оешуын шул галәмәтләрдән санау фарыздыр. Кешеләр төрле, аларга караш та төрле. Шуңа күрә кайчакта рәтле кешеләр күңеленә җайсыз кагылулар да була торгандыр инде...
Шуларның берсе Борис түгелме икән?
Управляющий каршында калын гына гәүдәле, киңчә битле, уртачадан чак кына калку бер кеше басып тора.
— Исәнмесез, Анатолий Самойлович.
— Утыр.
Тегенең хәл бигүк шәптән түгел иде булса кирәк, әйтүгә утырды.
— Рәхмәт.
Йөзе карачкыл, җилдә янганнан гына түгел, төсе шундый.
Борыны киң битенә ярашмый — бәләкәйрәк, чак кына «курносрак». Кечерәк, озынчарак күзләр. Мондый төсне, гадәттә, татар кыяфәтле диләр. Алай әйтәсе килми, чөнки бу — ике халыкны да белмәү аркасында килеп чыга торган әзер чагыштыру. Чынында ак чырайлы, зәңгәр яки яшел күзле күпме татар да, шомырт кара күзле, киңчә яңаклы күпме рус кешесе бар. Тегесен дә, монысын да түгәрәкләсәң, артылаш килеп чыгадыр. Түгәрәкләсәң, чын татар белән чын рус бер үк төсле.

— Я, Борис Дмитриевич, ни әйтерсең?
Борис ишетелер-ишетелмәс тавыш белән әйтте:
— Белмим. Сез чакырттыгыз бит, сүзне үзегездән күтәм.
— Ниләр әйтеп сөендерә алырсың?
— Сезгә ни кирәктер бит.
Лазарев сүзне ничек башларга һаман җай тапмый иде булса кирәк, җайсызлыкны урындык арасында шикелле сизгәндәй, арткарак тайпылып утырды, аркасы белән чак кына сөялеп торгач, тагы өстәленә таянды.
— Димәк, шатландырырлык бер әйбер дә юк.
— Ихтимал.— Борисның тавышында бернинди кызыксыну, мөнәсәбәт юк.
Лазарев шуңа күрә тагын да гаҗәпләнә төште. Әлегә ул сүзләрен үзенә хас булмаганча тынычрак әйтә. Үз чыгырына керсә, шактый тизли һәм шаулый башлый...
— Мин синең белән тагын бер кабат сөйләшмәкче булам, кешечә.
— Нәрсәсен сөйләшәсең инде аның? Нигә кирәк ул?
— Син минем өчен барыбер түгел — син минем өчен үз кеше, белдеңме, кадерле кеше син миңа, сукин сын.— Лазарев бу сүзләрне инде үзенчә әйтте.— Шулай булмаса, синең белән гәп сугып утырырга вакыт әрәм итә торган чакмыни?! Үзең беләсең, әнә ничек ду куптык. Көн саен диярлек яңа бригадалар, яңа идарәләр оеша. Аларга яхшы житәкчеләр, тәҗрибәле укытучылар кирәк. Бер кешене шулай икегә бүлергә торганда, син кайда адашып йөрисең?
— Әллә кайда түгел, мин монда, үзегез күрмәгәч...
— Юк, син — адәм көлкесе, бу — синең шәүләң генә, кара син аның кыяфәтенә, җебеп төшкән!
— Ангина миндә, температура, кирәк булса, больничный,— дип, Борис кесәсенә тыгылды.
— Кирәк булса, мин сиңа бу кәгазьләрдән подшивка ясап китерә алам. Тик сорагыз: берәр көн эштән калдыммы икән? Сугышта салкын тию дигән нәрсә юк иде. Монда да, ныклап уйласаң, барыбер фронттагы кебек.
— Беләм,— диде Борис баягы битарафлык белән,— сез — геройлар.
— Син кем?
— Инженер.
— Ә без инженер түгелме?
— Сез — геройлар, геройлар!
Борис ничектер мыскыллы кабатлавы белән начальнигын рәнжетте бугай. Тегесе тавышын акрынайту гына түгел, күзләрен дә кыса төште.
— Кызык, ничек инде ул алай?
— Безнең бит шулай хәзер — чын инженерлар кирәк түгел безгә. Шул исәптән, мин дә артык кеше. Безгә геройлар кирәк!
— Аңлашылмый.
— Инженерлар урынында — йомышчылар, сүз тыңлаучылар, башкаручылар, толкачлар — ыбыр-чыбыр шантрапа. Сезгә шулар кадерле.
Борис бу сүзләрне аеруча тынычлык саклап әйтте һәм бәлки шуңа күрә дә тәэсирле булгандыр алар. Лазарев ни әйтергә икән дигән сыман тагын аптырабрак калды. Борисны баштан-аяк карап чыкты — ялгыш ишетмиме, янәсе. Юк, форсаттан файдаланып, иптәш үзенең фикерләрен тагын да үстерә төште:
— Минем хаклы икәнне сез үзегез дә сизәсез, әлбәттә. Чөнки Казандагы җыелышта нәкъ минем сүзләрне сөйләп кайттыгыз. Хезмәтне фәнни оештыру кирәклеге хакында бик матур речь тоттыгыз. Минем хаклы икәнне белгәнгә күрә дә, сез мине яратмыйсыз. Чөнки мин сезне уйларга мәҗбүр итәм. Ә уйлау — кыенрак. Шуңа күрә аяк белән, бугаз

белән, тел белән дипломатик көрәшкә чыгарга, безнең кебекләрнең фикерләрен урлап, акыллы булып сөйләшергә, ә чынлыкта безне читкә кысрыкларга мәҗбүр буласыз. Ләкин сез барыбер бер нәрсә дә отмыйсыз, ә вакытны өчләтә күбрәк югалтасыз. Үзегезнекен дә, халыкныкын да. Үзегезне дә алдыйсыз, халыкны да.

— Менә молодец! Шәп!..— Лазарев, артык каты сүз ычкындырудан курыкты, ахры, елмаерга тырышты.— Менә сина кире беткән скептик.

«Мәгънәсез сүзләргә игътибар итмим», дигәндәй, Борис һөҗүмен дәвам иттерде:

— Әгәр житмәүчелек, оешмаганлык, тәртипсезлек аркасында килеп чыга торган кимчелекләр, җайсызлыклар булмаса — ә алар фәнни житәкчелек иткәндә юк дәрәҗәсендә аз була һәм бары тик контрольлек итәргә генә кала — эшнең асылын белмәү аркасында килеп чыга торган ясалма кыенлыклар булмаса, аларны җиңеп чыга торган геройлар да кирәк булмас иде. Минем кебек гади инженерлар гына кирәк булыр иде. Ләкин — юк. Иҗатны ыгы-зыгы алыштыра, җыелышлар, утырышлар, кычкырышлар... Ә анда: сез — геройлар! Интриганнар ук димим, әлбәттә... Ләкин...

— Ничек?

— Шулай, эшнең башын нәкъ менә фәнни житәкчелектән башларга кирәк иде. Техника белән чыннан да кызыксынсагыз, иҗат итәргә ихтыяҗыгыз бөтенләй үк үлмәгән булса, сез үзегезгә дә, безгә дә уйларга вакыт калдырырга тиеш булыр идегез.

— Куак артларында йөрергәме?

— Ә йөрсә соң? Ник? Бөек бер галим «Эврика!» дип ваннадан кычкырган — хәтерем ялгышмаса.

— Син нәрсә, берүзең техник революция ясап утырасың, ә?

— Ә техник революция дигәнегез ул туктаусыз бара. Югыйсә, Казанда сез ул сүзләрне кычкырып сөйләргә кыюлык итмәс идегез бит. Шулай, моңарчы безнең сүзне томалый-томалый килдегез дә хәзер, житәкчелекнең фәнгә әвереләчәген, ул процессның барыбер җиңелмәячәген сизгәч, безне читтә калдырып, үзегез тотындыгыз: инициаторлар тагын сез — оештыручылар, сез — оста! Ә без — чын иҗатчылар — тагын читтә...

Артык каты сүзләр ишеткән саен, Лазарев йомшара барды. Тегесе сүзләрен әйтә алмас хәлгә житеп арыгач, туктагач, аталарча диярлек җылылык белән әйтте:

— Менә мин син сукин сынны читтә калмасын дип тырышуым, шуның өчен чакыртуым лабаса. Читтә яшәү сиңа күңелсез була башлаган икән, бик шәп. Димәк, син капитализм чиреннән котыла башлагансың.

Борис сагая калды:

— Анысы нинди чир тагы?

— Биш ел Иранда эшләгән кеше бит син.

— Я, шуннан?

— Чит илдә яшәп күнеккән кешеләрне мин яхшы беләм хәзер.

— Шуннан?

Лазарев урыныннан торды — Борис та кузгалмакчы иде, управляющий аны ымлап туктатты да сүзендә дәвам итте:

— Анда инженер — гади башкаручы гына. Производство аныкы түгел. Ул аны белми дә, кызыксынмый да. Инженер, гомумән, предприятие язмышы турында, аның бүтән предприятиеләр арасындагы урыны, бүгенгесе, киләчәге хакында уйламый һәм уйлый да алмый. Кыскасы, ул анда хуҗа түгел, ә үзенә тапшырылган тәгәл бер функцияне башкаручы гына. Кушылганны үтәүче! Белдеңме?

Борисның күзләрендәге авыру төсләр усал очкыннар белән алышынды, ул үртәлеп диярлек кычкырды:

— Насыйбуллин кебек фәлсәфә сатып утырган хуҗага караганда бөтен механизм эшләсен өчен бер функцияне башкаручы винтик кирәклерәк һәм файдалырак. Чынлыкта — зуррак та.

Лазаревның куркрәүле тавышы ишетелде:

— Син миңа мешать итмә, мин синең ничек уйлавыңны беләм, ә син минекен аңлап житкер. Шулай, син анда хуҗа түгел — винтик. Синең акылың — ягулык... Билгеле бер сәгать эчендә фәлән литр акыл сарыф итәсең дә аннары син ул предприятиенеке түгел. Иртәгә иртән килүгә предприятие ябылмаган булса, билгеле бер күләмдәге акылың-зиһенеңне акчага әйләндерергә җай бетмәсә, сиңа шул җиткән.

— Кайгыртып, уйлап йөрү материаль кыйммәт түгел. Аның хаҗәте дә шул чама гына.

— Шулай итеп, синең принцип: «После нас хоть потоп!» Син үзеңне генә беләсең, калган вакыт — шалтай-балтай.

— Шалтай-балтай дигәнне кешенең шәхси вакыты, шәхси тормышы дип аңласак, мин килешәм.

— Шәхси вакыт җилгә очыртыр өчен түгел, ә, Маркс әйткәнчә, иҗади, рухи үсәр өчен... Һәрхәлдә, производствоны син үз байлыгың дип исәпләсәң, шулай килеп чыгар, иҗатка китәр иде. Ләкин бөтен хикмәт шунда, кабатлап әйтим, производствоның хуҗасы түгел син, ә хезмәтчесе генә. Шул тойгы белән син килешкән һәм ул синең тәнеңә сеңгән, гадәтеңә, натураңа әйләнгән. Менә нәрсә ул капитализм чире. Синдә ангина түгел, менә шул чир — сыйнфый чир.

— Ыһым...— Бу ымлыкта мыскыллау, үчекләү идеме, әйтүе кыен. Моңысы Лазаревка тәэсир итмәде. Ул, урынына яңадан утырып, үз сүзләренең хаклыгына чын күңелдән ышанган тавыш белән үз өстенләгән күбрәк сиздерергә тырышып, болай сөйләп китте:

— Синеңчә, шәхси вакыт, шәхси яшәү нәрсә дигән сүз инде ул — анысын да беләм — чит илдән кайткан белгечләрне күп күрдем мин. Аларның кайберләре, ишетәсеңме, бөтенесе дә түгел, ләкин, кайберләре, туган җирләренә өр-яңа «Волга» белән, супермодельле костюмнар белән, күзгә иң нык ташланган тәкәбберлек, кыланчыклык һәм ялган мөстәкыйльлек белән ялтырап, шаулап кайтып төшәләр. Валютадан безнекенә әверелгән акча — бу мөстәкыйльлек һәм һавалану чүпрәсе. Шуңа күрә ул инженер начальство белән дә, менә син минем белән сөйләшкән кебек, курыкмыйча сөйләшә.

— Сезнеңчә, мин куркырга тиешме? Ялагайларыгыз әнә бик курка, ә үзегез юкта...

— Син мине тыңла... Чөнки сиңа начальство белән ачуланышудан зыян юк төсле. Ну, должностеңнан төшерделәр ди — түбәнрәк постка, азрак зарплаталы эшкә. Ә анда күчкәннән сиңа ни зыян? Экономика сине кысрыкламый — син чынлап та иректә. Түбәнрәк эштә тагын да ирекләрәк, тынычрак, әлеге дә баягы шәхси яшәүгә күбрәк вакыт кала.

— Шәхси яшәү — шәхси ирек... Дөрес. Анысы да бар. Бер үк нәрсә болар.

— Вәт әле менә син аның нинди ирек икәнен. Эш сәгате беткәнне минут стрелкасына карап җиткерәсез дә, аннары — хушыгыз, безне онытмагыз,— дип, кая булса да табигать арасына элдерәсез. Хатыныгыз-балагызны утыртасыз да... Иң яхшы очракта — хатын һәм балалар... Аңлыйсыңмы? Иң яхшы очракта!

Борис елмаерга гына мәҗбүр булды,— дөрес сүзгә җавап юк шул.

— Менә сиңа — шәхси яшәү. Күпме шулай шәхси яшәргә мөмкин? Күпме бер үк нәрсәне кабатларга мөмкин? Кабатлау кешене үстерми дә, баетмый да.

— Бу темага бәхәсләшергә ниятем юк.

— Синең файдага түгел ул чөнки. Менә мин сиңа хәзер файдалы нәрсә тәкъдим итәм — категорически тәкъдим итәм: управляющий буларак кына түгел, өлкән дусың буларак. Ни дисәң дә, син монда элекке дуслык аркасында килгән кеше бит.

— Дуслыкны күрсәттегез инде...

— Да, начар, әлбәттә. Чит илгә китканче үк СМУ начальнигы булган кеше хәзер кая таба тәгәрәде? Әйтергә оят! Аннан ары тәгәрәргә урын да калмады. Ярга барып терәлдең инде, мәтәләсең генә калды.

— Кирәк булса, мәтәлербез дә...

— Көлке түгел. Актык сүзем шул — иртәгәдән башлап, мондый шәхси яшәүне туктатасың. Хатыныңны алып кайтасың.— Егет нидер әйтмәкче иде, Лазарев аны сүзеннән бүлдерде: — Теләсәң ничек килеш. Куып җибәрергә көчең житкән икән, килешергә дә житсен.

— Мин аны кумадым.

— Ну, китәргә мәжбүр иткәнсең икән, килешә дә бел, гафу үтен, алдына тезлән, ләкин тиз арада хатының, балаң Чаллыда булсын.

— Квартир бер генә бүлмәле.

— Бүген алып килсәң, сиңа иртәгә ике бүлмәле квартир бирәбез. Килештекме? — Борис каршы сүз әйтмәде, ләкин килештек тә димәде.— Моннан соң мин синең янда шикле кызлар күрәсе булмыйм, син алар белән тормыш төбендәге кешеләр төсле азып-тузып йөрүеңне туктат, боргаланып маймыллануыңны ташла... Кызлар кармаламасын синең...— дип тозлы-борычлы усал сүз әйтте.

— Анатолий Самойлович! — Борисның йөзенә аптырау галәмәтләре чыкты.

— Зыян юк, без үз кешеләр...

Борис сүзсез калды — ияген сыйпаштырды. Мәңгелектән килгән инстинкт — ирләр шулай ияклрен сыйпыйлар, хатын-кызлар прическаларын рәтлиләр — тәннең тиресен чиста тоту инстинкты галәмәте. Кешеләр бу хәрәкәтләрне киеренкелекне йомшартыр өчен, уйларга вакыт алу өчен (үзләре дә сизмичә) эшлиләр.

— Мин беркемнән дә курыкмыйм,— диде Борис, ниһаять, тынычланып.

— Әйбәт алайса. Килештек.

— Мин уйлармын.— Шулай дигәч, Борис китәргә җыенды.

— Уйлыйсы юк монда. Бар, секретарьдан командировочный яздыр да юлга чык...

Бу сүзләрнең мәгънәсе Борис өчен хәл итүе коточкыч кыен бер мәсьәлә иде шул. Ул, актан да, карадан да сүз әйтмичә, үз уйларына бирелеп, саубуллашырга кирәклеген дә башына китермичә, чыгып китте.

* * *

Борис белән Анатолий Самойлович арасында нинди сөйләшү булганлыгын Фәез чамаласа да, Бориска моның ничек тәэсир итәсен әйтүе кыен иде. Тик шунысы бәхәссез: Борис өчен нидидер борылыш булырга тиеш һәм ул булачак. Чөнки болай озак яшәү мөмкин түгел. Тик менә Фәез үзе көткән яңалык кына озаграк килә бугай. Кама белән очрашу һаман алда, һаман хыялда әле. Теге чакта бөтенесен вакытка тапшырып дөрес эшләсә дә, соңыннан шуның кирәкле мизгелен чамалый алмады, ахрысы. Фәезнең вакытлыча читләшеп торуын кыз игътибарсызлык дип, үзенең матурлыгын, яхшылыгын күрмәү дип аңлагандыр, мөгаен. Телдән әйтелмәсә дә, барыбер кыз белән исәнләшмәү булып чыкты. Кызларга син акылсыз, диген, үпкәләмәс, ә менә ямьсез дип кара, гомерлек дошманыңа әверелер ул синең. Фәез Каманың үпкәле карашын соңгы вакытта бигрәк тә ачык сизә башлады...

Шулай, вакыт дигән нәрсәне ычкындырды бугай егет...

Кызны күздән яздырыр, күзне томалар өчен март бураннары шаулап узды. Каманы юксынып апрель ташты. Файдасыз эзләнү, юксынуларны мыскыллап май килеп елмайды. Эшләгән җиренә барып та кызга сүз кушарга һич җай һәм сылтау таба алмады егет. Бүлмәләренә идарә начальнигы белән кергәннәр иде — кызлар, егетләр соң дәрәҗәдә җитди сөйләштеләр — начальник белән бергә булгач, Фәезгә дә эш буенча гына, җитди итеп җавап бирделәр. Андый җайсыз хәлдә Фәез кызга бер иренен чалшайтып кына да елмая алмады. Ярый әле, өмет дигәнең өзелми...

Авыл һәм поселок тирәләрендә агач утырту эшенә бөтен дөнья кузгалган кебек иде. Шушы хәтле халыкның үз инициативасы белән кузгалганын тою шатлыгы кызны юксыну хисен бераз җиңеләйтә төште. Фәезнең күңеле ул көнне шактый күтәренке булды.

Кеше саен күп дигәндә бишәр чокыр тигәндер — шуларны казырга куштылар. Илле-алтмыш сантиметр тирәнлектәге — киңлеге дә шул чама гына — чокырларны Фәез сәгать эчендә казып, башкаларга ярдәм итәргә дә кереште һәм казырга тиешле урын беткәч, үсентеләр килми торган арада, тәнәфес кебегрәк нәрсә барлыкка килде. Әлбәттә, Фәез форсатны ычкындырмаска тиеш — ул Камиләне эзли китте.

Урам һәм юллар буйлап кызлар-егетләр танцы оештырганнар. Күпме шат йөз, күпме караш, күпме елмаю һәм көлүләр, күпме тавышсызымсыз вәгъдәләр... Юк, берсе дә Фәез теләгән, берсе дә ул эзләгән түгел.

Ары китте. Әнә яланда, Кама буенда, трактор җир сөрә. Зур бер басу озакламый урман булачак, нарат урманы. Көрәкләп түгел, орлыкларны чәчеп тырмалаячаклар. Поселок белән рәттән яшь нарат урманы хәзер үк шаулап утыра — урманмы, бакчамы — аеруы читен, шулай да барыбер — матурлыкка ни дип исем кушсаң да үзгәрми ул. Менә Каманы бүтәнчә атаудан аның гүзәллеге кимемәде... Камилә ни — Кама ни... Шулай да ник аны, чын исеме белән түгел, ә Кама дип йөртәсе килә икән соң? Исемнең дә үзенә күрә нииндидер мәгънәсе, матурлыгы бар, күрәсең. Исем яңгырашы күзгә күренгән гүзәллеккә туры килсә бигрәк тә шәп. Шулай, шәбен шәп, ләкин хәзергә җисеме юк, исеме генә телдә бутала, ә аңардан ни кызык? «Бал, бал» дип кабатлаганнан телдә бал тәме тоелмый, диләр ләбаса! Тик... бу нинди тавыш? Наратлыкта бугай?

— Галя, Галя!

Хәер, һәр ике кешенең берсе Галя диярлек. Хикмәт анда түгел, хикмәт ул исемне әйткән тавышта. Ә бу тавыш Каманыкы булырга тиеш.

— Ә син нәрсә, Слава, ни көтәсең?

Шул ук тавыш... Ләкин бу юлы кәефне кырды да ташлады.— «Нинди Слава тагы?» Хәзер генә наратлыкка таба атлыккан Фәез шып туктап калды — «Анда кереп, хыялын да җимереп чыкмасмы? Ычкынды шул кирәкле вакыты, ычкынды. Теге чакта комачау иткән койрыкчы егет югалса, бүтән бәйләнчекләре килеп чыкты. Слава дигән таныш түгел ул юньсезнең куркыныч бер кеше булуы ихтимал».

Ләкин бармыйча да ярамый, дөресрәге — бармый калырга көче җитми егетнең. Телдән әйтелмәгән, куктән ингән боерыкны тыңлап, ары китте һәм ачыклыкта таган атынучыларның берсе чынлап та Кама икәнлеккә тәмам ышанды. Ике кыз таганда атыналар, шулай да аста — биш-алты егет. Мөгаен, Слава дигәне дә шунда инде аның. Кайсы икән?

Фәез, якынрак килеп, егетләр белән исәнләшкән булды — Борисны күрмәгәннәрме, янәсе, шуны сорады. Борис монда булса, сөйләшерләр

идеме, юкмы — анысын әйтеп булмый, әлбәттә. Тегеләр: «Нинди Борис?» дигәч, аңлатып тормады үзе. Хәер, ул хәтле төпченүче дә юк бит.

— Галя, давай, син төшеп тор инде, әзрәк мин дә кыланып карыйм,— диде егетләрнең берсе.

— Кыланмый тор әле,— диде кыз.

— Без төшкәч,— диде Кама. Җил белән кочаклаша, елмая-көлә үзе!

Шушы мизгелдә Фәез, үз гомерендә беренче тапкыр дигәндәй (ярабби, соңгысы гына була күрмәсен!), егетлек эшләп ташламасынмы — үзе дә сизмәстән:

— Кама, анда сезне көтәләр, — дип дәште.

— Кайда?

— Баш идарәдә.

— Мин анда ник кирәк?

— Алдашма, син Борисны эзлисең,— диде егетләрнең берсе тупас кына итеп.

Алайга китсә, Фәез дә төшеп калганнардан түгел. Бүтәннәрдән аерылып торган шул егет янына килде дә, бераз гына янап:

— Син кайсы идарәдән? — дип сорады.

Егет исә мыскыллы карашын гына елтыратып, кыз янына атлады — саклап тора, янәсе.

Фәез кеше белән кычкырышкандагы кебек кызаруын сизә, ләкин һаман үзенә кирәген эшли бирә:

— Кама, төшегез әле, мөмкин булса.

— Ник? — дип гаҗәпләнде кыз, һәм, аныкыннан бигрәк, егетләрнең күзе шар булды.

— Бер генә минутка.

— Әйттегез бит инде. Мине баш идарәдә көтәләр. Ә минем барасым килми.

— Эш буенча...

— Без эшне таган атынганда эшләмибез,— диде Галя дигәне.

Фәезне санга сукмыйча, атына-очына бирделәр. Күзләр белән генә ияргә, күзәтеп кенә торырга кала мондый чакта... Кызларның икесе дә кара чалбардан һәм кызыл кофтадан. Галя яланбаш, ә Кама зур чәчләре өстеннән яулык бөркәнгән.

— Кама, ишетәсезме? — каян чыккан әрсезлек?! — дип кабатлады Фәез дә.

— Ишетмим! — диде Кама, хәтта бу юлы елмаймады да. Слава дигәне чынлап та яраткан егетеме икәнни? Алайса, бетте баш. Бусы койрыкчыдан яманрак шикелле, койрыксыз төсле тоела.

— Кама, шаяртмагыз, минем бик житди йомыш бит. Эш юктан буталып йөрүем түгел.

Кызлар тукталмыйча гына, югарыдан карап, Фәезгә таш төсле сүзләр ыргыталар.

— Питомникка барырга кирәк, ишетәсезме? — дип үзсүзләнгән булды мескен Фәез.

— Синең беләнме әллә? — диде Галясы.

— Анысы неважно.

— Синең белән булмагач, бармыйбыз.

— Бергәләп тә мөмкин, ачуны бик китерсәгез.

— Ә кем кушты? Лазаревмы? — диде Кама, Галя төсле котыртып.

— Кем дип, сезнең начальник, Бикашев.

— Бикашев командировкада! — Кама тагын чыркылдап көлде дә тагын да катырак атынырга керешә.— Әйдә, Галя, акылдан язган егетләр күп булыр бу дөньяда!..

— Синең аркада саташканга охшап тора,— диде Слава дигәне,

туп-туры Фәезгә карап.— Мин сине беләм, син дүртенче идарә начальнигы бит.

Фәез, үзенең бик җайлы хәлдә түгеллеген чамалап һәм моның өчен Камага рәнҗеп, кырт борылды да китеп барды. Киткәндә Каманың да чыраена җитди төс чыкканын сизми калмады һәм хәзер дә аркасы белән шул карашны тоеп бара. «Бүгенгә шушысы да җитеп торыр». Ә берничә секундтан...

— Фәез! — дип эндәшкән тавыш ишетелде. Билләһи, Кама тавышы! Һәм кыз йөгереп тә килде. Фәез ни дә булса аңлап өлгергәнче, егетенңе үзе култыклап, тәкәббер кыяфәт белән атлап та китте.

— Эх, Кама...

— Бик масайма, мин тегеләргә үч итеп кенә...

— Ничек үч итеп?

— Кулга бер эләккән кошны ычкындырабызмы соң инде, дип торган булалар.

— Җитмәсә, циниклар икән.

— Ә мин әйттем, кош булсам, сезнең кулдагысы түгел, ирекле кош мин, дидем дә сезнең янга йөгердем.

— Яхшы кыз син, Кама... Әкият...

— Я, я, сез дә телегезгә салынмагыз — гади бер кыз.

— Гади түгел шул.

Шул сүзләрне генә сөйләшеп өлгергәч тә, баягы юлдашлар күзеннән югалу белән, кыз кулын ычкындырды һәм җитди кыяфәткә керде. Хәзер аның белән сүз башлау баягыдан да читенрәк иде. Аптырагач, егет, үзенең элекке хаталарын хәтерләп һәм аларны кабатламаска тырышып, каушый-каушый сораган булды:

— Сезнекеләр кайда?

— Анда Бикашев юк.— Кызның күзләре хәйләкәр елмая иде.

— Булмаса соң! Агачлар китергәннәр. Башта сезгә утыртыйк, аннары — безгә.

Егет кызны җитәкләмәкче булган иде дә, тегесе, йөгерә-атлап, танышлары янына барды һәм ике көрәк алып, берсен Фәезгә тоттырды:

— Карап карыйк, сез утырткан агач үсәр микән.

— Үсмичә! — Ике үсентене бер чокырга куйгач, Фәез кызның әйтелмәгән соравына җавап бирде.— Безнең бүгенге күрешүгә истәлек булсын.

— Сентиментально!..— Бер сүз егетнең бөтен сөмсерен койды да төшерде. «Яратмый!»

Шуннан соң сүз агач, көрәк, туфрак һәм чокырдан ары узмады. Ахырда, кайтыр чак җиткәч, кыз шатлыкны көтелмәгәндә генә китергән кебек, шундый ук тизлек белән алып та китте.— Ул, зәңгәр кош, бүтән ят төркемгә кушылып, таныш сәер елмаюы белән, канат очын гына ялтыратты:

— Пока, Фәез!..

Егет әле генә утыртылган зәгыйфь үсентеләр янында катты да калды. «Шул кирәк сиңа! Тагын үзе култыклап алып китәр дип көттеңмени? Адәм рәтле нәрсә генә әйтә алдың? Булмый синнән, булмый — кызлар төсе күрмичә сакал агартачаксың син, егет!»

Хыял — җил, тәнгә кагыла, кулга бирелми. Хәзер ул җил ялангач кәүсәләрне тирбәтә...

Кайчандыр бу агачлар — аллеялар, бакчалар һәм урманнар булып — (Ә Фәез белә: бүгенге бу өмә районның барлык авылларында кузгалды!), Фәезнең эшкә ашкан ярты хыялы кыяфәтендә, чынга ашмаган мәхәббәтенең бары тик тиле һәм ышанычсыз бер ашкыну гына икәнен сөйләп, моңаеп утырырлар.

Борис мондый хәлдә калмас иде...

Әле кайчан гына икесенең дә күнел көр, эшләре шәп бара,— дөньялары гомумән түгәрәк иде. Хәзер икесенең дә тормышлары кайсы яктандыр китек һәм көйсез. Берсе бер яктан арттырып җибәрде, икенчесе икенче яктан... Димәк, гаеп аларның икесендә дә булган — югыйсә, берсенең генә тормышы көйсезләнер иде.

Фәез үзенчә, Борис үзенчә нәрсәнедер күрә, исәпли һәм нәтиҗә чыгара алмыйлар, күрәсең, яши белмиләр... шул яшәү фәнен үзләштерә алмыйлар. Болай ярамый, һич тә ярамый — егетлек түгел бу...

Һәм Фәез, йөгерә-атлый, кызны куып житте:

— Мин сезне озатмакчы булдым.

Камилә ачуланмады, көлде генә:

— Кая?

— Җир читенә.

— Киттек.

Халык арасында шундый сүз сөйләшүдән дә ары китә алмыйсың инде. Әле болары өчен рәхмәт. Димәк, сөйләшергә мөмкин. Ә Фәез, тиле, якын килергә куркып күпме йөрде! Хәзер ул инде курыкмаска сүз бирде — ак тәүбә, кара тәүбә! Төрле кеше төрле автобуска утырып таралышкач, ниһаять, алар икәүдән-икәү генә калдылар! Менә бит бәхет!

— Мин синсез тора алмыйм, Кама.

— Һи-һи-һи-и!..

Әлеге дә баягы сәер көлүе белән көлә кыз — әллә яратмый, әллә яратып үрти. Ник икәнен бәлки әле үзе дә белмидер. Белгәч әйтер. Шуңарчы түзәргә дә мөмкин. Дөнья гел әйбәткә бара бит, көннән-көн яктыра!

Аны-моны уйламастан, беренче номерлы автобуска утырдылар да Иске Чаллыга килделәр. Иске каланың тын урамнары һәм тыкрыклары буйлап йөрделәр. Сүз иярә сүз чыгып, теге чакта концерттан соң йөгерүне хәтергә төшергәч, Фәез кызның ул вакытта кая, ничек качуын сорады.

— Бик беләсең киләме? — дигән булды кыз.

— Бик килә, ач әле серенне.

— Күзләреңне йом да өч минут ачмыйча тор. Менә шулай.

Фәез ике-өч минуттан күзләрен ачса, кыздан тагы җилләр искән иде. Тыкрыкның икенче ягыннан эзләп карады, бүтән урамнарга чыкты — юк. Минутлардан сәгатьләр җыелды — юк та юк. Я инде, шушыннан соң әкият юк дип кем әйтә алыр? Кыз тиз генә автобуска утырып яңа калага китте яки бүтән урамга качты дип тә әйтергә булыр иде. Сер ачылгач, бәлки дөнья чак кына ямьсезләнеп куяр иде. Кызлар ахыргача серле булып калырга тиештер шул... Болай — дөнья бөтенләй бүтән төсле. Синең белән бергә килгән кыз бала тагын икенче рәвешкә, елга рәвешенә керде...

Текә яр.

Аста — дулкын шыбырдавы, су чайкалуы, Кама тавышы...

— Һи-һи-һи!..

Ник көлә ул? Юк, көлми. Көлүдән туктаган, нидер сөйли башлый. Фәез аны тагын аңлый. Менә нәрсәләр әйтә Кама:

— Мин — Кама... Мин гасырлар буе тыныч яшәдем, беркемгә комачауламадым, кешеләрнең күңелләрен иркәләдем, гомерләрен озайттым, баеттым,— ямь-яшел әрәмәләрем, җимешләрем, үләннәрем, чәчкәләрем, таулы-таулы ярларым белән, яшертен сукмакларым белән, кечке шавым, төнге серләрем белән бәхетле иттем. Мин сине дә шулай иркәләрмен, мин сине дә шулай сөярмен — тик кагылма минем серләремә, кагылма, тимә минем тынычлыгыма, сафлыгыма, кагылма минем горурлыгыма. Мин — Кама, сине яратырмын бары шул чагында, син кагылма минем серләремә!

Их, Кама, Кама!

Кичәгең изге, бүгенгең кадерле минем өчен, тик киләчәгең тагын да кадерлерәк, тагын да изгерәк. Минем сине тагын да матуррак итәсем килә. Үзеңне генә түгел, тирә-ягыңны, бөтен тормышыңны. Һәм теләгемә ирешермен дип беләм. Җаның теләгәнчә киенер, бизәнер өчен сиңа яңа фабрикалар төзелә... Җаның теләгән якка сәфәр китә алырлык тимер юллар, асфальт юллар салына, өр-яңа күперләр сугыла. Көне житкәч, уттан ясалган муенса, уттан ясалган алкалар, мәрҗәннәр, энҗеләр, тагын-тагын күп бизәкләр белән бизәнгән хәлдә, җемҗем килеп, өр-яңа театрларга, культура сарайларына, стадионнарга барып керерсең. Дөньяның һәм тарихның барлык принцессалары, королеваларь, хәтта гүзәллек призлары алган барлык чибәрләр синнән көнләшер! Менә сиңа нинди матурлык вәгъдә итәм мин, Кама!»

Сүзләр ярларга килеп кагылалар да тагын арырак, ераграк китәләр — аларны дулкыннар озата бара, сүзләрне таулардан тауларга, әрәмәләрдән урманнарга илтеп, төнге җил чыңлата.

Моңарчы беркайчан да, беркемгә дә билгеле булмаган, бары тик үзе генә эзләп тапкан серле мәхәббәт дөньясына килеп чыкты Фәез. Моннан да зур бәхет бармы икән?! Табигатьнең үзе белән берләшкән гүзәллеккә, мәңге яшь, мәңге үлемсез һәм сихерле гүзәллеккә мәхәббәт! Менә шушы яшел яз кебек, җәй кебек, ямансу көзләр кебек, ап-ак хисләр белән дөньяны агарткан йомшак һәм саф карлар кебек, саисыз-чамасыз йөрәкләрнең һәркайсына аерым-аерым истәлекләр калдырган төннәр һәм таңнар кебек — мәңгелек мәхәббәт!

Әкият бар.

Әкият — тормышның үзе.

Тормыш — үзе әкият.

Алар мәңге берга!

*Ахыры бар*

## Дифгать Сирай

### Төндә

Төнге тынлык баскан урамнарны,
Бар табигать чумган йокыга.
Тик ай гына, йолдызларны җыйнап,
Күктә мәҗлес ясап утыра.
Яз килүен бәйрәм итәдер ул,
Шатлыкларын аның кем бозар!
Җиргә якты күбрәк төшсен дипме,
Балкып-дөрләп яна йолдызлар...
Җиребезне, күгебезне шулай
Гүзәл итеп килә күрәсе.

Сискәнәмен,
Әгәр йолдызларның
Калтыранып куйса бирәрсе.

### Дәвам итәбез

Сез коммунист булмагансыз, диеп,
Әтиләргә һич юк үпкәбез:
Алар барган Ильич сызган юлдан,
Ә без аны дәвам итәбез.

Киндер күлмәк, чабаталар киеп,
Таугә буразнаны салганнар.
Кирәк чакта Ленин эше өчен
Кулларына мылтык алганнар.

Һәйкәл булып басканнары күпме! —
Кайтмаганнар иген игәргә...
Сез коммунист булмагансыз, диеп,
Кем әйталсын андый ирләргә.

Сез коммунист булмагансыз, диеп,
Әтиләргә һич юк үпкәбез;
Алар эшен,
Коммунистлар булып,
Без — уллары дәвам итәбез.

## Кар сулары акты

Кар сулары акты.
Йөрәгемнән
Сагышларым төште юылып.
Җир яшәртеп бәбкә үлән чыкты,
Тәүге чыклар төште коелып.
Кабат туды иркә яз гөлләре,
Кабат туды ләззәт-сагышлар...
Алларыма иелеп җәй шатлыгын
Сөйләр әле, сөйләр арышлар.
Дулкынына күмелеп мин аларның,
Җыр сузармын бәхет турында...
Ак тәлгәшен туэгый-туэгый җилдә
Коена шомырт кояш нурында.
Аның кебек тагын бер мәртәбә
Булса иде яфрак ярасың.
Шомырт шавы әйтә кебек гүя:
«Үкенечләр җирдә калмасын!»
Кар сулары акты.
Йөрәгемнән
Сагышларым төште юылып.
Әллә шуңа җиргә баскан саен
Чыга кебек шатлык ургылып.

## Нигез

Бомбалардан барысы көл булса да,
Нигез торды, нигез купмады.
Күтәрделәр өсләренә мәңге
Аумас итеп яңа йортларны.

Ныклыгына ышанмаган күпләр
Бәреп ватты шунда башларын.
Россия ул! — СССРның нигезе! —
Ленин салды тәүге ташларын.

Шул нигездә утыра татар халкы,
Белорусы, мари, чувашы...
Дуслык хисе белән цементланган
Ул нигезнең күптән һәр ташы.

Өйләр күтәрәләр,
Заводларның
Корпуслары ашкан болытка.
Ташлар түгел, бөек дуслык ята
Нигезендә аның, онытма!

## Шамил Маннапов

●

Бер мәкаль бар:
Үз гомереңдә, диләр,
Бер өй салып керсен ир-егет.
Шуңа мәллә яңа төзелеш, дисәң,
Яшьләр тора бездә җилкенеп.
Өй генәме,
Кала төзи алар,
Үзенә дә төзи, дуска да.
Алар төзегән урамнарга заман
Өлгерәлмый исем кушарга.
Заман шулай,
Үзе ашыктыра,
Тик исемне бирми ашыгып.
Исеме булыр,
Эше генә булсын,
Исем-атсыз калмый яхшылык...

### Йолдызлар

*Калмык шагыйре Е. Буджаловтан*

Төнге күктә, саргылт эз калдырып,
Кинәт кенә йолдыз атылды.
Югалды ул җир читенә төшеп,
Минем уйлар шунда тартылды.

Нигә сүнде икән соң бу йолдыз?
Теләсәң ничек кенә бәялә.
Әллә аны иптәшләре шулай
Ташладылар микән бәлагә?

Бәлки, һичкем белән аңлашалмый
Ул күп еллар җәфа чиккәндер.
Ялгызлыктан тәмам сабырын җуеп,
Үзен-үзе һәлак иткәндер...

Ә бәлки, ул бер тәкәббер булып,
Яраткандыр үзен зурларга,
Сөрелгәндер күктән шуңарга?!

Ул югалды. Моңа карап ләкин
Кымшанмады берни дөньяда;
Төнге күкне тутырып элеккечә
Җем-җем итеп йолдызлар яна.

Яңа фатирга күчтек без:
Үзем, әнисе, кызым.
Ял җиттеме, карчык белән
Өйдә икәү көнозын.
Иске дус, таныш-белешләр
Калды башка районда.
Аның каравы, кызымның
Эше күп икән монда.
Шулар белән көннәр буе
Уйный безнең Зөбәйдә.
Бик еш кына дус-ишләрен
Алып керә өйгә дә.
Бу йорттагы балаларның
Безгә таныш һәммәсе,
Безнең дуслар:
Лена,
Лира,
Азат,
Самат
Һәм Нәсим...
Бер көн шулай чәй эчәбез,
Үзем, әнисе, кызым.
Үзебез генә күңелсез
Булыр дисәм көнозын,
Килеп керә:
Лена,
Лира,
Азат,
Самат
Һәм Нәсим.
Әтисе белән әнисен
Җитәкләгән һәммәсе...
— Таныш булыгыз,— диешеп,
Күрештерделәр безне.
Сөенеп елмаюлары
Яктыртты өебезне.
Күңелләр түгәрәкләнде,
Түгәрәкләнде табын.
Ә нәни дуслар үзләре
Урамга чапты тагын.

Ял җиттеме, хәзер бездә
Кунак була көнозын.
И күбәйде дусларыбыз:
Бик рәхмәт инде, кызым!

## Егор Уткин

### Ат сакларга чыга

Кичке энгер. Күз бәйләнеп килә.
Инеш аша агач күпердә
Күпме-күпме тояк тавышлары,
Атлар чыга төнге көтүгә.
Инеш аръягында яшел болын
Урманга ук барып тоташкан.
Атлар утлар. Ә малайлар төнне
Учак ягып чыгар тоташтан.
Чалкан ятып күкне күзәтерләр,
Метеормы оча, корабмы?..
Кызыктырмый малайларны хәзер
Кыйссалары Шәкүр каракның.

Малайларны тарта элеккечә
Атлар, төнге көтү җәйләрен.
Онытмаслар зәңгәр төндә эчкән
Төтен исе сеңгән чәйләрен.

Инеш буендагы учаклары
Күңелләргә күчеп янарлар...
Кичке энгер, күз бәйләнеп килә,
Ат сакларга чыга малайлар.

### Үз үре бар җирдә

Соң туганмын, диеп, зарланмады,
Бар җирләр, дип, инде ачылган.
Ул яңа бер мавыктыргыч дөнья —
Атлантида ачты басудан.
Карангыда гына кайтып керә,
Арып кайтып керә өенә.
Ужымнар, һай, әйбәт — сөенә ул,
Яңгырлар юк, яумый — көенә.
Янгыр юкмы? Тәрәзәсе аның
Кыска төнгә ничә ачыла.
Таң нурлары — сигнал ракетасы,
Ул кырларга янә ашыга.
Тузаннарга батып бетә үзе,

Танырсың тик шаян күзеннән.
Юк сораулар белән кагылмагыз,
Ризамы, дип, эштән, үзеннән?
Кагылмагыз аның күңеленә,
Үз үре бар җирдә кешенең.
Шуннан ачыла аңа тормыш яме,
Гүзәллеге җирнең, эшенең.

## Тегермән

Инеш буендагы тегермәнгә
Монда һәркем юлны өйрәтер...
Узган җәйдә яшен сугып киткән
Буа өстендәге тирәкне.
Җилдә шаулап үскән зифа талдан,
Белмим, яшен нинди үч алган?
Болай да бит монда моңсу тынлык,
Карт тегермән череп, кыйшайган.
Көч-дәрт бирми инде хәзер аңа
Көзге сулар булсын, язгысы.
Таш өстендә алабута үскән,
Һай, гомерләр, дөнья язмышы!
Үзен тарткан таш өстендә бит ул
Бер дә юкка гына үсмәгән.
Булды еллар, ашлык оны түгел,
Алабута акты мөшкәдән.
...Кыш бабаң ни, тегермәнче карт ни —
Охшаш, диләр, авыл яшьләре.
Ул елларда тегермәнче абзый
Яшел иде — кашы, чәчләре...
Яшел иде моңсу чырае да
Кунгач алабута онтасы.
Монда хәзер юллар онытылган,
Еллар, сезне ничек онытасы?
Юраш буендагы карт тегермән
Күпме хезмәт итте бу якта...
Ташларына үскән алабута
Тирән хатирәләр уята.

# АЗАТЛЫК ҖЫРЛАУЧЫ ПОЭЗИЯ

Вьетнам — бер үсеп торган агач.
Ботаклары — Төньяк, Көньягы.
Көньяк белән Төньяк — бер кешенең
Ике кулы, ике аягы.
Һавабыз һәм суларыбыз — уртак,
Безнең уртак биек таулар бар.
Партиябез, юлбашчыбыз уртак,
Аералмаслар безне дошманнар.

*Батыр Вьетнам халкы әнә шулай җырлый...*

*Вьетнамның Төньягында һәм Көньягында яшәүче барлык халыкларның да теләкләре бердәм һәм уртак: Ватан бәйсезлеге өчен барган азатлык көрәшендә җиңеп чыгу, үз илеңдә үзең хуҗа булу.*

*Вьетнам борын заманнардан бирле — шагыйрьләр һәм чәчәннәр иле санала. Аның халкы элек-электән шатлыгын да, кайгысын да җыр белән белдерергә ярата.*

*Вьетнам әдипләре халык арасында аеруча хөрмәттә һәм игътибарда йөртелә. Матур әдәбиятка булган мондый караш бу илдә буыннан-буынга күчеп дәвам итә. Мәсәлән: XI гасырда Ханойда махсус «Әдәбият кәлисәсе» салыну иҗат эшенең мактаулы һәм кадерле хезмәт булуын күрсәткән фактлардан берсе. Шушы кәлисәдә ел саен илнең яшь әдипләре шагыйрьлеккә имтихан тотканнар. Ярышта җиңеп чыккан шагыйрьләрнең исемнәре мактау тактасына — ташка уеп язылган. Ул ташлар әле дә сакланалар. Шагыйрьлеккә имтихан тоту йоласы Вьетнамда дүрт гасыр буена дәвам иткән.*

*Прогрессив вьетнам поэзиясе элек-электән феодализмга каршы көрәш идеяләре белән сугарылган була. Вьетнам әдәбияты тарихын XV—XIX йөзләрдә Ле Тран Тон, Донг Минь Кхьем, Нгуен Зу, Доонь Тхи Дием һәм Хо Суан Хыонг кебек атаклы шагыйрьләрнең иҗатлары бизи. Алар үз әсәрләрендә, башлыча, вьетнам хатын-кызларының авыр тормышын чагылдырганнар. «Вьетнам поэзиясенең алиһәсе» дип йөртелгән Хо Суан Хыонг, мәсәлән, кыз чагында үзе дә икенче хатынлыкка көчләп бирелгән була. Ул үзенең ялкынлы һәм тапкыр шигырьләре белән феодализм йолаларына, хатын-кызның кимсетелүенә каршы көрәш уты ачкан. Вьетнамда хәзерге көндә дә туры һәм матур сүз әйткән кешене ишетсәләр: «Хо Суан Хыонг кебек әйтте»,— диләр.*

*Вьетнамның бүгенге яңа революцион поэзиясе әнә шул борынгы әдәби традицияләргә нигезләнеп үсә һәм ул үз халкының бай көрәш тәҗрибәсен чагылдыра.*

*Моңарчы Вьетнамдагы төп халыкның гына, ягъни вьетнамлыларның үзләренең генә, язма әдәбияты булган, ә илдәге калган кырыкларп телдә сөйләшүче халыкларның язуы бөтенләй булмаган. Хәзер исә тхо, тхай, ман, кхмер кебек халыкларның үз язмалары бар, аларның һәркайсының милли әдәбиятлары һәм сәнгатьләре үсә.*

*Вьетнам әдәбиятының бүгенге көн геройлары — Америка агрессиясенә каршы көрәшүче патриотлар.*

*Вьетнам поэзиясе тирән психологик кичерешләргә бай булган образлары белән укучылар күңелен җәлеп итә. Шагыйрь кинди генә чолганышта яшәмәсен — йолдызлы зәңгәр күк йөзе, туган-үскән иленең әкияттәгечә гүзәллеге, елгаларының, урман-кырларенең һәм хәтфәдәй яшел болыннарының матурлыгы аның әсәрендә үз чагылышын таба. Ләкин табигать матурлыгын утларда яндыручы басыннар исә туган җирне сызланырга, сыкранырга, ирексездән кешеләрне газаплы шартларда яшәргә мәҗбүр итәләр. Сугыш тудырган фаҗигале авырлыкларны вьетнам язучылары да үз җилкәләрендә кичерәләр. Алар сугыш барган районнарга чыгып айлар буена халык арасында яшиләр. Батыр халыкның Америка башкисәрләренә*

*каршы көрәшен, аның тормыш ихтыяҗларын өйрәнәләр. Халыкның шатлыгын, кайгысын уртаклашалар. Алар авылның иң ярлы кешесенә төшәләр һәм хезмәтчәннәр партиясе таләп иткән түбәндәге «өч шартны» үтәргә тиеш булалар: хуҗа белән бертигез эшләргә; хуҗа ни ашаса, шуны ашарга; хуҗа нинди шартларда яшәсә, шулай яшәргә сүз бирәләр. Бу бер язучылар өчен генә куелган шарт түгел, әлбәттә, авылга килгән һәркем өчен дә мәҗбүри.*

*Чын дуслык — авырлыкта сынала, ди халык. Авыр сугыш көннәрендә Вьетнам белән безнең ил арасындагы эчкерсез дуслык мөнәсәбәтләре көннән-көн ныгый һәм көчәя бара. Әдәбият исә бу дуслыкны үстерүдә күпер хезмәтен үти. Хәзерге вакытта Вьетнамда совет әдәбияты җәүһәрләрен тәрҗемә итү һәм бастырып тарату елдан-ел киң колач ала бара. Шулай ук безнең ил матбугатында да Вьетнам язучыларының әсәрләре еш басылып тора. Мәсәлән, 1966 елда татар һәм вьетнам язучылары әсәрләреннән төзелгән татар телендә «Җиңелмәс Вьетнам» исеме белән җәмәгатьчелек тәртибендә бер китап басылып чыкты. Укучыларыбыз бу китап аша Вьетнам әдәбиятының бай эчтәлекле һәм югары художестволы әсәрләрен укып, вьетнамлыларның азатлык өчен көрәштә күрсәткән батырлык үрнәкләре белән таныштылар.*

*Вьетнам поэзиясе бүгенге көндә солдат поэзиясе булып күз алдына баса. Ул халык белән тыгыз бәйләнештә, аның көрәшендә иң алгы сафта бара. Вьетнам халкының шагыйрьләр армиясе үз җырларында халыкка хыянәт итүче курчак армиясе ялчыларын, аларны узындыручы империалистларның мәкерле планнарын фаш итә.*

*Журналыбызның бу санында без яңа Вьетнам поэзиясенең кайбер үрнәкләрен урнаштырабыз.*

## То Хыу

### Яшел күлмәк

Матур күлмәкләр тектең,
Ман син аның агын...
Манмыенча киялмыйм,
Сугыш бара, җаным.

Хәтфә чирәмдәй төсе
Яшел булсын аның.
Ап-ак килеш кияргә
Сугыш кушмый, җаным.

Мангач бик утырса да,
Бәлаләрдән яклар...
Туган ягымның төсе
Үлемнәрдән саклар.

...Мәңге сүнмәс, мәңге яшь
Мәхәббәтең белән —
Мин сине яклап, Илем,
Янган утка керәм!

### Вьетнам кызына

Герой кыз Лигә багышлана

Син бер кызмы, фәрештәме,
Тиңләшер кемнәр генә?
Кара болыт төсле чәчләр
Таралган иңнәреңә...

Күзләреннең упкынында
Яшен уты бар сыман,
Буй-сыннарың бигрәк зифа,
Бөгелә-сыгыла, тал сыман.
Үлем сине алалмаган.
Син тере, исән менә!
Кулларың нәфис, охшаган
Бакчаның гөлләренә;
Мәнге яшәрдәй, нык алар,
Корычтай бөгелә генә!
Аһ, нинди сызлана тәнең!
Аһ, нинди салкын тезең...
Төшенәм, бик авыр хәлең,
Килче, бер үбим үзем.
Уян син, гүзәлкәй! Терел!
Терел, бу бит төш кенә...
Ут, инә, үткен хәнҗәр дә
Үтәлмаган түшеңә.
Йөрәгеңдә
нәфрәт-ялкын,
Калганда тамчы каның —
Авылың, йортыңны түгел,
Ил саклап сафта калдың.
Син исән! Яшьнәп яшә!
Сине ал байрак дәшә...
Ак биләүләргә биләп,
Бәллү көйләрен көйләп,
Бөтен ил, бөтен халык
Тирбәтә хәйран калып:
Анаңдай, йокың бүлдерми
Тынычлык саклар җирең;
Тху-Бон[1] буйлап янгырар
Көрәштә җиңү җырың.
Күзеңдә яз көлсен өчен,
Озайтырга гомерең синең,
Алсулансын өчен йөзең —
Җан өрергә әзер илем!
Син — чын кызы Вьетнамның,
Бөтен тормышың көрәштә,
Кем син, Вьетнам сылуы Ли?
Тылсымлы зат, я фәрештә?!

## Те Хань

### Ленин һәм Аппассионата

1

Ут уйнаткан январь көннәрендә
Ленин килә дусты Горький янына.
Мамык карлар уйнап, арып-талгач,
Җиргә төшеп тынып ята ялга:
Түбәләргә ап-ак карлар ябыла.

[1] Тху-Бон — елга исеме.

Тәрәзәдә кыш туй итә. Тышта
Январь белән бәхәс кызып китә:
Ленин, мичкә утын ташлый-ташлый,
Китап алып, шәм янына үтә.
Йорт хуҗасы ярлы-ябык яши,
Илнең үзе кебек гади, садә.
Сый урынына бөек Бетховенны
Ул уйнарга куша пианинода.

Таныш клавишлар телгә килә,
Күкрәп уза Аппассионата.
Кырлар шавы, кошлар җыры агыла,
Туплар тавышы яңгырап тора анда!
Дәрт, ышаныч һәм омтылыш монда...
Тыңлый аны Ленин, алмый тын да.
Моңнар аша җирне үтә күрә,
Планетаның гүя йөрәген тоя.

Аккорд тына, Ленин саубуллаша.
Салмак, сабыр гына төн тын ала.
Тротуарда аның карлы эзе
Ярсу ноталардай ярылып кала...

2

Ханойда күрештек. Җиңү юлы
Җиңел түгел, тик шатлыклы иде.
Сөеклем! Сиңа нәрсә бүләк итим?
Булмаса, ал Аппассионата
тыңлап торган
Ленин портретын...
Истә тотыйк аның елмаюын.
Ул — җиңелмәс һәм ул — үлемсез җан.
Көрәш кубар,
Бу сугышта, сөзәк урамнарда
Шекспир һәм Микеланджелолар
Көрәшер безнең баррикадаларда!
Октябрьның җиңү авазына
Аваздашлык табар
Гаҗәп тавышлары аларның да.
Нурлы таңнар төн башына җитәр,
Кешеләргә җиңү хәбәр итәр.
Бәгырем, каушама син давыллардан.
Безне Бетховен җыры кыю итә!
Ул — безнеке...
Нгуен Чай, Нгуен Зу[1] кебек,
Ул безгә көч бирә, гайрәт кертә.
Бу көнне бик яхшы хәтерлә син:
Туплар тавышы... Төтен сарган җирем...
Бетховенның Аппассионатасын
Без тыңлыйбыз. Тыңлый аны — Ленин!

---

[1] Нгуен Чай (1380—1442) һәм Нгуен Зу (1765—1820) — күренекле вьетнам шагыйрьләре.

## Хоанг Тхи Минь Кхань

●

Көчсезләнеп тала бара минем куллар.
Акрынаеп, адымнарым тукталалар.
Маңгаема картлык тирән җөйләр ясый,
Күзләрем дә инде тоныкъ, күрми башлый.
Гөлчәчәкле бакчамны төн капласа да,
Моның өчен мин кайгырмыйм һәм зарланмыйм.
Үзем һаман артык бирсәм дә тормышка,
Аңардан мин үзем өчен азрак алдым.
Яшь чагымда иркен, рәхәт гомер сөргәч,
Бернигә дә үкенмим мин картлык килгәч.

## Фам Хо

### Тәҗрибәсез бал корты

Беренче бал җыюы иде бал кортының...
Менә кинәт ул бер чәчәк күреп алды.
Умартама күп итеп бал җыйныйм диеп,
Шул чәчәккә җан-фәрманга очып барды.
Күп маташып йөрде сантый ал чәчәктә...
Хәлдән тайды — бал табылмады, әлбәттә.
— Эх, каян тап булдым,— диде,— килбәтсезгә!
Үзе ал да... ләкин бал юк шөкатьсездә!

Чү, ни булды! Чәчәк телгә килде шулчак:
— Хурлыйсың син... Мин бит бары — кәгазь чәчәк!

## Ван Дай

(Шагыйрә)

### Солдат курткасы

Көньяклардан салкын җилләр исә.
Янгырларда йөридер солдат...
Барлы-юклы акчам сарыф итеп,
Мамык куртка сырам ыспайлап.
Җөйләр салып инәм оча гына...
Бик тигез дә түгел ул шуңар.
Жылысы да булмас инде артык,
Тегү текканмени бу куллар...
Ләкин аның тышлыгы нык, эрсез,—
Халкым аңа биргән жылысын.
Фронтка салам аны, ләкин белмим
Киючесе кемнәр буласын.
...Бүген төнлә ачы буран уйный —
Каралтылар елый, җил улый.
Ә үземнең бернәрсәм юк ябыныр,
Тән салкынны тоймый барыбер...

Ә. Синегулов тәрҗемәләре

Әхмәт Рәшитов

# ӨЧЕНЧЕ ОЧРАШУ



Язның: «Барыбер киләм, барыбер җиңәм!» дип кире беткән кыш белән тарткалашкан чагы иде ул. Шундый көннәрнең берендә халык телендә «Татарстан котыбы» дигән исем алган Әгерҗе якларына командировкага барып чыгарга туры килде. Бу, юлда очраган бер абзый әйтмешли, «аллалар һәм кешеләр тарафыннан онытылган» җирләрдә таныш-белешләремне, бигрәк тә иң якын дусларымның берсен очратырмын дип һич кенә дә уйламаган идем.

Барысы да көтмәгәндә булды. Район газетасы редакциясендә подшивкалар актарып утырганда, кайбер мәкаләләр астында таныш исем-фамилия — «М. Шаммасов» дигән имза чагылып китте. «Сәламәтлегегезне саклагыз», «Радикулитны дәвалау турында», «Чисталык өчен көрәшик», «Кан бирү — иң шәфкатьле эш»...

Әйе, ул врач. Улдыр, мөгаен, улдыр...

— Ниндирәк кеше бу Шаммасов дигән врач? — дип сорыйм мин редактор Тәүфыйк абый Рәхмәтуллиннан, икеләнүләремне сиздермәскә тырышып кына. Тәүфыйк абый — минем күптәнге танышым. Ул Буа район газетасында эшләгәндә, мин — укучы малай — тәүге хәбәрләремне аңа күтәреп килә идем.

— Ә-ә, безнең якташ ул. Бидәнге егете. Актив хәбәрчебез,— ди Тәүфыйк абый.— Шәп врач. Аның турында «Социалистик Татарстан»да да язып чыктылар...

Әлбәттә, ул!.. Калганы яшен тизлеге белән эшләнә. Телефон безне Әгерҗенең үзәк больницасы белән тоташтыра. Без очрашырга сүз куешабыз.

Менә ул ак халаттан, бераз аптыраганрак кыяфәт белән басып тора. Соргылт чәчләр, кыска, ләкин имәндәй нык гәүдә, киң күкрәк, күзләре шул ук шаянлык һәм мөлаемлык белән елмая. Тик еллар гына аның маңгаена берничә сызык салган.

— Исәнме?!

— Исәнме?!

— Нинди җилләр белән?..

Аннан ул, кисәк кенә борыла да, кабул итү бүлмәсеннән чыгып килүче картка:

— Абый, сезгә кыймылдарга ярамый, дип әйттем бит инде. Хәзер менә машина килер дә операциягә алып китәрләр үзегезне,— ди,— менә монда диванга ятып торыгыз,— һәм җайлап кына агайга урын әзерли башлый.

Аннан транспорт юклыктан зарланып ала. Әле генә ишектән борчулы кыяфәт белән килеп кергән медсестра кызга:

— Узып баручы теләсә кайсы машинаны туктатыгыз. Һәр минут кадерле,— дип күрсәтмә бирә. Каушамый, каударланмый, тавышын күтәрми. Һәр сүзе үлчәнгән, беркем йөзендә дә ризасызлык галәмәтләре күрмәссең.

Әйе, бу ул — минем яшьлек дустым Миңгәрәй. Врач Миңгәрәй Шаммасов.

* *

Юк, мин бу сөйләгәннәрем белән аның тулы образын гәүдәләндерергә җыенмыйм. Юл язмалары яки истәлекләр дә түгел минем хикәям. Ул, барыннан да бигрәк, безнең буынның тормыштагы урыны турында уйлану, замандашларыбыз портретына берничә штрих төшерергә омтылыш, бабалардан аталарга, аталардан балаларга күчә барган бөек мирасның эзлеклелеген, дәвамлылыгын аңларга тырышу гына.

Хәзер чәчләренә көмеш кунган олы буын кешеләре безнең якты киләчәгебез, бәхетле яшьлегебез хакына Кышкы Сарайны штурмлаганнар, җир шарының алтыдан бер өлешендә азатлык һәм матур тормыш урнаштырганнар. Аннан соң килгән икенче буын бу казанышларны Бөек Ватан сугышы кырларында яклаган, аларны рейхстаг түбәсенә кадалган алсу байрак итеп җилфердәткән.

Октябрь таңында языла башлаган яңа тарих бүген өченче буын белән очраша.

Өченче очрашу! Бар дөньяга яңа социалистик дәүләтнең барлыкка килүен хәбәр иткән «Аврора» залпы яңгыраган данлы заманнарның идеалын мирас итеп алган, Волочаевка көннәрен, илебезнең индустрия гигантлары — Днепр ГЭСы һәм Магнитка турында китаплардан гына укып белгән, сугыш җиле язмышларына бала чак һәм яшьлек хатирәләре булып кына кагылып үткән бу өченче буын революция тапшырган эстафетаны ничек дәвам итә соң? Мин бу язмада әнә шул турыда уйланам. Күз алдымнан бер-бер артлы дусларым, иптәшләрем, таныш булмаган чордашларым уза. Хыялымда чирәм җирләр героикасы, космосны яулау, Новосибирск янындагы Академия шәһәрчеге, Совет — Кытай чигендә Мао провокаторларына отпор биргән Даманский утравы баһадирлары пәйда була.

Еллар үткән, буындашларымның кайсылары Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Ленин һәм дәүләт премияләре лауреатлары булганнар, икенчеләре орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән. Кемнәр генә юк алар арасында: эшчеләр һәм колхозчылар, инженерлар һәм космонавтлар, врачлар һәм укытучылар, журналистлар һәм фән эшлеклеләре, партия, совет, комсомол һәм профсоюз работниклары... Ил язмышы өчен тәп җаваплылык торган саен менә шушы өченче буын кешеләре өстенә төшә бара. Күренекле хезмәтләре өчен КПСС Үзәк Комитеты членлы дәрәҗәсенә күтәрелгән, хезмәт иляре депутатларының Верховный һәм җирле Советларына сайланган чордашларыбыз азмыни безнең? Аларның һәркайсы безнең буын горурлыгы! Ленин партиясе тәрбияләп үстергән яңа дәвер кешеләре алар! Җитдиләр, сабырлар, тынгысызлар...

* * *

Миңгәрәй Шаммасов та әнә шул өченче буынның типик бер вәкиле. Шаккатырырлык батырлыклар эшләргә дә, бөтен дөнья күләмендә танылырга да өлгермәгән әле ул. Аның хезмәте яңа тормыш төзүче миллионнарныкы кебек үк тыйнак һәм гади. Орденнар һәм медальләр дә дәгъва итми, фанфарларга да табынмый. Ул — миллионнардан берәү. Мин аны, башкалардан аерып, идеаллаштырырга да, бердәнбер итеп күрсәтергә дә теләмим — аның мисалында өченче буын кешеләренең үсеш эволюциясен абайларга, бала чак дустым белән өченче очрашу турында гына сөйләргә телим.

Әйе, соңгы — өченче очрашу турында...

* * *

Без моннан 20 ел элек Олы Тархан урта мәктәбенең сигезенче классында укыганда танышкан идек. Егерме дүрт кыз арасында «егет» исеменә дәгъва итүче алты малай... Миңгәрәй Шаммасов, Хәмзә Минкин, Тәүфыйк Җиһаншин, Илдар Әүхадиев, Фарит Өлмә һәм мин... Алтыбызда алты төрле характер. Шулай да бөтенебез диярлек Миңгәрәй белән дуслашырга омтыла. Бу сабыр холыклы, җор сүзле малай безне ни белән җәлеп иткәндер инде. Әйтүе кыен.

Мине аның белән әдәбиятка мәхәббәт якынайтты. Олесь Гончарның «Байрак йөртүчеләр» романын укыгач, гәплөшә-гәплөшә Тархан урамнарын буйлавыбыз хәтергә вөруча нык сеңеп калган. Рухи яктан бер-беребезне аңлавыбыз да, чын мәгънәсендәге беренче очрашуыбыз да шул булгандыр инде. Ул яши торган квартирага җитәбез дә тагын кире борылабыз. Шулай бер-беребезне озата-озата төн уртасына кадәр йөр-

дек без. Яшәү мәгънәсе, киләчәккә алып барачак хыяллар турында сөйләштек шикелле. Аннан мәктәп күләмендә әдәби альманах чыгару турында килештек. Икебезнең дә романтика канатында очкан, шигырь белән мавыккан чагыбыз иде.

Әйткән сүз — аткан ук. Ике атнадан альманахыбыз классташларыбыз кулына барып ирешә. Рәссамыбыз Илдар Әүхәдиев аны матур итеп бизәде. Тәүфыйк Җиһаншинның хикәясен, Миңгәрәйнең лирик парчаларын, минем тәүге тәҗрибәләремне эченә алган иде ул. Ләкин нинди парадокс: әдәбият белән шашынып йөргән Миңгәрәй математика, физика, химия кебек төгәл фәннәргә күбрәк күңел бирә иде.

Аеруча ул химия дәресләрендә җанлана. Укытучыбыз Хәмдия апаның сөйләвен без кызыксынып тыңлыйбыз. Ул дәреслекләрдә булмаган күп кенә нәрсәләр турында да мәгълүматлар бирә, абыйсы атаклы профессор Гыйлем Камайның хезмәтләрен телгә ала. Ә Миңгәрәй аның иң яраткан укучыларыннан булгандыр, мөгаен, аны һәрвакыт безгә үрнәк итеп куя, «химия бик мавыктыргыч фән ул, аны бер яратсагыз, аерыла алмыйсыз», — ди торган иде.

Класс җитәкчесе Рәхмәтуллина апа алып барган физика дәресләрендә дә Миңгәрәй «5»леләрне башкаларга караганда күбрәк ала иде.

Төгәл фәннәргә булган әнә шул олы мәхәббәт һөнәр сайлаганда да хәлиткеч роль уйнаган, күрәсең, гомерен ул иң кешелекле профессиягә — медицинага багышларга карар иткән.

Очрашкан чакта ирексездән хатирәләргә биреләсең. Ул эштән бушагач та, без берәм-берәм классташларны искә төшерә башладык. Бөтен класс егетләрен һуштан яздырып йөргән иң чибәр кызыбыз — Мәгъсүмә Чумаринаны, атаклы шахматчыбыз Хәмзә Минкинны, кырыслыгы белән малайларның теңкәсенә тигән Шамилә Чумаринаны телгә алдык. Миңгәрәй миңа караганда хәбәрдаррак булып чыкты.

— Шамилә хәзер — педагог. Математика укыта, не шали, брат... Хәмзәне Казанда слесарь булып эшли дип ишеткән идем. Гаиләсе дә шактый зурайган, ди, бугай... Ә синең авылдаш?..

— Тәүфыйкны әйтәсеңме? Ул зур гына начальство хәзер, — дим мин, — Казанның укыту-производство предприятиеләрендә сукырларны һөнәргә өйрәтә. Мастер...

— Да, бар иде заманнар... Диңгез тубыктан дип йөргән гамьсез чаклар.

— Ә хәзер менә төпкә җигелеп тартабыз инде. Һәммәбез дә тормыш мәшәкатьләренә күмелгән... — ди Миңгәрәй, фәлсәфәгә бирелеп. — Чыннан да кызык бит... Әле кайчан гына борын асты кибеп җитмәгән малайлар идек. Хәзер «Фәлән Фәләнович» дип дәшәләр. Барыбыз да тормышта үз урынын тапкан... Яраткан эшебез бар... Бала-чагалар үрчеп китте. Әтиләр-әниләр булырга өлгердек. Кызык инде, бер карасаң...

— Ә синең йөрәккә ут салып йөргән классташ ничек соң?.. «Катюша»ны әйтәм, күргәнең бармы?..

Ул авылдашы Кәүсәрия Измайлованы шулай «Катюша» дип үртәргә ярата иде.

Миңгәрәй кисәк кенә тынып кала (авырткан җиренә кагылдым бугай!). Аннан сүзне башка нәрсәгә күчерергә теләп булса кирәк:

— Сәрияне хәтерлисеңме? — дип сорап куя.

— Рәхмәтуллинанымы?.. Үзебезнең старостабызнымы?.. Ничек инде онытасың аны...

— Үлде шул ул... — ди Миңгәрәй, тирән көрсенеп. — Мин сискәнеп китәм. — Педагогия институтын тәмамлап эшли генә башлаган иде. Менә бит ничек ул тормыш дигәнең... — Аннан үзен гаепле санагандай тезеп китә. — Күпме яхшы кешеләрне үлем безнең арадан алып китә... Их, бернинди авыру алдында да чигенми торган кодрәткә кайчан ия булырбыз... Һәркайсыбызның күңелендә матур эз калдырган, яшәүне сөйгән кешенең шундый иртә үлүенә һич ышанасы килми...

* * *

Моннан алдагы очрашуда Миңгәрәй минем алда икенче яктан — бөтенләй көтелмәгән яктан ачылган иде. Татарстан сәламәтлек саклау министрлыгына ашыгып иде ул. Аны, медицина институтын тәмамлау белән, караңгы гына бер авылның участок больницасына баш врач итеп җибәргәннәр икән.

— Бинасы бөтенләй ташландык хәлдә. Койкалар җитешми. Дарулар, инструментлар һәм процедура кабинетлары турында әйтәсе дә юк. Аспирин булып аспиринны өҗәткә

алып торабыз. Мене министр янына теләнергә керәм әле...— дип сөйләнде ул, дулкынлануын һәм борчылуын яшерергә тырышып. Мин аны беренче тапкыр шундый аптыраган кыяфәттә күрдем. Әйтерсең ул инстанцияләрдән инстанцияләргә йөри-йөри нәрсә дә булса майтарып булачагына өмет өзгән, тик яшьлек энергиясе, яшьлек горурлыгы гына барысыннан да ваз кичүдән тыеп тора иде.

Ул кырыс кына саубуллашты да, зур-зур атлап, ашыга-ашыга Кремль капкасына таба атлады. Анда министрлыкта мәсьәлә ничек хәл ителгәнен мин озак еллардан соң гына белдем.

Җил-давыллардан, дөнья мәшәкатьләреннән качарга теләгәндәй, авылдан читтә, урман куелыгы арасына кереп сыенган больница бинасы Миңгәрәй Шаммасовны шыксыз кыяфәт белән каршылый. Бүрәнәләре черегән, тәрәзәләре ватык — барысы да ташланган һәм мескен күренә. Аркылы-торкылы сузылган бауларда кибәргә эленгән марлялар һәм кемнәрнеңдер керләре чайкала. Эче поша Миңгәрәйнең, барысына кул селтәп китеп барырга, дигән уй да килә аның башына. Ләкин нидер тота, җибәрми: эчке сиземләү белән ул үзенең җиңәчәге, кыенлыкларны ерып чыгачагына күңеленд: ниндидер бер ышаныч саклый.

Яшь врачка барысын да хуҗалык эшләреннән башларга туры килә. Башта ярым җимерек йортны дәвалау учреждениесе кыяфәтенә кертәләр. Миңгәрәй оешмадан оешмага, колхоздан колхозга чаба: төзү материаллары юнәтә, осталарын таба. Тиздән 25 койкага исәпләнгән һәм кабул итү бүлмәсе булган икенче бина өлгерә. Рентген аппаратлары кайтарыла, больница инструментлар, дарулар белән тулысынча тәэмин ителә.

Участок авылларында медицина-агарту һәм аңлату эшләре җәелдерелә. Авырулар исәпкә алына, профилактика чаралары үткәрелә. Дәвалауның эффектлылыгы күтәрелә. Больницаның тәкъдимнәр кенәгәсендә беренче рәхмәт сүзләре языла башлый. Хәер, ул гел иң җылы йөрәк хисләреннән генә гыйбарәт түгел.

«1962 елның 27 декабрендә кызыбыз Чулпанны больницага үлем хәлендә алып килдек. Яңа елны каршылау төнендә дә бала өчен кайгыртып йөрүче баш врач иптәш Шаммасовка һәм медсестралардан Сарага, Мәрьямгә, Луизага зур рәхмәт әйтәсебез килә».

Меңләгән мактаулар арасыннан шелтә яки үпкә сүзләрен һич таба алмассың: әйе, хуш килгән яшь врач авыл кешеләре күңеленә. Чөнки ул алар өчен вакытын да, көчен дә, төн йокыларын да кызганмаган.

Кызыклы бер деталь. М. Кәримова дигән бер хатын, Балтач авылы больницасы хезмәткәрләре киңәше буенча, Ижевскида республика онкология диспансерына мөрәҗәгать итә. Аны, башка өлкәдән дип, кире кайтарып җибәрәләр. Ләкин Шаммасов авыруның язмышына битараф кала алмый. Кичекмәстән Удмуртиянең сәламәтлек саклау министрлыгы белән элемтәгә керә, бу хәлнең килеп чыгуына әчинып хат яза. Нәтиҗәдә Ижевск онкологлары авыруны чакыртып алалар, аннан гафу үтенәләр һәм тиешле ярдәмне күрсәтәләр.

Миңгәрәйнең китап киштәсендә русча-удмуртча сүзлек күргәч, башта аптырап калган идем. Аның үзенә күрә сере бар икән.

— Еш кына удмурт авылларыннан килгән авыруларны кабул итәргә туры килә,— ди врач,— кайберләре ни русча, ни татарча бер авыз сүз белми. Нишлисең, менә шул сүзлек ярдәмендә аңлашабыз. Башта бик кыен иде, хәзер аз-маз сукалыйм инде...

Аның һәрбер сүзеннән, һәрбер эшеннән тынгысызлык сизелеп тора. Эшли башлавының беренче чорында аңа шундый хәл белән очрашырга туры килә: кайбер ата-аналар, балаларын кызганган булып, терелеп җиткәннәрен дә көтмичә, аларны больницадан алып китү җаен карыйлар. Ә ахырдан авыру өзелгә, тагын дәва сорап мөрәҗәгать итәргә туры килә. Шаммасов мондый «шәфкатьле» ата-ананы оялта, үгетли, кирәк икән, власть органнары белән куркыта. Авылларда медицина темаларына ясалган лекция һәм докладларында андый «мәрхәмәтле» ата-аналарны да еш телгә ала, конкрет мисаллар китерә, район газеталарында: «Яратумы бу? Юк, түгел, җинаять»,— дигән мәкалә язып чыга.

«Аккан су гына пакь була»,— диләр. Миңгәрәй дә бер урында таптанырга, хәрәкәтсез торырга яратмый. Үзенең квалификациясен күтәрү өчен туктаусыз эзләнә, һәртөрле мөмкинлектән файдаланырга тырыша. Ел саен диярлек аны врачларның белемен

күтәрү институтында, башка медицина тармаклары буенча оештырылган махсус курсларда очратырга мөмкин. Күпкырлылык, универсальлек — район врачы өчен иң кирәкле сыйфатлар. «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз»,— дип, борынгылар белми генә әйтмәгәннәрдер.

Әнә шул төпле белем аңа һәртөрле авыруны җиңәргә, кеше сәламәтлеге сагында уяу торырга булыша да инде. Халык ихтирамы чишмәсе дә әнә шуннан кайнап чыга. Шаммасов берничә ел рәттән Барҗы авыл советына, Әгерҗе район советына депутат итеп сайлана. КПСС район комитетының, ТАССР сәламәтлек саклау министрлыгының мактау грамоталары белән бүләкләнә.

* * *

1967 елда Миңгәрәй Шаммасовны Әгерҗенең үзәк больницасына баш врач урынбасары итеп күчерәләр. Яңа җир, яңа мәшәкатьләр. Ләкин һәр эшне намус белән башкарырга яраткан врач өчен яңа урынга күнегү авыр булмый. Аны биредә дә үз итәләр.

Өченче — соңгы очрашу вакытында мин аны нәкъ менә шунда күрдем. Моennан эшкә чумган дустым белән иркенләп сөйләшү тиз генә насыйп булмады. Ул, монда «кабул итү сәгатьләре» беткәч, стационарда ятучы авыруларга «обход ясарга», аннан әле күптән түгел генә ачылган медсестралар курсында ике лекция укырга тиеш икән.

Сүз уңаенда хатынына һәм сеңелесенә дә «медицина җене» йоктыра алуы белән «мактанып» алды, вакыт тарлыктан зарланды. Аннан, үз-үзен шелтәләгәндәй, тезеп китте:

— Хәер, монысына безгә зарланырга иртәрәк әле. Ир уртасы яшенә җитеп, көчнең ташып торган чагы. Авырлыкның иң зурысы безнең өскә төшми кем өстенә төшсен... Элегрәк безнекенә, ә иртәгә... Тормыш шулай инде, безнең як мишәрләре әйтмешли, куласасы әлинә...

Аның бу риясыз һәм беренче карашка уйламыйча гына әйтелгән сыман тоелган сүзләрендә тирән мәгънә бар кебек тоела миңа. Чыннан да, бүген төп авырлык 30 яшьтән 50 яшькәчә кешеләр өстенә төшә бит.

— Менә бездән соңгы буын ни кырыр инде,— дим мин, кайбер карашларны күздә тотып.

Миңгәрәй көлә:

— Нәрсә, безнең алга да аталар һәм балалар проблемасы бастымыни инде?!

— Шулай да алар безнең кебек сугыш елларының авырлыгын баштан кичермәгәннәр, тормышның матур якларын гына күреп үскәннәр... Кайбер кешеләр бит аларның «твист» һәм «рокн-ролл» белән мавыгуларын, модалы кием артыннан чабуларын гына күрәләр...

— Кысыр хәсрәт,— ди Миңгәрәй, кемнәрнедер шелтәләгәндәй итеп.— Мин көнләшеп куям әле кайчагында, алар бездән бәхетлерәк булачаклар, эш дигәндә дә бездән кимен куймаслар.

Безнең сөйләшү ул эштән бушагач төнге караңгылыкта тынып калган Әгерҗе урамнарыннан атлаганда дәвам итә.

— Менә син безнең медицина өлкәсен генә ал,— дип кабат кызып китә Миңгәрәй. Аның тавышында талчыгу-арыу билгеләре дә сизелми.— Хәл ителмәгән мәсьәләләр дә ай-һай бит әле. Ул рак дигән корт чаккыры нәрсә, йөрәк авырулары — егерменче гасырның аждаһалары... Булдыра алганча тырышабыз инде.— Бу проблемаларны тулысынча бездән соң килгән буын хәл итәчәк...

...Без ул кичне бик озак гәпләштек йөрдек. Әйе, Миңгәрәй белән һәрвакыт күңелле шул. Сөйләшер темасы да әллә каян табылып тора. Күрәсең, кеше үз эченә йомылып башкара торган эше белән чокчынып яшәми — аны тормыштагы һәрнәрсә кызыксындыра, ул тормышның үзәгендә кайный. Малай чактагыча ук җор сүзле һәм сабыр, һәрнәрсә белән кызыксынучан һәм җитди — гүя ул бер дә үзгәрмәгән. Шул ук вакытта күпме белем һәм тәҗрибәне үзенә сеңдергән һәм аякларын җиргә нык терәп баскан. Тормышка гашыйк булып, үзен илнең хуҗасы саныап яши ул бүген.

Замандашым, яшьлек дустым белән очрашу миндә әнә шундый уйлар куегатты.

# Фәләх Насыйров

# ПРОФЕССОР ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВА

Зәйнәп Шәйхиевна гадәттәгедән соңрак кайтты. Гыйльми совет утырышында тоткарланган иде. Баскычтан күтәрелгәндә, гәүдәсе авыраюын, буыннары талчыгуын сизеп:

— Нигә мин шулай арыдым әле! — дип куйды.

Хәер, бу табигый да иде: ул бүген операция өстәле янында бик киеренке сәгатьләр уздырды. Операция башлангач күп тә узмады, авыру Литучинаның йөрәге тибүдән туктады. Җан тетрәткеч минутлар иде бу. Мондый чакта врачлар иң элек профессорга карыйлар. Ә авырулар!.. Алар тормышларын аңа ышанып тапшыралар. Әйе, профессор булуның дәрәҗәсе дә, җаваплылыгы да бик зур!

Бүген операция ясалган авыру байтак шәһәрләрдә булып, больницаларда ятып чыккан иде. Төрлечә дәвалап караганнар аны, берсе дә файда итмәгән. Авыруда фибромиома шеше һәм гиофез бизе үскән. Нәтиҗәдә ул бик нык симергән, кан басымы күтәрелгән. Бу хәл операциянең уңышлы чыгачагына өметне киметә. Шуңа күрә операция ясауны бер врач та үз өстенә алмаган. Аны Йошкар-Оладан Казанга җибәргәннәр. Монда ул, врачларның белемен күтәрү институтының икенче акушерлык-гинекологик клиникасына килеп, профессор Гыйләҗетдиновага күренде. Авыруны больницага салып, бик җентекләп тикшергәннән соң, профессор аңа операция ясарга дигән карарга килде. Юкса, фибромиоманың яман шешкә — саркомага күчүе мөмкин. Операциянең җиңел булмаячагын профессор бик яхшы аңлый иде. Операциягә ул махсус наркотизаторлар чакыртты. Әмма наркоз биргәндә, бигрәк тә операция вакытында, авыруның хәле начарланды, аңарда коллапс күренешләре булды, кан басымы төште, пульсы югалды. Операцияне туктатып, ашыгыч чаралар күрергә туры килде. Басымны күтәрә торган дарулар белән бергә кан салдылар. Авыруны яңадан тормышка кайтарып, аны коткарып калу өчен никадәр көч куелды.

Операциядә профессор Зәйнәп Шәйхиевнадан гына түгел, аңа ярдәм итеп торган медицина фәннәре кандидаты Наилә Рәхимовадан да, наркотизатор врачлардан һәм операция сестраларыннан да никадәр белем һәм сәләт соралды.

Магаданнан килгән авыру Миңнуллина белән дә җиңел булмаган иде. Аның тормышын саклап калу өчен да алар аз көрәшмәделәр. Ул да сирәк очрый торган бик кыен авыру иде. Ана белән бала арасында резус конфликт, ягъни каннарның резус фактор ягыннан антителалар бик күп җыелган. Бала тапканнан соң, анада кан агулану башланган. Зәйнәп Шәйхиевнаны кич белән больницага чакырып алдылар. Дежур врачлар Гертруда Гавриловна Шестякова, Асия Дусаевалар белән бергә, ул төне буе авыру яныннан китмәде. Мондый очракларда медицинада кулланырга мөмкин булган чараларның барысы да кулланылды.

Әмма чир чигенмәде.

Икенче көнне аның гемоглобины 30 га кадәр төште. Шуннан соң ике бөере дә эшләми башлады. Нинди генә кан салсалар да, нинди генә плазма кертсәләр дә, бәтенесенә дә организмы бик көчле реакция бирә. Шуннан соң аны алтынчы шәһәр больницасына күчереп, ясалма бөерләрдән файдаланырга туры килде. Бөерләренең

функциясе тергезелгәч, авыруны кабат үз больницаларына алып дәваладылар. Хәзер ул сау-сәламәт. Врач өчен моннан да зур шатлыкның булуы мөмкинме! Егерме алты еллык врачлык хезмәтендә Зәйнәп Шәйхиевна боларга охшашлы авыруларны аз күрмәде, катлаулы операцияләрне аз ясамады. Ничәмә ананы ул үлемнән тартып алды, ничәмә балага тормыш бүләк итте.

Бу әле ул башкарган хезмәтнең бер ягы гына. Ә аның икенче ягы — белгечләр әзерләү; Казанга врачларның белемен күтәрү институтына килгән акушер-гинекологларга лекцияләр уку, алар белән тематик дәресләр уздыру, авыруларга обход ясау һәм яшь врачларны операция техникасына өйрәтү, тәҗрибәсен яшьләргә бирү. Болардан тыш киеренке гыйльми хезмәт, врачлар өчен кулланма дәреслекләр, халыкка популяр брошюралар, газета-журналларга мәкаләләр язу. Яшь белгечләр әзерләү белән бергә, аңа врачларның фәнни эшләренә җитәкчелек итү бурычы да йөкләнгән. Педиатор Эльза Гайнуллина, ординатор Александра Марковна Гисина, врач Галина Николаевна Дмитриева, бүлек мөдире Клавдия Николаевна Осипова һәм башкалар аның кул астында яңа проблемалар өйрәнәләр. Бүгенге гыйльми совет утырышында шул врачларның кайбер докладлары тыңланган иде. Зәйнәп Шәйхиевна әле һаман да шуларны уйлап кайтты.

Өйгә кайткач та әле мәшәкать бетми. Монда ул профессор түгел, иргә — тормыш иптәше, улга — ана, анага — кыз. Аш-су әзерләү дә аның өстендә.

— Илдар, өйгә килен алып кайтсаң да вакыт иде инде,— дип үпкә белдерә ул улына.— Аз булса да кул арасына керер иде.

— Өлгерермен әле, әни,— ди улы.

Аның улы Илдар моннан ике ел элек институт тәмамлады, хәзер ординатурада. Ул да, әнисе юлыннан китеп, врач булды. Улы белән сөйләшкән арада Зәйнәп Шәйхиевнаның әнисе, Гыйльмиҗамал түти, кызына бер төргәк хат китереп бирде.

— Бүген бигрәк күп килгән,— диде ул, гаҗәпләнеп.

Зәйнәп Шәйхиевна Уфадан килгән хатны күреп, иң элек шунысын ачарга ашыкты. Хәле ничек икән!

Хатны ул йотлыгып укыды.

«Кадерле Зәйнәп Шәйхиевна! Үзем сау-сәламәт. Хәзер мин ана булдым. Аңлыйсызмы, ана! Хыялларым тормышка ашты!

Кадерле Зәйнәп Шәйхиевна, миңа күрсәткән ярдәмнәрегез өчен йөрәгемнән ташып чыккан кайнар рәхмәтләремне сезгә кат-кат әйтәсем килә. Сез баламны саклап калырга мөмкин булган бердәнбер ярдәмне күрсәттегез. Сездән башка мин бу бәхеттән мәхрүм була идем. Сез минем күңелемдә иң якын, иң кадерле кеше булып мәңге калырсыз. Мине дәвалаган һәм тәрбияләгән барлык врачларга һәм сестраларга — Иван Васильевичка, Наилә Исхаковнага, Римма Мостафовнага, Ирина Мирзанидовнага бик зур рәхмәт әйтүегезне үтенәм. Сезгә нык сәламәтлек, эшегездә зур уңышлар теләп, Тамара».

Зәйнәп Шәйхиевнаның йөзе яктырып китте. Тагы бер җиңү! Әйе, гыйльми хезмәтенең тагын бер җимеше бу! Тамара моннан җиде ай элек аңа өзгәләнеп хат язган иде.

«Сезнең «Фибромиома потагенезына карата» дигән китабыгызны укып чыкканнан соң, мин Сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым,— дип башлаган иде ул хатын.— Дөрес, мин медик булмагач, андагы бик күп нәрсәләрне төшенә алмадым. Шулай да мин бер нәрсәне — аналыкта фибромиома шеше булганда, Сезнең больница коллективының йөклелекне саклап калуын аңладым. Миңа 29 яшь. Беренче мәртәбә бала көтәм. Әмма миндә фибромиома шеше булуы беленде. Мондагы врачлар аналыкны алдырырга тәкъдим итәләр. Ләкин мин андый операциягә риза булмадым. Бу бит гомерлеккә ана булу бәхетеннән мәхрүм ителү дигән сүз. Мин баламны саклап калырга, ана булырга телим. Кайчан чакырсагыз да, Казанга килер идем. Зинһар, ярдәм итә күрегез».

Зәйнәп Шәйхиевна бу авыруны Казанга чакыртып алды. Больницага салып тикшергәннән соң, шешенә операция ясады. Өенә кайтып киткәч тә ул аңа хатлар язып, киңәшләр биреп торды. Менә хәзер ул ана булган. Шатлыгын уртаклашып хат язган. Юк, Тамара өчен генә түгел, Зәйнәп Шәйхиевна өчен дә бик зур шатлык, бик зур бәхет бу!

Гыйльаҗетдинова икенче хатны алды. Конвертына күз салгач, аптырап калды. Үзе эшли торган ГИДУВтан язганнар... Бу ни хәл!..

«Хөрмәтле Зәйнәп Шәйхиевна! Безнең кафедра коллективы Сезне илле яшегез тулу көне белән чын күңелдән котлый һәм Сезнең фәнгә зур өлеш кертүегезне, галим буларак үсүегезне, бик яхшы врач һәм педагог булуыгызны зур канәгатьләнү белән билгеләп үтә. Сезнең киләчәктә тагын да нәтиҗәлерәк эшләячәгегезгә, ГИДУВ галимнәренең казанышларына лаеклы өлеш кертәчәгегезгә тирәнтен ышана. Сезгә нык сәламәтлек, тормышыгызда зур бәхет теләп, травматология һәм ортопедия кафедрасы коллективы исеменнән профессор Лазарь Ильич Шулутко».

Өченче, дүртенче хатларда да коллегалары һәм авырулар аңа шундый ук котлау, тәбрик, рәхмәт сүзләре язганнар иде. Зәйнәп Шәйхиевна дулкынланып укыды ул хатларны. Аның күз алдыннан илле еллык гомере узды.

Хәтерендә комсомол еллары аеруча сеңеп калган. Ул рабфакта укыган чакта ук ВЛКСМ члены булды. Аны комсомол тәрбияләде, комсомол чыныктырды. Укуга, фәнгә булган ялкынны да аңа комсомол кабызды. Авырлыкларны җиңәргә дә комсомол өйрәтте. Әллә инде шуңа, ул һаман да үз коллективының комсомол оешмасы белән элемтәдә тора, аларга киңәшләр бирә, эшләрендә булыша.

...Еллар, юллар...

Еллар тиз генә узмаган, юллары да шома гына бармаган. Фән баскычларыннан ул җиңел генә күтәрелмәде. Аның әнисе — кулына каләм алып бер кәлимә сүз яза белмәгән бер ярлы авыл кызы. Әтисе — байда ялчы. Тормыш авырлыгын Зәйнәп күп күрде. Рабфакта укыганда ук хезмәт юлына аяк баскан иде. Аннан Үзбәкстанның ерак кышлагында акушерка булып эшләде. Укуга булган омтылыш аны институтка алып килде. Врач булып чыгуга фронтка китте. Ватан сугышы авырлыкларын үз җилкәсендә татыды. Шунда ул партия сафына алынды.

Илле еллык гомерендә искә алып сөйләрдәй вакыйгалары аз түгел аның. Әмма тормышының менә шундый олы юлдан китүе, фән баскычларыннан югары күтәрелүе барыннан да элек Ленин төзегән Коммунистлар партиясенә һәм Совет хөкүмәтенә бәйле. Хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук алып биргән Октябрь революциясе булмаса, ярлы бер татар кызы профессор булу турында хыялланa алыр идеме соң!! Профессор булу түгел, укырга-язарга өйрәнү дә аның хыялында гына яшәр иде.

**Мәгъсүм Насыйбуллин**

# ЭЗЛӘР КАЯ ИЛТӘ?

## Урман чибәрләре

Җәйге аяз көннәрнең берсе иде. Урманнар да, болыннар да, күлләр дә — бөтен табигать кояш нурларында иркәләнә. Бер-берсен уздырырга теләгән шикелле сайраша-сайраша, сабан тургайлары күтәрелделәр, җыр чылбырын үз артларыннан күз күреме җитмәс биеклеккә алып менделәр. Урман ягыннан искән җиләс җил болында нарат исе белән чәчәк исләрен бергә бутап йөри.

Таякка таянган өлкән яшьләрдәге укытучы пионерлар төркемен арырак алып китте. Колхоз басулары, ак каеннар үскән уйсулык, тырпаешып торган яшь чыршылыр артта калып, катнаш урман башланды. Яшел кибәннәрне хәтерләткән биек чыршылар арасында шома усаклар, бөдрә каеннар ешайганнан-ешая барды.

Шау-шулы укучылар төркеме тирә-яктагы табигатькә сокланырга да, ара-тирә бәхәсләшеп алырга да өлгерде.

Төркем челтерәп аккан чишмә янындагы кечкенә аланлыкта тукталды. Туган як тарихыннан кызыклы вакыйгалар тыңладылар, учак тирәли тезелешеп, хуш исле урман чәе эчтеләр, йомшак үләнгә чалкан ятып, урман сулышы, урман музыкасы, кошлар симфониясе белән хозурландылар.

Тынлыкны кинәт ботак шартлап сынган тавыш бүлде, кемнеңдер авыр адымнар белән атлап килүе ишетелде. Балалар сагаеп калдылар. Укытучы, күтәрелә төшеп, тавышланмаска ишарә итте. Киеренкелек үсә барды. Куаклар арасында җиңелчә кыштырдау ишетелде. Тагын да бераздан урман арасыннан пошилар килеп чыкты. Алда зур гәүдәле ана поши, горур кыяфәттә башын югары күтәргән, куе кызгылт төстәге йоны ялап шомартылган шикелле ялтырап тора. Ә аның артында нәзек, озын аяклы ике баласы. Ана поши хәвеф-хәтәрне санга сукмады, үзенә төбәлгән уннарча күзләргә игътибар итмичә, чишмә янында аякларын киң җәеп басты да салынкы иреннәрен суга тигезде. Балалары да шуны ук кабатладылар. Сусавын баскач, поши кисәк кенә башын күтәрде, борын тишекләрен киерде, колакларын шомартты. Урман чибәренең мәһабәт сыны таш скульптураны хәтерләтә иде. Ул фотоаппарат чертләгәнгә кадәр шулай горур кыяфәттә басып торды. Тавыштан өчесе дә сискәнеп куйдылар һәм, күз ачып йомганчы, агачлар арасында юк булдылар.

Бу сылу җәнлекләрне күпләрнең күргәне бар инде. Алар белән һәр очрашу кешеләргә куаныч китерде. Машинистлар, тимер юл аша чыгып

баручы пошиларны күрсәләр, тантаналы гудок бирә торган булдылар. Елгалардагы пароход капитаннары да шулай эшләде. Болындагы колхозчылар урман чибәрләрен күргәч, эшләреннән туктап, алар күздән югалганчы сокланып карап калдылар. Хайваннар үзләре дә кешеләргә күнегеп беттеләр, гудоклардан, мотор тавышларыннан курыкмый торган булдылар, юлларны кисеп чыкканда үзләрен кыю тоттылар. Еш кына авылларга да килеп кергәлиләр.



## Кышкы көндә

Табын мул иде, ашамлыгы да, эчемлеге дә житәрлек. Шуңа күрә алар өстәл артыннан кузгалырга ашыкмадылар. Арадан берсе, бармагы белән ымлап, иптәшләрен үз янынарак чакырды. Ниндидер зур сер әйтергә теләгән кыяфәт алды:

— Башыгыз эшлиме бераз?

— Синекеннән ким түгел.

— Шулай булгач, нәрсә карап торасыз соң? Борын төбегездә генә күпме ит! Бушлай...

Өч кеше иртә таңнан ат жигеп урманга табан юл тоттылар. Һәрберсендә куш көбәкле мылтык. Берәүсе йөзен ачы жилдән кулы белән ышыклап, сукранып куйды. Салкын жил киемнәрне йолыккалый, биткә кар бәрә иде.

— Нәрсә шыңшыйсың? — диде алдан килгәне, ачусыз гына.— Көннең шундый булуы әйбәт тә.— Аның үз-үзен тотышыннан мондый сәфәрдә беренче генә мәртәбә түгеллеге сизелеп тора иде.

Урманга кергәч, жил басыла төшкәндәй булды. Тик агач ябалдашлары гына чайкала-чайкала шомлы гөжлиләр, борчылалар. Кимерелгән усак ботаклары очрады, тора-бара пошиэзләре дә күренде. Кешеләргә жан керде. Кулларын селки-селки киңәшләшеп алдылар.

Тамак туйдырганнан соң, поши үзенең балаларын гадәттәге урынга алып килде. Йокысыз үткән төннән соң ял итәргә кирәк. Мамыктай йомшак, яңа яуган ап-ак карга яттылар. Ана поши үзе шунда ук йокыга китсә дә, колаклары уяу иде. Алар сирәк-сирәк селкенгәләп, «дерт»ләп куялар. Кинәт чыртлап ботак сынган тавыш килде. Йокы шунда ук таралды. Янәшәдән, озын-озын сикереп, куян чабып үтте. Кайдадыр саескан шыгырдаганы ишетелде. Поши тыныч кына йоклап яткан балаларына карап алды, әмма урыныннан кузгалмады, тик бераз калкына гына төште. Һәр шырт иткәннән курка башласаң, урманның кайчан тын булганы бар. Мондый буранлы, жилле көнне бигрәк тә. Аның белән рәттән арган балалары. Алар әниләренә ышаналар, алар тыныч йоклыйлар.

Кинәт иртәнге тынлыкны мылтык тавышы ярып үтте. Ана поши пружина кебек жыелып һавага сикерде. Куркудан күзләре канланды. Балалары торып, гадәттәгечә әнисенә сырылдылар, дерелди башладылар. Качарга! Ләкин кая? Куләгәләр өч яктан якынлашып киләләр. Алар баскан саен кар тавышы да, тигән ботакларның селкенүе дә, шомлы сызлавы да сизелә иде. Котылырга була әле, ләкин балалар... Нинди ана үз баласын үлемгә калдырып китсен инде. Поши дерелдәп ары сугылды, бире сугылды. Һәлакәтнең котылгысыз булуын аңлап, үзе үк үлемгә — агачлар иң сирәк урынга ташланды.

Моны күреп алган браконьерлар пошиның юлына аркылы төшәргә ашыктылар һәм шаккатып калдылар: горур башын югары тотып, сылу сынлы зур ана поши яланга табан чаба, ә ике баласы шул арада бөтенләй капма-каршы якка, урман куелыгына кереп чумдылар.

Ә поши... Саклык, курку дигәнне бөтенләй онытты ул. Ана мәхәббәте онытырды аларны. Әгәр янәшәдә чын аучы булса, браконьерларның юлына аркылы төшәр, кулларына сугар иде: «Атма!» — дип кыч-

кырыр иде.— Балалы пошины атарга ярамый. Рөхсәтең кесәңдә булса да. Ул үзенең сабыйларын өйрәтергә тиеш, азык табарга да, саклапырга да, барлык урман серләренә дә...»

Әмма монда андый кеше юк иде. Мылтык көпшәләре үлем бөркеде... Поши кешеләрнең якынлашуын күргәч, күтәрелергә тырышып карады. Ләкин аяклар тыңламый иде инде, ул карга сыгылып төште. Яралардан кайнар кан чаптырды. Пошиның дымлы, зур күзләрендә тирән хәсрәт, әрнү катып калды. Кешеләрнең беренче булып килеп җиткәне, ерткыч пират кебек, озын пычагын тартып чыгарды...

## Эзләр буйлап

Кемдер килеп ишек шакыганда, Ибрай уянган иде инде. Сафин юрганын ачып ташлады да торып ут кабызды. Сәгать дүрт кенә иде әле. Өйгә, үзе артыннан салкын ияртеп, зур гәүдәле кеше килеп керде.

— Иртә кузгалгансың,— диде Сафин, акланган шикелле итеп,— уз әйдә, утыр. Мин хәзер.

Ибрай ары сугылып, бире сугылып ашыга-кабалана киенеп йөргәндә, хатыны да торган иде инде:

— Алла бирмеш көн саен, таң тишеге белән чыгып китмәсәгез...

— Эшең шундый булгач, нихәл итәсең. Яктырганчы күл буенда, заказникта булырга кирәк,— диде Гафиятуллин.

— Көн бик салкынмы? — дип кызыксынды Ибрай, кыска туны өстеннән солдат каешын буып.

— Җил. Буран... Сак булырга кирәк.

Сафин карабины белән булышкан арада, хатыны азык-төлек хәстәрләде, аларны тиз-тиз генә сумкага төреп салды.

— Киттек.

— Кайчан кайтасың? Мунча ягыйммы?

— Як. Сәгать алтыларга әйләнербез.

Охотоведлар дәүләт заказнигына килеп җиткәндә, таң аткан иде инде. Яланда кайнаган кар өермәсеннән котылып, урманга кергәч, ат елдамрак юырта башлады. Соргылт күк йөзе яктыра бара. Тын гына юлларын дәвам иттеләр. Кинәт ерактан тонык кына булып мылтык тавышы ишетелде. Гафиятуллин белән Сафин бер-берсенә карашып алдылар.

— Нәрсә булыр бу?

— Куала! Баргач күрербез.

— Хәерлегә түгел бу. Таң тишеге белән заказникта мылтык тавышлары.

Тояк асларыннан кар сиптереп, ат юыртуында булды. Ә охотоведлар юлның ике ягын күзәтә бардылар.

— Эзләр! Поши эзләре!

Чанадан төшеп, эзләрне тикшерделәр. «Күптән түгел үткәннәр. Өчәү. Берсе зур поши, икесе балалары булырга тиеш. Мылтык шуларга төбәлеп атылмадымы икән?» — дигән сорау килде юлчыларга.

Эзләр буенча китәргә карар иттеләр. Әчкәрәк кергән саен урман куелана барды. Шулай ике-өч чакрым үткәннәрдер. Кинәт туктап калдылар. Яңа яуган карда чана эзе ярылып ята иде. Нишләп йөргән монда атлы кешеләр?

Эзләр урман ешлыгына юнәлгән. Атларын шушында калдырып, үзләре җәяүләп киткәннәр. Өч кеше. Берсе — уңга, икенчесе — сулга, ә өченчесе турыга юл тоткан.

— Димәк, ике аяклы ерткычларның икәүсе пошиларны бәжрага алганнар, өченчесе җәнлекләрне куркытып, иптәшләренә таба юнәлткән.

Охотоведлар эчкәрәк үттеләр. Менә биредә пошилар ял иткән. Яткан урыннары чокыраеп беленеп тора. Алар астындагы кар әзрәк җебе-

гән һәм бозланган. Менә куркышып як-якка сикергән эзләре. Әһә, зур поши тегеләй табан чапкан. Эз кинәт салам өеменә төртелеп өзелеп калды. Кая киткән соң поши, салам астына кермәгәндер бит инде? Сафин аягы белән саламны актарып ташлады:

— Хәмит! Монда кил!

Салам өеме астындагы кар кып-кызыл кан иде. Ә янәшәдә шул ук чана эзе.

— Их, элегрәк килсәк!

— Әллә кая китә алмаслар! Табарбыз! — диде Хәмит, ышанычлы итеп.— Мин тирә-якны караштырыйм әле, бәлки берәр кирәкле нәрсә табылыр. Ә син анализ өчен канлы карны ал. Саламны да онытма! Чана эзен үлчә. Акт яза тор.

Тиздән кузгалдылар. Чана эзенең кая алып барасын белмиләр иде әле алар. Урман эчендә биш-алты километр урап-сурап йөргәннән соң, чана юлы яланга алып чыкты. Монда элеккечә усал буран дулый, ачулана иде. Урыны-урыны белән эзләр бөтенләй күмелгән. Ат салам эскертенә терәлеп туктады. Чанадан төшеп, эскертне әйләнеп чыктылар. Түшкәне шушында яшермәделәрме икән? Юк. Салам гына йолыккаНнар.

Эзләү дәвам итте. Кыска кышкы көн төн белән алышынды. Ә эз һаман бара да бара. Ниһаять, алда утлар күренде.

— Байландык авылы,— диде җанлана төшкән Гафиятуллин.— Борыныңны салындырма, Ибрай, табарбыз. Мунча керергә дә өлгерерсең әле.

Йөкле чана сызган тирән эзләр авылга алып керде. Бер урамны үттеләр, икенчесен. Һәм таныш эз юкка чыкты. Аны бастырып чылбырлы трактор үткән иде. Табып кара хәзер җинаятьчеләрнең кая юл тотканын.

Шулай да «бәлки»гә өметләнеп, авылны әйләнеп чыктылар, капкаларга борылган эзләргә күз салдылар. Ләкин юкка гына.

— Әйдә, Мәхмүтләргә керәбез. Минем дус кеше ул. Кунып чыгарбыз, иртән күз күрер,— диде Гафиятуллин.

## Эзләү дәвам итә

— Тор, йокы капчыгы!

Ибрай күзләрен ачты. Тышта караңгы иде әле.

— Кая ашыгасыз? — диде йорт хуҗасы Нигъмәтуллин.— Бәлки, милиция чакырырга кирәктер.

— Өлгерербез,— диде Хәмит,— эз суынмас борын үзебез тырышып карыйк әле.

Унбиш-егерме минуттан соң алар колхоз бригадиры янында иделәр.

— Кичә ат җигүче булдымы?

— Булды. Өч кеше.

— Нинди эшкә бардылар?

— Басудагы чокырдан силос ташыдылар.

— Кайсы якта?

— Урман ягында.

— Кемнәр эшләде анда?

Бригадир кесәсеннән дәфтәр чыгарды, кирәкле битен ачты:

— Өчәү. Язып аласызмы?

Исемләнгән кешеләрне, эшләгән урыннарын тиз тикшереп чыктылар. Кабаттан бригада йортына урап килделәр.

— Нәрсә? Тапмадыгызмы?

— Юк әле.

— Бәлки, ярдәм итәргәдер? — диде бригадир.

— Атны төнгелеккә үзләрендә калдыручылар бармы?

— Юк, бездә андый гадәт юк.
— Бәлки, кемгә дә булса беркетеп бирелгән атлар бардыр.
— Юк, ветфельдшерны исәпкә алмаганда.
Ветеринарны табуы кыен булмады.
Беренче очраган малай ук биек койма белән уратып алынган зур агач йортка төртеп күрсәтте.
Ир уртасы кеше ашап утырган җиреннән кузгалып керүчеләрне каршылады. Тирле кулларын чалбарына сөртеп, Гафиятуллинга сузды:
— Зәйнуллин.
— Без танышлар шикелле. Кайдадыр очрашкан идек,— дип җавап кайтарды Хәмит һәм бу тулы гәүдәле, хәйләкәр күзле кешене кайда күргән хәтерләргә тырышты.
— Утырыгыз,— диде хуҗа,— чәй эчәрбез.
— Рәхмәт, эш белән генә кергән идек.
Зәйнуллин кунакларны артык кыстап тормады, өстәл артына утырып, яна-пешә чәй чөмерергә тотынды.
— Баш чатнап тора. Кичә бераз төшереп алган идек,— дип аңлатты ул.
— Кичә өйдә булмагансыз икән, кая да булса баргансыздыр инде.
— Утынга бардым. Җәфаланып беттем. Буран.
— Утынга кая бардың?
— Ничек инде ул — кая? Урманга.
— Нишләп урманнан буш кайттың соң?
— Кайтмассың менә! Барып житүем булды — йөрәккә ябышты. Утын кайгысымыни! Үзем көчкә кайтып җиттем.
— Чананы чыгып карыйк әле.
— Карагыз.
Хуҗа ашыкмый гына иңенә тунын салды, башына колакчын бүреген элде. Ишек алдына чыктылар.
— Чанада нинди кан ул?
— Фермадан үлгән бозау алып кайткан идем. Эткә дип.
Гафиятуллин чана карамаларын бәйләгән тимер чыбык арасыннан озын, каты йоннар тартып чыгарды. Бу поши йоны иде.
— Ә бу нәрсә? — дип сорады ул, йонны Зәйнуллинга күрсәтеп.
— Бе... белмим...— диде агарынып калган ветеринар.
— Белмисең? Ә менә бу нәрсә? — Гафиятуллин тирес өеме янына килде. Аның өстендә канга буялган салам ята иде. Шунда ук поши йоннары да табылды.
Кечерәеп калган, кызганыч кыяфәткә кергән Зәйнуллин ни дип тә җавап бирмәде. Ярдагы балыкныкы шикелле тик авызы гына бер ачылып, бер йомыла иде. Кинәт ул урыныннан кузгалды да мәче житезлеге белән капкага ташланды. Эзтабарлар аптырашып карап калдылар.
— Ибрай, син монда калып тор,— диде, ниһаять, Гафиятуллин,— Мин милициягә шалтыратып килим.

## Җинаятенә күрә җәзасы

— Менә без дә өчәү булдык,— дип каршылады Сафин нинди дер таныш булмаган кеше белән бергә әйләнеп килгән Гафиятуллинны.
— Таныш бул, бу иптәш Еникеев. Авыл советы депутаты. Тракторчы.
— Мин милициядән дип торам.
— Телефон аша сөйләштем. Үзебез дә башкарып чыгарбыз, дип уйлыйм.
— Акт төзи торыйк.
...Кичкә табан капка төбенә жигүле ат килеп туктады. Чанада хуҗа үзе һәм агалы-энеле Галиевлар иде.

— Әйдә түгел, урманда тоталар аны! — диде Харис, усалланып, тешләрен кысып.

Олысы, Шакир дигәне, Харисның иңбашына кулларын салды, тыныч тавыш белән сөйли башлады. Ләкин аның сүзләре энесеннән бигрәк, эзтабарларга юнәлтелгән иде:

— Кызма әле син. Кирәкми. Әйдә, ничек булса, шулай сөйләп бирик. Аңларлар. Чит кешеләр түгел бит. Күрше авыллар. Бер-беребезне беләбез.

— Булды инде, егетләр,— диде Зәйнуллин һәм актка кулын куйды. Галиевлар да имза салудан баш тартмадылар.

— Исерек баштан шайтан котырткандыр инде,— дип сөйли башлады Шакир Галиев. Пошины Харис белән мин аттым. Зәйнуллин куркытып безгә табан куйды. Үтенеч шул: эшне зурга җибәрмәгез, егетләр. Ни кушсагыз, шуны эшләрбез. Итне иртәгә үк илтеп тапшырырбыз. Дәүләткә дә зыян юк, мәгәриче дә булыр. Әлегә бер әрҗә аракы чанада. Башлый торыйк.— Ул кесәләреннән ике тулы шешә тартып чыгарды.

— Башта итне алып килегез әле, соңыннан күз күрер,— диде Гафиятуллин.

— Килергә икән, килергә. Сезнеңчә булсын,— җинаятьчеләр житез генә чыгып киттеләр. Артларыннан шалт итеп ишек ябылды.

Байландык кешеләре гаҗәпкә калдылар. Зәйнуллин өч көн рәттән кайтып күренмәде, өй хуҗасыз ятим калды. Авылда төрле имеш-мимешләр таралды.

Дүртенче көнне өй хуҗасы, берни дә булмагандай, янадан кайтып керде. Шул ук ерткыч күзләр, тупас бит, симез гәүдә.

Охотоведлар аңа биргән вәгъдәсен искә төшерделәр.

— Нинди вәгъдә?! Нинди ит? — дип акыра башлады ул, күзләрен акайтып.— Әнә заготконторадан сорагыз.— Җитез генә кесәсеннән квитанция тартып чыгарды.— Укыгыз. Поши ите тапшырылган.

— Бу бит, бу...

— Беләм, беләм ни әйтергә теләгәнегезне,— дип бүлдерде Зәйнуллин.— Ләкин без пошины рөхсәт белән, лицензия буенча аттык. Ул документ аучылар бригадиры Васильевта. Сез белмәгән кеше түгел ул. Хафаланырга урын юк, бары да законлы: лицензия бар, ит тапшырылган, сезгә тагын ни кирәк?

— Акылыгызга килдегезме әллә дип уйлаган идек. Юк икән. Өч көн буена төлке кебек эз яшерергә маташып йөргәнсез икән, оятсызлар. Барып чыкмас. Алдау белән генә котыла алмассыз!..

Гафиятуллин белән Сафин шул ук көнне милиция тикшерүчесенә җыйналган дәлилләрне китереп тапшырдылар.

Аларга рәхмәт әйтеп, тикшерүче җинаятьчеләрнең авылларына китте. Тентү үткәрделәр. Поши итләре табылды. Аучылар бригадиры булып саналган Васильев өендә үз кулы белән төзәтелгән ялган лицензияләр чыкты.

Суд булды. Зәйнуллинга да, Галиевларга да эшләгән явызлыклары өчен җавап бирергә туры килде. Алар белән бергә Васильев та судка тартылды.

...Икенче җәйне укытучы балаларны, гадәттәгечә, әлеге аланга алып килде. Саф һавалы урман элеккечә үк нарат исе, чәчәк исе белән тулы иде. Балалар, узган җәйдәге хатирәләрне искә төшереп, тагын да поши күренмәсме дип озак йөрделәр, һәр ят тавышка колак салып тыңлап тордылар.

Юк. Күренмәде.

Яшь пошилар мылтык тавышын онытып, кабат бу урыннарга килеп йөри башлаганчы күп еллар үтәр әле...

Сибгат Хәким

# КҮҢЕЛДӘН ЮЫЛМАГАН ЭЗЛӘР

## Сагыну

Ватан сугышы... Сугышта күргәннәремне моңа хәтле шигырьдә, поэмаларда бирергә тырышып карадым, сыйдырмадылар. Шигырьнең дә, поэманың да үз характеры бар, нииндидер югары нокталарны эзлиләр. Аларга вакыйгаларның да драматик киеренкелеге, романтикасы белән аерылып торганы булсын. Артык таралма, сибелмә, гомумиләштер. Кыскасы, дөнья хәтле материал читтә өелеп кала, әрәм кала. Дәфтәрләрдә еллар буена теркәлеп, тупланып килгән детальләр, факт, эпизодлар... Барысы да прозаны сорый. Шагыйрьгә прозаның кирәклеген аңладым.

Тагын мондый нәтиҗә ясадым үземә. Совет халкы бөек җиңүнең егерме биш еллыгын бәйрәм итте. Ватан сугышы турында фәнни хезмәтләр чыкты, генералларның, маршалларның мемуарлары басылды. Күзәтеп бардым. Бигрәк тә турыдан-туры үзем булган фронтларга караган материалларны кызыксынып күзәтеп бардым. Ләкин син кичергәнне бирәү дә, беркем дә кабатлый алмый икән. Шуңа күрә үзең яз, үзең күргәнчә, синең сүзең солдат сүзе, татар шагыйренең сүзе булып калсын. Әдәби әсәр дә түгел, көндәлек тә түгел, күңелдән юылмаган эзләр- үйланулар. Кыска-кыска язмалар...

• Мине язарга мәҗбүр иткән хис — сагыну хисе. Кемдә ничектер, миндә, гомумән, язар алдыннан башта шул хис туа. Күңел әкренләп боега, моңсулык баса, читләшә, йомыла. Хәзер дә минә күңел фәкать югалтудан, юксынудан, сагынудан гына тора кебек...

Кинәт мәйданнар искә төште. Сабан туе мәйданы... Минем өчен көрәшүчеләр таралышканнан соң җирдә, күңелдә ятып калган тынлыктан да авыррак нәрсә юк. Буш, тын, күңелсез...

Мәйданнар. Сугыш мәйданнары... Чирек гасыр узгач, кабат Дугада булырга туры килде миңа. Белгород өлкәсе, Яковлев районы. Ләкин безгә ул һаман Дуга, серле, дәһшәтле Дуга. Барысы да әлеге тынлыкта... Белеп торасың, җир дә сөрелгән, кайдадыр ялгыз тракторның тавышы да ишетелгәләп куя, барыбер шомлы. Тегe трактор да күз алдында танкка әверелеп бара шикелле. Кеше юк. Сыртларда, иске траншеялар-

рын өстендәге тынлыкта сагышым тирбәлә. Сагыну хисе күңелне шундый кисә, телә, талый, тәгәрәп-тәгәрәп үксисе килә. Солдатлар, бергә авыр юл үткән кешеләр кайда алар? Һәр солдатның үз полкы, үз дивизиясе бар. Минем дивизия — 375 нче укчы дивизия. Себердә оешкан. Ул 1942 елның кышында Калинин фронтындагы һөҗүмнәрдә катнаша. Ржев янында сугыша, язын ялга чыга. Безне шул дивизиягә өстәмә көч итеп җибәрделәр. Җәен, июль аенда, яңадан Ржевка. Минем фронттагы биографиям Калинин сазлыкларын үтеп, сусыз Дуга кырлары буйлап, Харьковны азат иткәнгә кадәр сузылган юл белән бәйле. Мин 1243 нче полкның взвод командиры. Полкташлар... Төрле төштән, төрле милләт кешеләре. Фронтта очраштык, дуслаштык... Чирек гасырдан соң сугыш мәйданында мин аларның йөзен-кыяфәтен, кыланышларын күз алдыма китерәм, серелгән кап-кара җир өстендә алар каяндыр бер секундка гына калкалар да юкка чыгалар. Рәшә эчендә шәүләләр... Минем егерме биш еллык сагышны бергә җыеп кычкырасым килә. Кайда алар?

Бу сагышымда минем Муса Җәлилләр, Гадел Кутуйлар, Фатих Кәримнәр, Абдулла Алишлар. Замандашлар, каләмдәшләр... Мәңгелек ут-югалтулардан туган сагыну хисе. Шул яздыра. Аркасына биштәрен асып сугыш кырына кереп киткән солдатны ни көткәнен әйтүе читен. Траншеялар, окоплар... Алгы сызык. Керә, берничә карамастан керә. Ул шулай кирәклеген бәры күңеле белән генә тоя. Мин дә нәкъ шул солдат кебек хәзер, алда фронт, кешеләр, язмышлар...

## Туй

1939 елның 31 декабре. Тукай урамы, мехчылар клубы каршындагы йортларның берсендә минем туй, минем яшьлегемнең туе.

«Пар ат»ның бәйрәмгә әзерләнгән чагы. Мине туйга алып килгән «Пар ат». Кыңгыраулары, моңнары белән капкадан керде, яңадан борылып чыкмады...

Буранлы көн. Капка төбендә торам, каршылыйм. Беренче кеше — Гадел Кутуй. Буран эченнән елмаеп, балкып, бусагадан ук өйгә ямь алып керүче Кутуй. Аннан Шәйхи Маннур... Муса Җәлил... Шатлыкта Кутуй белән ярышуы читен, ләкин Муса кушылса, ул шатлык тирәнәя төшә... Мусаны мин, бүе кечкенә булгангамы, сәке түрендә аяк бөкләп утырган элекке авыл тегүчеләренә охшаттым... Үзем дә белмим, ни өчендер минем күңелдә аның тагын бер моңдый шигъри образы яши. Элек кышкы буранларда кечкенә чанада китаплар тартып безгә китап сатучылар килеп керә иде. Кайры туннан. Түргә уза, китапларын сәкегә җәеп сала. Ягымлы, бераз каударлана, күзендә терекөмеш гел җемелдәп тора...

Тегүчегә охшатуымның каян килгәнен беләм. Түбән Осланда без, берничә шагыйрь, «Яшьлек юлы» исемле күмәк поэма яздык. Без үзебезгә тигән бүлекләрне язып бетердек. Муса һаман тотынмаган иде әле. Иртән тора да, сөлгесен иңенә асып, Идел буенда йөри, су коена... Аның бу иҗат итү формасы. Бер утырса, ул кузгалмый утыра, озак утыра. Ничегрәк утыруын мин аның шунда күргәнмен. Ике көннән Муса безгә алты йөз юллык бүлек эшләп китерде. Һәркайсыбызныкыннан ике-өч тапкыр зуррак һәм яхшырак та иде. Озак уйлап йөри, тиз эшли...

Безнең юл, яшь шагыйрьләрнең юлы, Мәскәү аша, Столешников тыкрыгы буйлап үтте. Муса Җәлилнең бу тыкрыктагы кечкенә бүлмәсе безнең туктала, рухлана торган урын иде. Ә Казанда? Казанда ул безне операга тартты. Мәскәүдән килгән профессор Литинскийлар язучылар клубында опера либреттосы, опера музыкасы турында регуляр рәвештә

лекция укыдылар, дәрес бирделәр. Муса үзе тудырышкан опера театрының эше белән янып яшәде, үзенә алмашны алдан әзерләде.

Туй... Муса белән Кутуй өстәлнең икесе ике башында. Урынны белеп сайлаганнар, экспромтлар әйтү өчен әйбәт... Кутуйга мин үземнең Казанга ничек килүемнең тарихын беренче тапкыр шушы туйда сөйләдем. 1930 ел, яз. Мин Күлле-Киме җидееллык мәктәбен тәмамладым. Клубта кичә. Мин шигырьләр укыдым, башкалар җырладылар, биеделәр. Биючеләр арасында чем-кара күзле, кара чәчле, нәфислеге, киеме белән бик нык аерылып торган ят кыз, яшь кыз... Ул вакытта Кимедә больницада Кутуйның апасы Зәйнәп Кутуева врач булып эшли иде. Ят кыз Казаннан, медицина институтыннан диделәр... Апасы янына кунакка кайткан кыз — Һава Кутуева. Таныштык. Дөресе, шигырьләрем таныштырды. Казан. Чернышевский урамы, Кремль каршында икенче йорт. Казанда беренче тапкыр аяк баскан квартирам — Кутуйлар квартирасы, монастырь ишек алдында, эчтә... Һава белән шунда очраштык. Татрабфакка да ул илтте, ул урнаштырды. Кутуй өйдә юк идеме, белми калды... Кутуйга бу турыда мин ун елдан соң, үзем дә шагыйрьләр рәтенә кергәннән соң гына сөйләдем... Юл ачтылар, юл күрсәттеләр. Талантлылар безне үз артларыннан иярттеләр. Без аларга һәрвакыт турылыклы.

Язучыларга бай иде бу мәҗлес. Яшь талантларның — Вәдүт Мифтахов, Мансур Гаяз, Әгъзам Камалларның — беренче рәхмәтләрен ишеткән Гази Кашшаф, Әхмәт Исхак... Бер читтә Хәсән Туфан... һәрвакыт язып утыручы Туфан. Куен дәфтәрен, яшел каралы авторучкасын чыгарып, җыелышта, хәтта мунча ишеге төбендәге урындыкта, мәҗлесләрдә гел нәрсәдер язып утыручы фанатик Туфан... Өзлексез экспромтлар яуды. Бокаллар ташыды, яшьлек ташыды. Бу шагыйрьләрнең иң олы дигәненә дә ул чакта утыз тугыз яшь. Аргда Фатих Кәрим юк, күпләр юк... Берничә айдан Туфаннан аерылдык... Каләмнең очы белән генә латинча бик вак итеп язган шигыре калды. Альбомнар эчендә ничектер сакланган бердәнбер шигырь. Экспромтлар юк. Бу исән.

Котлы булсын туегыз,
Уртак булсын юлыгыз,
Мисал итеп сөйләрлек
Гүзәл тормыш корыгыз!
Гасыр ахырына кадәр
Икәү бергә барыгыз,
Чәчләре көмешләнгән
Картлар була алыгыз!
Безнең тыгыз сафлардан
Китеп бара күрмәгез:
Тукай һәм Такташ кебек
Вакыт җитми үлмәгез.
Сезне сөйгән халыкның
Мәңге үлмәс көнелендә
Күп гасырлар буенча
Яшәгез икәү бергә.
Шагыйрь һәм шагыйрәдән
Илебез хезмәт көтә...

Ә Кутуйның туйда бүләк иткән кул сәгате миндә калды. Безне фин сугышына, аннан Бөек Ватан сугышына якынайткан вакытны, көн саен кыскара барган араны исәпләп торды ул сәгать... Кайсы фронтта йөрүдән туктагандыр, туктады... Сәгать исән...

Декабрьның буранлы соңгы көне. Яңа ел алдындагы, бөек вакыйгалар алдындагы туй. Мине канатландырып поэзиягә алып кергән дуслар... Декабрь, гомумән, минем биографиямдә әллә нинди сәер ай, шомлы ай. Дуслар белән соңгы тапкыр очраштырган үкенечле туй. Ә шулай да туй туй инде...

Мине ни өчен хәрби кеше итәргә тырышканнардыр, шушы көнгә кадәр һаман аңлый алмыйм. Характерым, табигатем белән хәрби түгел. 1933—34 елларда армиядә вакытта училищега алырга, кадрда калырга кыстадылар, калмадым... Институт бетергәч, һәр елны сборга, я Кабан артындагы хәрби лагерьга, я Саратовка. Күбрәк Саратовка. 1941 елның җәй башында янадан Саратов янындагы Татищево лагерьларына сборга эләктем. Монысында шактый озакка, өч айга. Җитмәсә, разведка буенча, штаб разведкасы. Миннән штабист, разведчик... Күрәсең, югары белемле булуым военкоматларга ошап куйгандыр. Шулайдыр дип уйлыйм. Татищево. Вак имәнлек. Имәннәр яшел, палаткалар яшел. Төп эш: топография, карта, разведка... Штаб эшенә азмы-күпме төшенеп иләшеп килгәндә, кинәт бүлделәр. Атмосфераның куерганын газеталагы хәбәрләр буенча да сизенә идек инде. Ашыгыч рәвештә җыенырга куштылар. Сборның яртысында өйләргә таралдык. Мин — Казанга. Күңел сизенә, ләкин куркынычны ул һәрвакыт кичектерергә тели, бәлки, бәлки дигән өмет белән яши... 22 июнь. Иртән Идел буена Дубкига чыктык. Халык күп, су коена, чыр-чу килә. Куаклар арасында гармун, җыр... Минем күңел тыныч түгел, ашкына. Торасы килми. Өйгә ашкына. Хатынның үпкәләвенә карамастан, пристаньга юнәлдем. Хатын да иярде. Икебез дә сүзсез. Бер карасаң, үпкәләшергә урын да юк шикелле, беркем дә арага кермәде, тыгылмады, буталмады. Кешедә сәер сизенүләр була. Пристаньга җиттек, сугыш башлану турындагы хәбәрне шунда тыңладык...

Мин запастагы взвод командиры. Сугыш башланган тәкъдирдә повестка алу белән барыр урыным билгеле: Бөгелмәдәге 16 нчы полкка алдан беркетелгән идем. Тиз тоттылар. Ике көннән вокзалга төштем. Озатучылар: өйләнеп ел ярым гына бергә яшәгән иптәшем Мәршидә, яшьлекнең биографияләргә кермәгән истәлекләрен үзе генә белгән шагыйрь Нәби Дәүли. Бөгелмә поезды. Казаннан мин ялгыз. Кич җитте, йокы кермәде. Күзем йомсам, малайның, әле бер яшь тә тулмаган малайның, тавышын ишетеп уяндым. Күрше купеда елый. Минем малай, тавышы нечкә, ачы, бернинди сугышлар да басып китәрлек түгел. Торып, үземә ышанмыйча, карап чыгам, зурлар гына. Тагын ятам. Ятуга янадан шул ук йөрәк өзгеч тавыш кабатлана. Бөгелмәгә барып кергәнче эзәрлекләде ул мине... Күңелдә тоныклык хис. Бала чакта иртән йокыдан кинәт уятсалар, шулай аптырап утырасың. Тоныклык хис. Мин авыл малае. Дошманны фәкать әдәби китаплар буенча романтик төскә кертеп күз алдына китергән беркатлы авыл малае... Казан, институт бераз күзне ачты... 1937 ел дөньяга киңрәк карарга, кешеләрне таный белергә өйрәтте. Өч мәктәп. Өченчесе алда. Аңа керүе дә җиңел түгел, аннан чыгуы да авыр. Аңысы тагы нәрсәгә өйрәтер?

Бөгелмә. Тимер юл вокзалы. Вокзал каршында — тимер юлчылар клубы. Иске агач клуб, агач койма. Койма эчендә тузанга баткан сирень куаклары. Батальон штабы шул клубта урнашкан. Маршевая роталарны шунда әзерлиләр. Июль. Сугышның башы. Кешеләрнең мингерәгән, буталган чагы. Клуб коймасы буенда атлар, арбалар. Ирләрен озата килгән, саубуллашырга килгән хатын-кызлар. Көтәләр, капкадан китмиләр, ялыналар. Алар койма буенда арбаларда куналар...

Без өйрәткән солдатларда мылтык, кул пулеметы, противогаз, кечкенә көрәк... Бөгелмә — Әлмәт юлының уң ягындагы урманны без таладык, яшь каеннар, яшь имәннәрне җилкәләрдә без ташыдык, блиндажлар кордык... Әз генә яңгыр явып үтсә, аяклардан итекләрне суырып, йолкып алып калучы үзле кара балчыклы киң урамнарын, зират буй-

ларын без таптадык... Бөгелмәнең иң кайнаган төше — вокзал белән клуб арасы... Поездлар... Фронтка туктаусыз агылган эшелоннарның ераклашкан тавышы... Күз яше.

Бераздан үзебез үк озаткан солдатларның кайберләре яраланып, Бөгелмәнең үзенә, аның госпитальләренә кайта башладылар. Нигә бик тиз? Чөнки алар юлда эшелоннардан һөҗүмгә кергәннәр, яннарында нәрсә бар, шуның белән сугышканнар... Яралыларның күзләрендә үпкә... Бөгелмә көнләп, сәгатьләп үзгәрә. Урамнарында Балтик буе республикаларыннан, Украина, Белоруссиядән эвакуацияләнгән семьялар... Бөгелмә тузаны фронт тузаны белән аралашты, тамак төбенә ятты. Тормышның әчесе реаль яклары, реаль картиналары белән көндәлек урын ала бара. Мине сугыш белән ерактан таныштыра шикелле. Әзерләнә тор, күнегә тор...

## Суслонгер. Гарәфи

Мари чигендә тудым, мари чигендә үстем, бала чакта зуррак кызларга ияреп мари урманнарына җиләккә бардым, абый белән утынын ташыдым. Дүртәр ташлы тегермәннәре белән атаклы Илләт, балыкка бай Илләт. Куе урман эчендә ул каралып тора, тын, тирән... Мари республикасының күп төшләрен беләм, ләкин Суслонгер турында беркайчан да ишеткәнем булмады. Хәер, станция генә бит ул. Казан белән Йошкар-Ола арасындагы станция. 1941 елның көзендә Бөгелмәдән мине Суслонгерга җибәрделәр. Сәбәбен армиядә әйтеп тормыйлар. Урман. Җәйге бараклар. Алар да җитми. Солдатлар хәрби эшкә өйрәнүдән бигрәк, бүрәнә ташыйлар, көнен-көне икешәр тапкыр барып, берничә километр җирдән — Суслонгер станциясеннән иңнәрендә такта ташыйлар. Төзәләр, коралар. Урман. Алан уртасында төпләр өстенә куелган казан. Батальонны туйдырырлык зур казан. Аш шунда пешә... Бөгелмәдән соң... Аның җылы өйләреннән, шәһәр мунчасыннан соң кинәт сине буш урманга, агач төпләре арасына, мүк һәм мүк җиләкләре үскән аланга китереп ташласыннар әле... Күнегә тор, иялә тор дигәндер инде язмыш...

Сугышта бер кат булып, яралары төзәлгәч, монда эләккән солдатларның маршевая роталар белән тизрәк янадан фронтка китәргә теләп мөрәҗәгать иткән сүзләре башта миңа бераз гаҗәбрәк иде. Әйе, баштарак. Аннан гаҗәпләнмәдем. Үземнең каләмдәш дусларны — Гариф Галиев һәм Габдрахман Әпсәләмовны да мин шунда, солдатлар белән Суслонгердан такта алып кайтышлый, очраттым. Очрашулар, күрешүләр, юлда, берәр агач янында тәмәке тарткан арада, кыска, ләкин истәлекле, кадерле. Айлар буе сорашасы килеп йөргән берничә сүзгә ишеткән җавап сине әллә нинди кыенлыклардан да алып чыгар шикелле... Бераздан композитор Заһид Хәбибуллинның да монда икәнлеген белдем. Гади колхозчылардан башлап, язучылары, композиторлары, танылган артистлары — барысы да кулына корал алган... Тагын бик якын кешене, авылдашны очраттым. Кызык бу тормышта, авылына кайтасың, аны эзләп син өенә керәсең, я ул колхозга ферма салып ята, я урманда, яки нииндидер йомыш белән мари авылында... Еллар буе шулай туры китерә алмый аптырыйсың. Гомер уза, онытыла төшә. Көтмәгәндә менә шул кеше Суслонгер урманындагы сукмакта пәйда була... Авылдаш Гарәфи минем язмаларда беренче конкрет кеше. Аның иске гадәте: сине күргәч, ул бер ун адым ара калдырып туктый, йомшак кына итеп көлеп тора, авылдагы чагыңны, шәһәрдә укып йөргән елларыңны чагыштыра, күңелеңнән кичерә. Йөзендәге һәр хәрәкәт шул хакта сөйли... Аннан күрешә: «Уйламаган идем»,— ди...

Урта буйлы, түгәрәк ак чырайлы. Ияк астындагы уентысы да әле бетмәгән. Яшьлектән әле күп нәрсә сакланган: ягымлы шаян караш, гармунчыларга хас гәүдәне төз, башны бераз читкә борыбрак тотышы... Гармунга түгел, әйтерсең арыш эченнән кызлар тавышы килгән якка карый...

Минем авылдашым... Гәрәфинең абыйсы турында язган поэмам да бар: «Сары капкалы йорт». Гәрәфи шул йорттан. Икесе дә атаклы гармунчылар. Икесенең дә яшьлеге, тормышы бөтен биографияләре белән миңа билгеле. Мәхәббәттә кайсы уздырды икән? Гәрәфидер. Сайлады. Буталуын үзе дә сизмичә яратты, беренчесенә янадан кире кайтты. Шунысы гаҗәп, берсе дә соңыннан аңа үч тотмады, мәхәббәтнең эчкерсез, саф, күңелне тилертеп, айкап узган бер чорына турылыклы булып, кимсету сүзе әйтергә кыймый яшиләр иде алар... Үпкәләре Гәрәфигә түгел. Көндәшләрнең берсе: «Минем көндәшләрне районнан үтиль итеп җыеп, барысын бер казанда кайнатсаң да бетәрлек түгел», дип сөйләгәне хәтердә калган...

Гәрәфи безнең тыкрык кызы Мәһирәгә туктаоды, ныклап тукталды, озакка, гомерлеккә. Абыйсының балалары — барысы да кызлар, дүрт кыз... Гәрәфинең барысы да малайлар, өчәү... Менә ул каршыга баскан, елмая, елмаюының артында юләр яшьлеге, янәсе: үзең беләсең, гөнаһлы, булды инде... Солдат киеме дә аңа килешеп тора, ыспай. Сугыштан инде бер чыккан, разведкадан яраланып чыккан. Семипалатта госпитальдә яткан. Хәзер автоматчылар ротасында... Минем караштта ул характеры белән я санбатта санитар, я штабта связной булырга тиеш иде... Иртәгә янадан фронтка. Моны ул миңа гына әйтте, шыпырт кына әйтте... Суслонгер урманнарында ноябрь җилләре исеп, ноябрь суыклары якынайганда, Гәрәфиләр ротасы, иртүк, безнең барак алдыннан Суслонгер станциясенә таба үтте... Ә мин — Горькийга, «Выстрел»га... Фронтка рота командирлары әзерли торган югары тактика курсларына бару өчен кулга язу алдым...

Гәрәфине икенче тапкыр фронтка барышлый очраттым. 1942 елның җәе. Таң алды, иртәнге эңгер вакыты. Солдатларым белән авыл кырыеннан атлыйм. Тын. Кемдер юл буендагы амбар янынннан каршыма атылды. Башта танып бетермәдем. Танығач, аптырап киттем: Гәрәфи. Постын ташлап, соңыннан нәрсә буласын да онытып, каршыма атылды. Плащ-палаткадан, автоматтан. Ул да безнең дивизиядә, тик икенче полкта гына икән. Безнең полк ялга туктагач, мине эзләп тапты. Бераздан үзенең бер гаеп эш эшләве турында, урманда көтүдән аерылып, адашып йөргән сарык бәтиен суеп ашаулары турында сөйләде. «Менә бит гөнаһлы булдым. Авылда чакта кешенең бернәрсәсенә дә тими идем». Үкенеп, әрнеп сөйләде... Авыллар, шәһәрләр яна, меңләгән кешеләр кырыла, ил ут эчендә. Гәрәфи сарык бәтиен кызгана. Гаепле, гөнаһлы. Әйтерсең ул минем алда — суд алдында утыра, башы иелгән, теләсә нишләт. Ул — солдат. Мин — офицер. Аерылышканда юлына күп итеп тәмәке бирдем. Янадан аерылдык... Ржев янында бер тирәдә сугыштык, полклар гына башка. Сугышның җәен, көзен, кышын шунда уздырдык, юлыбыз янадан бер генә тапкыр да туры килмәде. Шунда һәлак булды...

Сугыштан соң, 1946 елның маенда, авылга кайтырга уйладым, сагынылган. Өстә әле фронт гимнастеркасы, аякта итек. Казан белән Арча арасындагы Чыпчык станциясеннән җәяүләп кайтам. Юлда машина түгел, ат та очрамый. Ат дип нигәдер бик исем дә китми. Шулхәтле кичереш, шулхәтле газаплардан соң, исән-сау калганнан соң, алтмыш, җитмеш километр ике ара уйга да керми, үз җаема әкренләп кайтам, уйланып кайтам. Әйтерсең дөньяга янадан килгәнмен. Сугыштан чыгып тынлыкка әләксәң, сәер. Күңел әле берсеннән аерылмаган, икенчесенә иялэшеп җитмәгән. Май ае. Кешеләр җир казыйлар, бәрәңге утырта-

лар. Миңа сәер, әйтерсең кешеләр гел сугыш белән шөгыльләнергә тиешләр. Ят хис, кыргый хис. Әтнәне уздым. Каршыма, баласын житәкләп, бер хатын килә. Якынайдылар, таныдым: Гарәфинең иптәше, ундүрт яшьләр чамасындагы ир малай — аның олы малае. Нindидер йомыш белән Әтнәгә киләләр. Ә мин кайтам. Күңелсез хәбәр белән кайтам. Юл читенә утырып, аларга Гарәфи турында сөйләдем... Малае нәкъ Гарәфи: ияге батып, уелып кергән. Күзләре дә әтисенеке кебек моңсу. Сагыш белән арыганлык бергә кушылган да күзләр тынып калганнар... Әтисе кебек ягымлы. Нихәл итәргә дә белмәгәннән, бары тыңлап кына тора... Юлда шушылай күзгә-күз очрашудан да читен нәрсә юк. Син исән, авылыңа кайтасың, аны коткарып кала алмагансың шикелле. Хет кире кит... Әтнә белән Киме арасы унике чакрым жир. Иң авыры — сугыш түгел, сугышта узган дүрт ел түгел, шушы ара икән... Киттеләр. Алар мине үз гомерләренә ничә мәртәбә күрсәләр, шул чаклы сөйләтерләр...

## «Выстрел»

Горький. 1942 елның кышы.

Идел аша күпер... Автозавод... Көн аралаш диярлек тревога. Дошман самолетлары якынлашу белән, шәһәрнең төрле төшеннән безнең объектларны күрсәтеп күктә яктырган ракеталар. Күңелгә шом салучы ракеталар. Димәк, дошман агентурасы эшли, шактый ерак тылда да эшли...

Салкын кыш. Күп вакыт иртәдән кичкә кадәр кырда, чаңгыда тактик өйрәнүләрдә узды ул кыш.

«Выстрел»... Кайчакта ул шигъри дә, романтик та, каяндыр Пушкиннан, Лермонтовтан, бураннар эченнән дуэльдән яңгыраган күк тоелды. Кайчакта бик реаль, бик коры, бик кискен... Гаҗәп тыгыз сүз. Бөек Ватан сугышының бөтен киеренкелеген әйтеп бирә торган сүз. Ул сүздә мин пуляның сызгырып баруын ишеттем. Икеләнүгә бернинди урын юк, бер генә сүз: «Выстрел». Фронтка, фәкать фронтка!

## Сугышта беренче көн

Шәһәрдән — урманга, урманнан — шәһәргә... Бу юлы Калинин өлкәсендәге, фронт тирәсендәге урманга. 1942 елның апреле. Урман. Мин сугышта булып чыккан солдатлар арасында, 375 нче укчы дивизиядә. Себер кешеләре... Тазалар, нык характерлы, авыр-сабыр кешеләр. Үзләре турында аз сөйлиләр...

Җәй урталарында дивизия фронтка кузгалды. Хәрәкәт күбрәк төнлә, тавышсыз, урманнар ышыгында... Кешеләр колоннада, кешеләр уйда, атлыйлар, үзләре тупланалар, уйлары туплана. Аркаларында йөкләре авыр, шуңа күрә алар уйларның иң кирәклеләрен генә, булыша, яшәтә, өметләндерә торганнарын гына сайлап алалар да икенче дәрәҗәдәгеләрен юл читендә ташлап калдыралар кебек...

Фронт сызыгына кич килеп життек. Минем взвод төн үткәрү өчен безнең артиллеристларның позицияләре тирәсендә тукталды. Солдатларымны мин траншеяларга урнаштырдым. Үзем арба өстенә менеп яттым. Җимерек, ватык арба. Өстендә әз генә печәне дә бар. Кем арбасы, каян монда килеп кергән? Беренче күзгә ташланган нәрсә — шул гади крестьян арбасы. Күрәсең, авыл, печән өсте искә төшкәндер. Алда ни буласы турында бөтенләй уйламыйча мендем дә яттым. Арылган, изрәп йоклаганмын. Артиллерия тавышына уянып киттем. Кояш яңа чыккан. Немец артиллериясе безнең позицияләргә ут ачкан, ерак түгел снаряд-

лар ярыла. Артиллерист мине ачуланып арбадан траншеяга сөйрәп төшерде... Сугышта беренче көн шулай башланды. Беренче көн, беренче тәэсирләр, психологик кичерешләр. Курку хисе күңелдә башта ук туа-дыр дип йөри идем. Алай түгел икән. Бөтенесе беренче яралыларны күргәннән соң башлана. Яраланган, бәйләгәннәр, артка үзе чыгарлык хәле юк, чокырда ярдәм килгәнен көтә... Яра, кан, ыңгырашкан тавыш... Үлем якында гына әйләнә, җиле кагылып тиеп китә... Сагаю тойгысы күңелгә әкренләп керә, ләкин батырлыкны кешеләр, үзләре дә сизмичә, һәрвакыт эшлиләр. Батырлык өчен сугышның башы, уртасы яки ахыры юк.

Сугышта минем беренче көнем. Беренче көнне үк укучыга сугышасы җиремне, хезмәт итәсе частемне әйтеп китәргә телим. 1942 елның июле. Калинин фронты. Төп юнәлешем — Ржев. 1243 нче полк, 375 нче дивизия. Безнең дивизия 30 нчы армия составына керә. Командующие — генерал-майор Д. Д. Лелюшенко.

Бу армия безгә хәтле шактый озын юл үткән, 1941 елның дәһшәтле көзендә, дошманның Мәскәүгә якынаеп килгән көннәрендә, Көнбатыш фронтының уң канатында торып, Клин ягыннан Мәскәүне саклаган, соңыннан, безнең гаскәрләр үзләре контрһөҗүмгә күчкәч, Клинны азат иткән, декабрь, январь салкыннарында кар ярып, апрельдә пычрак ерып, сугышып Ржев тирәсенә барып чыккан, тәҗрибәле, утта чыныккан армияләрнең берсе. Мин шул армиядә. Артта — Мәскәү, Клин, Калинин, Старица... Алда — Ржев. Күпме көч куеп һаман алынмаган, дошман тарафыннан каршылык күрсәтү төененә әйләндерелгән, Мәскәүгә яңадан бер ыргылу өчен бик ныгытылган Ржев.

Ржев... Ул бераз томан эчендә, пәрдә белән капланган, ташлар, кирпечләр өеме, күгәргән тимерләр... Берниндн хәрәкәтсез, өнсез... Нигә күгәргән тимерләр? Әллә ут, төтен, су-сазлык барысы бергә кушылып, шундый күгәргән төсне күз алдына китерәләрме? Бәлки, бу шәһәр исеменең яңгырашы тудырган бер образ гынадыр, белмим, Ржев минем күңелдә гел авыр булып калды.

Без һөҗүмгә җиде дивизия күчтек. Берничә ай ял иткән, тәртипкә китерелгән, яңа кешеләр өстәлгән дивизияләр. Июль, эссе, аяз. Җитмәсә, алга бара торган җир ачык болынлык... Бомба ява. Син җиргә йөз түбән капланган килеш ятасың, тыңлыйсың, бомба чинап төшә, ул төшеп җиткәнче, гимнастеркаң манма суга әйләнә. Тагын йөгерәсең, берәр түмгәк янында тагын җиргә капланасың. Әйтерсең лә бер көтү дуңгыз чиный. Уң ягымда ике кеше. Алар минем кешеләр түгел, каян килеп буталганнардыр, әйтә алмыйм. Берсе — ир кеше, берсе — хатын-кыз. Башта ир кеше йөгерә, ул җиргә башын төртә, аннан теге хатын... Алар янәшә яталар, карашып алалар... Янадан алда... Ә самолетлар икенче, өченче тапкыр әйләнеп килә, сиреналарын үкертеп өскә кадала, бомбасы бетсә, пулеметтан яудыра, синс физик һәм мораль яктан үтерергә тели... Июль, болын. Үз хәлем хәл булса да, тегеләрне күзәтәм. Әйтерсең алар болынга чәчәк җыярга чыкканнар да кинәт мәхшәргә эләккәннәр... Шәфкатьсез каты сугыш. Ә минә шушындый кешеләрне күргәч, күңел йомшара, хәтта сугыш та бераз йомшарып китә шикелле тоела... Бу болынны мин бер ел кичтем кебек. Тик күз бәйләнә башлагач кына тынып калды ул... Актарылган, казылган... Мин солдатларымны барлыйм, җыям һәм теге ике кеше турында уйлыйм: исәнме алар?

## Саф рух, чиста рух

Язмыш мине гел үзем кебек гади кешеләр белән очраштырды. Алар арасында мин үземне бик табигый итеп сиздем. Арада тартыну бетте, арада җанны бер-берсенә тоташтырган җепләр сузылдылар, кешеләр

тиз ачылдылар. Сугышта мин аларны якыннан күрдем. Рухлары бөтен матурлыгы белән ялтырап китте. Әз генә дә тапланмаган саф рух, чиста рух. Шул кешеләргә ышанычым сугышта тагы да ныгыды.

Кеше күңеле төрле яктан ачыла. Кешеләр кызык, мең төрле. Минем взводта гына да күпме характерлар. Кайберләрен исемнәре белән хәтерлим, кайберләрен болай төсе-бите белән, образ буларак. Менә кеч-кенә генә, сары мыеклы, урта буйлы рус солдаты, Рязаньнан. Взводта аны «сары мыек» дип йөртәләр. Өендә дүрт баласы бар... Аның тормышта иң бәхетле минуты — хат укудыр. Плащ-палаткасын бөркәнеп, җайлап, йөзен Рязань якларына борып, алгы сызыкка арты белән утыра. Җил бармы-юкмы, хатны ул бөтен гәүдәсе белән каплый, әйтерсең сугыш утыннан балаларын саклый.

Өч почмаклы хат. Өч почмаклы җир... Гадәттә, болын итәгендә шундый җирләр була, очланып килә. Я анда солы чәчәләр, ин әйбәте — житен. Зәңгәр житен. Хатка шул кишәрлек кереп утырган кебек.

Кишәрлек кенә үзе. Ләкин җирнең бер кисәге. Анда бөтенесе дә бар, хәтта болынга чыккан очында печән арасында, түмгәк арасында саркып яткан чишмәсе дә бар... Кешеләрне нечкә күңелле, тугры итеп тәрбияли торган иң яхшы китап — туган җир.

Берәүләр юлда барышлый укый... ашаган арада... Берәүләргә хатны кайчан, кайда китереп тоттыралар бит. Алгы сызыкта дошманның артиллерия уты яңа туктап, һөҗүмгә күчкән чагында сиңа тәмәке белән бергә хат ташлап китәләр. Юри шулай эшләгән шикелле. Бер минуттан әллә син исән, әллә юк. Ә хатны үлеп укыйсы килә. Белми үлүдән дә үкенечлерәк нәрсә юк. Кеше үлгәндә җаны тынычланып, белеп үләргә тиеш.

Бу солдат исә күбрәк блиндаждан чыгып, блиндаж кырында укый. Бөтен дөнья күрсен, дошманнары күрсен. Елмая, елмаюы сары мыегы очына күчә, автоматына төшә, димәк, бар да исән-сау, бар да әйбәт. Мин, читтән, аның укып бетергәнен көтәм. Балаларының исемнәрен сорыйм. Ул хатны яңадан ача, исемнәрен әйтә. Ялса, оныта. Күзләрендә яшь. Үтер, хәтерләмим, ди. Бу контузиядән. Бервакыт шулай хат язып утырганда, якында гына снаряд төшеп, блиндаж астында да калды ул. Казып алдык. Казыган чакта көрәкләрнең аяк очларына тиеп-тиеп китүен тыңлап ятуы турында иптәшләренә сөйләгәнен беләм...

Сугышта кече командирлар стройдан тиз чыга... Алар җитми. Сугыш күбрәк солдат һәм кече командирлар җилкәсендә... Әлеге солдатны мин отделение командиры итеп куярга тырышып карадым, күнмәде. Хәтереннән зарланды. Солдат булып калды. Политрукка булышты, алгы сызыкка хат ташыды.

Хат утка алып керә. Алгы сызык... Атлаган саен мина. Тимер чыбык... Үз сукмагыңнан әз генә читкә борылдың — дошман пулеметы...

Хат ташыды. Аның өчен мина кырлары да, хәтәр сукмаклар да юк, кәлтә еланы урынына үрмәли, әрем арасыннан сары мыегы гына күренә, шуыша, сумкасы сөйрәлә, ут ачалар, сумкасын аның тимер чыбыклар, куаклар йолка, бөтен нәрсә йолка... Икенче иң бәхетле минуты — шушы минут... Өченче иң бәхетле минуты — башкалар хат укыганда читтән карап утыру. Ниндидер аерым ләззәт белән арттан кабатлап бара кебек, йотып бара кебек. Аңа бер генә сүз кирәк: все в порядке... Аннан ул кайдадыр яңгыраган «ура» тавышлары ишетә, шатлана. Солдатларның противогаз сумкаларындагы хатларда әнкәләренең изге теләкләре, догасы, җиренең моңы... Батырлык ул шул өч почмаклы хат рәвешендәге бер кисәк җирдән, туган җирдән, солдат хаты кадәрле генә җаннан, күзгә күренмичә, тыныч, шауламыйча калкып чыга кебек. Шундый батырлыкка таян, ул нык, ул ышанычлы...

## Кунак

Сугышта мин урман янган чакта агачтан агачка сикереп йөргән ялкын кисәге күк тиеннәрне күрдем. Әнисе юлда үлеп калгач, сугышчылар артыннан ияреп баручы колыннарны очраттым. Кошлар күптән янып беткән авыллар өстендә әйләнәләр... Сугышта да һаман синең белән, синнән калмыйлар, синнән аерылырга теләмиләр. Йорт, нигез алар өчен дә бер.

Көн буе дошманның артиллериясе, алты көпшәле минометлары, юнкерслары ут яудыра. Җирдә яшеренергә урын юк. Кичкә таба бер тына, бүген дә син исән, иптәшләрем берәмләп җыела, блиндажга җыела. Блиндажың авыллардан әллә кайда читтә, кыр уртасында, кылганнар эчендә, юньләп беленми дә. Блиндаж өстенә дә әремнәр үскән... Кич житә, караңгы төшә. Шундый тын, кешеләр анализ ясау өчен, уйларында яңадан сугышның эченә керәләр. Көндәлек сугышка анализ. Һәр солдат үзе белгәнчә, үзе аңлаганча... Юк, теоретик анализ түгел, болай, кичереп, иптәшләрен искә алып, сугышның хикмәтенә кара акыл белән генә төшенергә теләп...

Сугыш кинәт тынганнан соң кешеләрдә шундый бер момент булып ала, уйлана торган, аңын җыя торган момент. Аннан ашарга утыра, башкасын кайгырта... Шундый тын җәйге кичләрнең берсе. Блиндаж ишегеннән нәрсәдер әкрен генә тырный. Ачабыз. Мәче, соры мәче, ябык, ләкин кыю, курыкмый керә, әйтерсең монда кемнәр торганлыгын белеп керә. Без шат. Безне ул берничә минутка гына булса да өйләребезгә кайтарды, блиндажда өй төсе урнашты, солдат паегыннан өлеш булеп бирдек... Без аны үзебез югында блиндажда яшәр дип уйладык. Үткен, сизгер мәче булып чыкты. Менә-менә артиллерия хәзерлеге башлана дип торганда, ул иртән иртүк безнең барыбыздан да алданрак күздән югала, күрми дә каласың... Блиндаж яңадан чайкалырга керешә... Яңа көн, яңа борчулар. Кичәге иптәшләрнең күбесе арада юк. Мәче кайгысымыни, кеше кайгысы. Мәче бөтенләй истән чыга, онытыла... Нәкъ шул чакта, тынлыкның мәче генә тоя торган мизгеленнән файдаланып, гаепле кеше төсле шыпырт кына ишектән уза ул. Көн буе кайда йөри, нишләп йөри, бу җәһәннәм утыннан ничек исән кала, кунарга нигә безнең янга килә?

Арыган, карап тик утыра. Күзләрендә бушлык: кыр, әремнәр, кылганнар шәүләсе... Кеше кирәк. Кешесез күңелсез. Кешесез дөнья кызык түгел. Яралыларны ташучы этләрнең сиңа төбәлгән моңсу карашыннан, сугыштан кыргыйлашып беткән мәчеләрнең төпсез күзләреннән сугышның авырлыгын кайчакта күбрәк аңларга мөмкин... бу сугышта никадәр кыргыйлык...

Сугышның тагын бер көне уза. Бүген дә син исән. Бүген дә аның, мәченең, кичке энгердә кылганнар арасыннан, җиргә тәмам сеңеп, борчуына гафу үтенгән сыман, уңайсызланып килеп керүен көттек. Озак көттек...

## Төш

Төш күрәм. Идел, ак пароход. Пароходның палубасында татар язучылары: Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәтләр, Хәсән Туфаннар. Барысы да җәйге җиңел киемнән, ак күлмәктән, барысы да шат. Пароход мин басып торган яр кырыена якынлашты, менә Шәриф ага Камал алгарак чыкты һәм кулларын сузып мине ярдан палубага, үз араларына тартып алды...

Уяндым. Һаман шул Ржев яны, окоплар, траншеялар, алгы сызык... Күргән төшемә чиксез куанып уяндым, ышанып уяндым...

Фронт шартларына да әкренләп күнегәсең икән. Бер күнеккәч, йөри бирәсең. Ләкин каяндыр, ничектер бер тыныч тормыш җиле килеп бәрелдеме — бары да ташып, күңелнең яңадан газаплары кузгала, күңелне сагыш баса, татлы, ярсулы сагыш. Бу төш, төштәге хыял тәмам чыгырдан чыгарды мине.

Сагыш басты... Шәриф абзый... Тукайлар, Фатих Әмирханнар чорының зур бер вәкиле, татар әдәбиятының намусы, олы, хөрмәтле Шәриф абзыйны сагындым...

Мин сугыш алдыннан әдәбиятка килгән яшь шагыйрь. Шәриф ага матбугат йортының баскычында очрый, туктата, иңбашыма әкрен генә кулын тидереп ала. Сибгат, шигыреңне газетада укыдым, ди. Җылы бер-ике сүз әйтә, китеп бара... Миңа шул җитә. Шул ике сүз, йомшак, ягымлы куллар...

Сагыш басты. Матбугат йортының баскычларына, иптәшләр белән очрашкан баскыч бормаларына кадәр, җылы, шау-шулы язучылар клубы, кышкы кичәләрен, тәрәзәләрдән җемелдәп күренгән утларына кадәр сагынам. Кадерен белмәгәнбез икән.

Ржев янына килеп туктаган ак пароход... Сугышта кешеләрдә кайвакыт ниндидер сизенүләр, ышанулар белән бәйләрәк бер тойгы көчәя, аны дин дип тә әйтеп булмый, дин белән ике арадагы сәер хис... Туй түгел, сугыш бит!

Берничә көннән чыннан да мине чакырдылар. Мин армия газетасы редакциясен эзләп юлга чыктым.

1942 елның көзе. Авыр көз. Үзең Калинин фронтында, уйларың — Сталинградта. Бөтен көч Сталинградка... Ржев тирәсендә полк белән полк, дивизия белән дивизия араларында — стыкларда кешеләр җитми, өстәмә көчләрнең килгәне бөтенләй күренми башлады, булганы белән сугыш. Бөтен таяныч — артиллериядә. Дошман һөҗүмгә күчә-нитә калса, бөтен өмет — катюшаларда...

Көз. Берүзем юлдан уйланып барам. Безнең артиллериянең атканын тыңлап барам. Сөенәм, безнекеләр дөпелдәтә. Инде кич якынлаша. Алда күпер. Күпердән каршыма ашыга-ашыга хәрби кеше килә. Икебез дә күпердә туктап калдык, күрештек,— танышлар. Хәкимуллин, сугышка кадәр Татарстан китап нәшриятында главлитта эшләгән кеше... Хәзер автодивизонда политработник...

Алдан ук әйтим, юлым уңмады. Мин бит строевой офицер. Һәр строевой офицер исәптә-учетта вакытта кем сине алгы сызыктан редакция эшенә алсын. Мин әле партиядә дә түгел идем. Редакциядә сүз чыкканда кем дә булса берсе ул шагыйрь, ул язучы дип әйтеп ташлагандыр... Кыскасы, гадәттәге аңлашылмау гына.

Ак пароход, Шәриф абзый күңелдә һаман якты булып калды. Төшнең аның шул көнендә генә туры килүе шартмыни? Ул чакта чыкмасам, соңыннан чыктым, уттан исән чыктым. Ак пароход — ул татар әдәбиятыдыр, мин шул әдәбиятта, шул кешеләр сафында...

## Башлап куйган хат

Кешенең ни белән яшәгәнен күп вакытта билгеләве читен. Мәсәлән, алгы сызыктагы солдат... Күңелендә аның нинди уйлар ята? Нәрсә яшәтә? Ин хәтәр төштә төнлә секретта аны нәрсә җылыта? Төнлә, беркем белән дә сөйләшми, тып-тын гына разведкага барганда, күңелендә аның нинди хисләр кайный?

Өеннән хат та көтә ул. Хат килми торса, аңа политрукның җылы сүзе дә кирәк. Поварның вакытында пешергән тәмле ашы, боткасы...

Старшинаның бомба астында калып булса да китереп киткән махоркасы... Солдатны яшәткән нәрсәләр күп алар...

Солдатка боларның барысы өстенә тагын җан азыгы кирәк... Ржев янындагы сугышларда мин Илья Эренбургның газеталарда басылган мәкаләләрен көтеп ала идем. Мин генә түгел... Политрукның кулында газетаны күрү белән солдатлар иң башта: «Эренбург мәкаләсе бармы?» — дип сорыйлар. Бар икән, йөзләре яктырып, ачылып китә, вакыт тап та тизрәк укы, ул солдатның көндәлек нормасына, яшәү нормасына керә. Аны көндәлек рационнан сызып ташларга мөмкин түгел...

Язучы ничектер кушыла ала, солдатның рухы, настроениесе, уйлары белән бер булып китә ала... Талантмы бу? Нәрсә? Әллә ил язмышының язучы язмышы белән бер бөтенгә әйләнеп китүеме? Алексей Толстойда ул «Рус характеры», Твардовскийда «Василий Теркин», Фатих Кәримдә «Үч һәм мон», Эренбургта Ватан сугышы чоры публицистикасы.

Язучы сүзе... Солдат көтеп ала. Көнендә кирәк, сәгатендә кирәк. Фронтка, частька үз вакытында, хәлиткеч моментта килеп житкән корал... Взвод командиры буларак, мин язучы сүзенең — солдатка тәэсир итү көченең ни дәрәҗәдә зур икәнлеген үзем күрдем, фронтта күрдем. Илья Эренбургка чиксез хөрмәтем шунда туды.

Иҗатта фидакарьлек, язучының урыны ил язмышы фонында ачык күренә. Ватан сугышы елларындагы Ленинград, блокада һәм Ольга Бергольц... Алар бергә йөри. Язмышлары бергә үрелгән, әдәбиятка да алар бергә кергән...

Әйтәсе килеп тә вакытында әйтелми калган кадерле сүзләр була. Күп түгел алар. Берничә сүз һәм рәхмәт. Солдатлар исеменнән рәхмәт. Эренбургка үзе исән чакта хат язарга да уйлаган идем, тартындым. Ватан сугышына да хәзер чирек гасыр тулып үтте. Уйлар һаман күңелдә, һаман онытылмыйлар. Минем кебек башка солдатлар да искә аладыр әле. Аларның да башлап куйган хатлары бардыр...

## Җыр

Җыр онытылган. 1943 елның җәендә Белгород өлкәсенең азат ителгән авыллары читеннән төнлә колонна белән үтеп барышлый беренче тапкыр җыр ишеттем. Кызлар җырлый. Җырны берсе башлый, бетим дигәндә генә икенчесе алып китә, өченчесе күчәйтә, пиндидер озын, очсыз-кырыйсыз җыр, ахыры юк, божра шикелле түгәрәк, сәер тоелды бу миңа...

Моңа хәтле кайда булган ул? Елдан артык инде сугышта. Калинин өлкәсендәге авыллар аша узылган, туктап кунылган... Беренче тапкыр ишетәм. Җыр да яшеренә икән, эчкә күчә икән, яши, ләкин тынып тора.

Менә хәзер агыла, авылда башка бер тавыш та юк, фәкать шушы җыр. Солдатлар бер-берсенә сүз әйтергә уңайсызланып, тыңлыйлар, атлыйлар... Озын, әйтерсең оккупациядә яшәгән елларның озынлыгы анда. Кызларның тын һавада яңгыраган җәйге тавышында сагыш та түгел, дәрт тә түгел, җанның бер ташуы, газаптан котылып бушануы. Кызлар үзләре дә бу җырны җырлаганда берни турында да уйламыйлар, җырда яшиләр генә. Беләм, өйләренә таралганда да алар сүзсез генә таралачак, сүзсез генә урыннарына авачак...

Җыр онытылган. Үземә-үзем ышанмыйча атлыйм. Яңадан ишеткәннән соң гаҗәпләнәм. Җырсыз ничек яшәлгән, ничек торылган? Җырсыз дөнья караңгы, үле, тын. Көчле нәрсә икән бу җыр, илаһи нәрсә икән бу җыр, тамырлары әллә кайларга барып тоташкан... Агыла, миңа

хәзер шушы җырдан башка берни дә кирәкми, мине ул дөньяның читенә илтәчәк.

Җыр уянган, димәк, дөнья исән, димәк, дөнья яши.

## Иярле ат...

Ржев уртасындагы тар участок, кыен участок. Җиде дивизия унбиш километр җир узды, сафлар сирәгәйде...

Мәскәү — Ржев тимер юлы. Тимер юл өстендә Гребеево авылы. Авылы юк, нигезләре генә бар, исеме генә бар... Без инде Ржев читендә ук... Кызыл кирпеч йортлар... Тимер чыбык белән әйләндереп алынган бәрәңге бакчалары. Кешеләре күренми, сәер... Ржевка ук килеп тоташкан өч почмаклы урман. Башын җиндидер зур бер илаһи пычкы белән кемдер кисеп алган, очлары юк. Блиндажлар урынында — су. Судан бүрәнә башлары тәртеп тора. Тылдагы урман әйбәттер. Алгы сызыктагы урман — мәхшәр. Бар да синең өскә төшә, бар да синең өскә, бернәрсә күренми. Кайвакыт синең окоп белән янәшә генә тамырыннан кубып нарат гөрселдәп ава. Янәшә ятасың, басмаганы өчен рәхмәт әйтә-әйтә гаҗәпләнеп ятасың. Әйтерсең синең янда яраланган соры шинельле солдат. Төз, озын буйлы, баһадир гәүдәле солдат. Агачлар да кешеләр кебек үк көрәшәләр. Әгәр алар көрәшмәсә, бу урман күптән беткән булыр иде... Янды, яндырдылар. Шуңа ул кырыс, караңгы чырайлы. Көек исе, авыр ис, кызу, ашыйсы килми, тамак кипкән... Чыккач, мин аңа исем китеп карый идем. Тоташ ут. Анда безнең кешеләр. Шунда тагын, яңадан керәсе бар. Взводым белән күп кердем мин ул урманга. Күбрәк таң алдыннан... Урманга җиткәнче инкел урынны үтәсең. Шунда ялгыз иярле ат, җирән ат. Кояш чыгар алдыннан үлән ашап йөри, шунда әйләнә. Ә беразлан хуҗасына юлыктым. Үлән арасында... Яшел үлән, яшел каска. Касканы үләннән аеру читен. Каска бавын ияк астыннан эләктергән. Фәкать баш һәм каска... Мине урманга карап озата, тере күзләр, кара күзләр каска астыннан миңа төбәлгәннәр. Атышлар башланганчы, табигатьнең яңа уянып килгән чагында ул дөнья белән икәүдән-икәү генә сөйләшә кебек. Ни турында, нәрсә турында?

Без үзебез узган полосада, үзебез туктаган участокта һәлак булган кешеләрне күмә идек, тәртибе шундый. Каты һөҗүм барганда күмәргә өлгермәгән чаклар да була. Соңыннан аларны күмү командасы җыеп ала. Берсенең дә күзенә чалынмаган кешеләр дә очрый. Ята. Битендә иске газета кисәге — үтеп барышлый берәрсе каплап киткәнме? Бәлки, җилдер? Бу болай гына йоклап ятучылар дип уятырга теләгәнем бар минем. Уянмый. Шундый минутларда мин кинәт авылны сагына башлый идем. Күршедә авырып яки картаеп кемдер үлә. Танышлары, туганнары җыела. Сөлгеләр, тастымаллар, кәфенлекләр сандыктан алына. Нигезеннән әкрен генә алып чыгалар, тыкрыктан ашыкмый гына алып менәләр...

Кешегә никадәр хөрмәт...

Бу кешенең, каскалы кешенең яныннан урманга үттем. Ул тере, артымнан: мин синең якташың, мин сине сабантуйларында күргән идем, дип кычкырган кебек тоела.

Яныннан уздым. Кызганып түгел, сокланып. Кешенең рухына, йөзенә сокланып уздым...

Бу кешене күмәргә кулым бармый: тере ул, тере!..

Аты, авылда төн кунарга барган малайларның атлары шикелле, пошкыра-пошкыра үлән кырка. Ул да беркая да китми, белә, хуҗасының тере икәнлегенә ышана. Хуҗасы атының тамагы туйганны гына көтәдер, нәренә сикереп менәр дә яңадан утка атылыр...

Мәңге матур, мәңге тере кешеләр була. Үзләре һаман сугыш кырында. Үзләре һаман синең белән мәңге сөйләшеп яши.

Кайбер кешеләр чирек гасырлык вакытның калын бураннары аша кычкырып каршыма чыгалар... Нигә күз ачкысыз бураннарда, яланнарда күрәм мин аны? Савинцев Калинин фронтында минем связной иде. Кыш, ачык кыр, шәп-шәрә кыр. Берниндн авыл заты юк. Эт өргән тавыш килсә дә әчкә җан керер иде. Күп вакыт шулай кыр уртасында каласың... Кунарга урын кирәк. Ул эзли, сиңнән шактый читкә китеп эзли, бөтен җирне актара... Бераздан тавышы җил белән бергә кушылып яңгырый: таптым, таптым... Блиндаж таптым. Безгә хәтле кемнәрдер булып киткән, ташланган блиндаж. Эче тулы кар, боз. Баздан бер аермасы да юк. Савинцев блиндажны кардан чистарта, кечкенә чанада кырык-илле километр тартып килгән тимер мичне кертеп куя. Ничек тә җылынасы иде, төн үткәрәсе иде. Ятып йокларга суык. Себер егете. Дивизия белән фронтка Себердән килгән, кырык бернең кышыннан бирле гел шушында, утны бездән күбрәк күргән егет. Сул кулының бармаклары бөтенләй диярлек хәрәкәтләнмиләр. Шуңа күрә кәгазьне күкрәгенә терсәге белән кыса, уң кулы белән тәмәке сала, үзе әз генә елмаеп, уң кулы белән оста итеп бөтереп, тәмәкесен сиңа карап төрә. Карашы гаҗәп, бергә озын юл үткән, бергә кыен хәлдән чыккан кешеләрнең барысын да аңлата торган караш. Ул караштa сүрәнрәк кояш, йөзендә җил белән юл тузаны аралашканнан туган тут. Кырларның сыртларыннан, урләреннән җилләр җыеп китереп салган тут. Кичке үзәннәргә төшкән ниндидер шәүләләр дә шунда чагылып киткән кебек. Ул йөздә сафлык, тазалык, ныклык. Шуларның барысы өстенә фронт кырыслыгы... Кеше солдатка әйләнә. Басынкы, сабыр. Сугышта бөтен нервларның тартылган, соңгы чиккә җитеп киерелгән чакларында да ул сабыр. Аны артык салкын канлылыгы өчен хәтта гаепләргә дә мөмкин шикелле. Дошман килә, көченең күплегенә нык ышанганга күрәме, ятып, үрмәләп азапланмый, туры өстеңә килә. Кайвакыт гәүдә җиңеләеп кала, җирдә ятканыңны тоймый башлыйсың, әйтерсең йон кебек җиңел син. Савинцевлар шундый чакта бөтен взвод, бөтен ротаны үзләренең карашлары белән тоталар. Күп кенә очракта: фронт стабильләште, диләр. Минемчә, фронт стабильләшү өчен дә нык характерлар кирәк.

Бер иялләшкән кешедән аерыласы килми. Фронт юллары аны синең уйларыңа, сагышларыңа, яшьлегенә алып кергән. Тәмәке уртак, өйдән килгән хисләр уртак. Хат уртак... Ул яннан атлый. Әйтерсең синең гомереңикегә бүленгән дә янәшә бара, алда нинди генә язмыш көтсә дә, сиңнән бер адым да артка калмый... Юллар... олы, мактаулы, авыр юллар... Алар кешеләрне хискә баеталар, ярата белергә, сагына белергә өйрәтәләр. Дуслыкка өйрәтәләр. Кешеләр юлларда күзгә күренеп үсәләр, зураялар. Юллар кешеләрне олы йөрәкле итә.

Савинцев. Связной. Әгәр безнең күзләрне бәйләп җибәрсәләр, без аякларның сизенүе буенча гына да элекке, иске сукмакларга килеп чыгар идек. Куллар белән капшанып та күп кенә блиндажларга дөрес барып керер идек. Хәтта җиргә күмелгән миналарга үзебезнекеләр басмасын өчен яннарына төртеп куелган чыбыклар буенча да үз солдатларыбызны, алгы сызыкны барыбер эзләп табар идек...

1943 елның язы, апрель. Савинцев белән Белгород юнәлешендә үрдә ял итеп утырдык... Ржевтан киттек, ала алмыйча киттек. Бераздан, 3 мартта, аны бүтәннәр азат итте. Без түгел, бүтәннәр. Барыбер түгелмени? Түгел. Күпме тырыштык, көч салдык, күпме иптәшләрне югалттык. Күңелдә әрну, без түгелгә әрни күңел.

Кырда утырдык. Җир кипкән, җир моңсу. Өстән киек казлар очып узды. Себер ягына, Себердәге күлләргә очтылар. Озак карап тордык. Аларга аткан тавыш беркайдан да ишетелмәде. Бөтен фронт окоптан башын чыгарып карыйдыр сыман тоелды. Сугыш тизрәк бетәр төсле.

Кырда тиздән барып керәсе фронт сызыгына карап утырдык. Күңел киеренкелеккә шул хәтле күнеккән, башка якка йөзенне борырга унайсызланасың. Фронт сызыгының уйларыңны ерактан гипнозлый торган әллә нинди көче бар аның. Серле. Безнең өчен яңа фронт...

Фронт сызыгы. Җирнең күгелҗем сырты артында бар да яшеренгән. Фронт сызыгы өстендәге йолкынган аерым болытлар танкларга төбәп ату өчен алга чыгарылган тупларга охшыйлар. Кеше һәркайда үзенең урынын эзли. Синең урының шушы унар километрларга сузылган сыртларның кай төшендә, кайда?

Савинцев белән Дугага хәтле бергә булдык. Дугада аны разведротага алдылар. Искеләрдән, Ржев сугышчыларыннан, миндә берничә кеше генә калды. Яңаларны өстәделәр, күбесе Сталинградтан. Дала җилендә янган, каралган, чыныккан кешеләр. Хәрәкәтләре кыю, карашлары башка, зур вакыйгалар эчендә кайнаган кешеләрнең карашлары да бүтәннәргә ышаныч кертә...

Белгородка 12—15 километр кала, Харьковка бара торган таш юл читендәрәк Ерик поселогы урнашкан. Үзәндә Ерик елгасы. Йортлар шушы елганың ике ягыннан сузыла. Ерик безнекеләр белән немецлар арасында, уртада, ләкин безнеке. Ике як та сыртларга, биеклекләргә ябышкан, 1943 елның мартыннан бирле оборонада...

Минем взводның урыны Ерик аша салынган күпер төбендә. Ат белән бергә җәяүле узарлык кына кечкенә агач күпер...

Авыл малае, күпер янында үстем.

Тимерче алачыгы кырына килеп ат дагалатканын карап тора идем. Күпер такталары иңәрлек итеп балыкка йөгердем, күрше авылга сабантуйларына чаптым. Зурая төшкәч, җәйге тын кичләрдә күпер өстендә уйланып торырга ярата идем... Ериктә күпер читендә урнашуыма эчемнән шатландым, балачак хисләре, үз авылым күренешләре яңарды, мине сугыштан тыныч тормышка, табигый хәлемә кайтарып куйды. Савинцев белән кырдан карап утырганда бу күпер безгә күренмәде. Урыным минем менә кайда булган икән. Шунда ук зуррак авыл өе чаклы беренче баскыч мәктәп. Ятим, тын. Зурлар да, балалар да эвакуацияләнгән... Кешесез авыл. Ишекләрнең, капкаларның ачылып-ябылганын ишетәсе килә. Капка төпләрендәге урындыклар буш. Капкадан керү белән йөзенә сагыш бәрелә. Сагыш ишек алдында җыелып тора кебек. Сагыш тәрәзәләрдә. Тәрәзәләрдә калган шул йөз төрле сагыш буенча хуҗаларның кемлеген танып булыр шикелле. Кешесез бар да мәгънәсез.

Дуганың уртасында, армияләрнең, меңләгән танкларның бәрелешәсе урынында кечкенә агач күпер... Янында таллар. Таллар арасында гадәттәгечә Ерик агып ята. Саф, чиста, тыныч, гаепсез. Бу эшләргә бернинди катнашым юк дигән төсле, таллыкларга яшеренгән, беленми дә...

Савинцев иптәшләре белән разведкага шул күпер аша үтә. Күрсә, автоматын югары күтәрә, исәнләшә. Алар дүрт яки алты кеше. Күбрәк кичтән китәләр... «Тел» эләккәнче аларга йокы юк. Ә «тел»не кулга төшерү җиңел түгел. Дошман бөтен төшне ныгыткан, борын тыгарлык та урын калдырмаган... Ләкин сугышның законы каты: үтә, тап...

Сугышта мин разведчикларга сокландым. Кайвакытта бөтен фронт тына. Бигрәк тә май, июнь айларында кырда фронтның хәтта ничек сулыш алганына хәтле тыңларга мөмкин. Кемнеңдер шыпырт кына дәшкәне, алгы сызыкка килгән кухня янында сөйләшкән тавыш, ялгыш бәрелеп киткән чүмеч тавышы да аерым-ачык ишетелә. Нәкъ шул чакта алар, разведчиклар, җирдә тәмам урнашып җиткән тынлыкны бозалар. Аларны ычкындырмас өчен дошман ягыннан ут ачалар... Таң алдыннан мин аларны шул күпердә очрата идем. Яраланган иптәшләрен аркаларына салып уттан алып чыгалар. Ерик буенда туктап ял итәләр. Арыганнар, йончыганнар... «Тел» юк. Ике ара... Дошман позицияләре белән

Ерик елгасы ничә йөз метр ара икән ул? Шул бер полосада көн саен күпме эпизод, легендаларга керерлек күпме батырлык! Менә берсе. Безнең разведчиклардан (бу Савинцев группасы түгел) бары бер кеше котыла, калганнары ут астына эләгә, һәлак була... Котылган дигәне дә каты яралана, Ерикка житәрәк кырда бер агач төбендә хәлдән тaеп ава... Ун көн буена шунда ята, агач тирәсендәге үләннәрнең тамырларына чаклы кимерә, җир ындыр табагына әйләнә... Аны Савинцевлар группасы шул тирәдән яңадан разведкага узышлый күреп ала...

Ә Савинцев үзе? Дугада атаклы июль сугышлары башланыр алдыннан бер күрдем. Бу юлы да безнең юллар кисешкән урында — күпердә очраштык. Мин аны үз взводыма чакырып карадым. Сораса, бәлки, җибәрерләр дә... Әз генә дә икеләнмәде, юк, китми, разведка аңа ошый. Кызык, кеше иң башта бу эшнең куркынычлыгы турында уйларга тиеш иде. Юк... Разведканың аның үз кешеләре, шуның өчен яралган кешеләре бар. Батырлык бервакытта да ялгыз йөрми. Ул романтика белән янәшә, бергә. Бәлки, романтика үзе батырлыкны тудырадыр әле? Үлем бөтенләй артта, арткы планда, уенда юк...

Савинцев киткән як... Ачык кыр. Мина кыры. Тимер чыбык белән тотылган ут сызыгы. Беренче, икенче линия траншеялар... Тәҗрибәм буенча чамалап беләм: алар хәзер ярты юлда... Алар әнә ятып тыңлыйлар, алар әнә күкрәкләрендә шуышалар. Алар... Эчемнән барып життеләр дияргә өлгермәдем, көчле шартлау йөрәгем аша яңгырап узды, тетрәтеп узды... Колак шундый сак, сизгер, һәр авазны шундый оста аера, аларның яңгырашына карап кайда нәрсә булганын ялгышмый әйтергә мөмкин. Бу җире-ние белән кубарып, күтәреп ташлаган шыксыз тавыш — мина тавышы. Кара мина, кара үлем...

Савинцевны күпердә каршыладым. Иптәшләре аны носилка сыман нәрсәдә алып кайталар, янда автоматы... Калинин фронты. Ржев. Елицтән Дугага хәтле җәяүләп узган озын язгы юл ничектер йомгак булып чорналды да шушы кечкенә генә күпергә сыйды да бетте шикелле...

Дуга — күпер, сират күпере...

Мине исталек кызыксындырмый. Үземә уйланырга мөмкинлек биреп, чирек гасыр ара калдырып, поэмаларымда, язмаларда булсын, үткәннәргә бүгенге көннән торып карарга тырыштым.

Гомер буе тормышта үземнең урынымны эзләдем. Сугышта ул — окоп, траншея... Сугышка взводым белән кердем, взводым белән сугыштан чыктым. Шул кечкенә взводта уникe милләт! Халыкның олы йөрәген күрдем. Гади кешеләр турындагы карашымның ныклыгына тагын бер кат ышандым. Тормыш шулар җилкәсендә, илне сугыштан шулар алып чыкса чыга... Тормышның фаҗига кичергән һәм тантана иткән чакларының шаһиты булдым. Сугышта кичергәннәремнән бер хис калды: дошманыңнан үзеңне өстен итеп тою хисе. Тормышның һәртөрле ваклыкларыннан арынган, сафланган күңелдә бары шул яши. Шул олы хис житәкләгәндер, күрәсең, Дугада мин партия сафына керүемне ничектер сизми дә калдым шикелле. Ил язмышы үзе алып килгән... Моны да мин хәзер генә аңладым һәм эчемнән сөенеп йөрим...

Узганнарга йомгакмы бу? Өзеп әйтергә куркам. Һәр әсәр, китап үзенә күрә йомгак. Бөек Ватан сугышын да мин бөтен сугышларга йомгак булыр дип уйлаган идем... Бүген Вьетнам, Лаос, Камбоджа, Урта Көнчыгыш миңа ашыгып нәтиҗә ясарга кушмый. Дөнья катлаулы, идеологик көрәш кискен. Узганнарыма мин бүгенге позициямне тагын бер тапкыр ачыклау өчен генә кайтам. Узганнар бүгенгегә тоташа. Язучы һәрвакыт алгы сызыкта. Гражданлык хисе вакытлыча кабыну түгел, халык язмышы, ил язмышы белән бергә янып бара торган дәвамлы, тоташ хис. Иҗатта шул хиснең өзлексез януын телим...



Гөлшат Зәйнашева

# БӘХЕТЛЕ ГОМЕР



Сәнгать кешеләренең иҗат язмышы төрлечә. Берәүләр, кинәт кабынып, йолдыз кебек яктырып яналар да тиз генә сүнеп югалалар. Аларның даны, ничектер, кыска гомерле була. Җырчы артистлар арасында бу бигрәк тә шулай. Ә икенче берәүләр сәнгать күгенә гомер буе янар өчен кабынган йолдызлар булып күтәреләләр. Күренекле артистыбыз Фәхри Насретдинов — әнә шундый озак еллар балкып янар өчен кабынган йолдызларның берсе. Аның белән бергә сәхнәгә аяк баскан җырчыларның күбесе сәнгать мәйданыннан китте. Ә ул әле һаман җырлый, әле һаман җыр сөючеләрнең мәхәббәтен һәм ихтирамын казанып килә.

...Фәхри Насретдинов 1911 елда Татарстанның Апас районы Шәмбалыкчы авылында ярлы крестьян семьясында туа. Фәхринең бабасы, әтисе һәм әнисе дә, абыйлары, апалары һәм сеңелләре дә музыкага сәләтле кешеләр була. Кайсы гармунда, кайсы скрипкада уйный, кем кубызда, кем курайда уйнарга һәвәс була. Фәхри халык моңнарын тыңлап, халык көйләрен җырлап үсә. Әле 7 яшьлек сабый чагында ук сәхнәгә чыга, ягымлы тавыш белән, балаларча көйләп, ул халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай шигырьләрен сөйли. Бу 1918 елны илдә Совет властен урнаштыруга бер ел тулуга багышланган тантаналы кичәдә була. Туган авылының кечкенә генә клубында сәхнәгә аяк баскан Фәхринең сәнгать гомере әнә шулай матур булып, Тукай шигыреннән башланып китә.

...Ул бик яшьли әтисез кала. Бөек Октябрь революциясе булмаса, дүрт бала белән тол калган Наһар апа нишләр иде икән! Әле революциядән соң да авыр көннәр күп була. Илдә гражданнар сугышы башлана. Ул да түгел, Идел буена корылык һәм, шул корылык белән бергә, коточкыч ачлык килә. Шәмбалыкчылар, ачлыктан котылу әмәлен эзләп, төрле якларга күчеп китәләр. Наһар апа да, дүрт баласын ияртеп, ерак Себергә чыгып китә. Салкын Себер. Анда да ачлык, мохтаҗлык хөкем сөрә. Күп тә үтми, тиф авыруыннан Наһар апа вафат була, балалар бөтенләй ятим калалар. Күпмедер вакыттан соң Фәхри, олкән абыйсы Шәйхигә ияреп, Мәскәүгә килә, башлангыч мәктәптә укый, аннары туку фабрикасына эшкә керә. Шунда сәнгать юлындагы берен-

че адымнарын атлый. Ул фабрика эшчеләреннән оештырылган үзешчән хорга йөри башлый. Үзенең матур җырлавы, ягымлы, йомшак аһәңле тавышы белән тиз арада фабрика эшчеләренең мәхәббәтен казанып өлгерә. 1929 елда аны Мәскәүдәге Татар эшче театрына эшкә чакыралар. Халкыбызның күренекле артистлары Асия Измайлова, Хөсәен Уразиков, Сара Садыйкова, Газиз Айдарский, Гөлсем Камскаялар иҗат юлларын шушы театр сәхнәсендә башлыйлар. Әлеге талантлы коллективта Фәхри Насретдиновның профессиональ сәхнә эшчәнлеге башлана... Эшче театры Урал, Себер, Донбасс якларында гастрольләрдә була. Фәхри Насретдинов күп кенә музыкаль спектакльләрдә җыр белән башкарыла торган рольләрне уйный һәм концертларда чыгыш ясый. Күбрәк ул халкыбызның «Кара урман», «Сибелә чәчәк», «Шахта» кебек көйләрен җырлый.

Сәхнәдәге беренче чыгышлары уңышлы башланса да, Фәхрине ул гына канәгатьләндерми. Ул укырга, музыкаль белемен күтәрергә кирәк дигән карарга килә. 1930 елда Фәхри Насретдинов Мәскәүнең Рубинштейн исемендәге музыка техникумына керә. Аны тәмамлап чыгу елы, бәхеткә каршы, Мәскәү консерваториясе каршында татар студиясе ачылган чорга туры килә. Татарстаннан килгән күп кенә талантлы музыкантлар белән бергә, ул шушы студиядә укый башлый. Бөек рус композиторлары Чайковский, Танеев, Рахманинов традицияләрен саклаган данлыклы консерваториядә уку һәм В. И. Садовников кебек тәҗрибәле профессорлардан дәрес алу



*Ф. Насретдинов В. И. Ленин ролендә*

булачак җырчыга күп нәрсә бирә. Югары профессиональ музыкаль белем алып, ул Казанга кайта.

1939 елның 17 июнендә Н. Җиһановның «Качкын» операсы белән Татар опера һәм балет театры ачыла. Бу спектакльдә Фәхри Насретдинов Кирәмәт партиясен башкара. Үзе дә авылда туып-үскән җырчыга бу образның теләк-омтылышлары бик якын һәм таныш була. Кирәмәт образында Фәхри халык тапкырлыгын, халык җорлыгын сурәтли.

Фәхри Насретдиновның опера артисты буларак эшчәнлеге — үзенә бер зур иҗат. Бу күренекле артистның хезмәт юлы музыка һәм театр белгечләре тарафыннан махсус өйрәнелергә лаек. Мин исә журнал укучыларын Фәхри Насретдинов иҗатының кайбер характерлы яклары белән генә таныштырмакчы булам.

Фәхри Насретдинов, опера артисты буларак, үзенә тапшырылган һәр образның эчке дөньясын нык тоеп, ул образның иң тирән нечкәлекләрен сиземләп уйный. Актерлык осталыгы белән тавыш байлыгы аңарда искиткеч дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгән.

Фәхри Насретдинов чит ил һәм рус классик операларында, шулай ук милли операларыбызда зур осталык белән дистәләгән онытылмас образ иҗат итте. Яшьлек көче ташып торган шагыйрь Ленский («Евгений Онегин»), җиңел акыллы, тормыштан үзенә бары ләззәт кенә эзләп йөрүче ваемсыз герцог Мантуанский («Риголетта»), көчле мәхәббәт хисеннән нишләргә белми өзгәләнгән Альфред («Травиата»), акыят патшасы, киң күңелле, кешеләргә бары бәхет кенә теләүче Берендей («Кар кызы»), мәхәббәт газабын кичереп, көчле сагышка бирелгән Фауст («Фауст»), киң күңелле, яхшы ниятле Владимир Игорович («Князь Игорь») һәм төрлесе төрле яшьтәге, төрлесе төрле холыктагы дистәләрчә башка образлар. Илебезнең кайсы шәһәренә генә гастрольгә бармасын, театр куйган операларны кайсы милләт тамашачысы гына карамасын, Фәхри Насретдинов башкарган партияләр тамашачы күңелендә зур тәэсир калдыра. Т. Хренниковның «Давылга» исемле операсында бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин образын башкарып, ул үз талантының гаҗәп бай үзенчәлекләрен күрсәтте. Тирән фәлсәфи уйланулар, киеренке хис-тойгылар белән язылган бу образны башкару артистан гаять зур осталык сорый. Опера спектаклендә бөек даһи образын иҗат итүгә ирешүе Фәхри Насретдинов талантының ифрат күп яклы булуы турында сөйли.

Фәхри Насретдинов үзебезнең милли операларда, милли музыкаль комедияләрдә онытылмас образлар иҗат итте. Ул татар опера сәнгатен пропагандалауга иң күп хезмәт куйган артист. «Качкын», «Алтынчәч», «Ирек», «Түләк», «Намус», «Илдар» (Н. Җиһанов опералары), «Галиябану» (М. Мозаффаров әсәре), «Наемщик» (С. Сәйдәшев һәм А. Ключарев операсы) кебек спектакльләрдә, «Башмагым», «Акчарлаклар», «Идел буенда» (Җ. Фәйзи әсәрләре), «Тальян моңы» (Ә. Бакиров музыкасы) кебек музыкаль комедияләрдә ул төп партияләрне башкарды. Бу опералар һәм музыкаль комедияләрдә Фәхри Насретдинов иҗат иткән кайбер образлар музыка сәнгатебезнең алтын фондына кереп калды. Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсындагы Җик Мәргән белән Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендәге Галимҗан — әнә шундый вакыйга булырлык онытылмас образлар.

«Алтынчәч» операсын мин берничә тапкыр тыңладым. Җик Мәргән образында Фәхри Насретдиновны дүрт-биш тапкыр күрдем. Әмма, кайчан гына карамыйм, Җик Мәргән сәхнәгә һаман көч-куәт ташып торган яшь егет булып ашкынып чыга һәм искиткеч мөлаем, матур тавыш белән мәшһүр «Кара урман» ариясен җырлап җибәрә иде. Зал тын да алмый тыңлый. Бу атаклы ариядә Җик Мәргәннең горурлыгы һәм батырлыгы да, сагыш, мәхәббәте дә — барысы да бергә яңгырый. Халкыбыз эпосының легендар герое Җик Мәргән реаль тормыштагыча җанлы булып, шул ук вакытта легендаларга хас серле булып күңелләргә керә. Фәхри Насретдинов Җикнең ягымлы, лирик якларына аерата басым ясый. Шул ук вакытта ул аның батырлыгына, туган илне явыз көчләрдән азат итү өчен көрәш юлындагы какшамас ныклыгына да ышандыра. 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә «Алтынчәч» спектаклен башкалабыз тамашачылары зур дулкынлану белән каршы алды. РСФСРның халык артисткасы Н. Кемарская «Вечерняя Москва» газетасында бу спектакль турында зур мәкалә язып чыкты. Ул мәкаләдә Җик Мәргән образын башкаручы Фәхри Насретдинов турында мондый сүзләр бар: «Җик образында героика һәм лирика зур осталык белән бергә үрелгән. Фәхри Насретдинов бу партияне эчкерсез сафлык, ягымлылык белән башкара. Бу артист — опера сәхнәсенең чын мастеры, матур тембрлы тавышын ул искиткеч оста файдалана».

Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендәге Галимҗан образы — Фәхри Насретдиновның милли музыкабызны башкару өлкәсендәге иң зур уңышы, иң зур казанышы дисәк ялгышмабыз. Ул иҗат иткән Галимҗан акыллы, уңган, тапкыр һәм шул ук вакытта чамасын белеп кенә хәйләли дә белүче шаян һәм шук егет. Сөйгәне Сәрвәр өчен ул җанын бирергә әзер. Артист Галимҗан образын йомшак бер наз белән, яратып башкара. Аның уенындагы нәзакәтлелек, җиңеллек, дәрт, тапкырлык бөтен спектакльне бизәп тора. Фәхри Насретдинов Галимҗан образын озак еллар буена — комедия сәхнәгә кабат яңартылып куелган чакларда кайта-кайта башкарды.

Галимҗан бәхетле образ булды. Фәхри Насретдинов Галимҗанның арияләрен, аның Сәрвәр белән башкарыла торган дуэтларын күп еллар буе радио аша җырлады, эстрада концертларында башкарды. Бәхетле образ Галимҗан Фәхри Насретдиновның үзен дә бәхетле итте. Артистның опера сәхнәсендәге бөтен иҗаты шушы шат күңелле, тапкыр, акыллы, мөлаем егет Галимҗан язмышы кебек матур. Башкаларга ничектер, «Башмагым» спектакле турында сүз чыктымы, минем күз алдыма иң элек сәхнәдә укалы матур башмак тотып, бии-бии, елмаеп җырлап йөрүче Фәхри-Галимҗан килеп баса. Алар икесе минем күңелемә бер кеше булып кереп калган һәм ул мине һаман-һаман матурлык, гүзәллек, мәхәббәт дөньясына әйди кебек. Соңгы елларда Фәхри Насретдинов «Башмагым» спектаклендә Кәрим бай образын башкара. Кәрим байны да ул зур осталык белән уйный, байлыкка кызыгучы, тар карашлы бу кешене адәм көлкесенә калдыра. Ләкин күңел һаман Галимҗан ролендәге Фәхрине сагына.

Күптән түгел мин Фәхри Насретдиновның «Севастополь вальсы»нда үзбәк Рәхмәт образын башкаруын тагын бер кабат карадым. Өлкән яшьтә булуына карамастан, ул Рәхмәт образын һаман яшь чагындагы кебек җиңеллек белән уйный. Фәхри иҗат иткән матрос Рәхмәт образы бөтен спектакльне яктыртып, җылытып тора. Тамашачылар Фәхри-Рәхмәтнең сәхнәгә чыгуын көтеп утыралар һәм аның һәр хәрәкәтен, һәр сүзен, һәр репликасын зур кызыксыну белән каршы алалар, көчле алкышлар белән озаталар. Шулай ук соңгы вакытларда сәхнәгә куелган «Мәхәббәт җыры» (С. Садыйкова, Р. Гобәйдуллин музыкасы, Х. Вахит либреттосы) спектаклендә дә Фәхри Насретдинов шундый ук җиңеллек, шат күңеллелек белән төзүче-маляр Садыйк образын башкара. Садыйк сәхнәгә чыгу белән тамашачы ирексездән елмая башлый. Бераз «кәгеп алырга» яратса да, Садыйк, нигездә, әйбәт кеше. Ул башкалар язмышына гамьсез караучы, тупас күңелле кешеләрне яратмый. Җае чыккан саен, андый салкын канлы адәмнәрдән көлә. Фәхри Садыйк куплетларын, Садыйкның хатыны Әсма (бу рольдә Татарстанның атказанган артисткасы Фәгыйлә Тимирова) белән булган дуэтларын зур осталык белән башкара. Шуңа күрә Садыйк күз алдына сөйкемле, эш сөючә гади кеше булып килеп баса. Бу спектакльне карагач, күңелдә заман темаларын яктырткан сәхнә әсәрләре күбрәк язылсын иде, опера театрыбыз сәхнәсендә Фәхри Насретдинов кебек киң колачлы артистларыбыз замандашларыбыз образын күбрәк башкарсын иде дигән теләк туа.



*Ф. Насретдинов «Башмагым» комедиясендә*

Артистның опера сәхнәсендәге эшчәнлеге турында сүз йөрткәндә, аның иҗатына уңай йогынты ясаган сәхнәдәш дуслары, партнершалары, турында да бер-ике сүз әйтми калып булмый. Халкыбызның күренекле артисткалары Галия Кайбицкая, Шафика Котдусова, Мөнирә Булатова, Зөләйха Хисмәтуллина, Рәйсә Билалова, Венера Шәрипова, Гөлшат Сәйфуллиналар — аның чын иҗат дуслары. Фәхри Насретдинов бу артисткаларның һәркайсына карата күңелендә зур хөрмәт һәм ихтирам хисларе саклый.

Фәхри Насретдинов үзенең халыкка якын булуы белән аерылып тора. Ул, опера артисты буларак, югары профессиональ җырчы, шул ук вакытта эстрада һәм радио җырчысы да. Аның иҗатының бу ягы шулай ук күп кырлы. Меңләгән концертларда катнашкан, йөзләгән гастрольләрдә йөргән Фәхри Насретдиновны бу хезмәте халыкка аерата якынайта. Ул барлык композиторларыбызның диярлек әсәрләрен яратып башкара. Аның репертуарында С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, С. Садыйкова, Р. Яхин, Х. Вәлиуллин, Ә. Фаттах, Ф. Әхмәдиев һәм башкаларның җырлары бар. Композиторларыбыз, аңа атап, махсус җырлар



*«Мәхәббәт җыры» спектакленнән бер күренеш*

язалар. Ул — композиторлар һәм шагыйрьләрнең якын дусты, аларның әсәрләрен армый-талмый пропагандалаучы. Җ. Фәйзинең «Кызыма» (М. Җәлил сүзләре), «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» (С. Хәким сүзләре), Х. Вәлиуллинның «Онытырга мөмкин түгел» (Ә. Ерикәй сүзләре) җырларын гына искә төшерик. Фәхри Насретдинов башкаруында бу җырлар музыка сәнгатебезнең алтын фондына керделәр.

Фәхри Насретдинов башкарган җырлар ни өчен шулкадәр күңелгә ятышлы, йөрәккә якын соң! Моның сере нәрсәдә икән! Мөгаен, Фәхри Насретдиновның үз эшенә — сәнгатькә бик җитди каравындадыр. Мөгаен, халыкның таләпләрен, уйларын, хисләрен яхшы белүендәдер. Мөгаен, заманыбыз сулышын яхшы тоеп яшәвендәдер, иҗат итүендәдер. Ул һәр җырга тирән мәгънә салырга омтыла. Ул җырдагы эчтәлеккә, фикергә басым ясый. Көйнең, музыканың чиста яңгыравына, көйдәге бормаларның урынлы булуына нык игътибар биреп, сүзләрнең гаҗәп ачык, дөрес әйтелешенә ирешә. Һәр әсәрдә ниндидер яңалык, яңа аһәң табарга омтылып, ул кайвакыт гади генә көйне дә шундый тырышлык белән бөртекләп әзерләп, кабат-кабат репетиция ясап, эшләп башкара. Аннары үзе дә: «Апара кебек җырны әлбә итәбез инде, мәрхүм гармунчы Фәйзи ага Биккинин әйтмешли, бөтен витаминнарын китереп җырлыйбыз инде аны!..» — дип шаяртып куя. Шаярырга, көлкеле мәзәк сөйләргә ярата ул. Театр дөньясында нинди мәзәк бар, барысын да ишетеп ала һәм үзенә генә хас тапкырлык, җорлык белән башкаларга сөйли. Шуңадыр, ахры, шаян җырлар башкарганда, ул сине ихтыярсыз елмайта, көлдерә. Җ. Фәйзинең «Чәчләребез чәчкә бәйләнгән» (Ш. Маннур сүзләре), З. Хәбибуллинның «Казан кызы», «Нәсимә» (Н. Арсланов сүзләре), З. Исмәгыйловның «Ләлә» (Н. Нәҗми сүзләре) кебек җырларын шундый бер күңелле шаянлык белән җырлый, аның башкаруында бу җырларда халыкның тапкырлыгы, үткен акылы чагыла. Фәхри Насретдиновны шундый шаян җырлары өчен авыл тамашачылары аерата ярата.

Җыр өлкәсендәге хезмәтләре турында сөйләгәндә, Фәхри Насретдиновның һәр композитор белән озак елларга сузылган иҗат дуслыгына чын-чыннан сокланырга мөмкин. Халкыбызның күренекле композиторлары С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, А. Ключаревның бик күп җырларын башкарган ул. Ә инде композитор Җ. Фәйзи белән бу өлкәдәге иҗат дуслыгы бигрәк тә матур. Җ. Фәйзинең иҗат юлы башланган еллардан алып, бүгенге көнгәчә күпчелек җырларын беренче башлап Фәхри Насретдинов җырлый. Мәшһүр «Урман кызы», «Соңгы мәртәбә» (Һ. Такташ сүзләре) җырларын иң беренче башкаручыларның берсе — Фәхри Насретдинов. Бу җырларның халык күңеленә тирән үтеп кереп, үлми яшәвендә аның хезмәте зур. Җ. Фәйзи иҗатын Фәхри Насретдиновтан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Композитор З. Хәбибуллин белән иҗади дуслыгы да аның шулай ук матур һәм күптәннән килә. «Сиңа», «Батыр егеткә» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Казан кызы», «Утыр әле көймәгә», «Нәсимә» (Н. Арсланов сүзләре), «Зәңгәр» (Г. Насрый сүзләре) һ. б. җырларын башкарып, ул З. Хәбибуллин иҗатын пропагандалау эшенә лаеклы өлеш кертте. Сара Садыйкованың иҗат юлы башланган көннәрдән алып, Фәхри Насретдинов аңа зур игътибар белән карый. «Кәтам сине»не (Ә. Ерикәй сүзләре) иң элек Фәхри Насрет-

динов җырлый. С. Садыйкованың «Җилфер-җилфер» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Муса» (С. Хәким сүзләре), «Йөрәк сере» (И. Ганиева сүзләре) кебек җырларын да Ф. Насретдинов зур дулкынлану белән башкара. Композиторларыбызның күп кенә җырларын популярлаштыруы белән бергә, Ф. Насретдинов халык көйләрен җырлауга да аерым игътибар бирә. Ул башкарган халык көйләреннән «Рәйхан» (Н. Исәнбәт сүзләре) җырына аерым тукталмый булмый. «Рәйхан»ны күп җырчылар башкарып карады. Әмма Фәхри Насретдинов башкаруындагы «Рәйхан» үзе бер дөнья ул. Киң сулыш белән, иркен тавыш белән, киеренке хисләр белән җырлый ул аны. Фәхри Насретдинов башкаруында яңгыраган «Рәйхан» көендә гүзәллек, сафлык, мәхәббәт, сагыш, үкенү һәм шул ук вакытта омтылыш, ярсулы ашкыну бергә үрелеп, бер бөтен, тирән кичереш булып яңгырый.

Фәхри Насретдинов — табигате белән йомшак күңелле кеше. Аның табигатендәге бу йомшак күңеллелек ничектер сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшев характерын хәтерләтә. Шунлыктандыр, ахры, радиокомитетта эшләүче иптәшләр композитор Салих Сәйдәшевнең иҗат һәм тормыш юлына багышланган радиопостановканы әзерләгән вакытта Салих Сәйдәшев роленә Фәхри Насретдиновны чакыралар. Артист шатланып риза була һәм Салих Сәйдәшев ролен ул шундый оста итеп башкара, әйтерсең микрофон алдында Фәхри Насретдинов түгел, Салих ага үзе чыгыш ясый. Кеше буларак, хуш күңелле, тормышында, иҗатында, дуслары арасында гади һәм мөлаем Фәхри Насретдинов яшь җырчыларга бик ярдәмчел. Үзенең күп еллык тәҗрибәсен ул яшьләр белән бик теләп уртаклаша, яшь җырчыларга тавышны ничек камилләштерергә кирәклеген өйрәтеп киңәшләр бирә. Казан консерваториясендә вокаль буенча педагог буларак, ул җырчылар хәзерләү эшенә турыдан-туры катнаша. Хәзер Татар дәүләт филармониясе солисты, яшь җырчы Булат Балтанов, Ульяновскида эшләүче җырчы Леонид Усовлар — Фәхри Насретдинов шәкертләре. Татар дәүләт опера һәм балет театрының хорында җырлаучы яшь солистларга, шулай ук Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистларына ул вокаль буенча даими рәвештә киңәшләр биреп, алар белән якыннан тәҗрибә уртаклашып яши. Опера театры һәм радиокомитет каршындагы художество советларында файдалы фикерләре, киңәшләре белән катнашып, һәрвакыт ярдәм итә. Җәмәгать эшләрендә активлыгы аның үз иҗат эшләренә һич тә комачауламый. Казанның офицерлар йорты каршындагы үзешчән артистларга шефлык итә ул. ВТОның Татарстан бүлегендә сәхнә ветераннары советында член булып тора.

Илебез буйлап күп гастрольләргә йөрүе белән бергә, Фәхри Насретдинов чит илләрдә — Кытайда, Бирмада, Вьетнамда, Кореяда булды. Хөкүмәтебез, татар совет музыкасын үстерүдәге уңышлы хезмәтләре өчен, 1944 елда Фәхри Насретдиновка Татарстанның атказанган артисты, 1950 елда Татарстанның халык артисты, ә 1957 елда РСФСРның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирде. 1959 елда ул Тукай бүләге лауреаты булды. Фәхри Насретдиновның күкрәген «Почет билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм күп кенә медальләр бизи.

Сәнгатькә багышланган авыр һәм мактаулы хезмәт белән гомер дигәнең сизелми дә үтә. Менә Фәхри Насретдиновның да яше өлкәнәюгә бара. Ә ул үзе бу турыда бөтенләй уйламый да. Алтмышка таба якынаюы турында исенә төшергәч, хәтта аптырап китте. Тавышы да аның элеккечә үк матур, элеккечә үк чиста, ачык. Җырчылар арасында сирәк була торган күренеш — үзе өлкәнәеп барса да, Фәхри Насретдиновның тавышы яшьлегендәге кебек көчле, тигез, саф. Тын алулары, сулышлары иркен саклана. Саклана дигәннән, үзен һәм тавышын бик нык саклый ул. Салкыннан да, җил-яңгырдан да, төрле авырулардан да саклый. Бергә гастрольдә йөргән дуслары аның турында: «Тамагын ул яшь баланы саклаган кебек саклый»,— диләр.

«Социалистик Татарстан» газетасының 1970 елгы 22 февраль санында басылып чыккан мәкаләсендә журналист һәм яшь шагыйрь Рәшит Зәкиев Фәхри Насретдинов турында болай язган иде: «РСФСРның халык артисты Фәхри Насретдинов җырлаганда картаюны, сүнүне, сүрелүне белми торган тавыш, башкару осталыгы хакында уйланасың. Кайчан, кайда тыңласаң да, бу көмеш тавышның көче, гүзәл төсмерләре кешене әсир итә».

Быел көз Фәхри Насретдиновка 60 яшь тулды... Ә үзе «Башмагым»дагы яшьлек дәрте ташып торган Галимҗан кебек көләч, мөлаем һәм бәхетле ул!.. Бәхетле гомер озын булсын! Җыр әле дәвам итә!

Роза Фәтхуллина

# УҢАЙ ГЕРОЙ ЭЗЛӘҮ ЮЛЫНДА

1905—1907 еллардагы беренче рус революциясе татар җәмәгатьчелегенә зур йогынты ясады. Иҗтимагый-сәяси һәм эстетик фикерләрнең үсешенә ул куәтле этәргеч булды.

Әнә шул чорда татар әдәбиятында критик реализм методы урнаша. Әмма ул еллардагы әдәби хәрәкәттә критик агым көчле булуга да карамастан, аңа әле мәгърифәтче язучыларның әдәби принциплары йогынты ясап килә. Яшь язучыларның байтагы К. Насыйри, З. Бигиев һ. б. иҗаты йогынтысында әдәбиятка килә. Азатлык хәрәкәте барышында туган өр-яңа метод, элеккесеннән бик нык аерылып торган метод, шундук барлык язучыларның язу алымы булып әверелми.

Галимҗан Ибраһимов та беренче хикәяләрендә мәгърифәтчелек идеяләрен алга сөрә, ул замандагы дини-схоластик мәгариф системасының халыкны үз артыннан ияртә алмавын, җәмгыятьне чын прогресска әйдәрлек көрәшчеләр тәрбияләргә сәләтсез булуын фаш итә. Иҗатының беренче чорында язылган күпчелек хикәяләрендә автор үз героен романтик идеалга тәреп бирә. Бу яктан аның «Диңгездә» хикәясе аеруча характерлы. Хикәянең герое үзе яшәгән җәмгыятьтәге тәртипләрдән риза түгел, халыкның наданлыгына эче поша, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә. Ул иксез-чиксез диңгез белән хозурлана һәм кешелек җәмгыятендә табигатьтәге кебек гармония булмауга пошына. Хикәя герое актив көрәшкә зарыккан. Давыл вакытында бүтән пассажирлар кайда барып бәрелергә белмичә палубада ыгы-зыгы килеп йөгерешкәндә дә ул үзен бик кыю тота. Давылда ул зур эшләр башкарырлык көч күрә. Сәяхәт тәмамлангач, йокымсыраган ярга, тынчып беткән җир өстенә чыгасы килми аның. Ләкин тормышны үзгәртердәй көчләрне герой реаль чынбарлыктан түгел, абстракт идеаллардан, гүзәл тормыш турындагы нигезсез хыяллардан эзли. Нури карт образы геройның пошынуларын тагы да арттыра. Ул бу тормышның матурлыгын, реаль чынбарлыктагы көрәшчене күрми, шуңа күрә аны романтик иллюзияләр биләп алган.

Галимҗан Ибраһимов, идеал эзләп, узган заманнарга әйләнеп карый. Тик ул «Йөз ел элек» исемле хикәясендә авыл кешеләренең наданлыгыннан һәм изелеп яшәвеннән башка нәрсә күрә алмый. Халык шәригать кануннарына ышана, ә ул кануннар кешенең җанын гарипләндерә, аны кол итеп асрый. Дин — халыкны буйсындырып тоту коралы, аны яңалыктан һәм мәдәнияттән аерым яшәтү чарасы. Автор әнә шундый фикергә килә.

Язучы эзләнүләрен дәвам итә: тормышта, бәлки, якты яклар да бардыр! Кеше дөньяга гел изелеп, гел мәхрүм булып яшәр өчен генә килмәгәндер! Шул сорауларга җавап рәвешендә «Сөю — сәгадәт» хикәясе языла. Әсәрнең герое Риза бәхетен мәхәббәттә таба һәм аны гомере буе саклый.

Әмма геройның шәхси мәхәббәттә табылган бәхете генә язучыны канәгатьләндерә алмый әле. Аның үз героен һәрьяклап камил шәхес, тормышка актив йогынты ясаучы кеше итеп күрәсе килә. Ә мондый герой аңардан киң полотнолы әсәр язуны таләп итә. Һәм, ниһаять, аның «Яшь йөрәкләр» романы дөньяга килә. Бу роман Г. Ибраһимов өчен зур әдәбиятка ныклы адым булды. Анда автор шул заман татар

җәмәгатьчелеге алдында торган проблемаларны гына куеп калмый, геройларының психологиясен, рухи үсешен дә ачып бирүгә ирешә.

Романның үзәгендә — Зыя образы. Ул — интеллигент кеше, талантлы музыкант. Әмма табигый сәләтен үстерү өчен аңа яшәп килгән җәмгыятьтә кирәкле шартлар юк. Шулай да теләгән тормышка ашыру өчен, Зыя бар нәрсәгә риза, бер әйбердән дә тартынып тормый. Ул мунчага качып кубыз уйный, гармун уйнау, җыр тыңлау өчен «тәтәйләр йорты»на йөри. Музыкага һәвәслеге аркасында аңа күп кыенлыклар күрергә туры килә.

«...Явыз куллар белән аяусыз читлек эченә бикләнеп куелган асыл кош, үзенең кошлык табигате белән гашыйк булган киңлекләрнең, ирекле һавада, матур җырларда туктаусыз очарга теләп тә, әллә кемнәр тарафыннан ясалган тимер рәшәткәләр аның бу теләгенә, бу табигый өмитенә каршы барып, азатлык бәндәсен мәңге тоткынлык трагедиясендә яшәткән кебек, Зыяның эчендәге, тәңренең үз кулы, үз ирадәсе белән куелган музыка таланты, музыка дәрте ничаклы омтылса, ничаклы тырышса да, куәтле мохит аңа дөньяны күрсәтми, хаким мохит аны һаман да ирекә җибәрүдән тимер куллары белән тыя иде» [1],— дип яза автор Зыяның музыкага омтылышы турында.

Романның нечкә хисле интеллигент, шул ук вакытта максатына ирешү юлында һәр төрле физик һәм мораль каршылыклардан тайпылмаучы Зыя образын сурәтләүгә багышланган битләре тирән бер моң белән сугарылган. Әмма Зыяга ярата музыкасы да, Мәрьямгә мәхәббәте дә кайгы-хәсрәт кенә китерә.

«Зыя гомерендә кеше белән сугышкан адәм түгел,— дип яза Г. Ибраһимов үз герое турында.— Кан түгү, кеше үтерү дигәнне авызга да аласы юк. Ул адәм кыйнауны түгел, йөккә җигелгән атларның сугылганын күргәндә дә мөтәссир була. Әмма бүген шул үзе үләргә йөргән, хәлсез Зыядан адәмнең әҗәленә сәбәп булырлык куәт чыкты» [2].

Әйе, Зыя кеше үтерә, үз гомерен ялчылыкта үткәргән, яхшы күңелле Хаҗи картны үтерә. Әмма бу үлемгә дә шәригать кануннары сәбәп. Шәригать Зыяны җинаятькә этәрә, ә Хаҗи карт шул канунның корбаны. Романның һәр бите кешене әрткычка әверелдерә торган чынбарлыкка, шул вакытта яшәп килгән тәртипләргә кискен протест белән сугарылган. Автор Зыя сүзләре белән бу тормышка ләгънәт укый:

«Менә тормыш! Менә сиңа хөррияте шәхсия! Яшәргә уйлыйсың, бәхет эзлисең! Бар да әрәмгә! Бар да юкка!.. Имеш, музыка хәрам! Матурлык гонаһ! Матурлык белән тәләззез хәрам! Матурлык алдында сәҗдә итү көферлек! Соң, илаһым, алай булгач, безгә ник мондый җан бирдең! Ник безне туң йөрәк, тупас күңел итеп яратмадың!» [3].

Шунысы әһәмиятле, язучы үз героеның характерын үсештә, үзгәрештә күрсәтә. Зыя семьясы белән конфликтка керә, бабайлар кушканча гына яшәү мөмкин булмавын, кешегә ирек кирәклеген аңлап, үзен семья, дин канунары белән бәйләп тоткан җепләрне өзәргә тырыша. Ләкин тырыша гына. Хәзергә әле ул алардан арына алмый.

Г. Ибраһимов кеше һәм җәмгыять, интеллигенция һәм халык, аларның бер-берсенә мөнәсәбәте турында җитди уйлана. Җәмгыять кешеләрнең рухи омтылышларын гамәлгә ашырырга ирек бирми, ә кеше җәмгыять богауларыннан ычкынырга, җәмгыятьтән читләшергә тырыша. Ә интеллигенция халыктан ерак, ул халык газабын аңламый. Халык та Зыя кебекләрне чит итә. Шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки халык андыйлар изүеннән, кысрыклавыннан җәфа чигә. Бу яктан романда солдатка алу күренешен сурәтләгән бүлекләр гыйбрәтле: крестьян малайлары белән Зыяны да алалар, әмма тегеләр аны үз итми.

«Яшь йөрәкләр» романында Г. Ибраһимов үз героеның рухи трагедиясен шактый тирәнтен сурәтли. Язучы Зыяны ярата, әмма шул ук вакытта аның булдыксызлыгыннан, ихтыярсызлыгыннан көлә дә. Зыяның йөрәк параличыннан үлүе дә очраклы хәл түгел. Автор моның белән шуны әйтергә тели: халыкка файдалы булырга омтылу, намуслы булу, киләчәккә идеалларың булу гына җитми. Бу юлда конкрет эшчәнлек күрсәтмәү — ул үлем белән бер. Шуңа күрә автор омтылышларын, теләкләрен гамәлгә ашыра алырга сәләтсез герое белән бәхилләшергә мәҗбүр.

---

[1] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. 1 том. Казан. 1957 ел. 287 бит.
[2] Шунда ук, 331 бит.
[3] Шунда ук, 416 бит.

Бу яктан Сәлим язмышы да бик характерлы. Сәлим 1905—1907 елгы революция вакытында шәкертләр хәрәкәтенә катнаша һәм төрмәдә утырып чыга. Халыкка хезмәт итү уе белән саташып йөри. Әмма, реакция чоры башлангач, җиңелүдән күңел төшенкелегенә бирелеп, скептикка әверелә. Скептицизм да, кылган хезмәтләреннән ваз кичү дә аңа ярдәм итми. Ул — тере мәет һәм үз-үзен үтерергә мәҗбүр. Үләр алдыннан Сәлим түбәндәге язуны калдыра:

«Берәрсе үтереп ташлагандыр дип, юкка гөнаһлы булмагыз, алтатарны үзем корып, чигәмә үзем төзим... Минем өчен, әлбәттә, кайгырмассыз, чөнки мин күптән үлек идем...»

Г. Ибраһимов әлеге романын язу дәверендә шуңа төшенә башлый: җәмгыятьтә яшәп тә, аннан азат булу мөмкин түгел икән. Бары тик халык бәхете өчен актив көрәш кенә кешегә шәхси бәхет һәм азатлык бирергә мөмкин. Бу фикер Сабир образы аша үткәрелә. Зыяның абыйсы Сабир да үзенең мохите белән разый түгел. «Кешенең җан вә табигате илә тормышы арасында ачыктан-ачык тәзад [каршылык — ред.] булса, ирекле йөрәк аны күтәрә алмый»,— дип яза автор Сабирның бу ризасызлыгы турында. Сабир да әтисе күрсәткән юлдан китми. Ул эшли, төрле урыннарда мөгаллимлек итә, «зур гына байларда контор вә сату эшләре белән дә чуалып карый». Кыскасы, атасыннан бәйсез яшәргә, үз язмышының хуҗасы булырга омтыла.

Әмма ничек итеп!.. Зыя үзендәге сәләтне, мөмкинлекләрне файдалана алмый, чөнки ул үз язмышының хуҗасы түгел. Әйләнә-тирәдәге, чынбарлыктагы шартлар каршында ул югалып кала, чөнки ул көрәшче түгел. Әмма һәлак булса да, Зыяда азатлыкка омтылу бар, әгәр ул көрәшче булса, кешеләргә хезмәт итә алыр иде, халыкны уята, аңа бәхет юлларга ярдәм итә алыр иде. Зыя татар халкының үз рәссамнары, үз композиторлары турында хыяллана.

— Ул музыкаң, ул рәсемең белән ни чыгарасың! Ул татарның корсагын туйдырамы!.. диючеләргә Зыя:

— Улмы! Җан бирә! Җан бирә! Үлгән йөрәкне тергезә! Халыкка үзлеген, үзенең дөньяда барлыгын искә төшерә, ул безне канатландыра... [1] — дип җавап бирә.

Р. Роллан романының герое Жан-Кристоф та шундый ук фикер йөртә: «Үземнең сәнгатем белән мин,— ди ул,— тынычландыра алам; әйләнә-тирәмдә көч һәм шатлык тудыра алам. Беләсеңме син, нинди дә булса бер канатлы җырның матурлыгы ни хәтле бәхетсезлекләрнең сагышларын таратканын!»

Шунысы кызык: һәр ике әсәр бер үк вакытта диярлек язылган! Р. Роллан китабы 1911 елның ноябрендә дөньяга чыкса, «Яшь йөрәкләр» романы 1912 елның маендә язылып бетә. Бу факт һәр ике сүз остасының чын сәнгатьнең әһәмиятен, аның массаларга тәэсир итү көчен ачык күрүләре турында сөйли.

Шулай итеп, Зыя үлгән йөрәкләргә җан өрергә тели. Аның абыйсы Сабир да рухи азатлыкка омтыла. Әмма ул, энесеннән үзгә буларак, кара крестьян арасына китәргә, шунда үз язмышын табарга тырыша. Ул, дөрес, азатлык юлын эзли, ләкин бу азатлык бары аның үзе өчен генә. Ул җиргә хуҗа булырга, шат күңелле, таза тәнле, эш сөючән хатын алырга кызыга. Аның идеалы бары шул гына. Мещан бәхете турында гына хыяллана ул. Үзенең бу омтылышлары турында ул Зыяга болай ди:

«...Мин сүзем, гакылым белән генә түгел, үземнең инстинктым белән үк авыл ягына карыйм... Анда булыр минем... үземнең сукам, үземнең атым. Мин үземнең таза кулларым белән үз сукама үз атымны җигеп, үз җиремне сөрермен дә үз орлыгымны чәчеп, үземә генә караган икмәк җитештерермен... Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын. Миңа шул җитә дә» [2].

Тормышта урнашкан нормаларга, чынбарлыкка протест йөзеннән Сабир, үзенең шәхси хуҗалыгын булдырып, шуның ярдәмендә бәйсезлеккә ирешергә, үзенең «мин»енә урын табарга тырыша. Егерменче, утызынчы елларда, аннан соңрак та күп кенә тәнкыйтьчеләр Сабирны Г. Ибраһимовның уңай герое санадылар. Әлбәттә, болай дип раслау хата фикер.

Г. Ибраһимов — характеры белән бунтарь табигатьле кеше. Ул шул замандагы тәртипләрне кабул итә алмаган, туган халкының язмышы турында кайгыртып яшәгән. «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909 ел) хикәясендә үк инде ул «тамак коллары»на, мещанлыкка каршы чыга.

---

[1] Шунда ук, 390 бит.

[2] Шунда ук, 271 бит.

ә Сабир омтыла торган бәхет — индивидуализм. Сабир теләгән гамәлгә ашырса да, шул ноктада тукталып кала. Романның соңгы битләре укучыны Сабир артыннан барырга түгел, Зыя хыялларына иярергә — халыкны уятырга, әмма максатка ирешү юлында эшлекле булырга, тәвәккәлрәк булырга өнди.

Зыя образы лирик җылылык белән өртелгән һәм индивидуальләштерелгән. Зыя белән бергә язучы үзе дә борчыла, җәфа чигә. Зыя образы аша ул үзенең иң матур хыялларын, омтылышларын тасвирлый. Әммә, зур художник буларак, Г. Ибраһимов Зыяның йомшак якларын да читләтеп үтми, аның эшлексезлеген, ихтыярсыз булуын фаш итә. Дөрес, автор Зыяның әтисе белән, шуның аша үзе яшәгән сыйнфый катлау белән бәйләнешне өзәргә көче җитмәвенә сәбәп тә таба. Бу сәбәп — Зыяның әнисенә булган мәхәббәтендә, аның язмышы өчен борчылуында. Әгәр Зыя әтисе белән бәйләнешне өзсә, Җәләш мулла юлдан язган улының үчен Зөләйха абыстайдан алачак. Шулай итеп, Зыя ерып чыга алмаслык каршылыклар эчендә кала. Язучы кешенең үзен әйләндереп алган шартлар белән тыгыз бәйләнештә булуын ышандырырлык итеп сурәтли.

Зөләйха абыстай һәм Зыяның сөйгән кызы Мәрьям образларында шул чордагы хатын-кызның семьяда һәм җәмгыятьтәге хәле тасвирлана. Мәрьям — мирза кызы. Ул Пушкинның «Евгений Онегин» әсәрендәге Татьяна кебек үк мәхәббәт романнары укып тәрбияләнә. Мәрьям чынбарлыктагы тормыштан ерак тора, үзе укыган романнардагы героинялар язмышы белән яши. Әммә, бәхетсез героинялардан аермым буларак, ул үзен бәхетле кеше итеп күз алдына китерә. Яшәп килгән шартлар, әйләнә-тирәсендәге мохит аны пассив шәхес итеп тәрбияли. Аңа сөйгәне Зыя белән очрашып сөйләшергә рөхсәт ителми, Зыяның солдат хезмәтен тутырып кайтуын көтәргә дә мөмкинлек бирмиләр. Әнисе Фатыйма бикә, мирза кызы өчен солдат хатыны булу хурлык дип, кызына ир итеп үзләре кебек үк мирза Фәхрине сайлый.

Г. Ибраһимов Мәрьям образын тасвирлаганда да капиталистик тормыш шартларында кешедә ерткычлык сыйфатларының барлыкка килүенә басым ясый. Башта оялчан, сүз тыңлаучан, ягымлы Мәрьям җәмгыятькә, яшьлеген харап иткән, сөйгән кешесеннән аерган кара көчләргә булган протестын иренә карата нәфрәткә әверелдерә. Зыя да, Сабир да, Мәрьям дә иске тормыш белән конфликтка керә. Аларның өчесе дә, ләкин һәрберсе үзенчә, тормышның үзгәрүен тели. Алар — яшь йөрәкләр, череп таркалу процессындагы искелек күренешләренә каршы күтәрелгән яңа буын вәкилләре.

Яшь йөрәкләргә каршы торган кара көчне Җәләш мулла образы гәүдәләндерә. Бу образны тудыруга язучы бик озак, иҗади эшчәнлегенең башыннан башлап ук әзерләнә. Ул һәр әсәрендә, К. Насыйри, З. Бигиев, Г. Тукай, Ф. Әмирхан традицияләрен дәвам итеп, дин әһелләренең чын асылын ачып бирә. Язучы романда, калку итеп, Җәләш мулланың «мин-минлек» сыйфатын беренче планга куя. Шушы сыйфаты аша аның барлык тискәре яклары фаш ителә. Руханилар катлавының кара көче дә, бу көчләрнең кара канаты астыннан яшь буынның якты дөньяга чыгарга омтылышы да Җәләш мулланың «мин-минлеге» белән бәйләнештә гәүдәләндерелә.

Кешелек җәмгыяте фәнгә, азатлыкка омтыла. Прогресс өчен корбан һәм аның кануннары киртә булып тора. Заман «алла колы»ның кешегә, шәхескә әверелүен, аңарда табигать тарафыннан бирелгән иң яхшы сыйфатларның гөрләп үсешен таләп итә. Карагруһчылык, фанатизм сазлыгына муеныннан баткан Җәләш мулла тормышта яңалыкны, хаким сыйныфларның тешетырнагы белән каршы торуларына карамастан, туктаусыз үсә барган яңалыкны, чорның яңа таләпләрен күрергә дә, ишетергә дә теләми. Бу яңалык, заманның бу таләпләре Җәләш мулла һәм аның кебекләрнең гадәти карашларын җимереп, «гавам» өстеннән хакимлек итү нигезен какшата. Шуңа күрә дә руханилар яңалыкка юл бирмәү өчен бар көчләренә тырышалар. Бу уңайдан Галим хәзрәтнең фикер йөртүе бик гыйбрәтле.

«Гәзиттәме! Гәзиттәме! — дип җикеренә ул, төкерекләрен чәчә-чәчә.— Ул гәзитне кем чыгара соң... Синең кебек кыска койрыклар бит... Әллә анда юньле адәм бар, димсең!.. Ашарга тапмыйлар да дөньяның гайбәтен сатып, акча җыялар... Мин менә патша булсам, барын җыяр идем дә, сырт буйларын тунатып, тәүбә иттерер, барлык китапларын утка ягар идем... Тагы тыңламасалар, күлләрен күккә очырыр идем мин ул эт авызларның...» [1]

Җәләш мулла болай козгын гына булса

[1] Шунда ук, 348 бит.

да, үзен бөркет дип хис итә. Аның ата-бабалары да шулай булганнар, улларын да бөркет итеп күрәселәре килә. Әмма тарих тәгәрмәче алга тәгәри, заман борынгы тәртипләрне җимерә, вата. Җәләш мулланың «мин-минлеге» заман, тормыш көн тәртибенә куйган яңа үсентеләргә бәрелеп, челпәрәмә килә, ул яшәвенең мәгънәсен югалта. Уллары ул теләгән юлдан китмиләр, муллалыктан алып ташланалар. Муллалык указыннан колак кагу — аның өчен үлем белән бер.

«Яшь йөрәкләр» романында Җәләш мулланың бөтен әшәкелеген фаш итеп, аның рухи язмышын күрсәтеп, Галимҗан Ибраһимов хакимлек итүче сыйныфларга карата протест игълан итә. Җәләш мулла омтылышларының чынга ашмавы, тырышлыкларының юкка чыгуы дин әһелләре хакимлегенең нигезе җимерек икәнлеген гәүдәләндерә.

Әсәрдә автор, геройлары белән бергә, үзе дә тормышның мәгънәсен эзли. Шул замандагы стройның шәхес үсеше өчен яраксыз икәнлеген күрсәтеп, ул җәмгыятьнең бу системасын гомумән кире кага. Әмма язучының алга куйган идеаллары хәзергә әле реаль чынбарлык белән конфликтка керә. Г. Ибраһимов, критик реализмның башка вәкилләре кебек үк, үзе яшәгән чынбарлыкның тискәре күренешләрен фаш итә, кешенең якты идеалларын мыскыллаучы социаль шартларны хөкемли, әмма социаль азатлык өчен көрәш юлларын күреп җиткерми.

Әдәбият белгечләре дөрес әйткәнчә, Г. Ибраһимов критик реализмга актив көрәшченең романтик эзләнүләре аша килә. Күп кенә тикшеренүчеләр язучының романтизмы «Яшь йөрәкләр» романында аеруча ачык чагылуы турында әйтәләр. Алар үз фикерләрен геройның халыкны сихерле музыка белән уятырга омтылуы белән нигезлиләр. Әйе, Г. Ибраһимов иҗатындагы реализм принциплары романтизм белән катлаулы мөнәсәбәттә бара. Шуңа күрә дә «Яшь йөрәкләр» романында язучының реализмны үзенчәлекле. Язучы төп игътибарны үз геройларының эчке дөньясына юнәлтә. Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең асылы персонажларның эчке дөньясы аша ачыла.

Сюжет логикасы, андагы борылышлар, ачык һәм яшерен конфликтлар роман геройларын физик һәм әхлакый яктан һәлакәткә китерә. Зыяның йөрәк параличыннан үлүе дә, Мәрьямнең, ирен үтерүдә гаепләнеп, каторгага хөкем ителүе дә, Сәлимнең үз-үзен атуы да, Җәләш мулла теләкләренең гамәлгә ашмавы да очраклы түгел. Ибраһимов үз геройларының рухи халәтләрен, аларның психологиясен даими игътибар үзәгендә тота. Геройларының кайсысы нинди иҗтимагый катлам вәкиле булуына карап, автор аларның язмышына карата хөкем чыгара. Иҗатының башлангыч чорында Г. Ибраһимов халыкны азат итү бурычын шәкертләргә һәм интеллигентларга йөкли. «Яшь йөрәкләр» романында исә ул үз героеның мондый идеалларына балта чаба, аларның нигезсез булуын гәүдәләндерә.

Р. Роллан «Жан-Кристоф» романының ничек туусы турында болай дип яза:

«Әсәрнең беренче, ачыкланып беткән сызмалары 1896 елның маена туры килә. Әмма уйланганнар киңрәк иде. Минем алда бер генә герой түгел, ике герой тора, аларның язмышлары бер-берсе белән үрелеп барырга, бер-берсен тулыландырырга тиеш иде: Хыял һәм Хәрәкәт...

Хәрәкәт драмасы язылмый калды. Минем Хыял драмасын гына язарга көчем җитте».

Р. Ролланның «Жан-Кристоф» романындагы кебек, Г. Ибраһимов та ике герой: Хыял һәм Хәрәкәт иҗат итәргә теләгәндер. Әмма ул чордагы социаль-тарихи шартлар аңа бары тик бер генә героен — Хыялны гына гәүдәләндерергә мөмкинлек биргән. Ул Хыял драмасын язган, аның трагик язмышын Зыя образына туплаган. Бары тик сигез елдан соң гына ул Хәрәкәтне үзенең герое итте. Совет чоры иҗатының беренче әсәрендә — «Яңа кешеләр» пьесасында ук инде Хәрәкәт өстенлек ала. Әмма әле ул Хыялдан да арынып җитмәгән. Шулай итеп, хәзер инде аның әсәрләрендә Хыял да, Хәрәкәт тә тигез хокуклы булып яши башлыйлар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: «Яшь йөрәкләр» романы романтизмга хас әдәби-сурәтләү чаралары белән баетылган реалистик позициядәге әсәр. Татар әдәбиятындагы беренче психологик роман булу белән бергә, ул шул ук вакытта социаль роман да. Г. Ибраһимов үз геройларының индивидуаль язмышларын социаль язмышлар итеп гәүдәләндерә. Ә бу нәрсә шул заман татар әдәбияты өчен яңа иде.

**Тәлгат Галиуллин,**
филология фәннәре кандидаты

# ХЕЗМӘТ КЕШЕСЕНЕҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ

Мәгълүм булганча, революциягә кадәрге татар поэзиясе нигездә авыл кешесен, аның кичереш-омтылышларын сурәтләү юнәлешендә үсеп килде. Революция чоры һәм аннан соңгы давыллы еллар поэзиябезнең тематик колачын нык төрләндереп, аның эстетик яңгырашын көчәйтеп җибәрде. Иҗтимагый тормышның, халык язмышының үзенчәлекле елъязмасы булган шигърият үзенең тәүге адымнарыннан ук чорның алдынгы героен, революция һәм гражданнар сугышы өермәләрен кичеп, зур төзелеш башлап җибәргән эшчене, аның хезмәтен данларга кереште. М. Гафури, һ. Такташ, Х. Туфан, Н. Исәнбәт, Ф. Бурнаш, Ш. Фидан кебек шагыйрьләр үзләренең шигырь-поэмаларында чорның иҗади энтузиазмына тирән соклану белдерделәр, эшченең көндәлек хезмәте, шул процесста туган яңа әхлак нормалары алар өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булды. Дөрес, ул елларда язылган иң уңышлы әсәрләрдә дә декларативлык өстенлек итә, шәхеснең эчке дөньясын, кабатланмас характерын сурәтлисе урынга, хезмәт процессының тышкы якларын тасвирлау белән мавыгу үзен нык сиздерә иде әле. Хәтта һ. Такташның тирән оптимизм хисе белән сугарылган «Эшлиләр» шигырендә дә эшче «тимер куллы даһи», «киң сахрада җәннәт төзүче», «батыр үгез кебек», тимердән индер бөгеп ятучы әкият батыры, хәзерге чор термины белән әйткәндә, супер шәхес итеп сурәтләнде. [Дөрес, «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар» поэмаларында шагыйрь эшче сыйныфының тарихи миссиясен, ил язмышында тоткан ролен бик төгәл һәм тулы итеп чагылдырырга ирешә.]

Ил белән бергә поэзия дә үсә барды. Утызынчы еллар әдәбиятында эшче образы татар шигъриятен яңа үрләргә әйдәп барган якты маякка әйләнде. Поэзиянең тормыш белән бәйләнеш алымнары төрләнде. Бишьеллыкның тарихи адымнары шагыйрьләрне зур тормыш ташкынына ташлады. М. Гафури Себер комбайн заводы төзелешенә багышланган уңышлы лирик шигырьләрен бирде. Ш. Маннур «Колчеданлы таулар өстендә», «Чуен ташкыннар», «Бетончылар җыры» шикелле күләмле әсәрләрен бастырып чыгарды. Ф. Кәрим эшче коллективы туугa, яңалыкның һәр өлкәдә җиңә баруын тасвирлауга багышланган «Җиденче мич» поэмасын язды. Үзенең «Орлес заводында» М. Җәлил авыл егетенең производствога килүен сурәтләде. «Хулиган», «Зәйнәп» поэмаларында яңа әхлак һәм яңа тормыш өчен көрәш романтикасын җырлады.

Әлбәттә, ул чорда язылган барлык поэма-шигырьләр дә заман һәм тарих сынавын үтә алмады. Шулай да утызынчы елларда иҗат ителгән шигъри әсәрләрнең иң уңышлылары хәзерге шагыйрьләр өчен дә үрнәк булып тора. Х. Туфанның татар эшчесенең революциягә, яңа тормышка килүен сурәтләгән «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», Ф. Кәримнең «Җиденче мич», М. Гафуриның «Себер исталеге» әсәрләре әнә шул турыда сөйли. Өлкән буын шагыйрьләребез башлаган матур традиция

 

хәзерге поэзиядә ничек үстерелә! Бу өлкәдә нинди уңышларыбыз бар!

Сүз дә юк, хезмәт темасына багышланган әсәрләр арасында күңелне биләп алырлык, авыл тормышына һәм мәхәббәт шикелле мәңгелек темаларга язылган әсәрләр белән бер рәткә куярлык шигырь-поэмалар да аз түгел. Шул ук Хәсән Туфанның «Талантлы син, Кеше туганым», «Вахтадан кайта егетләр», «Тормышка мәхәббәт» шикелле әсәрләрен искә төшерик. С. Хәкимнең «Үрләр аша...» поэмасы татар поэзиясенең офыгын киңәйтеп җибәрде. Шулар янына Әнвәр Давыдов, Шәйхи Маннур, Зәки Нури, Хисам Камалов, Әдип Маликов, Гамил Афзал, Шәукәт Галиев, Илдар Юзеев һәм Зөлфәтләрнең хезмәт темасына багышланган уңышлы әсәрләрен өстик.

Иң әүвәл, зур хөрмәт белән, мәрхүм Әнвәр Давыдов исемен телгә аласы килә. Шагыйрь әдәбиятта шәһәр һәм хезмәт темасын сурәтләүгә, башкача әйткәндә, урбанистик поэзияне үстерүгә зур өлеш кертте. «Себер кварталы трактында» исемле шигырьләр бәйләме өчен генә дә аның исемен хезмәт поэзиясен җырлаучы иң танылган әдипләр белән янәшә куеп булыр иде.

«Себер кварталы трактында» циклы хыялга байлыгы, эш процессыннан бигрәк, кешене, аның кичерешен һәм язмышын үзәккә алып сурәтләве, гуманистик рухы һәм ил каршында торган проблемаларны, бигрәк тә әхлак мәсьәләләрен кыю рәвештә күтәрүе белән отышлы. Шигъри циклның сюжеты катлаулы түгел. Шагыйрь шәһәр читендә яңа төзелеп яткан районның бер тәүлек эчендәге тормышы, шундагы яңалыклар, күләгәле күренешләр турында яза, шулар тәэсирендә кузгалган кичерешләре, шатлыгы һәм кайгысы белән уртаклаша:

Ишекне киң ачып Илгә чыгам:
Көн симфониясе мине каршы ала.
Биек дулкыннары кочагында:
— Дең-деңң! —
минем моңым чайкала.
Хәрәкәт,
Хезмәт,
Мәхәббәт —
Көн башлана.

Шагыйрь илдә, туган шәһәрендә барган бөек төзелешләрне сурәтләү белән генә канәгатьләнми. Ул замандашын да аңларга омтыла. Һәм эшчене фидакарь хезмәткә дәртләндергән хисләр ташкынын ачып сала:

О, яратам мин бу хезмәт патшалыгын,
Бу колачның иңе кайда башлануын
беләм бит мин.
Ул — күкрәктә.
Эшче күкрәгендә!
О, яратам мин бу хезмәт патшалыгын!

Хезмәтнең гомуми пафосын чагылдыру гына, тарихи чор һәм җирлек, тирәлек белән бәйләнеше артык томанлы булган эшче образы гына хәзерге укучыны канәгатьләндерә алмас иде. Шагыйрь моны аңлап эш итә. Гигант төзелешләр, фән-техника һәм космосны яулау өлкәсендәге ачышлар физик һәм интеллектуаль хезмәтләрне якынлаштырып кына калмады, эшченең характерын, психикасын һәм тарихи прогресстагы ролен дә үзгәртте. Ә. Давыдов хәзерге кешенең рухында туган үзгәрешләрне бөтен муллыгы белән чагылдыра алмаса да, эшченең тарихтагы ролен һәм хезмәт процессының зур үзгәрешләр кичерүен төгәл ачып биргән. Эшче көрәшенең әтисе заманында көчле булуы белән дан казанган. Иңбашында бер йөк таш йөртә, «чапкан атны тып» туктата алган. Ә аның улы «карандашы белән бер сыза да бер атомга миллион атлар көчен туплата. Һәм ажгырып ыргылырга әзер торган сугышның җигүле арбасын туктата» («Эшче көрәшем»).

Үндүрт мөстәкыйль шигырьдән торган «Себер кварталы трактында» циклы хезмәт темасын сурәтләүдә яңалык тууны хәбәр итте, яңа юллар ачты. Шул ук вакытта шагыйрь татар совет поэзиясенең гуманистик традицияләрен, эстетик табышларын дәвам иттерүче новатор буларак та чыгыш ясады.

Х. Камаловның «Әлмәт эскизлары» Ә. Давыдов башлаган традицияне дәвам иттерә. Бирегә лирик һәм психологик башлангыч, кеше кичерешләрен сурәтләү зуррак урын алган. Ә. Давыдов төзелешнең үзен һәм фонын ярatып сурәтләсә, Х. Камалов шул фонны тудыручы кешеләрне аңларга омтыла. Бәйләмнең үзәгенә бәхетнең мәгънәсе һәм шәхеснең, бу очракта эшченең, тормыштагы урыны турында тирән уйланулар салынган:

Бу ташларда кемнең кул җылысы?
Кем тирләре аккан бу төштә?
Тәрәзәләрдә кемнең өлмәюы

Балкып китә һаман нур төшсә?
Ул төзүче үзе ничек икән,
Тапты микән бәхет бу эштән?
Булгандыр бәхетсез чаклары да:
Башкаларга бәхет төзегән...

Кешене бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары аша сурәтләү — хәзерге алдынгы әдәбиятның, бигрәк тә совет поэзиясенең магистраль юлы ул.

Х. Камалов үзенең фәлсәфи-этик фикерләрен җанлы, канлы кеше образлары аша чагылдырырга омтыла. Тискәре тип бюрократ Гафаров, кырыс Илсур, җилбәзәк Лира һәм туры сүзле, үзен урман, ил хуҗасы итеп тойган Харис образлары — һәркайсы хәзерге җәмгыять үсешенең билгеле бер үзенчәлеген чагылдыралар. Үзенең патриотик максимализмы белән Харис егерменче, утызынчы еллар геройларын хәтерләтә:

Күңелем акка көнем ак минем,
Туган җирнең һәрнәрсәсен җәллим,
Бәр ла шундый начар як минем.

Шулай итеп, әгәр Ә. Давыдов хезмәт темасын эре, масштаблы образлар аша, публицистик дәрт һәм ялкын белән сурәтләсә, Х. Камалов исә илһамын лирик-психологик аһәңгә, салмак һәм тыйнак уйлануларга ышанып тапшыра. Ул беренче карашка кечкенә һәм әһәмиятсез күренгән вакыйга-күренешләр аша җитди фикерләр үткәрә һәм ахыр чиктә Ә. Давыдов башлап җибәргән идеалларга килеп чыга.

Хезмәт темасын тасвирлауның алымнары төрлечә булырга мөмкин. Ә. Давыдов стиле дә отышлы, Х. Камаловның эзләнүләре дә кызыклы. Хәзерге поэзия болардан башкарак алымнарны да белә. Мәсәлән, әдәбиятта хезмәтнең турыдан-туры үзе, аның процессын сурәтләгән, көн кадагына суккан шигъри очерклар, репортажлар да яшәп килә. Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләре турында заманында шигъри очерклар шактый язылды. Олы тема турында уйлану, эзләну чорында мондый әсәрләрнең язылуы да табигый күренеш.

Хезмәт темасы киң гомумиләштерүләр ясарга да зур мөмкинлек бирә. И. Юзеевнең «Шундый безнең егетләр», Ә. Бакировның «Заманыбыз — могҗизалы», Г. Афзалның «Могҗизалар чоры», «Дөнья көлсен» шигырьләрен кабат күздән кичерик. Аларда хезмәтнең конкрет чагылышын, хезмәт кешесенең характерын сурәтләүдән бигрәк, хезмәтнең нәтиҗәсен, гомуми пафосын, тарихи процесста тоткан әһәмиятен күрсәтүгә игътибар юнәлтелә:

Көрәш белән, хезмәт белән еллар үтә.
Уйлый кеше, эшли кеше, иҗат итә;
Җир-ананы нурга урап, гөлгә төреп,
Тимер сугып, җырлар җырлап бәйрәм
итә...

(Г. Афзал. «Дөнья көлсен».)

Нури Арслановның «Баулылар», Зәки Нуриның «Чистай вальсы», «Буа кызлары» шикелле җырларының нигезендә дә шулай ук гомуми хис ята. Чынбарлыкны сәнгатьчә сурәтләүнең бу алымы үз чиратында егерменче елларга — Ф. Бурнашның «Татар пролетариатына», Н. Исәнбәтнең «Коммуна тимерлегендә», һ. Такташның «Эшлиләр» кебек шигырьләренә барып тоташа.

Шагыйрь үзен бер генә төрле алым белән чикли алмый. Гаять бай һәм күп кырлы тормыш эзләнүләрне дә төрле юнәлештә алып барырга мәҗбүр итә:

Шундый безнең егетләр:
Мактануны белмәсләр,
Җир әйләнеп кайтсалар да,
Күккә борын чөймәсләр.
. . . . . . . . . . . . .
Шундый безнең егетләр:
Дөнья баглый өметләр,
Дошман килсә, ракетадай
Атылып китәр кебекләр...

Тагын бер мисал:

...Күп тормады, аннан үзе китте
Ерак хыяллары артыннан.
Җитен чәчләреннән җилфердәвен
Күрә алмам инде кайда да;
Тегерменче кызы Светлана
Тимер юллар сала тайгада.
...Бер тавыш юк.
Оеп, йокымсырап,
Нидер көтә иске тегермән.
Тик ул килми...
Яз киләсен хәбәр иткән кебек,
Ерakларга чыгып йөгергән...

Бу өзекләр И. Юзеевның «Шундый безнең егетләр» һәм «Светлана» исемле шигырьләреннән алынды. Аерма материалның төрле өлкәдән алынуында гына түгел. Тормыш күренешләренең төрлелеге шигырьләрнең интонациясен дә, стилен дә, лирик аһәңен дә үзгәртә. Берсендә — гомуми интонация, шатлык, горурлык хисе. Икенчесендә — ниндидер сагыштан, җиңелчә кайгыдан туган үкенечле сурәтләү аша бирелгән конкрет образ, лирик сурәт. Әмма ике шигырь дә — чын сәнгать әсәре.

ике шигырь дә хезмәт кешесен сурәтләүгә багышланган.

Яңадан Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша...» поэмасына әйләнеп кайтыйк. Тәнкыйть аңа бик хаклы рәвештә югары бәя бирде. «Үрләр аша...» болай ниндидер тәр тематик калыплар буенча язылган әсәр түгел. Поэманың формасы иркле һәм гаять күп сыйдырышлы. Алгы планда шагыйрь образы, аның уй-кичерешләре, язмышы тора. Поэманың төп сюжет канвасы да шагыйрь шәхесе белән тыгыз бәйләнгән. Авторның хисләре Ватан сугышы герое Ярулла һәм Халидә образлары аша укучы йөрәгенә барып тоташа. «Иделдән соң Халидә кая! Дуслык юлы әллә чикләнгән!» дип, шагыйрь укучының үзенә мөрәҗәгать итә, хезмәт кешесенең язмышы турында бергәләп уйланырга чакыра. Әйтерсең лә шагыйрь белән укучы заман, шәхес, коллектив турында ашыкмыйча, җайлап кына гәпләшеп утыралар.

С. Хәким Татарстан нефте («Ромашкино ромашкаларының исе килә кебек нефтьтән»), чәчәк атып, үсеп килгән Әлмәт шәһәре («Туганда да шаулап туды Әлмәт»), «Дуслык» трассасы турында уйлана. Шуның өстенә ул поэманың өчтән бер өлешен сугыш герое Яруллага багышлый, хәзерге әхлак, кеше белән кеше арасындагы якынлык, хезмәттә ныгыган дуслык турында яза.

Коллектив һәм шәхес, меңнәр һәм берләр мәсьәләсе совет әдәбиятының беренче адымнарыннан ук көн тәртибенә куела килде. С. Хәким дә үзенә генә хас юлсукмаклар буйлап шушы темага килеп чыга. Катлаулы, авыр терминнарны кулланмыйча гына, аны чишеп тә бирә:

Билгесез җил исеп, керфекләрне
Билгесез моң кинәт сарганда,
Башлап кына җибәр, берәм-берәм
Кушылалар таллар «Сарман»га.
Халидәне дусларыннан аер,
Юк, аерылмас мәңге Халидә;
Язмышлар бер, юлда сагышлар бер...
Халидәләр яши һәр өйдә...

Халидә хезмәттә юаныч, шатлык таба, кайгы-хәсрәтләрен, сугыш алып килгән сагышларын оныта.

Ә син, ә син онытырга тырыш,
Тынычландыр җаның хезмәттә.

Шагыйрь аерым кеше язмышы, аның тыйнак һәм фидакарь хезмәте турында сөйләү аша чор проблемаларына килеп чыга, шәхеснең рухи дөньясын, теләк-омтылышларын тасвирлау аркылы әһәмиятле мәсьәләләр турында уйлана.

Аерым кеше язмышында ил язмышын күрә белү, конкрет сюжет аша гомумиләштерүгә ирешү, реалистик материалны романтик тасвир чаралары белән үрелдереп үстерә белү социалистик реализм сәнгатенең үзенчәлекле сыйфаты. Мондый омтылыш бүген генә тумады, әлбәттә. Ф. Кәримнең «Җиденче мич» поэмасы шулай ук конкрет сюжетка корылган. Вакыйгасы да, ил күләмендә алып карагында, артык әһәмиятле түгел кебек. Ләкин шагыйрь, күренеш-хәлләрне түкми-чәчми сөйләп бирү белән генә канәгатьләнмичә, публицистик киңлеккә чыга, металл җырын тудыра:

Киң сула син, Урал,
Газлардан мартенга
ут ал,
Шаулатып чыңгырәп
металл,
металл,
металл!!!

Синтетик поэзиянең югары үрнәген «Киләчәккә хатлар» поэмасында Һ. Такташ бирде. Стиль үзенчәлекләре буенча Такташтан үзгәрәк юл белән атласа да, чор һәм кеше язмышын бер үремтәдә сурәтләргә омтылышы белән С. Хәким «Үрләр аша...» поэмасында Такташ иҗатына, аның гүзәл һәм тылсымлы сәнгатенә якынлашты.

Күренә ки, хезмәт темасын сәнгатьтә чагылдыруның алымнары күп төрле. Ләкин бу алымнарны үзләштерү һәм теманың актуальлеге генә уңышка алып килми әле. Уңышлы әсәр язу өчен материалны йөрәк аша үткәрү таләп ителә.

«Әлмәт эскизлары»нда кызыклы табышларга юлыккан Х. Камалов «Зәй буенда» поэмасында тормыш-көнитеш материалын гади кабатлау юлына баса, шуның аркасында уңышсызлыкка очрый. Сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе ягыннан карагында да поэма әллә ни шәп түгел. Сүз җае чыккан-да, шунысын да искәртеп үтәсе килә. Хезмәт темасына һәм замандашыбыз образына багышланган эпик әсәрләр идея-эстетик яңгырашлары, тәэсир көчләре, хәтта композицион яңалыклары буенча да тарихи-революцион, гражданнар сугышы һәм Ватан сугышы тематикасына багышланган әсәрләр белән ярыша алмыйлар. Бер карагында, борчылырлык нәрсә юк шикелле.

Поэзия иҗтимагый һәм техник прогресс белән янәшә атларга тырыша. Космосны яулау башлангач, шул темага багышланган шигырь-поэмалар күбәеп китте. Роберт Әхмәтҗанов «Йолдызстан» исемле романтик поэмасын язып чыкты. М. Шабаев «Маяйлар», «Космонавт улы», Ш. Мәхмүтов «Бөек үзгәреш» шикелле үзенчәлекле әсәрләр иҗат иттеләр. Татарстан нефте дә шагыйрьләребезне эзләп тапты, аларның илһамнарын уятып, талант күзәнәкләрен ачып җибәрде. Бу темага багышланган иң күләмле шигъри әсәр — Ш. Маннурның «Җир-аңкәнең сылу кызы» исемле повесте. Повесть киң тормыш күренешләрен сурәтләү, чорны иңләү, характерларны психологик тирәнлекләре һәм драматик коллизияләре аша тасвирлау ягыннан шул ук темага багышланган проза әсәрләре белән ярыша алмаса да, җиңел укыла, мавыктыргыч итеп язылган. Шагыйрь нефтьчеләрнең яңа көнкүрешен, яңалыкның искелек киртәләрен җимереп, туктаусыз алга ашкынуын, яшьләрнең хезмәт белән бергә туган мәхәббәтләре, ялгышулары, уңышлары турында дәртләнеп сөйли. Ләкин повесть җәмәгатьчелек тарафыннан зур ачыш һәм әдәбиятта яңа сүз булып кабул ителмәде.

Бүгенге татар поэзиясендә хезмәт кешесенең рухи дөньясы, шатлыгы һәм кайгысы, уй-фикерләре турында матур итеп язган омтылышлы әсәрләр аз түгел. Ләкин тирәннәнрәк уйлана, тикшерә башласаң, уңышлы әсәрләрнең санаулы икәнен күрәсең. Бигрәк тә олы язмышлы кешеләр, үзен тулысы белән хезмәткә, социалистик идеалларга багышлаган, рухи матур кешеләр турында олы итеп язган шигырь-поэма һәм җырларның сирәк күренүе борчый.

Дөрес, эзләнүләрне, ачышларны инкарь итеп булмый. Ләкин аерым шигырьләр булса да, гомумән, хезмәт темасына һәм эшче образларына багышланган классик әсәрләр белән янәшә куярлык җитди яшь поэзия дә юк әле. Мәхәббәт һәм табигать, дуслык, ата-ана һәм туган авыл, ай һәм космос турында һәр елны йөзләрчә шигырьләр язылып тора. Эшче темасы шул зур шигырьләр ташкынының берничә процентын гына били. Әлбәттә, поэзияне процентлар белән үлчәп булмый. Хәзерге шагыйрьгә утызынчы еллардагы шикелле: «Мәхәббәт, авыл табигате турында язма, хезмәт темасын җырла» диеп, рецепт биреп булмый. Ләкин сан үсешеннән башка сыйфат сикерешенең була алмаганы да мәгълүм. Шул ук утызынчы елларда хезмәт темасы поэзиянең өчтән бер өлешен алып тора иде...

Хезмәт темасына язылган әсәрләрнең күбесе бүгенге таләпләр югарылыгыннан шактый түбән тора. Кайберәүләр традициядән өйрәнүне гади кабатлау дип аңлыйлар. Мәсәлән, Ә. Габиди «Верховой» шигырендә С. Хәкимнең шул исемдәге әсәренең төп ачышын, «төшен» кабатлау юлына баскан. З. Шәйхуловның «Шофер дустым, әйдә Айга», Ф. Шәфигуллинның «Эшче горурлыгы», Ә. Гайнуллинның «Тулай торакта», «Төнге смена» шигырьләренә фикер олылыгы, масштаблылык, эшченең психологиясендә, характерында туган яңалыкларны образлы сурәтләү осталыгы җитми. Яшь шагыйрьләребез эшче турында егерменче, утызынчы еллардагыча язуны дәвам иттерәләр.

Хезмәт темасы, кайберәүләр уйлаганча, ниндидер тар, профессиональ тема гына түгел. Ул — совет поэзиясенең яшәү рәвеше, эчке хасияте. В. Маяковский, һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, С. Хәким мисаллары күрсәткәнчә, хезмәтне сурәтләү аша да гомум кешелек һәм гомум гуманизм проблемаларын калку итеп куеп була. Хезмәт темасына багышланган күпчелек әсәрләргә шигъри нәфислек, интеллектуаль югарылык, киеренкелек һәм драматизм җитми. Ә драматизмнан башка поэзия, бигрәк тә поэма яши алмый. «Үрләр аша»... поэмасының көче дә тормыш драматизмын үзәккә куя белүдә. Кызганычка каршы, күпчелек шигырьләрдә лиризмны риторика, сәнгатьчә нәфислекне күпшылык, тирәнлекне шигъри ялтырау, образлы гадилекне примитивлык алыштыра. Романтик ачышка, хыял киңлегенә тиешле урын бирелми. Кыскасы, татар поэзиясе әлегә эшче сыйныфы каршында бурычлы. Хезмәт кешесе шигъриятта физик батырлыгы, рухи матурлыгы белән гасырларны сокландырырлык итеп яңгырарга тиеш.

# КЕШЕ һӘМ ТАБИГАТЬ

**Ямиль Мустафин. Голубая лошадь. Хикәяләр. Рус телендә. «Московский рабочий» нәшрияты. 1971 ел**

«Ул иясез эт иде. һәм җәмгыятьнең гамәлдәге кануннары буенча агулап үтерелергә, гади генә әйткәндә, юк ителергә тиеш иде...»

Җәмил Мостафинның «Котырган эт» исемле хикәясе әнә шулай башланып китә. Ул хуҗасыз калып кыргыйланган эт язмышы турында. һәм, күргәнегезчә, беренче җөмләләреннән үк әсәр безне «җәмгыятьнең гамәлдәге кануннары» белән табигатьнең язылмаган законнары арасында яшәп килгән каршылыклы мөнәсәбәтләр даирәсенә алып керә.

Чиктән тыш ямьсез һәм гарип эте булган бер хатынның башына әлеге иясез эт котырмадымы икән, дигән шик килә. Алдын-артын уйлап тормастан, ул әлеге шиген башкаларга сөйли. Шул көннән башлап ниләр генә күрми мескен эт башы. Олы гына апалар, аны күрүгә, тизрәк балаларын кулга алалар һәм истерик тавыш белән: «Котырган эт килә! Котырган эт килә!» — дип кычкырырга тотыналар. Аның артыннан мылтык белән куалар, аңа агуланган ит кисәкләре ташлыйлар... Бары гадәттән тыш вакыйгадан соң — әлеге иясез эт бер баланы үлемнән коткарып калгач кына — дача халкы арасында аның «йөзе аклана», дәрәҗәсе күтәрелә...

«һәлакәт» исемле икенче бер хикәядә бу конфликт тагын да тирәнәйтелә, фаҗигале нәтиҗәгә кадәр үстерелә. Шулай бервакыт урманда янгын чыга. Куркудан котлары алынган җәнлекләр тайгадагы поселок эченә качып котылмакчы булалар. Бирегә аларны тәҗрибәле карт поши алып килә, аның артыннан йоннары көйгән бүреләр, төлкеләр, тиеннәр һәм башка җәнлекләр чабыша. Уртак кайгы урман җәнлекләрен вакытлыча берләшергә, үз араларындагы элекке дошманлыкны онытып торырга мәҗбүр итә. Поши, мәсәлән, ялгыш басып рысь балаларын үтермәс өчен, елга аша чыкканда тизлеген нык киметә, ә аның артыннан ике көн буе куып йөргән аю бу форсаттан файдаланмый — пошига ташланмый. Гомум кайгыны хәтта ау этләре дә аңлый кебек, алар җәнлекләргә үз юллары белән качарга комачауламыйлар. Бары картаеп, бөкрәеп беткән Пронька картның гына яшеренер урын эзләп ишек алдына кергән пошига мылтык төзәргә кулы күтәрелә.

Автор бу хакта мораль укып маташмый, әмма аның симпатия-антипатияләре кем ягында икәнлеге әсәрнең сәнгатьчә тукымасыннан ук сизелеп тора. «Поши бер якка авышып җирдә ята. Башына чал кергән, киң мөгезләренең очларын ут көйдереп соргылт төскә керткән, ә менә күзләре искиткеч акыллы һәм яшьләр. Ул ыңгырашмый да, гырламый да, башка туганнары кебек, үлем ачысыннан калтырап аякларын да тарткаламый.

Ул горур һәм дәрәҗәсен төшерми үлде. Аның куәтле тәне буйлап вак кына дулкыннар йөгерешеп узды, гүя ки аңа салкын иде, һәм ул соңгы тапкыр һаваны да ниндидер җиңеллек белән комсызланып, көрән төскә кереп барган борын тишекләрен киереп сулады». (28 бит.)

Пошига карата «горур һәм дәрәҗәсен төшерми» кебек сүзләр куллану сәеррәк тоелә. Мондый сыйфатлар Җ. Мостафин хикәяләрендәге башка җәнлекләргә дә хас. «Котырган эт» исемле хикәядәге эт, хаксызга рәнҗеткәне өчен, хуҗасын ташлап китә. Ә «Кыргый мәче» исемле хикәя-

дә тасвирланган мәче, мәсәлән, кешеләргә ияләшеп кенә калмый, дуслык хакына үз-үзен корбан итүгә кадәр барып җитә. Гомумән, Җ. Мостафин китабында сурәтләнгән җәнлекләр еш кына кайбер кешеләргә караганда да мәнлерәк, юньлерәк һәм мәрхәмәтлерәк булып чыгалар.

Нәрсә бу? Антропоморфизм күренеше, ягъни кешегә хас сыйфатларны, фикер һәм эмоцияләрне җәнлекләргә күчләп тагумы? Һич юк. Авторның хикәяләре тормышны белеп, кыргый хайваннарга хас холык-гадәтләрне тирәнтен күзәтеп язылган. Һәм хикмәт Җ. Мостафин әсәрләрендәге җәнлекләрнең кешеләргә охшаш булуында түгел, без үзебез — табигать балалары. Автор традицион темага яңача якын килгән һәм нигездә аның белән килешми мөмкин түгел.

Соңгы ун ел эчендә безнең табигатькә, аерым алганда, ерак элгәреләребез булган төрле тереклек ияләренә карата мөнәсәбәтебез сизелерлек үзгәрде. Без кеше натурасының гадәттән тыш өстенлеге турындагы һавалы һәм берьяклы карашлардан акрынлап арына барабыз. Ныклап тикшерә башлагач, шул нәрсә ачыкланды: табигатьтәге җан ияләре (кайчандыр кеше үзе дә шулар арасыннан чыккан, билгеле) без уйлаганнан «акыллырак» икән.

Күп уйлап тормый гына, кешеләргә хас гадәт һәм сыйфатларны күздә тотып, без «бүре законы», «бүре ерткычлыгы» кебек тәгъбирләр кулланырга яратабыз. Баксаң, әлеге тәгъбирләрнең килеп чыгуында бүреләрнең гаебе әллә ни зур түгел икән. Сыйнфый җәмгыять шартлары тудырган аларны. Табигать дөньясы турында күп әсәрләр язган Джеймс Эльгер бүреләр арасында мәгълүм бер «гаделлек» һәм «турылык» кагыйдәләре яши, ди[1].

Аннан соң, хикмәт табигать законнарында гына түгел, үзебездә дә бугай. Бар иде заманнар, теләпме-теләмичәме, кыргый хайваннарның ерткыч булуына, табигать законнарының рәхимсезлегенә кирәгеннән артык басым ясый идек. Яшәү өчен өзлексез көрәш барган шартларда бары иң көчлеләр генә исән кала, дия идек. Әгәр бүген җәнлекләрнең моңарчы игътибардан читтәрәк калып килгән яки ялгыш аңлатылган сыйфатларына игътибар итә башлаганбыз икән, димәк, бу кешеләрнең аң үсешендә алга таба тагын бер адым ясалган дигән сүз. Бу җәһәттән караганда, табигать законнарының, Җ. Мостафин китабында күрсәтелгәнчә, «акыллы» булуы — бу үзе кеше акылының үзенчәлекле чагылышы. Һәм кеше белән табигать законнары арасындагы без башта әйткән каршылыкның уңай якка чишелеше дә нәкъ менә шунда инде.

Юк, язучы мәдәният казанышларын кире какмый, безне «гадиләшергә», «дүрт аяклап» йөри башларга да чакырмый. Ул кеше белән табигать, кеше белән җәнлекләр арасында эчкерсез бәйләнеш булдыру юлларын эзли. Һәм «Тайфун», «Күк толпар», «Бөркет һәм туры ат» кебек хикәяләре аша моның мөмкин булуын да исбатлый. Бу яктан караганда, «Диңгездә» исемле хикәя аеруча кызыклы.

Кинәт чыккан давыл балыкчыларны ике атна буе диңгездә куып йөртә. Кешеләрнең азыклары бетә, сулары да бер-ике эчәрлек кенә кала. Көтмәгәндә баркасны шторм вакытында хәлсезләнгән карлыгачлар сырып ала. Эсселектән әлсерәгән кошларның һавага күтәрелерлек хәлләре калмаган була. Шул чак кешеләр соңгы суларын кошларга бирәләр. Ахырдан, изге эш эшләүләрен аңлап, үзләренең үк күңелләре күтәрелеп китә, исән калуларына ышанычлары арта. Яисә «Куркак Гастон» исемле тагын бер хикәяне алыйк. Тайгада яшәүче кешеләр адашып калган болан баласын тәрбияләп үстерәләр. Тора-бара аңа шулкадәр ияләшеп җитәләр, болан баласының фаҗигале үлемен һәркем ифрат дәрәҗәдә авыр кичерә.

Кеше һәм табигать законнары арасындагы мөнәсәбәт яңа мәсьәлә түгел. Тик шунысы бар: әгәр шәхси милекчелеккә, табыш артыннан куугa, табигый байлыкларны рәхимсез эксплуатацияләүгә корылган капиталистик дөньяда кеше белән аны чолгап алган тирәлек арасындагы конфликт берничек тә уңай хәл ителә алмаса, бездә исә, Җ. Мостафин бик дөрес күрсәткәнчә, бөтенләй башка хәл. Кеше үзен чолгап алган табигать белән эчкерсез бәйләнеш булдырырга сәләтле һәм тиеш. Тик аңа карата тагын да игътибарлы булырга, аны тагын да ныграк аңлый белергә генә кирәк. Чөнки табигать һәм андагы тереклек ияләре кешенең яшәве өчен зарури тирәлек кенә түгел, ә бәлки эчкерсез җылылык чыганагы да.

Р. МОСТАФИН

[1] Салли Кэрригер. Дикое наследство природы. Рус телендә. Мәскәү. 1969 ел. 44 бит.

## Бүгенге тәрҗемәче

Татар матбугатында тәрҗемә зур урын тота; аның үсеш юлына күз салсаң, берничә үзенчәлекле этабын күреп була. Октябрьга кадәрге тәрҗемәләр нигездә башлангыч чорга карый. Октябрьдан соңгы беренче ун ел өчен тәрҗемәнең дәүләт күләм әһәмиятле бурыч дәрәҗәсенә күтәрелүе хас. Егерменче елларда тәрҗемә әдәбиятның гомуми күләме кискен артып, төрләре дә элекке белән чагыштырганда бик киңәя. Рус теленнән тәрҗемәне Октябрь безнең алга чын тормыш ихтыяҗы итеп куйгач, шул өлкәдәге беренче кадрлар үсеп чыга. Аннан соңгы берничә дистә еллар дәвамында бу практика киңәя, тәрҗемәчеләрнең осталыгы, тәҗрибәсе арта бара. Илленче елларны бу өлкәдә аякка басу, бүгенге югары дәрәҗәгә ирешү чоры дип карап була. Политик-философик әдәбият тәрҗемәсе аеруча үсеш алды, иң хәзерлекле кадрлар шушы өлкәдә җитеште, гомумән, бу өлкәгә зур әһәмият бирелде, китап нәшриятында марксизм-ленинизм классикларын тәрҗемә итү буенча махсус редакция дә бар иде (эшләр җиңеләя төшкәч, алтмышынчы еллар башында ул политик һәм тарихи әдәбият редакциясенә кушылды).

Элеккерәк елларда, аерым алганда, сугыштан соңгы ун еллык дәвамында кадрларыбызның белем һәм тәҗрибә дәрәҗәсе бүгенгедән шиксез түбән иде әле. Тәрҗемәчедән, беренче чиратта, мәгънә ялгышы җибәрмәү таләп ителде, ягъни төп критерий итеп тәрҗемәнең аңлаешлылыгы куелды. Шулай итеп, бу өлкә үзе бер мәктәп булды, тәрҗемәчеләрнең бөтен бер буынын тәрбияләде, теоретик гомумиләштерүләр өчен ныклы база булып үсте. Шушы өлкәдә тәҗрибә туплап остарган күренекле тәрҗемәче Сәгыйт абый Фәйзуллинның «Ике тел хәзинәсе» (1964) дигән китабы да — шушы соңгы чорның тәҗрибәләрен гомумиләштерү рәвешендә дөньяга килгән хезмәт. Алтмышынчы елларның башында газета-журнал битләрендә булып үткән дискуссия дә шул ук чорның турыдан-туры чагылышы иде. Махсус аспирантура курсын үткән кадрларыбыз да (мәсәлән, Р. Шириязданов, Р. Юсупов) әлеге чор традицияләрендә тәрбияләнделәр. Р. Юсуповның «Рус теленнән татарчага тәрҗемә итүнең кайбер мәсьәләләре» (1970) исемле кандидатлык диссертациясе, Р. Сибгатовның «Тәрҗемәгә ике караш» («Казан утлары», 1970, № 7) исемле мәкаләсе һәм бүтән мәкаләләрнең күпчелеге илленче еллар тәҗрибәсенә нигезләнгәннәр. Соңгы елларда гына берничә оста тәрҗемәчебезнең Язучылар союзы членлыгына кабул ителүен шулай ук игътибардан читтә калдырып булмый: бу да алга таба бер адым дигән сүз. Шулай итеп, бүгенге көндә безнең тәрҗемә өлкәсендә шактый бай тәҗрибәбез, теоретик мирасыбыз, югары хәзерлекле кадрларыбыз бар. Теоретик әдәбияттан, күп төрле белешмәлекләрдән, сүзлекләрдән файдалана алабыз. Хәзер университетның гына да берничә кафедрасында тәрҗемә теориясе фән буларак укытыла. Язучылар союзы каршында тәрҗемәчеләр секциясе эшли...

Ә тәрҗемә үзе һәм аны башкаручылар ни хәлдә соң?

Һәр чорның үз таләбе була диләр. Моның шулай икәнен тәрҗемә өлкәсендә дә күрәбез. Мәгълүм булганча, җитештерүнең үсүенә китергән иҗтимагый сәбәпләрнең берсе — хезмәт бүленеше. Шуңа охшашрак бер хәл соңгы елларда тәрҗемәчеләр арасында да күренә. Алар арасында үзенә күрә бер специаллашу барлыкка килә. Күптәннән эшләп килә торган бер төркем политик, тарихи әдәбиятны тәрҗемәләвендә дәвам итә. Вакытлы матбугаттагы «кыска» тәрҗемәләрне икенче берәүләр башкара. Балалар әдәбиятындагы яхшы тәрҗемәләрнең шактые К. Миңлебаевныкылар, ул шулай ук киң күләмле тарихи-социаль әсәрләрне дә тәрҗемәли. Тарихи-революцион тематикалы, киң тасвирлы романнар Х. Гобәйдуллин кулыннан үтә. Шушыңа якынрак юнәлеш белән елкән буын язучыбыз А. Шамов, яшьләрдән В. Зыятдинов бара. Фәнни-популяр әсәрләр һәм политик-публицистик әдәбият күбрәк Н. Габитов өчен хас. Фәнни-нәфис прозада С. Ибраһимова эшли. Кардәш телләрдән тәрҗемә итү осталары үсеп чыкты. Чит телләрдән дә турыдан-туры тәрҗемәли башлау алдында торабыз.

Һәр тәрҗемәченең үз белем дәрәҗәсе, диапазоны, үз зәвыгы (монысына басым

ясап үтәсе килә) һәм шуларга тулысынча бәйле үз мөмкинлекләре бар. Ул үз юрганына карап кына аягын суза ала. Икенче төрле әйткәндә, үз өлкәсен тапканда, ягъни тәрҗемәдә үзен тапканда гына (язучы кебек үк) тәрҗемәче уңышка ирешә ала, үсеп китә.

Тәрҗемә прозаны укыганда хәзер тагын бер нәрсә күзгә ташлана: ул да булса тәрҗемәченең татарчаны яхшы белүе. Русчаны белү бүгенге тәрҗемәче өчен инде нигездә проблема булудан туктады. Ә менә үз, туган телеңне белү мәсьәләсенә без әле тиешенчә игътибар бирмибез кебек. Тәрҗемәче ул — тел остасы булуны дәгъвалаучы дигән сүз. Оригиналдагы фикерне татарча әйтеп бирү, татарча укучыга аңлату өчен пассив тел дә бик җитәргә мөмкин. Ә инде оригиналның хисләр сөйләмен, стилен, кыскасы, аның рухын бирү, дөресрәге, тәрҗемәдә дә саклау өчен татар телен аңлау гына җитми, аны белү кирәк. Урынында һәм вакытында файдалану өчен зарур тел чараларының хәтердә булуы мәҗбүри. Чөнки телебезнең чаралары иксез-чиксез. Сүзлекләргә дә кертелмәгән күпме сүзләр, бигрәк тә мәгънәләр һәм мәгънә төсмерләре яши халыкта! Ике генә мисал. Пединститут укытучысы М. Сәгыйтов материалларына карағанда, Г. Ибраһимовта (моннан илле-алтмыш ел элек иҗат иткән язучыда) «тавыш» сүзенең йөз илле үзенчәлекле төсмере һәм кулланыш очрагы бар икән. Ә соңгы татарча-русча сүзлек, ягъни бер язучыныкын гына түгел, бәлки бөтен халык телен колачлаган сүз китабы «тавыш»ның егермеләп кулланыш очрагын гына теркәгән. Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда «сайрау» сүзе унлап мәгънәдә кулланылган, ә сүзлектә шуларның икесе генә күрсәтелә. Сүзлекләргә кертелмәгән мондый тел байлыгын һәр язучы иҗатында гына түгел, тәрҗемәче хезмәтләрендә күпләп табып була.

Бүгенге тәрҗемәчеләрнең алгы сафында баручыларның берсе — Таһир Нурмөхәммәтов. Тәрҗемәче буларак ул бүген генә мәйданга килгән кеше түгел. Аның шактый нык кулы белән оста теле алтмышынчы еллар башында А. Рыбаков әсәрләрен («Хәнҗәр», «Бакыр кош») тәрҗемәләп чыгарганда ук күренгән иде. А. Рыбаковны ул яхшы тәрҗемәләгән иде, теле дә бай, матур иде. Әмма шулай да бу әле Таһирның чын үз теле, үз стиле түгел иде. Күрәсең, ул вакытта тәрҗемәче үз өлкәсен тапмаган булган әле. Тәрҗемәдә ул үзен соңрак, мәхәббәт лирикасы белән сугарылган социаль-психологик романнар тәрҗемәсенә керешкәч тапты. 1967 елны ул гарәп язучысы Сәхип Җамалның «Кара чәчкәләр»ен татарчалаштырып беренче уңышка иреште. Вак-төяк кимчелекләре булуга да карамастан, ул роман күңелгә бер якты күренеш булып кереп кала, ә теле елмаеп, көлеп һәм җырлап тора! Кем генә мавыгып укымагандыр аны?! Инде тәрҗемәченең яңа бер хезмәте — төрек язучысы Ришатнури Гүнтәкиннең «Чалы кошы» романы татарча чыкты. «Кара чәчкәләр»дәге диярлек тема, шул ук тарихи чор, бердәй диярлек социаль-тарихи шартлар тасвирлана... һәм тәрҗемәченең дә эш нәтиҗәсе бердәй. Моннан соң инде чыннан да Таһир үз өлкәсен, үз стилен, үз телен, тәрҗемәче буларак та үзен тапкан дип әйтми булмый.

Романның иҗтимагый әһәмияте, әдәби кыйммәте турында сөйләүне әдәбиятчыларыбызга калдырып, аның турыдан-туры безне кызыксындырган ягына күчик.

Бүгенге тәрҗемәче өчен эчтәлекне бирү проблема булып тормый. Оригиналның стиле нигездә саклана: җылата торган урыннар җылата торган итеп, көлкеле күренешләр көлдерерлек итеп, кичерешле тасвирламалар — йөрәккә үтәрлек итеп тәрҗемәләнәләр. Бу романда да шул ук хәлне күрәбез. Менә безнең күз алдыннан Фәриданең бала чагы, үсмер чагы, укыган еллары, укытучылык иткән чоры, төрле даирәдә булуы, күп кешеләр белән очрашуы-бәрелешүе һ. б. ш. күренешләр үтә. Ахыр чиктә бер кешенең ярты гомере, бер илдәге тормышның билгеле чоры күз алдыбызга килеп баса. Төп образ булган Фәридә дә кирәксе урында көлеп, шаярасы вакытта шаярып, кирәк булса ачуланып, ләкин һәр вакыт үз-үзе булып, бөтенлекле бер тип булып күңелдә кала. Ришатнури тарафыннан төрек телендә иҗат ителеп, төрек рухы белән сугарылган кыз Таһир тарафыннан татар сүзләреннән яңа бер мәртәбә (бу юлы инде татар телендә) барлыкка китерелеп, Ришатнуридан алган рух белән үк сугарылып татар укучысына килеп җитә. Автор файдаланган әдәби алымнарны тәрҗемәче дә файдаланган, авторның идеясе тәрҗемәдә дә сакланган. Тәрҗемәче моңа ничек ирешкән соң? Бу сорауга инде телче күзлегеннән карап җавап бирергә кирәк.

Таһир — татар телен яхшы белүче. Ул, мәсәлән, сүзлекләрдә очрамый торган күп кенә сүзләрне бу тәрҗемәсендә файдаланган: номерчы, багышлама, шуктуган, төемчан, үлем-тәшем, мескенәю һ. б. ш. Яки менә «мөдирә», «хыял итү» кебек ясалгылар. Бездә ир дә, хатын-кыз да — бәрысы да мөдир, чөнки телебезнең табигате шундый. Ә «Чалы кошы» романында тасвирлана торган дөньяны, андагы җәмгыятьне, андагы мөнәсәбәтләрне күз алдына китерсәң, нәкъ менә «мөдирә» сүзенең кирәклеге күренә. Сүзлекләребездә «хыяллану» фигыле бар, аның мәгънәсе «хыял итү»неке кебек түгел. Соңгысы сүзлекләрдә бирелми: сирәк кулланылганга дыр, күрәсең. Ләкин аңа карап ул татар теленең байлыгы булудан туктамый ич, аның үз мәгънәсе дә бар; урыны белән ул «хыяллану» сүзен алмаштырырга да мөмкин.

«Ишекне сызык кына ачу», «итәк кигән бу карчыганың тәҗрибәсе баланы тибеп алуына — тыныч кына карап торырлар иде микән» кебек әзекләрдәге «сызык», «тибеп» сүзләре бу мәгънәләрендә сүзлекләрдә бирелмәгәннәр, ләкин тәрҗемәче тарафыннан телебезгә хас мәгънәләрдә кулланылганнар.

Тәрҗемәнең төп сыйфатларыннан берсе — татарча яңгырашы, «әйләндереп теккәннең» эзләре калмавы. Моңа ирешү өчен телебезнең сүзләрен, боларның мәгънәләрен белү генә җитми, идиоматик берәмлекләрен (фразеологиясен) белү дә шарт. Әйтик, төрек берәүне «авызыннан борчагын алды» ди, ягъни серне яшерүдән туктады ди, ә татар: «телен чиште» диярга мөмкин. Яки төрек «Урта диңгездә капитан, Мисырда солтан» дигәндә, татар «эшләмәгән эше юк, киләндергән төше юк» ди. Шундый сурәтле-образлы сөйләмне Таһир да шактый уңышлы файдаланган. Менә берничә генә мисал:— аяк терәп каршы килү;— Тормыш — агу чәчкәсе. Яманга үлем юк, яхшыга торым юк анда;— Сөйгән сигез, теләгән бер диләр бит. Ә минем җан теләгәнем бер генә — Фәридә генә һ. б.

Кай очракта идиомаларның да сирәгрәк очрый яки сүзлекләрдә теркәлмәгән мәгънәсе табып кулланылган. Мәсәлән, «ашый» дигән мәгънәдән тыш, «буш сүз сөйли» мәгънәсендә дә йөри торган «тегермәне тарта» әйтеме Таһирның бу тәрҗемәсендә сөйләү генә түгел, тырышу дигәнне дә аңлата:— бичара балаларның аз гына булса да күңелләрен күтәрү, көлдерү өчен ниләр генә кылмыйм. Ләкин юк, тегермәнем бушка гына тарта иде.

Идиоматик фразеология урынына җыр әзекләре уңышлы гына килгәннәр:— мин үз көнемнә үзем күрим дип мөгаллимә булган идем. Ләкин ялгышлык булып чыкты бу.— [Әмма] узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да дип тикмәгә генә җырламыйлар.

Тәрҗемәгә нигез итеп русча басма алынган, ләкин тәрҗемәченең естәлендә оригинал да ята. Кардәш телләрнең якынлыгыннан файдаланып Таһир тагын бер откан. Менә, мәсәлән, элеккерәк стилебез өчен хас, ләкин бүген дә тулысынча аңлаешлы «ханә» сүзенең кулланышы: каекханә, кер ханәсе, кабулханә, каразылханә, даруханә, мөгаллимханә һ. б. Мондый сүзләр кулланып сурәтләү милли җирлекне тулырак күзалларга ярдәм итә.

Бу абзацны кечкенә чигенештән башлыйк. Матур әдәбият теленә матур әдәбият таләбен кую дөрес һәм зарур. Аерым алганда, ул формасының (бу очракта: теленең) матурлыгы, күңелгә хуш килүе белән дә матурлык хисе тәрбияләргә, һәр хәлдә, укучы тарафыннан үз ителергә, яратылырга тиеш. Халыкның уннан тугызы «гыйнвар» дип сөйли икән, ягъни шул форманы үз итә икән, димәк, аңа шулай табигый, матур тоела. Калган уннан бере дә гел «январь» гына дип сөйләми, чөнки рәсми сөйләм стиле белән өйдәге-семьядагы стиль бер түгел. Телебез көчәйсен, алга китсен дисәк, аның күбрәк тамырлы үсентеләрен — уннан бер өлешесен түгел, бәлки уннан тугызлысын тәрбияләп үстерергә кирәк. Гомумхалык теленең рухын аңлаган тәрҗемәче яки язучы телендә дә «гыйнвар», «сәркәтип» («сәркатип» түгел!) кебек формаларның урын алуы бик табигый һәм зарури күренеш.

Гомумән, бу тәрҗемәнең үзенчәлекләге — чын халыкча сүзләр, мәгънәләр, тәгъбирләр, формалар кулланууда. Алар оригиналны тулырак аңларга ярдәм итәләр. Берничә генә үрнәк:— әйдә, киткәнкиткән, ахырына кадәр яшермик инде;— оеш-оеш булып кара бөрлегәннәр утыра;— егерме яшьлек егетләрне бөгеп салам әле мин;— әйләнеп чыккан бюрократ;— бетерен тирги;— кырык чатлы тыкрык;— хуҗабызны беләсез ич инде... кискән — кырыккан һ. б.

Урынына кертеп утыртылгач, искергән дип йөртелгән сүз дә («кәбә» сүзе) бер дә

искәрмәгән булып чыга:— [Укытучыга иялләшеп, күнегеп җитмәгән укучылар] алан-ялан миңа караналар, үзләре, ташбака тәпиен көбәсенә яшергән шикелле, аякларын акрын-акрын асларына җыялар иде.

Уңышлы тәрҗемә үрнәкләре монда мисалга китерерлек дәрәҗәдә генә түгел, әлбәттә. Тәрҗемәче баштарак кына бераз теленең «көен» таба алмый маташкан булса кирәк. Ләкин ахырга таба инде ул югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән. Нәкъ менә кайтырга чыгам дигәндә генә җиләкнең оясына очраган шикелле, китаптан аерыласы килми — эчтәлеге дә, стиле дә, теле дә мавыктыра. Менә бер генә өзек:— әйе, Камран, күзен йомды исә, аны тач шушы хәлендә күз алдына китерә иде. Ә менә хәзер аның каршында, бу кызның алты ел буена хыял итеп йөргән сурәте түгел, ә чын Фәридә үзе басып тора. Кәмран исәнгерәп чайкалып китте, матур төшеннән аерыласы килмәгәндәй бер мәл күзен йомып торды, аннары нәрсәгә сөялим икән дигән төсле каушабрак тирә-ягына каранды.

Моны үз телебездә язылган өзек дип кенә кабул итеп була: тәрҗемәлекнең эзе дә юк.

Тәрҗемәченең тел белүе (татар телен генә күздә тотам), аның бөтен нечкәлекләрен хәтерендә саклавы, яхшыны начардан, кирәклене кирәксездән, зарарлыны файдалыдан аера алу сәләте һәм шуның өстенә төп теоретик фикерләрдән хәбәрдар булуы бәләкәй нәрсә түгел, билгеле. Әмма тәрҗемәчегә болар гына җитми икән әле. Моның өчен тагын ихтыяр ныклыгы, карашларыңны якларга-сакларга һәм исбатларга әзер тору, ягъни билгеле бер дәрәҗәдә сугышчан принципиальлек сыйфаты да кирәк икән. Хәзерге заман китабы дөньяга чыкканчы шактый озын, катлаулы юл үтә. Мәсәлән, ул тәрҗемәчедән рецензент кулына барып керә. Дөньядагы бар гыйлемне дә, мәгълүматны да белеп бетереп булмый, син бер өлкәне яхшырак белсәң, рецензент икенчесен тирәнрәк белергә мөмкин. Кыскасы, рецензияләүче кешенең ярдәме тими калмый. Килешмәүләр килеп чыккалый: кем нинди күзлектән карый. Мәсәлән, Таһир болай ди:— юк, Фәридә ханым, бу төннән соң таң атмасын беләм мин. Рецензент болай тәкъдим итә:— бу төннең кабатланмасын беләм мин... Әмма рецензент вариантында мәгънә генә кала, ә тәрҗемәче вариантында сөйләүченең рухи халәтен дөрес чагылдырган сурәтләү дә бар. Китапта бу җөмлә шулай калган да. Таһир варианты:— ес-башы иптәшләренеке шикелле булса да, ул килеш-кыяфәте белән — аерылып тора. Рецензент тәкъдиме:— килеш-кыяфәт — шул ук ес-баш ич инде. Соңгы вариант төгәлсезрәк. Китапта дөресе калган. Тәрҗемәне русча текст белән чагыштырып баручы рецензент болай ди:— әллә нилләр сөйлисең. Ә китапта болай басылган:— шул да сүз булдымы инде, Фәридә? Бу очракта мәгънә аермасы күренми. Бәлки, Таһир оригиналдан читкәрәк киткәндер (бу урынын оригиналдан карамагач, бәхәсне хәл итә алмыйм), әмма шунысы ачык: китаптагы вариант тәрҗемәнең дә, оригиналның да гомуми рухына ятыша, яраша. Димәк, ахыр чиктә бу очракта да тәрҗемәче хаклы. Чибәр хатынга егет бер урында «фәрештәм» ди, рецензент моны «гүзәлем» дип төзәтергә тәкъдим ясаган. Әмма бу очракта безнең тел Таһир биргән форманы күбрәк куллана. Оригиналы да шулай — melegim дип бирелгән. Китапның утыз тугызынчы битендәге «я аның җаны, я минеке» дигән җөмләне рецензент алып ташларга тәкъдим иткән. Эш оригиналда ja onı, ja kendimi дигән фраза торуында гына түгел. Беренчедән, тәрҗемәченең варианты чыннан да вакыйгалар барышын дөрес, төгәл чагылдыра, икенчедән, оригиналны кулда тотып торганда үз вариантыңны яклавы җиңелрәк. Илле тугызынчы биттә «сумкалы әмрикән кызлары кебек фырт кына пароходка менеп утырсам икән. Ялгыз башым гына диюем. Ләкин тәтәмнәр (апамнар) бу теләгемә аһ орып каршы төштеләр» дигән урын бар. Рецензент шуның уртадагы җөмләсен төшерергә кушкан. Ислам дине хөкем сөргән дөнья өчен кызның бер башы, ялгызы гына юлга — сәяхәткә чыгуы табигый түгеллекне аңлаткан җөмлә бу, шуңа күрә дә Таһир оригиналның kendi kendimi (үз алдыма, үзем генә) дигән сүзләрен дә дәлил итеп бик урынлы китергән. Димәк, рецензент белән ике арада фикер башкалыклары килеп чыкканда тәрҗемәче турыдан-туры төрекчә оригиналга да мөрәҗәгать итеп, бик откан. Рецензент нык булышкан, әлбәттә. Тик бу урында сүз ул хакта бармый, ә аның фикер-карашларында ихтимал булган төгәлсезлекләрне бергәләп бетерү турында сүз бара.

Китапның ахырында җыйнак кына «Соңгы сүз» бирелгән. Бусы инде оригиналда юк, тәрҗемәче өстәмәсе. Май бутканы

бозмаган — бик урынлы, кирәк булып чыккан бу соңгы сүз. Чөнки китапны укып чыккач та аннан тиз генә аерыласы килми. Шунда инде тәрҗемәченең үз иҗаты ярдәмгә килә.

Бездә тәрҗемәчеләр еш кына рус теленең бик күп сүзләрен шул килеш кенә, тәрҗемәләмичә, татар сүзе белән алыштырмыйча гына алалар. Фразаларны кисәге-кисәге белән калькалаган тәрҗемәләр дә бик күп. Бу соңгысы аеруча зарарлы, чөнки ул тыштан-өстән караганда татарча булып күренеп, телне бозуга китерә, һәр хәлдә, гарипли. Әз-мәз генә булса да, бу күренеш танылган тәрҗемәчеләр телендә дә хас, профессиональ язучыларыбыз, шагыйрьләребез эшләгән тәрҗемәләрдә дә шул ук дәрәҗәдә очрый. Бу яктан Таһирга тел тидерерлек түгел. Тик ул икенче чиккә ташланган: гомуми кулланыш сүзләре, формалары урынына ул искергән, диалекталь, гади сөйләм элементларын артык еш кулланган. Хәтта бөтенләй аңлашылмый торган сүзләр дә бар: рушдия, тәәссеф һ. б. Тәрҗемәченең кайбер сүзләре хәзерге буын укучысы өчен бик авырдан аңлашыла торганнар: бәхтияр, мөрәббия һ. б. Бу тип сүзләр, мәсәлән, Тукай томнарында да тәрҗемә белән бирелгәннәр. Искергән формалар да очрый: җавабән; реверанс кылу; язып утырмактамын; саф һавалы хәятны кичермешем һ. б. Татар телендә «укыну» сүзе бар, әмма «әбигә кычкырып китап укыну» юк. Китапта шундый бер-ике урын бар:— моңлы көйләр сызгырына;— ат тып-тып җиргә тибенеп тора. Бу күренешне теп оригиналга якынаерга тырышу дип карау дөрес түгел: телебездә үз чараларыбыз булмаганда гына оригинал сүзләрен, тәгъбирләрен һәм формаларын күчереп утырту кабул ителгән.

Диалекталь сүзләр, тәгъбирләрнең урынсыз кулланылу очраклары да бар: тәү, тәүге, кусә, карый заман, карый хатын һ. б. Бу төр кимчелекләрнең шактый өлешен рецензент та күрсәткән, алар өлешчә төзәтелгәннәр дә, шулай да Таһир таякны үз ягынарак бөккән. Рецензент укыган кулъязмада «ул йоклаган булып утыра утыра да кисәк чагасын батырып куя», «ул сурәбәтнең ни гаебе булсын» өзекләрендәге аңлаешсыз яки авыр аңлашыла торган сүзләрнең астына сызып сорау куелган булган, тик Таһир моңа колак салмаган.

Тәрҗемә дөньясындагы хезмәт бүленешендә Таһир үз урынын, өлкәсен һәм стилен табып, үз теле белән әдәбиятка керә. Аның бу теле-стилендә әз-мәз тәгәлсезлекләр бар, әлбәттә. Әмма моны бер тәрҗемәченең кимчелеге генә дип булмый. Бу күренеш хәреф ятлаучылыктан икенче чиккә — иркле тәрҗемәгә күчүнең бер чагылышы булса кирәк. Чөнки матур әдәбиятта иркле тәрҗемә хәреф ятлаучылыктан күп яхшырак. Бу очракта да чик бар, билгеле. Тел остасы дигән исемне күтәргән яки күтәрергә алынучы кеше бу чикне үзе белер инде. Кыскасы, һәр чорның үз үсеш дәрәҗәсе булган кебек, шуңа ярашлы үз теориясе дә була. Әйтик, илленче елларда нигездә төгәл тәрҗемә мөмкинме-түгелме дигән мәсьәлә хәл ителде. С. Фәйзуллинның әлеге китабы, беренче чиратта, шуңа багышланган. Ул чорда мәсьәләне гомумән карау зарур иде. Ә бүгенге көннең үз дәрәҗәсе бар. һәм шушы дәрәҗәне чагылдырган бүгенге теория — практика өлкәсендәге хезмәт бүленешен чагылдырган тәрҗемә теориясе кирәк. Шул хакта сүз алып барыр вакыт җитте. Әйтик, прозачылар, дәреслекчеләр, сатириклар, өченче телдән тәрҗемә итүчеләр һ. б. ш. аерым-аерым җыелышып янәә гомуми очрашуда шушы хосусый мәсьәләләрне куеп шул хакта фикер алышу оештырганда, эшкә файда булмас идемени?!

Татарча язылган әдәбият белән тәрҗемәләнгән әдәбиятның күләмен чагыштырып караучылар бардыр, әлбәттә (бу очракта мин гомуми матбугат продукциясен күздә тотам). Ә минә шушы ике төр әдәбиятка бирелгән игътибарның күләмен чагыштырып карасаң... тәрҗемәгә игътибар бөтенләй бирелми икәнлеге күренә. Кыскасы, чын мәгънәдә югары тәрҗемә культурасы турында сөйләр вакыт җитте.

**Г. АХУНҖАНОВ**

Вәли Хангилдин

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ИСЕМ-ФАМИЛИЯЛӘРЕ

Исем-фамилияләр телдәге сүзлек хәзинәсенең бер өлешен яки тармакчыгын тәшкил итәләр. Һәр милли телдә иң зур урынны шул тел коллективына тарихи бирелгән, үзенә хас исем-фамилияләр биләп тора. Татар телендә дә ул шулай. Шуңа күрә, тел культурасы турында мәсьәлә күтәрелгәндә, сүзлек хәзинәбезнең бу тармагына бөтенләй кагылмый үтү, һичшиксез, ярамас иде. Чөнки бу өлкәдә дә безнең мәдәниләштерелергә тиешле моментларыбыз байтак.

Беренчедән, төрле үзгәрешләр аркасында, халкыбызның исем-фамилияләре үзләренең борынгы җирле чыганакларыннан һәм төзелү үзенчәлекләреннән аерылганнар. Безнең исемнәр бакчабызда инде кайчандыр киң урын тоткан Тимеркәй, Мәргән, Айбулат, Бикбулат, Идегәй, Байгилде, Көнсылу, Абыз, Абызгилде, Акчура, Байчура, Ташбулат, Ишбулат, Бикташ, Айдар, Миңлекәй, Бикә, Миңсылу, Илче, Бүләк кебек исемнәр юк диярлек. Мондыйларның кайберләре фамилияләрдә генә сакланган. [Булатов, Бикбулатов, Хангилдин, Акчурин, Абызгилдин, Ишбулатов, Ишбүләков, Ишбулдин, Байчурин һ. б.]

Икенчедән, яшәү тарихының төрле чорларында халкыбыз бүтән дәүләтләр һәм халыклар белән экономик, политик һәм культура бәйләнешләренә керә. Шул процесста безнең исем-фамилияләребез өлкәсендә дә зур үзгәрешләр килеп чыга. Тел бүтән ил халыклары, бүтән тел коллективларына хас исем һәм фамилияләр белән чуарлана башлый.

Мәгълүм булганча, Урта һәм Түбән Иделдә яшәгән төрки халыкларга — тарихта болгар исеме белән танылган, соңгы чорларда татар исеме алган халыкларга — ислам дине IX йөзләрдә керә. Бу вакыйга, заманнар үтү белән, әлеге халыкларның идеологияләренә генә түгел, бәлки көнкүреш һәм гореф-гадәтләренә, хәтта исемнәренә дә зур йогынты ясый. Дин башлыклары халыкның кулланылыштагы үз-тума исемнәрен гарәп исемнәре белән алмаштыра башлыйлар һәм шул хәрәкәтне өзлексез җәелдерә баралар. Нәтиҗәдә Гали, Госман, Әбүбәкер, Зөләйха, Шәриф, Шәрифә, Кәрим, Кәримә, Габдулла, Хәйрулла, Вәлиулла, Гайнетдин, Шәмсетдин, Хөснетдин, Галләметдин, Габдрахман, Габдрәхим, Габделхак, Хөрмәткамал, Шәмсенур, Хәмзә, Закир, Зәкәрия, Мәхмүт, Мәхмүдә кебек йөзләрчә яңа исемнәр пәйда була.

Алтын Урда, Болгар дәүләтләре һәм Казан ханлыгы чорларында әлеге процесс көчәйгәннән-көчәя бара. Дин башлыклары балаларга гарәпчә исем кушуны берьюлы үз кулларына алалар һәм аны дини гадәткә әйләндереп җибәрәләр. Бу чорларда иранлылар белән алыш-биреш һәм шул ук ислам дине буенча бәйләнеш тыгызлану сәбәпле, безгә фарсыча кеше исемнәре тагыла башлый [Гәрәй, Сәхибгәрәй, Җиһан, Җиһанша, Шаһгали, Гөлнар, Гөлчәһрә, Абруй, Диләрә, Дилбәр һ. б.].

Дәүләтнең Урта Азия белән бәйләнеше көчәю барышында шундагы кайбер илләргә, шәһәрләргә, башлыча Бохарага барган татар сәүдәгәрләре, укырга барган татар шәкертләре, мәдәниләр аннан «җан» сүзе өстәлгән гарәпчә исемнәр алып кайталар. Татар теленә Рәхимҗан, Газыйҗан, Сабирҗан, Габдуллаҗан, Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Җиһандар, Миһран, Рушан, Маһира,

Бәһрам, Ростәм, Шаһзадә кебек исемнәр өстәлә.

Соңгырак заманда, аеруча XIX йөзнең актыккы мизгелендә һәм XX йөзнең баштагы ун елларында, татар халкының Төркия белән турыдан-туры культура бәйләнешләре көчәю, татар яшьләренең бер өлеше шунда уку, шул ук ил белән әдәбият һәм вакытлы матбугат алмашу хәрәкәтләре киңәю аркасында, безгә шул ук гарәп исемнәренең төрекләштерелгән вариантлары да килеп керде: Рифгат, Шәүкәт, Тәлгат, Җәүдәт, Рәмзия, Рәшат, Шамил, Наил, Назыйм, Фоат, Мидхәт, Әнвәр, Фәридә, Халидә, Хәмидә һ. б.

Мөселман татарлары совет чорына чаклы рус халкына һәм Көнбатыш Европа халыкларына хасрак исемнәрне кабул итмәделәр. Моңа, һичшиксез, ул чактагы дини, милли аерымлану һәм шул юллардагы көчле пропаганда нәтиҗәләре комачаулагандыр. Совет чорында андый тоткарлыклар бетерелде. Шунлыктан татар халкының исемнәре рус һәм Көнбатыш Европа халыкларына хасрак исемнәр исәбенә дә арту мөмкинлеге алды. Бүгенге көндә инде татар балалары һәм татар яшьләре арасында Альфред, Эдуард, Луиза, Римма, Вира, Венера, Долорис, Рафаил, Роза, Фидел кебек күп төрле милли чыганакларга барып тоташа торган исемнәрне еш иштергә туры килә. Керәшен татарларында исә иң зур урынны рус исемнәре били.

Әнә шулай, татар халкының бүгенге исемнәр бакчасы әллә никадәрле аерым милли чыганаклардан алынган кырык корамадан тора. Фамилияләребез дә үзләренең чыганаклары ягыннан шулай ук чуар, чөнки алар шул ук исемнәрдән ясалганнар. Шуның белән бергә, фамилияләрнең бик борынгы исемнәргә нигезләнгәннәре дә бүгенге көндә әле шактый җанлы һәм киң кулланыла.

Чыганакларының шундый күп төрлелеге исем-фамилияләребезнең фонетик һәм грамматик төзелешләрендә дә иксез-чиксез төрлелекләргә сәбәп булган. Чөнки аларның зур күпчелеге татар теленең үз эчке законнарына я бер дә буйсынмаган, яки аңа өлешчә генә буйсынган. Мондый хәл әдәби телебездә аларның төзелеш, әйтелеш һәм язылышларын бердәмрәк кагыйдәләр астына алып нормалаштыру эшен бик нык читенләштерә. Шунлыктан безнең әдәби телебез бүгенге көндә дә исем-фамилияләребезне куллану практикасында гаять күп киреәксез чуарлыклар, бер ук исем-фамилияләрнең төрлечә әйтелеш һәм язылышлары белән җәфалана. Менә аның бездәге кайбер мисаллары: Әхмәтҗан-Әхметзян-Ахметзян, Рауза-Роза, Габдулла-Абдулла-Аптулла-Гаптулла, Җәппаров-Җаппаров-Җапбаров-Яппаров-Яббаров, Гомәр-Гүмер-Омар, Рәҗәпова-Разяпова-Раджапова, Һаҗәр-Хаҗәр-Хазяр, Җәләлетдин-Җәлалетдин-Залялетдин-Джалялетдин, Шәриф Кәмал, Шәриф Камал, Ш. Кьамал, Һади Такташ, Хади Такташ (мисаллар телебезнең сөйләмә һәм язма төрләреннән алынып тупланды).

Күренә ки, монда аеруча фонетик чуарлык зур. Хәлбуки, исем-фамилияләребез өлкәсендәге әйтелеш һәм язылыш бердәмлеге әдәби телнең үз төзеклеге өчен генә түгел, ул халкыбызның көндәлек аралашуында, бигрәк тә, рәсми эшләр һәм аңлашулар барышында дөреслек, ачыклык һәм төгәллекне тәэмин итү өчен әһәмиятле. Әдәби телләре нормалашкан халыкларның исем-фамилияләре исә әйтелеш һәм язылыш бердәмлегенә шактый ирешкән була. Мәсәлән, рус халкының исем-фамилияләренә карата ул яктан зарланмыйлар.

Дөрес, татар телендәге исем-фамилияләр арасында фонетик үзгәрешләргә тиз генә бирелми торганнары да күп. Шамил-Шамилә, Дамир-Дамирә, Закир-Закирә, Наил-Наилә, Равил-Равилә, Шакир-Шакирә, Айсылу, Азат, Марат, Илдар, Илдус, Кузай, Надир, Самит, Тукай, Алпар, Алма, Муса, Сандугач, Нур, Нурия кебекләр әнә шундыйлар. Ләкин ата-ана һәм аларның якыннары, балага исем сайлаганда, ул исемнең фонетик һәм грамматик төзелеш якларыннан тотрыклы булуыннан бигрәк, аның нинди дә булса эчке мөнәсәбәт, бәйләнеш якларыннан үзләренә ошавын: яраклылыгын, ягымлылыгын, сөйкемлелеген күз алдында тоталар. Элек-электән үк ул шулай килгән. Исемнәр я баланы чолгаган табигать, җәмгыять күренешләрен яки аның шуларга билгеле мөнәсәбәтен, яки, киресенчә, баланың үзенең башкаларга юнәлтелергә тиешле мөнәсәбәтен чагылдырырга тиеш булган. Татар халкының да кайчандыр кулланылган һәм бүген дә кулланылыштагы исемнәре, һичшиксез, әнә шундый карашлардан чыгып сайланган. Алай гына да түгел, татар халкы хәтта бүтән халыкларга хасрак исемнәрне үзләренә күчергәндә дә аларны үзләренең яки үз заманындагы идеологиянең кушуынча яраклылык карашыннан чыгып сайлаган. Төзе-

леш ягыннан аларның бик катлаулылары, авыр әйтелешлеләре дә күп. Мәсәлән: Габделәтыйф, Зәйрелбәнат, Сәйфелмөлек, Хисаметдин, Гайнелбәян, Хәлбетдин, Мөхәммәтрәхим, Габделгалләм, Фәтхелислам, Гыйззелбәнат, Зәйнелбәнат, Гобәйдулла, Зәйнелгабидин һ. б.

Ләкин, шуңа да карамастан, ислам дине җитәкчеләре һәм гарәп телен белүчеләр андый исемнәрне халык арасында таратуны өзлексез дәвам иттергәннәр. Киң халык массасы исә ул чакта әле алардагы яраксыз моментларны бөтенләй аңламаган. Укымышлылар арасында да аны сизүчеләр һәм аңа игътибар итүчеләр бик аз булган. Шуларның берсе — һәм ихтимал беренчеседер — Г. Тукай. Ул гарәпчә кеше исемнәренең саф дини мәгънә аңлата торганнарын һәм катлаулы төзелештәгеләрен кулланылуны бик каты гаепләгән. «Исемнәребез хакында» дип аталган бер мәкаләсендә ул, шундый исемнәр турында байтак фикер йөрткәннән соң, менә мондый нәтиҗәгә килүен яза: «Безгә тугач та үзебезгә мөстәкыйльлә бер адәм булырга исем җәһәтеннән юк юл калдырылмый:

Без — Габдулла, ягъни ниндидер бер алла колы.

Без — Гобәйдулла, ягъни ниндидер ходай колчыгы.

Без — Гыйбадулла, ягъни ниндидер алла коллары.

Без — Әхмәдулла, ягъни алланың бер Әхмәте.

Без — Рәхмәтулла, ягъни алланың бер мәрхүме.

Менә бу ямьсез, мәгънәсез, тозсыз мөрәккәб[1] исемнәр — һәммәсе дә безнең диндар... хәзрәтләребез хезмәте!»[2]

Аңлашыла ки, Г. Тукай гарәп халкы исемнәреннән бөтенләй баш тарту мәсьәләсен куймаган, бары тик аларның яраксыз мәгънә белдерә торган кушма төрләрен генә яратмаган ул. Чыннан да, кушма төрдәге гарәп исемнәренең иң зур күпчелеге кешеләрне я ислам диненә, яки аллага бәйләп куя. Аларның Мифтахетдин, Имаметдин, Габделхаликъ, Габделрәхим, Байнулла кебек «дин» сүзе, алла исемнәре ялганып төзелгәннәрнең һәммәсе дә диярлек әнә шундыйлар. Балага исем сайлаганда, аның мәгънә ягыннан яраклылыгына игътибар итү күптәннән килә. Ләкин күп ата-аналар, гарәпчә кеше исемнәренең мәгънәсен аңламаганлыктан, ул эшне, күбесенчә, муллаларга тапшыралар иде.

Балага исем сайлау белән һәрбер халык бик ерак заманнардан бирле шөгыльләнгән булырга охшый. Хәтта шул мөнәсәбәт белән кайбер халыкларда зур-зур мәрасимнәр — туйлар, мәҗлесләр, бәйрәмнәр оештыру гадәте дә булган һәм хәзер дә ул бар. Шуның белән бергә, кеше исемнәренең килеп чыгу, үрчү һәм таралу юлларында халыкара уртак моментлар да күп булырга кирәк. Безнең бу мәсьәлә өстендә аз-маз гына күзәтү һәм уйлануларыбыз да шундый нәтиҗәгә китерде. Мәсәлән, миңа күп кенә төрки халыкларда кулланыла торган кеше исемнәренең байтагы мәгълүм. Аларның чыганаклары бездәгечә үк диярлек. Ләкин үзтума исемнәр аларның кайберләрендә күбрәк һәм ныграк сакланган. Хаслап әйткәндә, миңа танышрак булган башкорт, казакъ һәм кыргыз телләрендә болар күбрәк. Шулар йөзендә күп кенә исемнәрнең килеп чыгу юллары һәм андагы уртак моментлар да беркадәр билгеләнергә, хәтта ачыкланырга мөмкин. Мәсәлән, башкортта Ходайбирдин фамилиясе, кыргызда Кодай бирген [Ходай биргән], Алла бирген [Алла биргән] кебек исемнәр татардагыдан фонетик төзелешләре белән генә беркадәр аерылалар. Мәгънәләре исә бер үк.

* * *

Кешеләр, гадәттә һәм күбесенчә, үз исемнәре белән генә аталып йөртеләләр. Шуның белән бергә, бер үк исемдәге кешеләрне бер-береннән аерып билгеләү яки кешегә хөрмәт күрсәтү өчен, аларның үз исемнәрен «ата» исемнәре белән бәйләп куллану да бар. Бу форма рус телендә ата исемнәренә «вич» һәм «на» кушымчалары ялганып ясала. Үзара мөгамәлә һәм аңлашу процессында ул формаларның боларда ике төрле әһәмияте бар: бер үк исемдәге кешеләрне аерып аныклау һәм эндәшелгән кешегә карата хөрмәт, үзендә исә әдәплелек күрсәтү. Рус интеллигенциясенең әдәби тел практикасында бу формалар аеруча әнә шул соңгы функцияләрендә яки шундый мәгънә төсмерләре белән урнашкан.

Татар халкы исә соңгы чорга чаклы бары тик аралаша торган кешеләре арасында бер үк исемле кеше икәү яки берничә булганда гына ата исеме өстәлгән форма кулланырга мәҗбүр була иде. Мондый очракта ул ике төрле синтаксик төзелмә куллана: 1] ата исеменә үз исеме

[1] Мөрәккәб — катлаулы, кушма.
[2] Г. Тукай. Әсәрләр. IV том. 1956 ел. 96 бит.

тагылган тезелмә. Мәсәлән: Муса Гомәре, Шәйбәк Гомәре һ. б. 2) үз исеменә өстәлгән ата исеменә, «улы, кызы» дигән сүзләрнең берсе ялганган тезелмә. Мәсәлән: Гомәр Муса улы, Гомәр Шәйбәк улы, Хәят Гыйлман кызы, Маһирә Солтангали кызы һ. б. Ләкин ул ике тезелмәнең беренчесе, нилектәндер, әдәби телебезгә бөтенләй кертелмәгән. Икенчесе исә телнең язма төрендә шактый актив кулланыла. Кыскасы, татар телендә дә кешеләрне ата исеме катнашында төзелгән исемнәр белән атау, исемләү булган һәм ул бүгенге көндә дә теге я бу күләмдә кулланыла. Ләкин ул ике төрнең берсе бездә дә бер үк исемдәге кешеләрне аерып билгеләүдән башка функция үтәми. Аларда эндәшелгән кешегә карата хөрмәт күрсәтү һәм әдәплелек төсмерләре дә сиземләнми.

Ләкин әдәби телдә моның да әһәмияте зур. Шуңа күрә татар халкы, кешеләргә эндәшкәндә, мөрәҗәгать иткәндә һәм гомумән алар белән аралашканда, исемнәрнең шундый ягымлы мәгънә төсмере белдерә алуы белән дә күптән үк кызыксынган, һәм ул шуңа лаеклы исем тезелмәләрен дә тудырган. Әмма бу форманың төзелеше монда бик үзенчәлекле. Болар ата исеме катнашында түгел, бәлки кешенең үз исеменә аны олылау, хөрмәтләүне яки якын күрүне белдерә торган аерым сүз өстәү юлы белән төзелгәннәр. Мондый өстәмәләрнең бүген дә киң файдаланыла торганнары менә болар: абый-абзый, апа-апай, ага-агай, ханым, туташ, туган, иптәш сүзләре. Мәсәлән: Вәли абый, Җәләй ага, Гөлсем ханым, Мәрьям апа, Галия туташ, Хәсән иптәш һ. б. Бу форма татар телендәге сөйләмнең һәрбер төрендә (әдәби, әдәби түгел, язма һәм сөйләм төрләрендә) гаять киң кулланылып килде. Мәсәлән: сүз Габделхәй агага бирелә (җыелыш сөйләме); Риза абый кызыклы гына тәкъдимнәр ясады (кулуарда сөйләшүчеләр теленнән); Вәли абыйга минем бер соравым бар (сектор утырышында); Зәйнәп апа күп кенә тарихи әһәмиятле әсәрләр белән таныш икән (доклад тыңлаучылар сөйләменнән).

Шуның белән бергә, икенче яктан, соңгы елларда татар әдәби телендә күптән урнашкан ул формалар белән генә чикләнмичә, шул ук хөрмәт күрсәтү, олылау максаты белән, рус телендәгечә, кешенең үз исеменә өстәлгән ата исеменә «ич», «на» кушымчалары ялганган форманы кабул итерү практикасы куллану да бар.

Кыскасы, югарыда сөйләнелгәннәр һәм китерелгән мисаллар нигезендә, кешеләрне аныклап күрсәтү һәм хөрмәтләү төшенчәләрен чагылдырылган исемнәр сайлау буенча безнең тел практикабызда зур төрлелек, хәтта беркадәр тәртипсезлек тә яшәп килү фактлары ачыла. Халкыбызның киң сөйләү телендә ул факт ике төрдә, вакытлы матбугатта һәм эш кәгазьләрендә бер генә төрдә, киң әдәби һәм әдәби түгел сөйләмнәрдә тагын үзенә башка, ягъни татарча да, русча да йөртелә икән. Билгеле, әдәби тел гомумән, бүгенге көндә аеруча, андый чуарлык белән килешеп торырга тиеш түгел. Мәсьәлә фәнни планда тирәнтен өйрәнелергә һәм шул нигездә мондагы ул төрлелекләр дә максатка лаеклы тәртипкә китерелергә тиеш. Ләкин бу эш бик җитди карашлардан чыгып башкарылуны таләп итә. Дөрес, ул төрлелекләрнең сөйләү-сөйләшү телендә генә торып калган беренче вариантын әдәби телгә үрләтүне яклаучылар табылмавы мөмкин. Шуннан башкалары бит әле сөйләү телендә һәм әдәби телебезнең бер (язма) яки ике терендә дә (язма һәм сөйләмдә) шактый киң кулланылалар. Боларның берсен дә берьюлы гына гамәлдән чыгаруны кагыйдәләштереп булмас. Вакытлы матбугат һәм матур әдәбият практикасында «ич», «на» кушымчалары белән ясалган төрләргә әле зур урын бирелмәсә дә, әдәби стильнең һәрбер төренә боларның да әкренләп һаман үрмәли барганлыгы ачык сизелә. Бу факт та матбугат һәм әдәбият практикабызда ачык чагыла.

Моңа хәтле мин фамилияләребез турында аерым рәвештә тукталмадым, аларның исемнәребез белән бертөрле яки уртак моментларын күрсәтү белән генә чикләндем. Чынында исә бу мәсьәлә алай гына ачылып бетми, фамилияләребезнең үзләренә генә хас кайбер фактлары да күз алдына китерелергә тиеш. Чөнки, гадәттә, фамилия куллanудагы ялгышларыбызның бер өлеше шул фактларны белмәү яки тиешенчә аңлап җитмәү белән бәйләнгән була.

Мин монда татарларның фамилия куллану буенча иң борынгы тарих башын эзләргә керешмим. Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылганнан соң исә, халкыбыз рәсми эшләрдә, язмаларда фамилия йөртергә тиеш булган, һәм бара торгач шул безнең гадәткә кергән, кайбер төркемнәр аны үзара мөгамәләдә дә йөртү юлын тотканнар.

Безнең фамилия формаларыбыз тел чыганаклары ягыннан өч төркемгә аерыла: гарәп, рус һәм татар формалары. Гарәп теле формасы исемнәребезгә ый-и кушымчасы, рус теле формалары ов-ев, ова-ева, ин-ина кушымчалары ялгану юлы белән ясалалар. Полякча ский-ская кушымчасы ялганып ясалган фамилияләр дә күренгәли. Бөтенләй кушымчасыз фамилия ролендә йөртелгән исемнәр дә бар. Мисаллар: Х. Хәйри, М. Гафури, Х. Бәдигый, Г. Камал, С. Сүнчәләй, Г. Кашшаф һ. б.

Билгеле, кешегә үзенең фамилиясен ясау өчен ул формаларның тегесен я бусын сайлау турында боерык та, кагыйдә дә бирелә алмый, чөнки ул аның үз эше. Ләкин татарча сөйләмдә гадәткә кертелгән һәм рәсми кабул ителгән форманы яки формаларны үзгәртмичә куллану һәркемнән таләп ителергә тиеш. Бу сызыкта бердәмлекне сакламау очраклары әле бездә күренгәли. Кайберәүләр кушымчалы һәм кушымчасыз формаларның икесен дә йөртәләр яки ов-ев, ова-ева кушымчаларының калын, нечкә төрләрен ялгауда тотрыксызлык күрсәтәләр. Рөстәмов-Рөстәмев, Ямашова-Ямашева, Тумашова-Тумашева-Тумашева. Шулай ук, сирәк булса да, ый-и кушымчасын ике вариантта куллануны саташтыру очрагы да юк түгел: Бәдигый, Насыйри, Мәүла Колый урынына Бәдиги, Насыри, Мәүля Коли дип йөртүчеләр бар.

Бу исә, үз нәүбәтендә, фамилия формалары куллануардагы шундый чуарлыкларны бетерү юлында да чара күрелергә тиешлекне искә төшерә. Болар да беркадәр кагыйдәләштерелүгә, һичшиксез, мохтаҗ. Кагыйдәгә бирелмәгән чыгармалар исә сүзлеккә кертелергә тиеш булыр.

Без монда татар халкының исем-фамилияләре өлкәсендә аларның туу, үрчү һәм кулланылу төрлелекләрен һәм аларның фәнни тикшерү иләгеннән үткәрелеп сайланырга тиешлеген әйттек. Шул юл белән исем-фамилия куллануны әдәби нормалар астына алу мөмкинлеген дә искәрттек. Ләкин моңа чаклы бу юлдагы эш әле бездә исем-фамилияләребезнең язылышларын беркадәр тәртипкә китерү буенча исемлекләр төзү, фәнни нигезләре булмаган кайбер кагыйдәләр тәкъдим итүдән узганы юк. Дөрес, аларның исемлеге дә, һичшиксез, кирәк. Ул гына түгел, хәтта аларның тулы сүзлеге дә булырга тиеш. Шунсыз бу мәсьәлә хәл ителә алмаячак. Ләкин сүзлектә аларның язылу үрнәкләре генә түгел, бәлки әдәби әйтелеш вариантлары да бирелергә тиеш. Моның өчен исә сүзлеккә кертелгән һәрбер исем һәм фамилиянең лексик-семантик, фонетик-акустик һ. б. яклардан нык тикшерелгән булуы шарт. Шунсыз мондый белешмәлек яки ярдәмлек киң җәмәгатьчелекне канәгатьләндерә алмаячак. Безнең фикеребезчә, исем-фамилияләребезнең язылу үрнәкләре яки бердәм язылышлары һәм әдәби әйтелеш вариантлары менә мондый нигезләрдән чыгып билгеләнергә тиеш:

1. Аларның үз әдәби телебездә (язма һәм сөйләм төрләрдә) кулланылырга тиешле вариантларын билгеләү. Мәсәлән: «Әхмәтҗан, Ахметҗан, Ахметзян, Ахметзан, Ахметжан» рәвешләрендә йөртелә торган төрләрнең әдәби сөйләмдә һәркем тарафыннан кулланылырга (язылырга, әйтелергә) тиешле вариантларын ачыклау.

2. Исем-фамилияләребезнең рус әдәби телендә йөртелергә тиешле вариантларын билгеләү. Монда инде аларның язылырга тиешле үрнәкләре генә билгеләнә.

Бу пунктларда күздә тотылган эшләр җентекле һәм дәвамлы күзәтү, фәнни тикшеренү шөгыльләре сорый. Монда һәрбер исем-фамилия, безнең уебызча, менә мондый якларыннан каралырга, өйрәнелергә тиеш: 1) тоташларынча калын я нечкә әйтелүләре ягыннан; 2) калын, нечкә авазлар һәм иҗекләр аралаш төзелгән булулар ягыннан; 3) гади һәм кушма төзелешләрдә булулары ягыннан; 4) шул өч төрдә төзелүләре буенча татар телендәге кушымчаларның калын һәм нечкә төрләренең кайсын кабул итүләре ягыннан.

3. Халыкара уртак кулланылырга тиешле исем-фамилияләребезнең бердәм вариантларын билгеләү. Бу соңгы пунктны гамәлгә ашыру җиңел булыр. Рус әдәби телендә андый исем-фамилияләрнең әзер вариантлары бар. Шулар безгә дә ярый.

Исем-фамилияләребез өстендә әнә шундый җентекле анализ үткәрү, һичшиксез, аларның әйтелеш яки язылышларын беркадәр нормалаштырырга, кагыйдәләштерергә мөмкинлек тудырыр иде. Никлы кагыйдәләр астына алырга мөмкин булганнары турыдан-туры сүзлеккә кертелерләр иде. Нәтиҗәдә, сүзлек хәзинәбезнең бу тармагы да билгеле әдәби нормалар юлына аяк басар һәм мондый эш гомуми культурабызга кертелгән әһәмиятле бер өлеш тә булыр иде.

Срур Сүнчәләй

# УЕННАР

*Борынгы авыл яшьләренең күңел ачулары*

## Кечкенә кереш

Халкыбызның борынгы этнографик хәзинәсеннән алып без инде бер-ике материал бастырган идек: «Каргалыда татар туе» («Казан утлары» журналы. 5 сан. 1967 ел) һәм «Борынгы авылларда өмәләр» («Азат хатын» журналы. 9 сан. 1969 ел). Хәзер тәкъдим ителә торган «Уеннар» да шул ук Башкортстандагы Яңа Каргалы авылы тормышыннан алынып язылды. (Элек аны Бәләбәй Каргалысы дип йөртәләр иде.) Мин үзем шул авылдан чыккан бер кеше булганга күрә, андагы гореф-гадәтләрне, йолаларны яхшы беләм һәм хәтеремдә дә алар яхшы сакланган. Ләкин биредә язылганнар — хәтердә сакланган нәрсәләр генә түгел. Элек-электән үк мин авылыбызның этнографиясе һәм фольклоры белән кызыксына килдем, шулар буенча әкренләп материал да тупладым. Кыскасы, югарыда телгә алынган «Каргалыда татар туе» белән «Борынгы авылларда өмәләр»не дә һәм менә бу «Уеннар»ны да минем тарафтан әнә шулай җыелып, өйрәнелеп язылган бер хезмәт дип карарга кирәк.

Дөрес, бездә халык иҗаты турында язылган зур һәм төпле хезмәтләр шактый күп, мин аларны аерым-аерым санап тормыйм. Чөнки һәркемгә билгеле алар. Тик минем бу тәкъдим иткәнем әнә шул зур хезмәтләргә кечкенә генә бер өлеш булып өстәлер дигән өметтә калам.

Авыл кешесенең хезмәте — иген игү һәм мал карау — борын заманнардан ук ел фасыллары белән нык бәйләнгән булуын һәркем белә. Тик биредә шуны гына өстәп әйтәсе килә, элегрәк заманда авыл кешеләре елның төрле вакытларын да хезмәткә бәйләп, сабан өсте, чәчү өсте, печән өсте, урак өсте дип йөртәләр иде. Шулай ук тәүлекнең төрле вакытын да сәгать белән билгеләмичә (элек аның сәгате дә булмаган), йолдызларга, таң атуга, кояш чыгуга һәм кояш баюга карап чамалаганнар. Кышын, мәсәлән, «Чулпан калыккан, тиздән таң ата» яки «иртә күгәрә башлады, тиздән яктыра» дигәннәр. Җәен исә «таң сызылды», «кояш сөнге буе күтәрелде» яки «төш җитте», «төш ауды», «кояш икендегә төште» дигәннәр, һәм шуңа карап эш башлаганнар яки эшләреннән туктаганнар... Кыскасы, авыл кешесенең тормышы әнә шулай өзлексез әйләнеп торган авыр хезмәт белән бәйләнгән.

Ләкин борынгырак заманда авыл халкының хезмәте генә түгел, кызу эш арасында ял итеп, күңел ачып ала торган вакытлары да ел фасылларына бәйләп йөртелә иде. Әйтик, чәчү алдыннан яз бәйрәме — сабан туе уздырыла. Чәчү белән печән өсте арасында туйлар ясап алалар. Шәһәрдән кунаклар кайта, җыеннар вакыты җитә, җыеннарга йөрү башлана.

Авыл яшьләренең күңел ачулары — язгы тугай уеннары, тау уеннары, кызларның атнакич куна йөрүләре, җиләккә барулары, сахрага чыгулары да шул ук иркенрәк вакытларга туры килә. Бу вакытны «уеннар өсте» дип тә йөртәләр иде.

Көзен һәм кышын кич утырулар, каз өмәләре, егетләрнең тәрәзәгә йөрүләре, кызларның утырмага килүләре — болар инде җәйге-көзге эшләр беткәч башлана. Ләкин төптәнрәк тикшереп карасак, бу күңел ачуларның кайберләре үзләре дә турыдан-туры эш белән бәйләнгән булуын күрәбез. Мәсәлән, өмәләр. (Җәен урак өмәсе, көзен каз өмәсе.) Яшьләр бу өмәләргә бик теләп баралар, чөнки алар шунда очрашалар, күрешәләр, күңел дә ачалар, ләкин төп максат барыбер эш үзе: урак урып көлтә бәйләү һәм каз йолку (монысын кызлар гына эшли).

Инде кышын кич утыруларга яки утырмага йөрүләргә килсәк, монда да кызлар үзләренең кул эшләреннән аерылмыйлар. Шуны истә тотарга кирәк, элекке заманда авылның җиткән кызлары өчен зарури бер эш — ул да булса киндер сугу иде. Бу эш, ягъни киндер сугу, яз башыннан алып, печәнгә төшкәнче дәвам итә [1]. Ләкин моңа кыш буена диярлек әзерләнергә кирәк. Хикмәт шунда, киндер сугу өчен кирәк булган җитен-сүсне көз ахырында, чана юлы төшкәч кенә базарлардан, ярминкәләрдән алып кайталар. Кич утыручы һәм утырмага килгән кызлар менә шул җитеннән, төннәр буе утырып, җеп эрлиләр. Ә язга чыккач, эрләнгән җепне җепшек карга салып агарталар, буяучыга биреп буяталар, ул җепләргә кушар өчен киҗе-мамык алдыралар, бары шуннан соң гына киндер сугу башлана. Шулай итеп, авыл кызының кулы бервакытта да эштән өзелеп тормый.

Күңел ачуларның тагын бер ягын искә алырга кирәк. Борынгы авылларда яшьләргә танышып, күрешеп йөрү өчен мөмкинлекләр бик чикле булган. Ләкин төрле хорафатлар белән чикләндерелгән тормышта да яшьләрне азмы-күпме таныштыру өчен рәтен-юлын тапканнар. Еш кына хәлләрдә күңел ачу уеннары егет өйләндерү, кыз бирү кебек изге максатны күздә тотып, яшьләргә бер-берсен күрер, сынар өчен мөмкинлек бирү йөзеннән дә эшләнгән. Бик борыннан килгән гадәт буларак, ул илнең билгеле бер тәртип-низамына да әйләнгән.

Биредә сүзне дә әнә шундый борынгы низамнардан саналган кызларның кич утырулары, егетләрнең тәрәзәгә йөрүләреннән башлап китәсе килә.

## Кич утырулар

Борчак саламы саргайды — кич утыру вакытлары җитте, дия торган булганнар. Көз җитеп көннәр кыскарып, төннәр озаю белән, кызлар өчен тагын матур, күңелле вакытлар җитә. Кич утырулар, каз өмәләре, утырмага йөрү, егетләрнең исә тәрәзәгә йөрү вакытлары башлана. Бу вакытны алар җәйге, көзге эшләрдән соң көтеп алалар.

Гадәттә, өйләре иркен, гаиләсе азрак яки кунак өе булган кызның йортында күрше кызлар җыелышып утыралар. Моңа картлар, яшь хуҗалар да уңай шартны китереп торалар. Кичке аштан соң гаилә эше беткәч, бала-чага яткач, картлар кичке намаздан кайтып үз урыннарына урнашкач, авыл өстендә кичке тынлык урнаша. Шул чакта егетләр, бер-берсенә барып, капка төпләрендә туплана башлыйлар. Кызлар кич утырачак өйләргә киләләр.

Ә инде хуҗа кыз кичкелеккә өйне аеруча матур итеп җыеп, мөмкин булган кадәр уңайлаштырып куя. (Лампага керосин сала, куыгын чистарта һ. б.) Төнге чәйгә барынча чәй ашлары да хәзерләп куя. Кызлар үзләре дә юынып, матуррак киенеп, төзәтеп киләләр. Егетләр тәрәзәгә килгәндә, аларга тыштан яхшырак күренер өчен, һәркайсы тәрәзә турынарак җаен табып утырышалар. Һәркайсының алып килгән кул эше була — кайсы тегү тегә, кайсы чигү чигә, кайсы ниндер бәйли...

Алар үзара сөйләшеп, көлешеп, матур итеп җырлашып утыралар. Эш арасында тәрәзәгә күз сирпеп алалар. Кеше булса, утны баса төшеп, кемлеген белергә тырышалар. Тик үзләрен ничек тә әдәпле, тыйнак, сөйкемле итеп тоталар — чөнки тәрәзәдәге егетләрнең күзләреннән кызларның бер генә кыланышы да ычкынмый.

Күршедән кергән кызлар утырмага килгән кызлар белән аеруча озак утыралар. Үзләре әйткәнчә, беренче әтәчкә чаклы (димәк, ярты төнгә кадәр дигән сүз). Ләкин никадәр озак утырсалар да, дәртсезлек, сүлпәнлек, йончыганлык күрсәтмиләр. Ата-

[1] Бу вакытны «киндер өсте» дип тә йөртәләр иде.

аналар да кызларның болай озак утыруларына каршы бер сүз дә әйтмиләр, киресенчә, кич утыру алдыннан кызларына бераз гына йоклап алырга вакыт та бирәләр.

Утырмага килгән кызлар турында берничә сүз. Аларны кунак кызлар дип тә йөртәләр. Каз өмәләре үткәч, кышын бөтен кызлар үзләренең якын туганнарына утырмага йөриләр. Туганнары үзләре аларны билгеле бер вакытка утырмага китерәләр. Кызлар үзләре белән берәр айлык кул эше алып киләләр. Аларның күбесе җеп эрли, язгы киндергә хәзерләнә яки чигү чигә. Һәрхәлдә, вакытны күп алырдай, басылып утырып эшли торган эшләрен алар утырмада утырып эшлиләр. Бу урында шуны да әйтергә кирәк, ул чакларда заманның соравы буенча буй җиткән кызларга җыелышып кич утырырга ихтыяр кую һәм утырмага йөргә рөхсәт итүләр кызның үз кирәк-яракларын җитештерүгә мөмкинлек бирү өчен дә эшләнгән. Кыскасы, яшьләргә күңел ачарга ихтыяр кую белән бергә, тормыш кирәге дә күздә тотылган.

Кызлар күмәкләшеп кич утырганда эш арасында күңел ачу һәм «бәхет сынау» уеннары уйныйлар. Җырлар җырлыйлар.

Кызларның кич утырганда җырлый торган берничә генә җырларын да китереп үтик:

Быел да бодай бик уңган,
Кыйблаларга таба егылган.
Җан тартмаган җиргә язма, ходай,
Җан тартмаган җирдән кем уңган.

Җилбер дә җилбер җил кайда,
Җилбердәтеп тә үскән буй кайда.
Җилбердәтеп тә, үскән, әй, буйларның
Кадерләрен белгән ир кайда.

Тәрәзәләр ачтым, уклар аттым,
Былбыл балаларын уяттым.
Бер күрер өчен дә җаннар аттым,
Күреп лә күңелләрем җобаттым.

Казаннардин килгән, әй, җиз курай,
Җефәк калфак кигән кыз уйный.
Үзе дә уйный, үзе җырлый,
Күңелкәе аның кемне уйлый.

## Тәрәзәгә йөрүләр

Егетләрнең тәрәзәгә йөрүләре кызларның кич утырулары белән нык бәйләнгән бер гореф-гадәт санала. Кызлар кич утырмаса, егетләр дә кеше тәрәзәсенә барып карамаслар иде. Кул эше белән кич утыручы кызларның тәрәзәләре төбенә килеп күзләү гаеп эш булмаса да, яшьләргә әдәп, инсаф диган нәрсәне бик нык сакларга туры килгән. Егет кыз күзләү нияте белән йөри икән, шул ук вакытта ул үзен дә сынатмаска һәм үзен әдәпле егет итеп танытырга да тиеш була. Шул илдән ул өйләнәсе кызын табарга тиеш. Бу очракта егет үзенең берәр якын дусты белән генә йөри. Алар аеруча саклык белән үзләрен танытмый гына, бүрекләрен басып киеп, перчатка кигән куллары белән битен ышыклап яки тәрәзә яңагына ышыкланып, күп вакыт бер дә кеше барлыгын белдерми генә күзләргә тырышалар. Ләкин кызлар да бик сизгер булалар. Тик белмәмешкә генә салышалар (мондый вакытта аларга аяк астында кар шыгырдауны сизү дә җитә). Гадәттә кызлар җырлашып утыралар. Әлеге билгеле теләк белән йөрүче егетләр ябык тәрәзә капкачларын ачып карыйлар, киткәндә ябып китәләр. Өйләнмәгән егет кызлар каршында һәм ил өстендә шулай ук сынау күзе астында. Чын егетләр турында халык җыры шулай әйткән:

Карчыгадай дигән, әй, асыл кош
Кош кундырмас агач башына.
Асыл да егет, удал егет
Сүз китермәс газиз башына.

Гомумән, теркем белән йөрүче егетләр дә күп була. Алар да кеше капкасыннан шаулап килеп кермиләр. Араларында гармунчы егет булса, матур итеп гармунга кушылып, кыска көйләр җырлап, урам буйлап узалар. Кызлар утырган өйләргә кергәли баралар. Тик мәчет, зират турыннан гына үлгәннәрнең рухына ихтирам йөзеннән җыр-

ламый узалар. Бу чорларда егетләр һәрвакыт кыз күзләү нияте белән генә дә йөрмиләр. Җыр әйтә:

Егет егетлеген итәр,
Ат эчерер буранда.
Йөрәгенә чыдамыйча,
Җырлап йөрер урамда...

Иртә генә торып көтү кудым —
Каргалыкай буе андызга.
Үзе дә уйный, үзе җырлый,
Моңаядыр егет ялгызга...

Тәрәзәгә йөрүләр егетләр солдатка китәр алдыннан аеруча җанлы була. Алар арасында тәвәккәлрәк егетләр дә булуы мөмкин. Ләкин киртәдән чыгучы егетләрне кызлар бер дә яратмый, үзләрен ваксытмыйлар, андыйлар булса, утны басалар, пәрдәне төшерәләр.

Әнә шулай күзен һәм кышын каз өмәләре, кич утыру, тәрәзәгә йөрү, утырмада утырган чаклар яшьләр өчен бик матур, күңелле, җанлы вакытлар булып калалар. Кызлар өй эчендә, ә егетләр тышта, тәрәзә төбендә булсалар да, һәр ике як үзләрен аралашкан кебек хис итәләр. Кайсы җаны тартканын күреп кала, кемдер күзе төшкәнен күреп китә. Шуннан башка кызлар утырган җиргә егетләр кереп утыру юк.

Кызлар күмәк утырган чакларында бәхет сынау уеннары һәм башка уеннар уйныйлар. Инде шуларга күчик.

## Бәхет сынау уеннары

Бәхет сынау уеннарын күмәк кыз җыелып кич утырганда яки утырма кызлары белән утырганда уйныйлар. Мәсәлән: «Раштва уены». Бу татар авылларында уйнала торган уен ни сәбәптән рус бәйрәме исеме белән йөри башлагандыр, безгә билгеле түгел. Бәлки, яңа ел башында уйналганы өчендер!

Уенны ярты төн җиткәч уйныйлар. Әүвәл кеше аягы тынгач, эткән йорт эшләреннән туктагач, ике кыз үзара бер дә сөйләшмичә генә су буена төшеп чиләк белән су китерәләр. Суны җылы урынга куеп торалар. Ярты төн җиткәч, шул суга кызлар һәркайсы, билгеләп, бер кашык сала. Бер кыз өсте тастымал белән ябылган чиләккә кулын тыгып суны бутап тора. Такмак әйтүче карчык бер такманы әйтеп бетерүгә, теге кыз бер кашыкны тартып чыгара. Әйтелгән такмак шул кашык иясенә була.

Такмаклары:

Чи-чи тавык, чи тавык,
Чебиләрең җый, тавык,
Чебиләрең җый, тавык,
Куначаңа мен, тавык.

Ак сарай өең булыр,
Ак калач ашың булыр,
Ак сарай эчләрендә
Кадерле башың булыр.

Шул рәвешчә, барлык кашыклар такмак әйтелеп чыгарылып беткәч, кашыкларны кире чиләккә салалар. Барысы да җыйнаулашып ишегалдына чыгалар һәм чиләк белән кашыкларны тигез җиргә, чиста кар өстенә болгап-болгап сибеп җибәрәләр. Бик иләп кенә, карны таптамыйча, һәркем үз кашыгын эзли... Ничек ятканын карый. Кашык чалкан төшсә, суы да тулы булса — бәхете тулы була, бай була, имеш. Кашык аз су белән төшсә — бәхете уртача була, капланып төшсә — бәхетсез була, имеш. Кашыкның сабы авылның кайсы очына карап төшсә — шул очка кияүгә чыга, читкә карап төшсә — чит авылга кияүгә китә була.

Такмаклардан шул икәве генә хәтердә калган. Такмакларның мәгънәләрен сүзләре үк әйтеп тора: беренчесе ишле балалы, гаиләле була дигән сүз.

## Сарык тотарга бару

Бу уен да шулай ук кызлар кич утырганда уйнала.

Кич утыручы кызлар, шулай ук бәхет сынау өчен, ишле сарык яткан абзарга керәп һәркайсы бер сарыкны тота. Бу уенның аермасы шул: карт сарык эләксә, карт кешегә бара, яшь сарык, симез сарык эләксә — яшькә, байга бара, имеш. Йоны коелган сарык эләксә, фәкыйрьгә бара, имеш...

## Киндер очы

Җиту кызлар суккан киндерләреннән әйбер кисеп тегә башлаганда артып калган очын, бәхет сынар өчен, уң кул беләгенә бәйләп урамга чыгалар. Беренче нинди кеше очрый — карт, яшь, бай, ярлы... Шуның буенча үзләренең язмышларын юрыйлар.

Бер кыз шулай күршеләр киндер суккан җиргә, кул эше итеп, яңа суккан киндереннән ашъяулык кисеп тегәргә керә. Киндернең артык очын кисеп ала да уң кулына бәйләп йортка чыга. Өй почмагыннан борылуга, каршысына капкадан зур капчык аскан карт хәерче килә. Кыз хәерчедән качар өчен аш өенә таба китә. Хәерче бу кызны хуҗа кызы дип белеп аның артыннан аш өенә бара. Иң кызыгы, ике кызның егылганчы көлүләре хәтердә калган.

## Суга җеп салу

Бер тәлинкә кебек савытка су салып, берничә катлам ике җепне бөтереп-бөтереп шул суга салалар. Салганда фал итеп бер кызның һәм бер егетнең исемнәрен әйтәләр. Фәлән белән фәлән кушылырлармы! Бөтереп салган җепләр кире сүтелеп, йөзеп йөри башлыйлар. Су өстендә йөзеп йөри торгач, яки кушылалар яки ерагаялар. Шуңа карап фал итәләр, юрыйлар. Ахырдан гөж килеп көлешәләр.

## Тынга бару

Тынга бару — тыңларга бару дигән сүз. Гаиләдә бер төрле вакыйга котелсә, халык арасында, «тынга бару» бар иде. Мәсәлән, улларын өйләндерү өчен берәр кызга ниятләп торсалар — бирерләрме, юкмы! Солдатка каралгасы уллары булса — алынырмы, калырмы икәнне сынар өчен, берәр күршенең йорты янына шыпырт кына барып стена аша хуҗаларның сөйләшүләрен тыңлыйлар. Шунда ишеткән сүзләргә карап булырын-булмасын юрарга тырышалар. Ишле балалы кешенең йортына баруны яраталар.

«Тынга бару»ны кич утыручы кызлар да уйный. Ләкин алар кеше йортына бармыйлар, буш амбарларга, келәт кебек каралтыларга баралар. Шунда берәр тавыш, мәсәлән, чут-чут тамчы тамган тавыш ишетелсә, акча саный, имеш, тешәсе йорты бай була, имеш.

## Язгы тугай уеннары

Тугай уеннары яки кичке уеннар, сулар ташып бетүгә, бераз җир сүрелгәч, су буе тугаенда яки берәр зур ихаталы кешенең йортында була иде. Язгы пычраклар суркып катага пычрак ябышмаслык булгач, яңа чыккан үлән өстендә кызлар сакчылы, арка сугыш кебек уеннар уйнап алалар.

Тугай уеннарына бер мәхәлләнең генә кызлары һәм алар тирәсенә егетләр җыйнала. Бу уеннар бигрәк тә кыш буе ябылып торган кызлар өчен яз башын котлап,

беренче карлыгачлар кебек бер-берсе белән көрешеп, гөрләшеп алу гына була. Чөнки алда әле аларның матур җәйдә тауга менү, сабан туе, җыеннар вакыты, сахрага чыгу, җиләккә бару кебек эш арасында күңел ачардай көннәре — уеннар өсте дип атап йөртелә торган чорлары булачак.

Уеннар өсте дип аталса да, алар авылның бетмәс-кимемәс эшләре арасында гына үтеп китә: бу вакыт ирләр өчен чәчү өсте булса, кыз-кыркынның үзләре өчен гаять әһәмиятле эш вакыты — киндер өсте. Кыш буе эрләгән җепләреннән тугым тугыйлар, сөлгеләр, ашъяулыклар, чаршаулыклар сугалар. Тугай уеннарына кызлар гадирәк киенеп чыгалар. Мәсәлән, матурлап тегелгән альяпкыч, яулыктан гына. Алар үзара якын-тирә кызлары гына әле.

Тугай уеннары турында язганда, сүз уңаеннан, элекке яшьләрнең уен мәйданында очрашканда үзләрен ничек тотуларына, үзара әдәп, инсаф саклау кебек матур якларына да тукталасы килә. Кызлар тирәсенә егетләр дә җыела, дидек. Алардан кайсыберсе, шул тирә кызларына якынрак булганы гына кызлар «сакчылы» уйнаганда «сакчы» булып кушыла. Ләкин шулай да уенга катнашкан бер кызны да тотмый, тик күрше кызы, кардәш тиешле кебек булса гына куып җитеп, җилкәсенә бармак очларын гына тидереп ала. Шул инде «тотты» санала. Кызларны үпкәләтүдән, оялтудан егетләр бик сак булалар иде. Әгәр тоткан кызы бу егет белән берр әттән торып уйнаудан баш тартса, егет һаман сакчы булып уйный бирә, тик кызык өчен йөгерүче кызларга кушылырга ихтыяр бирмәскә тырыша, шуның белән кызык-мәзәк өчен шаяртып ала, көлке тудыра. Ләкин ул заманнарда, әйткәнемчә, тәвәккәлрәк егет кенә уенга катнаша, башкалары кызлардан читтәрәк тупланып, уен-көлке сөйләп, кызларны күзәтеп карап кына торалар.

## Тау уеннары

Тугай уеннары беренче язгы-җәйге уеннарның башы булалар. Тугай уеннарына гадәттә бер мәхәллә, күрше-күлән кызлары, егетләре генә җыелалар. Инде тауга менүләр, тау уеннары, сабан туе үтеп җыеннарга чаклы, көннәр әсселәнеп җиткәч башланып, берничә җомга көн дәвам итәләр. Аларның төсе икенче — тугай уеннарына кызлар гади генә киенеп чыксалар, тау уеннарына инде иңбар яхшы киемнәрен киенеп баралар, яхшы диган күлмәкләрен, калфак-шәлләрен, вәлләрен ябынып, чулпы, муен таңкәләре, төймәләр асып, йөзек-беләзекләр киеп, белендерми генә кершән ягып (сандал ягу, белендереп кершән ягу гаеп иде) чыгалар.

Бу уеннар инде асылда кызларның үзләрен күрсәтүгә корылган. Бөтен авыл кызлары, яшь киленнәр, уңганрак хатыннар, карчыклар да чыгалар. Бу соңгылары кызларга күз салгалау нияте белән киләләр. Башта һәр төбәк кызлары үзләре каршындагы тауга менсәләр дә, соңыннан алар таудан тауга күчеп кушылалар, бер зур мәйданга әйләнәләр. Кызлар мәйданы тирәсендә шулай ук егет-җилән тупланып тора һәм кызлар артыннан таудан тауга күчә.

Тауга менү бары тик уеннар өчен генә түгел. Биредә берсен-берсе күрү-танышу күз алдында тотыла. Чөнки шушы тау уеннарында гына авылның күп кызлары бер-берсен күрә, таныша яки туганнарында утырмада утырганда, каз өмәләрендә танышкан, дуслашкан кызлары белән күрешеп, сөйләшеп ала. Әнә шунда инде алар үзләренең күркәм, сөйкемле якларын күрсәтеп калырга тырышалар. Чөнки алар бит күзгә-күз генә күрешмиләр, сөйләшмиләр, ә барлык кызыксынган хатыннар-карчыклар, ят кызлар каршында булалар. Шуңа күрә мөмкин кадәр мөлаем булырга тырышалар — кычкырып сөйләшмиләр, шаркылдап көлмиләр, бәлки ярты авыз белән генә сөйләшәләр, елмаеп кына көләләр, җилкәсе белән борчылмыйча, башы белән генә борылып күз сирпеп алалар.

Башка мәхәлләләрнең кызлары җыелганчы, кайчан тау читенә тезелеп утырып, авыл өстенә карап торалар. Авыл өстенә карап утырганда кайсының күңеле төбендә яшеренеп яткан өмет уты кузгалып, яраткан егетенең йортын күздән кичерә. Шуның белән җанына рәхәтлек тапкандай була. Авыл үзе таулар читеннән борылып-борылып аккан сай гына елганың якан як, сул як ярына утырган. Шуңа карата таулар югарыгы

оч тавы, урталык тавы яки түгәрәк тау исеме белән йөртеләләр иде. Араларында мәдехле таудан берсе «очлы тау» дип йөртелә. Бөтен авыл кызлары урта тауда кушылалар. Шунда танышып, сөйләшеп туйганнан соң бөтен мәйданнары белән очлы тауга баралар. Аннан түбән оч тавына күчәләр. Таудан тауга күчкәндә тизрәк, дәртлерәк барыр өчен «үрдәк чумышлы» уйный-уйный күчәләр.

Әйткәнебезчә, бусы — бөтен авыл яшьләре чыга һәм җомга көннәрдә генә үткәрелә торган тау уеннары. Ләкин моңардан тыш мәхәлләнең үзенең генә «кичке тау яки атна кич тавы» дип аталганы да була торган иде. Монысында инде таудан тауга күчеп йөреп булмый, бары тик һәр төбәк яшьләре каршыдагы тауга менеп, азрак уйнап, авыл өстенә карап утырып, күңел ачып кайтыр өчен генә чыгалар иде.

## Атнакич куна йөрү

Нәкъ шул уеннар вакытында буй кызларның атнакич куна йөрүләре дә була торган иде. Якын туганнары буй кызларны, кыш утырмага алган кебек, уеннар чорында атнакич куна китерәләр. Пәнҗешәмбе көн төштән соң аларны чакыручы хуҗалар барып алалар. Алар кичке уенга да чыгалар, икенче көнне тауга менәләр, мәйданда булалар, көн буе кунак булалар. Хуҗа кунак кызлар янына куна килмәгән күрше-күлән кызларын да чакырып аш үткәрә. Шул ук көнне кичен озатып та куя.

## Сахрага чыгу

Кызларның сахрага чыгуын олырак киленнәр оештыралар. Берәр карчыкны да иптәшкә алып, бер-ике арба булып чыгалар. Чәй ашлары әзерләп, самоварлар алып, үзләренең печәнлек кебек яхшы белгән җирләренә сахрага чыгалар. Җиләк вакыты җиткән булса, җиләк җыю белән дә бәйлиләр. Һәрхәлдә, эшкә төшкәнче яшьләр төрлечә күңел ачып калырга сәбәпләр табып торалар.

Болар барысы да борын-борын заманнан ук килгән, илнең горефкә әйләнгән гадәтләре. Шуңа күрә бу вакытларны «Уеннар өсте» дип атаганнар.



# ГӨЛСЕМ БОЛГАРСКАЯ

*(1891—1968)*

Шушы елның 19 ноябрендә халкыбызның күренекле артисткасы Гөлсем Болгарскаяның тууына 80 ел тулды.

Гөлсем Болгарская — мәдәниятебез үсешә тарихындагы иң колоритлы шәхесләрнең берсе. Әле 1910 елда ук ул Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасында эшли башлый. Аның шуннан соңгы бөтен гомер юлы сәхнә белән бәйле. Ярты гасырдан артыграк дәвам иткән иҗат эшчәнлеге дәверендә ул милли театр сәнгатебезне тудыру һәм үстерү эшенә әйтеп бетергесез зур өлеш кертте.

«Аң» журналының 1917 елгы 1 санында театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрамнең Болгарскаяга багышланган бер мәкаләсе басылган. Анда шундый юллар бар:

«Татар театры үзенең 10 еллык хәятында хатыннардан фәкать ике артистканы тәрбия кыйлып үстерде. Бу артисткаларның беренчесе Сәхипҗамал туташ Гыйззәтуллина булса, икенчесе, шөбһәсез, Өммегөлсем ханым Болгарскаядыр.

Болгарская чын мәгънәсе белән безнең милли сәнгатькяребез, үз артисткабыздыр. Яшь театрыбызның авыр минутлары, шуның илә бәрәбәр иң матур дәверләре Болгарскаяның исеме илә нык баглыдыр.

Киләчәктә татар театрының тарихын язучы булса, ул тарихның иң башына, иң шәрәфле сәхифәсенә, шөбһәсез, Болгарскаяның да исемен куячактыр».

Гөлсем Болгарская Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камаллар иҗат иткән елларда сәхнәгә килә. һәм ул башкарган рольләр арасында иң зур урынны Г. Камал тудырган образлар тәшкил итә. «Бүләк өчен»дәге Хәмидә, «Бәхетсез егет»тән Асрау, Гайшә һәм Гайни, «Уйнаш»тагы Сәрбиҗамал, «Беренче театр»дагы Гафифә, «Банкрот»тагы Гөлҗиһан... Саный китсәң, алар күп әле.

Г. Болгарская тарафыннан иҗат ителгән рольләрнең гомуми саны дүрт йөздән артып китә. Алар арасында төрле ил, төрле чор кешеләре бар. Артистка трагик образлар башкара, дистәләрчә комедияләрдә катнаша. Шулай да аның иҗатындагы төп урынны драматик пландагы сәхнә образлары алып тора: «Кызганыч бала»дагы Шәфика, «Ачлык кушты»дагы Мәһисылу, «Тигезсезләр»дәге Сәлимә, «Яшьләр»дәге Зәйнәп, «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин»дәге Зөбәйдә, «Яшь гомер»дәге Зөләйха, «Мәкер һәм мәхәббәт»тәге Луиза, «Яшенле яңгыр»дагы Катерина, «Төшемле урын»дагы Полина, «Гаепсездән гаепләләр»дәге Кручинина, «Надир шаһ»дагы Гөлҗамал... Бу образлар үзләренең фаҗигале язмышлары, халәти рухияләренең гаять тирән һәм бай булу-

лары белән аерылып торалар. Хатын-кыз азатлыгы — Г. Болгарская иҗатындагы төп темаларның берсе. Артистка үзе иҗат иткән өлеге образлар аша татар хатын-кызларын ирекка өндәде, аларны дини фанатизмнан, иске гореф-гадәтләрдән котылырга чакырды. Бу бигрәк тә Александр Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасындагы Катерина ролен башкарганда ачык күренде.

Катерина-Болгарскаяның азатлыкка чакыру авазы, аның йөрәгендәге давыллы хисләр ташкыны татар тамашачысында зур кызыксыну һәм теләктәшлек хисләре уятты. Татар халкының ялкынлы революционеры Мулланур Вахитовның бу спектакльгә карата махсус мәкалә язып чыгуы өнә шул хакта сөйли.

«Талантлы артистка,— ди ул,— җитди рольләрне уйнарга сәләтле булуын күрсәттә: ул ялган пафостан, бернинди кычкырынулардан башка да, тамашачыларга Островский героинясының азатлык сөюче шигъри табигатен ача алды. Кем белә, әгәр күңеле түрендә аны яшертен генә Островский героинясы белән туганлаштыра торган хисләр ярсып тормаса, Болгарская, бәлки, безгә Екатеринаның иң эчке кичерешләрен җиткерә дә алмас иде» [1].

Бөек Октябрь революциясен Гөлсем Болгарская чын күңелдән шатланып һәм хуплап каршы ала. һәм революциянең беренче көннәреннән үк, җиң сызганып, татар совет театрын тудыру, үстерү эшенә алына. 1919 елда башка сәхнәдәш дуслары белән бергә ул «Күргәзмә гаскәри татар театры»нда, ә инде Татарстан республикасы төзелгәч, «Беренче күргәзмә Дәүләт татар театры»нда эшли башлый. Революциядән соң артистканың иҗаты яңа буяулар, яңа алымнар белән баный. Әгәр революциягә кадәрге чорда аның иҗаты нигездә мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган булса, совет чорында инде ул ачыкган-ачык партиялелек позициясенә баса, үткен характерлы, оста сурәтләнгән уннарча образлар иҗат итә. Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» трилогиясендәге Ханзафа образы — моның ачык дәлиле.

Соңгы елларда Г. Болгарскаяга сәхнәдә төрлесе төрле характердагы бик күп карчыкларны уйнарга туры килде. М. Фәйзинең «Галиябану»ында яучы Бәдига, Т. Гыйззәтнең «Биш бүләк»ендә Мәрфуга, «Изге әманәт»тә Хәзинә, «Чаткылар»да Чикерткә Гыйльменисасы, М. Әмирнең «Тормыш җыры»нда Мәргубә артистка тарафыннан зур осталык белән гәүдәләндерелгән образлар. Гадилек, табигыйлек, тормышчанлык — Г. Болгарскаянең иҗат почеркын тасвирлый торган төп сыйфатлар әнә шулар.

Татар театры сәнгатен үстерү өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен Г. Болгарскаяга 1923 елда ТАССРның халык артисты дигән мактаулы исем бирелде. Ә 1925 елны ул РСФСРның атказанган артисты дигән исемгә лаек булды. Ул берничә мәртәбәләр хөкүмәтебезнең орден һәм медальләре, Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Гөлсем ханым Болгарская 1968 елның 8 январенда безнең арабыздан китте.

**Д. ГЫЙМРАНОВА.**

# ТЕАТРГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Татар театрында Г. Кариев тудырган һәм соңыннан матур традициягә әверелгән принципларның берсе — артистның бөтен барлыгы белән театрга бирелеп эшләве, аны тормышының максаты, яшәвенең мәгънәсе итеп каравы. Татар театры ветераннарының берсе Гөлсем ханым Болгарскаяның тормыш һәм иҗат гомерендә бу традиция бик матур чагыла. Безнең заман кешеләренең үзләре сайлап алган профессияләренә гомерлеккә бирелүләре, аңа бөтен сәләтен, рухи көчен бирүләре — бик табигый хәл. Ләкин революциягә кадәрге чорда, иске дөньяның кара көчләре тарафыннан тыелган, каһәрләнгән эшкә барырга җөрьәт иткән, аңа үзләренең язмышларын

[1] Габдулла Кариев турында истәлекләр. Казан. 1967 ел, 15 бит.

багышлаган татар егетләре, кызларының мондый кыюлыклары гадәти хәл генә түгел иде.

Мондый батырлык Гөлсем Болгарская шикелле кешеләрдә нинди сәбәпләр нәтиҗәсендә туа алган соң? Бу турыда уйланмыйча мөмкин түгел. Аның сәбәпләре берникә генә түгелдер, әлбәттә. Алар турында театр тарихчылары язар. Болгарская кебек сәхнә олканнәренең эш тәҗрибәләрен якыннан торып күргәнгә, аларның эшкә, иҗатка карашларын еш кына ишеткәнгә күрә, бу турыда берничә сүз әйтеп китәсе килә.

Татар театры туганда ук күңел ачу, кәмит күрсәтү урыны булып түгел, ә гыйбрәт урыны, кешеләрне күп еллар буе борчыган сорауларга җавап бирү урыны булып туды. Театрны башлап җибәрүче төп көчләр есләренә зур җаваплылык алдылар. Олы һәм авыр юлга чыкканда, киләчәк хезмәтләренең зурлыгын аңлап хәрәкәт башладылар. Бу беренче карлыгачларга, революция юлына баскан алдынгы татар зыялылары белән бергә, демократик идеялар белән янып иҗат иткән әдипләр ярдәмгә килде. Алар татар театрын үзләренең иң якын, иң кыйммәтле өметләре итеп кабул иттеләр.

Татар театры туганда ук олы максатлы булып, рухи оеткысы көчле булып туды. Ләкин бу юлга аяк баскан һәрбер артист гомерен аңа багышлый алмады. Бу авыр йөкне тартып бара алмыйча, юлдан егылганнар, читкә тайпылганнар да булмады түгел. Шуңа күрә дә җиленә-яңгырына, давылы-яшенена карамыйча йөкне тартканнарның, шулар арасында күренекле урыннарның берсен алган Гөлсем Болгарскаяның да, хезмәтләре бәя биреп бетергесез. Бу кешеләр өчен театр бик кыйммәтле. Алар аны, утны-суны кичеп алып чыгып, социалистик чорыбызга китереп тапшырдылар. Шуңа алар театрдагы хезмәтләренә изге хезмәт итеп карарга өйрәнделәр.

Шушы традицияне бөтен иҗат гомере буена алып килүче Гөлсем Болгарская өчен театрда зур эш, кечкенә эш, зур роль, кечкенә роль булмады, фәкать театр өчен кирәк булган хезмәт кенә булды. Күп еллар Гөлсем ханым белән бергә эшләү дәверендә бер генә тапкыр да аның театрга килеп: «Нигә миңа теге рольне бирмәдегез?», я булмаса: «Нигә миңа бу рольне бирдегез?» дип ризасызлык белдергәнен күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Нинди генә роль тапшырылмасын, нинди генә



*«Безнең шәһәрнең серләре» спектакленнан бер күренеш. Сулда Г. Болгарская.*

образ тудыру соралмасын, тискәреме, уңаймы ул, аның иҗатына якынмы, еракмы артистка бер генә вакытта да тапшырылган эштән баш тартмады. Үзе өчен нинди рольнең отышлырак булуы турында, тамашачыга кайсы образ белән якынрак килеп җитәргә мөмкин булуы турында уйламады. Театр өчен нәрсә кирәгрәк булса, Болгарская өчен дә шул кулай булды.

Болгарскаяга сәхнәдәге озак гомерендә бик күп режиссерлар куйган спектакльләрдә катнашырга туры килде. Ул, тәҗрибәле мастерлар белән бергә, яшь режиссерларны да еш очратты. Ул, яшьләренә, талант аерымлыкларына карамастан, аларны игътибар белән тыңлый, режиссерларның хезмәтләренә хөрмәт белән карый иде. Миңа Гөлсем ханым белән уннан артык спектакль куярга туры килде. Шуларның барысында да ул ару-талуны белми торган сәхнә кешесе икәнен күрсәтте. Ул вакытта ук инде аның, өлкән яшьтә булса да, яшьләргә хас энергия белән репетиция ясавына сокланмый мөмкин түгел иде. Яшерен-батырын түгел, артистларның кайберләре, спектакльдәге ролен берничә йөз кат уйный торгач, аерым спектакльләрдә яки күренешләрдә сүлпәнлек күрсәтә башлый. Әмма Гөлсем ханымның эшендә мондый хәлне очрату мөмкин түгел иде. Ул сәхнәгә һәр чыгуында бу рольне беренче кат уйнаган төсле бөтен энергиясен салып башкарды.

Хезмәт ярату — өлкән буын артистлар алып килгән күркәм сыйфатларның берсе. Гөлсем ханым нәрсә генә эшләмәсен, шул эшкә бирелеп, бөтен көчен салып, сабыйларча мавыгып эшләде. Рольләр башкарганда гына түгел, артист вазифасына кагылмый торган эшләрне үтәгән вакытта да шундый ук иде. 1942 елның җәендә Татар академия театры районнарга гастрольгә чыгып китте. Без зур состав белән, берничә машинага төялеп, үзебезнең иң яхшы спектакльләребезне алып чыктык. Бу спектакльләрдә артист кулына бирелә, сәхнәгә куела торган реквизит, бутафория әйберләре дә байтак иде. Кызганычка каршы, районнарның берсендә ул эшне алып баручы кеше, каты авырып, коллективтан аерылып калырга мәҗбүр булды. Хуҗасыз калган бу авыр эшне кемгә тапшырырга да белми аптырап торганда, Гөлсем ханым үзе теләп шушы эшкә алынды. Ә бит һәр спектакльдә аның рольләре бар, җитмәсә, спектакльнең буеннан-буена бара торган зур рольләр. Шуңа карамастан, ул үзенә җәмәгать эше итеп алган бу вазифасын гаҗәеп бер төгәллек белән башкарып чыкты. Мондый эшләр Гөлсем ханым тормышында беренчесе яки соңгысы түгел иде.

Артист хезмәте — авыр хезмәт. Чын артист акылы белән генә түгел, йөрәге белән дә иҗат итә. Йөрәге аркылы үткәргән рольләр анда эз калдырмавы мөмкин түгел. Әгәр дә бу эзләрне күрсәтә торган аппарат уйлап чыгарылса, без кайбер артист йөрәгенең телгәләнеп беткәнен күрер идек. Мондый кеше тормышта та тиз яраланучан була. Артист өчен үзе белән сәхнәдәш булган кешеләргә игътибарлы, кешелекле булуның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Болгарскаяның иптәшләре белән булган мөгамәләсендә шушы бик кыйммәтле сыйфатны күреп була иде. Аның кемгә дә булса тавыш күтәргәне, нинди дә булса күңелсезлеккә сәбәпче булганын хәтергә төшерүе читен. Алай гына да түгел, аның ачык йөзе, эчкерсезлеге күп кенә яшь артистларга теге яки бу сорау белән аңа мөрәҗәгать итәргә ярдәм итте. Гөлсем ханым элекке Казан татарларының көнкүрешен, гореф-гадәтләрен яхшы белгәнгә, яшьләргә кыйммәтле киңәшләр бирә, аларны милли киемнәрне ничек итеп җиренә җиткереп киярга икәнлеген аңлата, күрсәтеп бирә иде. Ул заман кешеләренең үзләрен ничек тотулары турында кызыклы мәгълүматлар сөйли иде.

Белеме, тәҗрибәсе белән рәхәтләнеп уртаклашкан кеше үзенә карата да һәрвакыт хөрмәт уята. Гөлсем ханым Болгарскаяны якыннан белгән кешеләр аны зур хөрмәт белән искә алалар дип уйлыйм.

**ШИРИЯЗДАН САРЫМСАКОВ,**
РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

## СЪЕЗД КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

Шушы көннәрдә Татарстан дәүләт музее оештырган күчмә күргәзмә әнә шулай дип исемләнгән. Диаграммалар һәм фоторәсемнәрдән торган 22 стендта республикабызның промышленносте, авыл хуҗалыгы, әдәбият һәм культура үсеше яктыртыла.

Күчмә күргәзмә беренче булып Минзәләгә юл алды. Шуннан ул Татарстанның башка районнарына китәчәк.

## НЕФТЬЧЕЛӘР ТУРЫНДА ЯҢА РОМАН

Татарстан язучыларының Әлмәт бүлегендә Шамил Бикчуринның нефтьчеләр тормышына багышланган яңа романы тикшерелде. Әсәр буенча фикер алышуларда язучылардан Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, Ю. Әминов, С. Кальметов, Г. Афзал, Р. Фәйзуллин һәм КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре С. Закирова катнашты. Алар романның нигездә уңышлы булуын билгеләп үттеләр, авторга аны тагын да камилләштерү буенча киңәшләр бирделәр.

## ӘДИП МАЛИКОВКА 50 ЯШЬ

Август аенда шагыйрь һәм прозаик Әдип Маликовка илле яшь тулды. Шул уңай белән, республика газета-журналларында аның иҗатына багышланган мәкаләләр басылды, клубларда һәм мәктәпләрдә әдәби кичәләр уздырылды.

Бәйрәм кичәләренең берсе Әлмәт районының Салкын Алан авылында да булып үтте. Кичәне, юбилярның тормыш һәм юлы турында кереш сүз сөйләп, Р. Төхфәтуллин ачты. Язучыны каләмдәш дуслары Г. Афзал, Ю. Әминов, К. Булатовалар һәм колхозчылар исеменнән Н. Сибгатуллин, М. Курамшиннар котлады. Аңа шулай ук тәбрик хатлары һәм телеграммалар, истәлекле бүләкләр тапшырылды. Соңыннан концерт булды.

## ТӘБРИКЛИБЕЗ

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен һәм илле яшь тулу уңае белән, СССР Верховный Советы Президиумы композитор Рөстәм **Яхинны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены** белән бүләкләде.

* * *

Совет әдәбияты өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән язучы Александр Николаевич **Булгаков** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Совет әдәбияты өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән язучы Константин **Лебедев** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

## М. ФӘЙЗИГӘ БАГЫШЛАП

Орскидагы крайны өйрәнү музеенда татар драматургиясе классигы Мирхәйдәр Фәйзи иҗатына багышлап күргәзмә ачылды.

Ул Оренбург өлкәсенең Күкшел авылында туган татар язучысының 80 еллык юбилеена багышлана.

* * *

Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Яхин колхозлардан башкалабыз Казанга киңәшмәгә килгән партоешма секретарьлары белән очрашты. Музыка белгече Л. Исәнбәт очрашуда катнашучыларны композиторның күп кырлы иҗат эшчәнлеге белән таныштырды. Артистлардан Ж. Сәләхова, Х. Гыйниятова, М. Имашевлар ул иҗат иткән җырларны һәм романсларны башкардылар. Очрашу «Культура эшлекләре — авылга» дигән девиз астында узды.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Роберт Батуллин, Радиф Гатауллин, Разил Вәлиев, җырчы-композитор Мәсгут Имашев республикабызның Мөслим районында булып кайттылар. Алар көндезләрен кыр станнарында, басуларда, болыннарда, ә кичләрен клубларда колхозчылар белән очраштылар, аларга әдәбият һәм сәнгать яңалыклары турында сөйләделәр, үз әсәрләрен башкардылар.

* * *

Ленинград язучысы Евгений Кутузовның әти-бабалары гомер буена заводта хезмәт иткәннәр. Евгений үзе дә Ижор заводында тимерче булып эшләгән. Шуңа күрә Евгений Васильевич үзенең әсәрләрендә төп герой итеп бүгенге эшче образын чагылдыра.

Евгений Кутузов әледән-әле илебез буйлап сәяхәт ясый, төзелешләрдә, завод-фабрикаларда була. Күптән түгел ул куәтле йөк автомашиналары чыгарачак Кама автозаводы төзелешендә булып китте.

Ленинград өлкәсенең «Ленинские искры» газетасы язучы Е. Кутузовның Чаллыдагы төзелеш турында мәкаләсен урнаштырган.

## ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Шушы елның май аенда әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин Германия Демократик Республикасында йөреп кайтты. Ул патриот шагыйрь Муса Җәлил исеме белән бәйле урыннарда булган, илнең хезмәт ияләре, әдәбият һәм сәнгать әһелләре белән очрашкан.

## ҖӘЙГЕ ГАСТРОЛЬЛӘР

Җәй — гастрольләр чоры. Татарстанның сәнгать коллективлары, башка еллардагы кебек үк, киң илебезнең күп өлкәләрендә, шәһәр һәм авылларында булып кайттылар.

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры җәйне Ульяновск һәм Волгоград шәһәрләрендә уздырды. Күрше өлкәләрнең тамашачыларына рус һәм дөнья классикларының әсәрләре белән бергә, Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсын, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» һәм Әнвәр Бакировның «Су анасы» балетларын күрсәтте.

Ике ай буе дәвам иткән гастрольләр вакытында безнең артистлар завод-фабрикаларда, колхозларда булдылар, әлеге өлкәләрнең хезмәт ияләре, әдәбият-сәнгать әһелләре белән очраштылар.

* * *

Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры быел тагын Уфада булды. Тугандаш Башкортстан тамашачылары безнең артистларны бу юлы да җылы һәм яратып каршыладылар. Бөтен спектакльләр диярлек аншлаг белән барды. «Совет Башкортстаны», «Советская Башкирия» һәм «Кызыл таң» газеталарында татар театрына багышланган зур-зур мәкаләләр чыкты. Башкортстан АССР Верховный Советы Президиумы театрны Почет грамотасы белән бүләкләде.

* * *

Үз чиратында башкалабыз Казанда күп кенә танылган театр коллективлары, җырбию ансамбльләре һәм концерт бригадалары булып китте. Аларның кайберләре белән укучыларыбызны таныштырган да идек.

Август аенда безгә тагын бер талантлы иҗат коллективы—Калининград драма театры килде. Кунаклар Казан тамашачыларына Ю. Чепуринның «Карлар», А. Корнейчукның «Иләк хатирәсе», В. Ежовның «Сандугачлы төн», А. Арбузовның «Иске Арбат әкиятләре», Д. Кьюсакның «Берлиндагы эссе җәй», А. Макаенокның «Трибунал», француз язучысы Эдман Ростанның «Сирано де Бержерак» исемле әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр күрсәттеләр.

* * *

Август аенда башкалабыз Казанда, республиканың Чаллы, Әлмәт һә[illegible]ка районнарында Калмык АССРны[illegible] пан» исемле җыр һәм бию анса[illegible]булып китте.

Ансамбльнең программасында, калмык халык җырлары, калмык шагыйрьләре һәм композиторларының әсәрләре белән бергә, СССР халыкларының җырлары да лаеклы урын алган иде. Калмык артистларының концертлары һәркайда уныш белән узды. РСФСРның һәм Калмык АССРның атказанган артисткасы В. Гаряева, Калмык АССРның атказанган артисткалары А. Мукаева, В. Ильцаранова, Калмык АССРның атказанган артистлары Э. Манджиев, П. Надбитов һәм А. Улиновларның чыгышын тамашачылар аеруча җылы каршыладылар.

## ЭКСПЕДИЦИЯ УҢЫШЛЫ БУЛДЫ

Казан археологларының тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдинов җитәкчелегендәге отряды шушы елның июль аенда Ульяновск өлкәсендә һәм Татарстанның көньяк районнарында тикшеренүләр үткәрде. Борынгы Болгар шәһәрләренең калдыкларын өйрәнеп, картага төшерүне максат итеп куйган бу экспедиция нәтиҗәсендә моңарчы билгеле булмаган 4 шәһәрлек (шәһәр урыны) һәм бер хәрби ныгытма табылды, шулай ук 20—30 елларда беркадәр тикшерелеп тә, кайсы чорга һәм культурага караганлыгы төгәл билгеләнмәгән 4 шәһәрлек өйрәнелде. Болары да болгарларныкы булып, X—XII йөзгә караганлыклары ачыкланды. Шундыйларның иң кызыклысы — Ульяновскидан ерак түгел, Зөя суы буендагы хәзерге Иске Әләйке авылы янында урнашкан шәһәрлек. Ул үзенең мәйданы белән мәшһүр Болгар һәм Суарларга тиң. Археологлар, шәһәрләрдән башка, алар тирәсендә урнашкан борынгы авыл урыннарын да тикшереп, кызыклы материал тупладылар. Гомумән, быелгы экспедиция Болгар шәһәрләрен табу һәм картага төшерү эшен төгәлләү экспедициясе булды. Андый истәлекләрнең саны хәзер 155 кә җитте.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

Фәтхи-Балыкчы исеме татар совет журналистикасы тарихында күренекле урын алып тора. 1926 елдан КПСС члены булган талантлы журналист иҗади хезмәт юлының күп өлешен «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә үтте. Республикабызда авыл хуҗалыгын үстерү елларында, беренче бишьеллыкларда аның публицистик мәкаләләре, очерклары, репортажлары, фельетоннары газета битләрен бизәп торды. Редакциягә килгән күп кенә яшьләр аңардан журналистлык осталыгына өйрәнделәр.

Шушы көннәрдә Татарстан Журналистлар союзы правлениесе һәм «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе коллективы республикабызның иң өлкән журналистларыннан берсе Фәтхи-Балыкчы (Хәлил Фәтхуллин) белән очрашу үткәрделәр.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

1972 елның май аенда «Казан утлары» журналының чыга башлавына 50 ел тула. Шул уңай белән Сез яңа ел саннарында журналның элекке редакторлары.

**Гази Кашшафның «Ил белән бергә атлаганда»** дигән истәлеген,

**Газиз Иделленең «Совет әдәбияты»ның авторлар белән эшләү тәҗрибәсе»** дигән мәкаләсен,

язучы **Гомәр Бәшировның «Социалистик реализм әдәбияты өчен көрәшкәндә»** дигән мәкаләсен,

журналның элекке сотрудниgы Әнәс Камалның «Журналның фронтовик язучылар белән элемтәсе» дигән истәлеген,

журналның элекке саннарыннан публикацияләр, хронологик материаллар һ. б. укый аласыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210